КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Зиннур МАНСУРОВ. Яңабаштан язмас тәкъдир каләме. *Шигырьләр*. ....................3
Фәрит ИМАМОВ. Вакытсыз вакыт... *Фантастик роман*. ....................9
Ренат ХАРИС. Унөчкә унөч. *Поэма-бәян*. ....................53
Кәрим КАРА. Җиләкле алан. *Повесть*. ....................58
Фәйрүзә МӨСЛИМОВА. Җәйнең җылы, кояш тулы аяз көне... *Шигырьләр*. ....................85
Рәмис ЛАТЫЙПОВ. Көрәксез нефтьчеләр. *Повесть*. ....................89
Хәбир ИБРАҺИМ. Чайкала җәйге рәшә... *Шигырьләр*. ....................122
Әхәт МУШИНСКИЙ. Иренка-иркәм. *Хикәя*. *(М.ВӘЛИЕВ тәрҗемәсе)* ....................125

ЯҢА ИСЕМНӘР

Гөләндәм ГАЛИЕВА. Мин яратам сине, әй, тормыш... *Шигырьләр*. ....................145

*Җәһәт тәнкыйть*: сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ....................148

*«Идел» журналына – 30 ел*: *фотоархив*. ....................150

«ШИФАЛЫ КУЛЛАР» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Гөлшат ДӘҮЛӘТБАЕВА. Энҗе. *Хикәя*. ....................152

«ТАТАРСТАН. ТАРИХ. ШӘХЕСЛӘР» ӘДӘБИ ОЧЕРКЛАР КОНКУРСЫ

Гөлинә ГЫЙМАДОВА. Рәсемле язмыш. *Очерк*. ....................159

ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рифә РАХМАН. Мөхәммәт Садри: «Минем серләр ачык алар, син тыңласаң». ....................163

КИТАП КҮЗӘТҮ

Гамирҗан ДӘҮЛӘТШИН. Прототөрки бабаларыбызга юл яручы китап. ....................166

ЮБИЛЕЙЛАР

Разил ВӘЛИЕВ. Минем Надир Дәүләтем... *(Надир Дәүләткә 75 яшь)*. ....................175

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНА 100 ЕЛ

Тарихың зур, юлың ерак, галиҗәнап татар китабы... *(Татарстан китап нәшриятының генераль директоры Илдар СӘГЪДӘТШИН белән Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА әңгәмәсе)*. ....................179

*Фән*: Көмеш касә серләре. *(Исмехан ГОСМАНЛЫ белән Дания ЗАҺИДУЛЛИНА сөйләште)*. ....................184

*Кайтаваз*: Айдар ХӘЛИМ. Иҗатыңа ак юл синең, бала! ....................185

*Музейларыбыз*: Луиза ЯНСУАР. Казан үзәгендә – «Татар китабы йорты». ....................186

*Шаян сәхифә:* Зиннур МАНСУРОВ. Уены-чыны бергә. ....................187

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....................190

КАЗАН УТЛАРЫ
*(«Огни Казани»)*
*№ 7 (1161) 2019*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Ринат Закиров**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**

*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**

*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**

*Мөхәррирләр:* **Лилия Вагыйзова, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева.**

*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (өлкән бухгалтер).

*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1617).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 26.06.2019, график буенча 26.06.2019, басылып чыгу вакыты 12.07.2019.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-1725. Тираж 4391.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2019 ел



Зиннур
Мансуров

# ЯҢАБАШТАН ЯЗМАС ТӘКЪДИР КАЛӘМЕ

## Хөкем

Ярыдагы терек яралгыдай,
туар мөддәт көткән илләр бар.
Татарстан,
　　　　сине нинди төстә
күрде икән безнең элгәрләр?

Ничә буын Ил-йорт нигезенә
өсти килгән алтын ниргәсен.
Татарстан,
　　　　газиз милләт хакын
даулар өчен иңдең җиргә син.

Фәрештәләр «Амин» пышылдаган,
баба туфрагына иелеп.
Татарстан,
　　　　үсә алырсыңмы
ыруг күзаллаган ил булып?

Әманәткә тугры өммәтебез
акылының салган бар көчен.
Татарстан,
　　　　куандырсаң иде
дәүләт тоткан кавем варисын.

Ил-ат рухы туры торсын, диеп,
күпме дәвамчылар иң куйган.
Татарстан,
　　　　күкләр сынап бага –
син яшәргә хөкем ителгән,
син я-шәр-гә хөкем ителгән!

---

Зиннур МАНСУРОВ (1949) – *Татарстанның халык шагыйре, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты; «Кул бирәм», «Җәрәхәтле йөрәк җылырак», «Күңелдә фидаи яшәсә», «Дөреслек икегә төрләнмәс» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Бердәнбер

Бәни адәм сайлый алмас ана затын,
сайлап алмый тәнгә иңәр җанын да.
Безнең башка сыймый торган серле хисап
башкарылыр гарше әгъля янында.

Туган илне сайлап алу мөмкин түгел –
шушы хакта элгәрләрең яд кыла.
Ватан хакы җиде баба каны белән
һәрбер терек күзәнәккә языла.

Милләт телен сайлау ирке була алмый,
сине варис санар өммәт бердәнбер.
Саташмагыз, карышмагыз, кизәнмәгез:
ана, ватан, телне Аллаһ биргәндер.

## Исәнлек билгесе

Артык төче сүзләр әйтеп,
мактанчыктай кыланмыйм, –
иртә таңнан күзем ачкач,
кат-кат шөкер кылам мин.

Колагыма фәрештәләр
пышылдаша: «Тере син!»
Аек башым салмак кына
инде уйлый төрлесен.

Бәреп керә милләт гаме –
шул иң олы исәбем.
Мәжрух бәгырь сызлый башлый,
димәк, чынлап исән мин.

## Иң газиз гамь

Төрле уйлар өтә башлый кайчак,
үзалдыңа оеп бас кына;
әллә нинди әрсез ыргым белән
бәреп керә алар башыңа.

Дөнья йөге баса – яхшы тоя
мондый хәл-халәттә булганнар...
Үзләренең мөһим икәнлеген
шулай сиздерәме бу гамьнәр?!

Эндәшәсе килә моң-зарларга,
«Беләм инде, – диеп, – сез барын.
Тыкшынмагыз күкләр тыңлаганда
ялварулы хитап сүзләрен!»

Болар миннән дәррәү сорый кебек:
«Ә иң өстә кайсы уй тора?»
Якты башым җиргә орган мәлдә
анысы... йөрәгемдә утыра.

## Әлифбалар аерымлыгы

Агу катыш бер сүз адәм затын
авыр хәлгә куя еш кына, –
авызлыгы сына явызлыкның,
башны мәнсез уйлар сара башлый,
дилбегәләр кулдан ычкына.

Саксыз әйткән сүзнең җиле бардыр
безгә килгән бик күп хәвефтә.
Әлмисактан кардәш халыкларга
кинәт дошман булып уйнар өчен
җитә бары дүрт-биш хәреф тә.

## Искергән сәгать ишарәте

Дөнья гаме тагын таудай баса башлый,
төрле уйлар башка килә иртәсен.
Кырыс вакыт янә катгый сорау бирә:
«Киләчәккә нинди кыйммәт илтәсең?..»

Үзе кадәр хаҗәт йөкне тартып барган
елдам бөҗәк очрап куя юлларда.
Үткәннәрнең тәҗел эшен үтәгәндәй,
берсен-берсе ашыктыра еллар да.

Кирәк чакта авырлыкны иңгә алып,
күтәрергә теләмәүләр сагайта.
Күпкә түзгән чылбырына нидер аскач,
җәһәтләнер артка калган сәгать тә.

## Акыллылык дәрәҗәсе

*Һәр акыллыга йөз ахмак тиеш...*
Абдулла Арипов,
Үзбәкстанның халык шагыйре

Шикләндерде шигъри шәрехләвең,
күңелемнән уйлар түгелде.
Зиһенлеләр синең исәпләүдән
бик мул килеп чыга түгелме?

Сыекланып киткән акылына
адәм үзе һаман су куша.
Әлмисактан бирле иләсләнеп
кавем белән кавем сугыша.

Бәндә холкын төрләп бүләр өчен
мөһим түгел катгый үзлек тә.
Сәвәләйгә тартым иләмәннәр
кермимени теге йөзлеккә?!

Вәгазьләсә БМО мөнбәреннән
Хозыр-Ильяс кебек чал кеше,
Җирнең газиз халкын шулай күпләп
кырмас иде ачлык чалгысы.

Кансыз залим канны ешрак түгә,
акыл теше булмый тиранда...
Кырыс хаклык өстә генә ята,
үзе ниһаясез тирән дә.

Кирәгендә йөзләр арасыннан
сыңар аксакал да табылмый.
Үксез телләр үлеп яткан чакта
кардәшемә әйтим тагын ни?

Шагыйрь зурдан  кубып гөман кыла,
мондый санның, сизәм, көче юк.
Инде шиккә төштем: берәр вакыт
аңын ачар микән кешелек?!

## Сәерсенү

Хакны язып, илгә күпме тәгълим кылды,
тәкать тотты, эчтән зекер әйтеп тә.
Нинди уйлар ташып кайный каләм белән
үз-үзенә кул салучы әдиптә?

Яшәү кайчак сәер инде – шушы хакта
зиһен йөртәм, бер сорауга ун кайтып.
Аһәңсазны ничек шулай озаталар,
ул чыгарган матәм көен уйнатып?!

...Җавап эзләп, кабат-кабат күккә багам,
төнге яшен тирә-юньне балкытты.
Чынбар өнме, серле төшме: үзе җыйган
хәләл балга батып үлгән... бал корты!..

## Кальга

Туган авыл. Зират. Чишмә тавы.
Чүгә төшкән иске йорт тора...
Хәтер кузы инде ничә еллар
ачы-татлы яшем йоттыра.

Күпме илләр гиздем: дөнья белми
шушы мәгарәгә тиң барын.
Аллы-гөлле кәнфит кәгазьләре
бизи аның түрге диварын.

Түшәменә кояш төшмәгәндер,
ә идәне салкын таш иде.
Мәһи әбкәй, терек нурга сусап,
тубал белән якты ташыды.

Кәккүк аваз сала сәгать саен,
шөрчек көн-төн җырлый бирерә, –
болар ничек җир-су телен аңлап,
гомер итте икән бер өйдә?!

Гөлбәчендә дога кылынганда,
салам түбәсенә бал яуган.
Изге карчык безне, баштан сөеп,
җиргә, денгә, телгә бәйләгән...

Тәпи эзем калган Чишмә тавы
төшкә керә әле хәзер дә.
Әбкәй йорты бер көч җимерә алмас
кальга булып яши хәтердә.

## Калкан

*Яшьлек дәфтәреннән*

Алдан сиздем: миндәй затка
иңмәс җиңел ярату.
Кыйммәт тора насыйп кылган
яр хакына җан ату.

Бериш көнче күбәләкләр,
гайбәт чәйнәп, ду килә;
кайнар башлы, күкрәк кагып,
дәшә төсле дуэльгә.

Мәҗнүн өне ничә тапкыр
«Саклан!» диеп кисәтә...
Кискен хәлдә сүнеп барыр
күзәнәккә көч кайта.

Нахак уклар яуган чакта,
йөрәк ярсып, кан кайный!
Миңа көбә кирәк түгел –
саклый сөю калканы.

## Тәкәбберлек

Бәгъзе адәм уңга-сулга авып китә,
кыен чакта түгелгәли кан-яше;
аңын ачып, ният кыла: гомер юлын
чиста биттән дәвам итә, янәсе.

Эзгә кергәч, үҗәт бәндә эчтән сызар,
инде барсын башлый, имеш, яңадан.
Мондый хәлдә, читлектәге җанвар кебек,
тынычлана алмый тора җан һаман.

Үкенүле антлар эчеп юанганда,
Алла колы, аек булып кал әле, –
Вакыт «бис»ка яшәр өчен форсат бирмәс,
яңабаштан язмас тәкъдир каләме.

## Бидгатьлек галәмәте

Иллә кызык заман килде
узындыргыч җен өчен, –
Хактан курка белмәс бәндә
алыштыра... җенесен.

Аны кем дә таный алмас:
әллә хатын, әллә ир?!
Менә шулай «Әннә» сүзе
кирәксезгә әйләнер.

Бәгъзе затлар Хөкемчегә
асылын бозып бармакчы.
Сыза, кешем, ничә гасыр
канга сеңгән бар яхшы.

Шәһвәт колы җанын сатмак –
кичерерме Күк аны?
...Азман тавык чукып ашый
үзе салган күкәйне...

## Мәңгелек искәртүе

Кайчак вакыт төссез ага башлый,
серле чоңгылларын ләм баса...
Изрәр йөрәк кинәт дертләп куя –
шомырт чәчәк аткан лабаса!

Еллар көен тоя алмый адәм,
тымык мәгарәдә тын ятып.
Гамьне ямьгә төрә яңа чынлык –
шомырт чәчәк аткан төнләтеп!

Моңсуланып калдым мәңгелекнең
чираттагы сихри таңында;
сискәндерде аның искәртүе –
шомырт чәчәк аткан тагын да!..

## Тырнак

*«...Тырнакларны, кәгазьгә төреп,*
*стена җарыгына куйдым».*
Габдулла Тукай

Мөнкир сыман, җайсыз сорау бирәм,
(әрсезлекне Аллаһ кичерсен):
«Өчиледә, шагыйрь, тырнагыңны
нинди уйлар белән кистең син?»

Әһле ислам, шәргый йола үтәп,
чистарыну өчен көн сайлар.
Синдәй затка күпме пычрак аткан
тырнагыңа тормас кемсәләр.

Савыктыргыч төртмә сүзләреңне
өммәтеңә ничә кат әйттең!
Ачу килгәч, аңлыйм, зәһәр чәчкән
төркемнәргә тырнак кабарттың.

Андый груһ һаман шүрли булыр
шигъреңдәге утлы күмердән.
Синең йөрәк тә бит, астан тешләп,
тырнак батыруны күп күргән.

...Бисмиллалы хәлдә пакьләнгәнсең,
күңелемне керсез әйлә, дип.
Каршыласын шушы тырнакларың
ахирәттә гөлгә әйләнеп.

## Карт шамакай елый

Ансат түгел гомер буе кызык эзләү,
тормыш мәзәк ясап тормый ялан да.
Сабыр гына уйнап-көлеп гасыр кичкән
карт шамакай үксеп елый яланда.

Акча тапты шаулы чорда шуклык кылып,
эчтән сыктар бәндәләрне елмайтты.
Һәрбер җайсыз кәмит өчен түләү кирәк –
шушы көнгә ул бит ничә ел кайтты!

Ашкын дәрткә бирелүче адәм углы
белә алмас шаяруның чамасын.
Илау салып яшен түгә «көлке шаһы»,
учы белән сыпырып куя чал чәчен.

Бүген аны аңламассың: әллә көлә
шырык-шырык, әллә елый сулкылдап.
Сәвәләйгә ачы сабак мөгаллиме
менә шундый гыйбрәт язган сул куллап.

Мондый затның җитди чагын күреп булмый
ачылганда безгә бары җор яктан.
Каһкаһәле көлүләрнең кайтавазы
күкрәү кебек ишетелә ерактан.

Нигә вөҗдан җанны даим талый икән,
барча халык мәхәббәтен яулап та?!
Сабыр гына уйнап-көлеп гасыр кичкән
карт шамакай үксеп елый аулакта...

## Виолончель

Уйга талган килеш сине тыңлыйм,
бәгыремне сәер моң изә.
Гамьле башым кинәт чыңлап куйды –
шаккатыргыч нинди могҗиза!

Чү, теп-тере кеше тавышына
охшап китә кайчак авазың:
ишетелә тансык әйтелешләр,
таныйм инсаннарның аһ-зарын.

Шушы хәлдә бүтән дөнья заты
гүя көйли-көйли эндәшә.
Әллә безгә күкләр тәгълим кыла
җанга аңлаешлы өн аша.

Тәшвишләнәм йөрәк тибешенә
ялганучы сихри дулкыннан.
Меңнәр бергә оран сала кебек
күкрәгендә сызлар дүрт кылдан.

Ошбу сергә куәт өсти тәсле
адәм тавышыннан көнләвең.
Ничек болай килеп чыккан, диеп
сорау бирим инде кемгә мин?

Хәттин ашып гөман итмим әле,
тормыйм фикер җебен савып та.
...Уйнак малай, әнә, изрәп йоклый
синең моңнар тулы савытта...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Фәрит
Имамов

# ВАКЫТСЫЗ ВАКЫТ...

ФАНТАСТИК РОМАН

«Ерак привал»га килеп җитәргә чама белән ярты чакрымлап калган иде. Зөфәр шунда гына нык арыганлыгын тойды. Гомумән, ул узарга тиешле маршрутның иң ерак арасы бу. Дистә чакрым җәяүләү тигез, шома юлдан барганда да ардыра. Ә урман эченнән, агач-куаклар арасыннан атлау тагын да кыен. Шуңа күрә ул урманчы өенә тизрәк барып җитәргә дә тамакка капкалап, ятып ял итәргә хыялланып атлый иде.

Мондагы тирәлекне Зөфәр яхшы күзалласа да, вакыт-вакыт компаска күз салгалый. Эте Аккүзнең бер ялгыштырмыйча аны гадәтләнгән юнәлештә алып барасына шикләнмәсә дә, ара-тирә тикшерү комачауламас. Борыны үтә дә сизгер акыллы хайван. Аңа компас та, карта да кирәк түгел. Аллаһы Тәгалә кешегә андый сизгерлек бирмәгән шул.

Урманчы өе урнашкан кечерәк аланга чыгарга ун-унбишләп адым калгач, Аккүз кинәт колакларын шомрайтты. Нигәдер урынында туктап калды да алга төбәлеп ырылдап куйды. Арыганлык белән Зөфәр аның бу халәтенә артык игътибар бирмәде. Куып җитте дә узып барышлый йонының сыйпап, тыныч кына: «Ерак калмады, әйдә, Аккүз, алга», – дип әмер бирде. Хуҗасының тыныч тавышы эткә дә тәэсир итте, әлбәттә. Ул тагын алга юыртты. Тик ике-өч метр ара уздымы икән, янә туктап ырылдый башлады. Зөфәр шунда гына бераз исенә килде. Акыллы хайван юкка ырламас. Ниндидер гадәти булмаган нәрсәне сизгәндер мәхлук. Бу урын юкка гына «Аю алган җир» дип аталмый. Моннан утыз еллар элек егерь Габделхәйне нәкъ менә шушы урында аю ботарлап ташлаган. Әллә соң урманчы йортына аюлар хуҗа булып алганмы? Ишеген җимереп кергән булсалар, алар өйдәге бөтен нәрсәне туздырып бетерәчәк. Кеше исен яратмый алар. Табигатькә һәрьяклап зыян салучы кешенең иң явыз дошман булуын тереклек ияләре сизмимени?!

«Тынычлан!» – дип әмер бирде дә тагын бер-ике адым алга атлап, куак ботакларын аралап, аланга күз салды... Һәм күзалдындагы күренештән, берәр мизгел ни уйларга белмичә аптырап калды. Урманчы өе аланның капма-каршы

Фәрит ИМАМОВ (1960) – *язучы, журналист; «Югалган эзләр», «Дөньяның кеме юк...», «Күләгә» исемле китаплар авторы. Түбән Камада яши.*

ягында – йөз-йөз илле метр арырак урнашкан. Зөфәр хәтта ул якка карамады да. Аланда бер төркем кешеләр күреп гаҗәпләнде ул. Дистә еллар буена Зөфәр белән аның аркадашы Камилдән башка сыңар кеше дә аяк басмаган шушы карурман уртасына каян шулкадәр халык җыелган икән?! Менә тамаша! Аулак күлгә бака хуҗа, дигәннәре шушы буладыр инде!

Ул бу кешеләрне баштарак геологлар яисә натуралистлар түгелме икән, дигән иде. Тик уйларыннан кире кайтты. Гадәттә, нинди дә булса туристик чараны уздыру край башкарма комитеты белән килешенеп башкарыла. Тайга кадәр тайгага бернинди озатучыларсыз кешеләр төркемен кертеп җибәрмәсләр. Ә бу кишәрлекләр Зөфәр эшли торган урман хуҗалыгына карый, шулай булгач, бу хакта иң беренче ул хәбәрдар булырга тиеш иде. Дөрес, бу тирәләр күрше урманчылык белән чиктәш, «чакырылмаган кунаклар»ның шул тарафтан килеп чыккан булулары да ихтимал. Тик андагы урманчылар яисә егерьлар, күрәләтә торып, натуралистларны чит биләмәгә алып килерләр идеме?

Бу уйларыннан ул бик тиз кире кайтты. Барыннан да бигрәк, аландагы кешеләрнең киемнәре сәер тоелды Зөфәргә. Мондый киемле кешеләрне кайдадыр күргәне дә бар иде хәтта. Уйлый торгач, исенә төшерде. Егерменче гасырның иң канлы вакыйгасы – тарихка Бөек Ватан сугышы дип кереп калган сугыш турындагы киноларда шушындый киемле кешеләрне күргәне бар иде. Немец солдатлары! Фашистлар! Димәк, болар – кино төшерүче артистлар булып чыга инде, дип фикер йөртте Зөфәр. Бирегә сугыш турында берәр нәфис фильм төшерергә килделәрме икән? Тик ни өчен урманчылык җитәкчелеге белән киңәшләшмәгәннәр? Мондый чаралар вакытында янгын куркынычсызлыгы да бар бит әле аның. Сугыш турында кинолар төшергәндә, пиротехникасын, тегесен-монысын кулланмыйча калмыйлардыр. Кем белгән, бәлки, югарыдагылар бу хакта хәбәрдардыр. Су башыннан болгана, балык башыннан чери, дигән кебек, вакланып, Зөфәрләр урманчылыгына белдереп торуны кирәк санамаганнардыр. Үз кулларында лабаса, нәрсә уйлыйлар, шуны кылыналар. Ә берәр гадәттән тыш хәл килеп чыкса, бөтен гаепне гади урманчыга өеп калдырырга бик оста алар.

Берникадәр шулай торгач, Зөфәр кинәт уйларыннан айнып киткәндәй булды. Тукта, нишләп, тегеләй түгелме, болай түгелме дип, баш ватып тора соң әле ул? Иң элек эшнең асылына төшенергә кирәк.

Шуларны уйлагач, аның әле берәр минут элек кенә булган киеренке халәте су белән юып алгандай юкка чыкты. Ул тынычланып, Аккүзнең башыннан сыйпады. «Юкка борчыласың, куркырлык бернәрсә дә юк, Аккүз. Аю да, бүре дә түгел – кешеләр. Артистлар... Киноартистлар булырга тиеш. Әйдә, алга атла!» – дип сөйләнде. Эт аның нәрсә сөйләгәнен аңламаса да, хуҗасының үз-үзен тотышыннан, халәтеннән һәм сүзләрнең әйтелешеннән, хәлнең алай ук начар түгел, хафаланырга урын юклыгын аңлады булса кирәк, уйнаклап алга ыргылды. Зөфәр дә итәк-чабуларын тарткалап, үзен «кеше кыяфәтенә» китергәндәй итеп, аның артыннан атлады.

Аккүз аланга атылып чыкты да, «һау-һау»лап өреп, каршы якта түгәрәкләнеп утырган кешеләр янына чапты. Ләкин шунда көтелмәгән хәл булды. Үзләренә таба килүче этнең өргән тавышын ишетеп, борылып караган «артистлар» арасында кинәт паника башланды. Алар утырган урыннарыннан сикереп тордылар, кычкырыша һәм тәртипсез йөгерешә башладылар, ашыгычлык белән кайсы абынып егылды, кайсы автоматына тотынды:

– Hund! Hund![1] – дигән авазлар яңгырады.

[1] Эт *(нем.)*

Шул ук мизгелдә автоматлардан ата башладылар. Аккүзгә төбәп аталар. Эт барган шәпкә кызганыч чинап, кинәт югарыга сикерде дә буш капчык шикелле лыпылдап, җиргә килеп төште һәм хәрәкәтсез калды. Атыш ничек кинәт башланган булса, шулай ук кинәт тынды. Әлеге хәлдән өнсез калган Зөфәр баруыннан туктады. Аннан соң үзе дә сизмәстән:

– Сез нәрсә, вәхшиләр?! Этемне харап иттегез бит. Чын корал белән?.. Шулай ярыймыни?! – дип кычкырып сөйләнә-сөйләнә, Аккүз гәүдәсе яткан тарафка ташланды.

Зөфәрне әле яңарак күреп алган «артист»лар автоматларын аның ягына бордылар. Арадан берсе:

– Partisan! Russische partisanen![2] – дип сөрән салды.

Икенчесе төбәп-нитеп тормыйча, автоматын тырылдатты. Бер пуля Зөфәрнең колак яныннан ук сызгырып үтте. Бер-икесе янәшәдәге куакка туры килде, аның берничә ботагы сынып төште.

Күрче, автоматлары чын патроннар белән корылган түгелме? Болар белән шаярырга ярамый. Артистларга чын патрон бирергә кемнең башына килде икән?! Аккүзне харап иттеләр бит болар, дигән уйлар йөгереп узды аның башыннан.

Ул эте янына килеп тезләнде дә ау мылтыгын янәшәгә куйды. Аккүзнең гәүдәсе автомат ядрәләре белән тишкәләнеп беткән, яраларыннан кан саркый. Бу хәлне күреп, Зөфәрнең күзләреннән кайнар яшьләр тамды. «Вәхшиләр, кансызлар!» – дип пышылдады ул, тешләрен кысып. Аның күңелендә кемнәр икәне билгесез әнә шул бәндәләргә карата чиксез нәфрәт хисе туып өлгергән иде инде.

Тынлыкны бозып, янә автомат тырылдап алды. Зөфәрнең янәшәсендә генә диярлек җиргә берничә пуля килеп кадалды. Ул урыннарда дымлы җирдән пармы, төтенме күтәрелде. Аның борынына әчкелтем дары исе килеп бәрелде.

– Рус, сдавайся! Hände oben! Руки верх!

Сүзләрнең ят телдәгеләрен ул аңламады, әлбәттә. Ә менә көчле акцент белән ватып-сындырып әйтелгән русча әмергә буйсынмыйча булдыра алмады. Чыннан да, болар белән шаяру урынсыз. Хәзер инде кирегә дә юл юк. Урман – чытырман, качсам – тоттырмам, дияр иде, йөгереп тота алмасалар да, аркага пуля җибәрүләре бик ихтимал. Ул качарга маташу урынсыз икәнен аңлап, ике кулын да югары күтәреп, урыннан торды.

– Schritt zur Seite! Шагай в сторону! – дип әмер бирде тагын шул ук тәрҗемәче, русчаны ватып-җимереп.

Зөфәр бер адым читкә атлады. Тегеләр төркеменнән ике бәндә аерылып, бу якка килә башлады. Берсе автоматын Зөфәргә төбәп торды, икенчесе иелеп, җирдә яткан мылтыкны алды.

– Gutes Gewehr![3] – диде ул, коралны әйләндереп карый-карый. Аннан соң мылтык түтәсе белән Зөфәрнең касыгына нык кына төртеп алды. – Treten! Schnell![4]

Аны эткәли-төрткәли урманчы өенә таба алып киттеләр. Шул йөз-йөз илле метр араны узганда да, тагын берничә мәртәбә аркасын приклад белән төеп: «Bewege sich das volle Schwein!»[5] – дип сөйләнде саклап озатучы. Зөфәр ул сүзләрнең мәгънәсен белмәсә дә, мактау сүзләре булмавын яхшы аңлады.

Аландагы атышу тавышын ишетеп булса кирәк, өй ишегеннән, коралларын

[2] Партизан! Рус партизаны! *(нем.)*
[3] Яхшы винтовка! *(нем.)*
[4] Әйдә, атла! Тизрәк! *(нем.)*
[5] Атла, ялкау дуңгыз! *(нем.)*

әзер тотып, тагын ике-өч кеше чыгып басты. Киемнәренә һәм погоннарына караганда, болары офицерлар булса кирәк. Иң югары дәрәҗәдәгесенең кулында пистолет.

Конвой Зөфәрне шулар каршына китереп бастырды да, солдатларның берсе хәрбиләрчә кимәленә туры китереп, доклад ясады. Зөфәрнең иңеннән салдырып алган кыр сумкасын – планшетны офицерга сузды.

Ул арада тирә-яктан солдатлар җыйналып, ярым түгәрәк ясап, әйләндереп алдылар. Кызыксынулары һәрберсенең йөзенә чыккан. «О-о, партизанен, партизанен», – дигән тавышлар ишетелде.

Өлкән офицер үтә дә кызыксыну белән, бик җентекләп Зөфәрне баштанаяк күзәтеп чыкты. Бигрәк тә урманчы киеменең петлицаларындагы билгеләрен һәм хәрбиләрнекенә охшаган фуражкасындагы кокардасын җентекләп карады. Шулардан дәрәҗәсен чамаларга тырышты, күрәсең.

– Гут, гут, – дип сөйләнде ул, канәгать калып.

Бу сүзләрнең немецчадан күчерелгәндә «яхшы» дигән мәгънәне аңлатканын Зөфәр шунда ук чамалады. Кайсыдыр кинода ишеткәне бар иде.

Аннан соң офицер җыелган солдатларга карап: «Divergieren!»[6] – дип кычкырды да, «Фельдфебель Шульц» дип эндәшеп, бер солдатны чакырып алды. Аңа бик төксе кыяфәттә ниндидер күрсәтмәләр бирде, ачуланып та алды булса кирәк. Төрле тарафка бармак белән төртеп күрсәтүеннән, бөтен якка да ныклы сак куярга әмер бирүен чамалау өчен немец телен белү кирәк түгел. Шульц аны үрә катып, бик буйсынучан кыяфәттә тыңлап торды. Аннан соң үкчәсен үкчәгә бәреп: «Яволь, гер гауптштурмфюрер!» – дип кычкырды да, кырт борылып, кемнәргәдер исемнәре белән эндәшеп, әмерне җиренә җиткереп үтәргә солдатлар ягына чапты. Дисциплина ягы нык күренә монда, дип үзенчә нәтиҗә ясады Зөфәр, нинди хәлгә тарыганын әлегечә төшенеп җитә алмыйча.

Офицер кырт борылып, урманчы өенең ишеген ачты да эчкә үтте. Зөфәрне озата килгән конвоир, аңа да өйгә керергә кушып, үз телендә нидер әйтте, сүзе үтемлерәк булсын өчен, мылтык түтәсе белән янә бер тапкыр нык кына итеп төртте. Алар эчкә үттеләр.

* * *

Монда әлеге «чакырылмаган кунаклар» беренче көннәрен генә түгел, ахрысы, ныклап хуҗа булып өлгергәннәре күренеп тора. Урындык хезмәтен үтәүче агач түмәрләре берничәгә арткан. Өстәл өстенә карта җәеп салганнар. Бер почмакта ниндидер биш-алты әрҗә. Киштәгә консерв банкалары тезеп куелган. Сәкегә солдат плащ-палаткасы җәелгән.

«Гауптштурмфюрер» дигән офицердан башка өй эченә тагын ике кеше керде. Аларның берсе тәрҗемәче икәнен шунда ук төшенде Зөфәр. Аңа офицер вакыт-вакыт «Хартман» дип эндәшә, исеме шулай, күрәсең. Ә икенчесе офицерның урынбасары кебек кеше иде булса кирәк. Ул сораулар бирмәде, тыңлап кына утырды. Дөрес, вакыт-вакыт офицерның колагына иелеп, нәрсәдер әйткәләде. Ә «гауптштурмфюрер» дигәне бик төпченеп сорау алды. Аның беренче соравын тылмач:

– Син кем? Каян килеп чыктың монда? – дип тәрҗемә итте.

Зөфәр алдашып торуны кирәк санамады. Хәер, нәрсәгә ялганлап торырга? Алай-болай кыңгыр эшләре юк, караклык белән шөгыльләнми, җинаять кылмаган, кеше үтермәгән. Шуңа күрә сорауга чатнатып җавап бирде:

[6] Таралышыгыз! *(нем.)*

– Зөфәр – мин. Зиннуров Зөфәр! Урманчы. Моннан кырык чакрымлап ераклыктагы Кучкән Сала авылыннан килдем...

Тылмач ул әйткәннәрне алманчага тәрҗемә итеп биргәч, офицер тагын аның ягына борылды. Зөфәрнең сүзләренә ышанмаганлыгы карашыннан ук сизелеп тора. Алга таба биргән сораулары урманчыны бөтенләй гаҗәпкә калдырды.

– Урманда партизаннар күпме?..

Менә сиңа тамаша! Партизан, ди! Егерме беренче гасырда яшиләр түгелме соң? Узган гасырда булган сугыштан соң йөз елга якын вакыт узган. Дөрес, бу урыннарда Бөек Ватан сугышы чорында партизаннар хәрәкәте булган. Монысын Зөфәр тәгаен белә.

– Бернинди партизан отрядлары да юк монда. Мин унбиш ел урманчы булып эшлим. Партизаннар турында ишеткәнем юк. Сез нәрсәдер буташтырасыз... Әллә мин саташам инде?..

– Фронт сызыгы кайсы тирәдәрәк? Алгы сызык бередән еракмы?..

– Берни аңламыйм... Нинди алгы сызык?

Аның җавапларыннан офицерның чырае сытылды, йөзе ачудан бурлаттай кызарды. Ул үз-үзен белештермәстән, утын түмәрендә утырган көе генә аягын күтәреп, Зөфәрнең корсагына типте. Дагалы үкчә шактый саллы төште. Ул тигезлеген югалтып, сөрлегеп куйды, кулларын як-якка җәеп, тотынып калыр урын эзләде. Өй уртасында торган «буржуйка» миченә орынып, идәнгә егылды. «Буржуйка» да шалтор-шолтыр идәнгә тәгәрәде. Офицер үз телендә: «Scheisse! Ivan... Russisch Schwein![7]» – дип ярсып кычкырырга тотынды. Аннан соң башын кочаклап утырды да: «Mein Gott! Feinde wohin verschwunden?»[8] – дип җикеренүен дәвам итте.

Зөфәр мүкәләп урыныннан торды. Өс-башларын тузаннан каккандай итте. Хәер, ул чарасызлыктан гына шулай эшләде. Монда инде хәл тузан кагудан узган иде.

Бераздан офицер башын күтәрде. Мәгънәсез карашын тагын аңа текәде. Аннан чираттагы сорауны бирде. Тәрҗемәче:

– Фронт сызыгы кайсы тирәдәрәк? Алгы сызык бередән еракмы? – дип сорауны янә кабатлады.

Зөфәр иңнәрен сикерткәләде. Алдан биргән җаваптан артык берни дә әйтә алмый иде ул. Шуңа күрә тагын тибеп җибәрмәсен дигәндәй, саклык йөзеннән читкәрәк тайпылды, офицерның һәр көтелмәгән хәрәкәтенә әзерләнгәндәй, тәне куырылып куйды.

Тик бу юлы гауптштурмфюрер үзен тыныч тотты. Хәтта кыяфәтендә ниндидер мәрхәмәтлелек чалымнары да күренеп киткәндәй булды.

– Komm her![9] – диде ул, Зөфәрне өстәл янына чакырып.

Өстәл өстендә яткан картага бармагы белән төртеп күрсәтеп, сорау бирде:

– Картаны аңлыйсыңмы? Без хәзер кайсы тирәдәрәк? – дигән сорауны кабатлады тәрҗемәче.

Зөфәр өстәлгә иелде. Карталар буенча бик оста белгеч булмаса да, ул үзенә кирәклесен яхшы аңлый. Аның һөнәрендә картаны белмәү гафу ителмәслек нәрсә. Чөнки зур мәйдандагы биләмәләр белән эш итүчегә ул бик мөһим. Шуңа күрә кыр сумкасында үз карамагындагы урман территориясенең дүрткә бөкләнгән картасын йөртә. Тик менә өстәлгә җәелгән карта ниндидер таныш булмаган билгеләр белән чуарланып беткән, һәм анда язылган сүзләр

[7] Рус дуңгызы! *(нем.)*
[8] Йә, Аллам! Дошманнар кая юкка чыкты соң? *(нем.)*
[9] Монда кил! *(нем.)*

дә чит телдә. Никадәр генә тырышып карамасын, картаның рәтенә төшенә алмады ул.

– Юк, мин монда берни дә аңламыйм. Минем телдә язылмаган. Сезнең кешеләр алган сумкамда үземнең картам бар. Аннан аңлатып бирергә була...

Өйгә кергәч, гауптштурмфюрер конвоирлар биргән сумканы ишек кырыендагы чөйгә элгән иде. Тылмач Зөфәрнең сүзләрен тәрҗемә иткәч, офицер сумканы алып, аннан дүрткә бөкләнгән картаны тартып чыгарды һәм өстәлгә җәеп салды. Зөфәр җанланып китте. Ул үз картасын яттан белә, төнлә уятып сорасалар да, андагы һәр тамганы чатнатып әйтеп бирә ала. Шуңа күрә картага бармагы белән төртеп күрсәтеп сөйли дә башлады:

– Монда масштаблар үзгәрәк. Шулай булса да, кайда нәрсә икәнен аңлатып бирәм. Менә бу – минем авыл Күчкән Сала. Аннан кырык биш чакрым ерактарак, төньякта – Южный посёлогы. Менә бу – безнең урман хуҗалыгы биләмәсе... Без хәзер менә монда. Бу «Ерак привал» дип атала... Минем карамактагы урман территориясенең иң ерак почмагы...

Гауптштурмфюрер картага иелде. Үзалдына мыгырданып нәрсәнедер чамалагандай итте. Үзләренең картасына янәшә куеп, озаклап чагыштырып маташты. Тик берни дә аңламады булса кирәк. Ярдәмгә урынбасарын чакырды. «Син берәр нәрсә аңлыйсыңмы?» – дигән кебегрәк ишарә ясагач, хәтта тылмач та өстәлгә иелеп, карталарны игътибар белән карый башлады. Тик алар да бармакларын карта өстендә бераз йөрткәләгәч, иңнәрен сикерткәләп, бернәрсә дә аңламаганнарын белгерттеләр.

Офицер башын күтәреп, янә Зөфәргә мөрәҗәгать итте:

– Авылыгыз аша рус солдатлары уздымы? Ә бәлки алар анда засадада яталардыр? – диде ул, йөзенә бик җитди төс биреп.

Аның бу соравыннан Зөфәр ни көләргә, ни еларга белмәде. Каршындагы урта яшьләрдәге әлеге ир-ат, үзе җитди кыяфәттә булса да, тузга язмаган сораулар биреп утыра. Кем ул, максаты нәрсәдә – белмәссең. Кеше карбыз түгел, чиртеп тикшереп булмый.

Бу хәлләрнең төш түгел, ә өн икәнлегенә аның иманы камил. Баштарак ул төш күрәм, ахры, дип, тәнен чеметкәләп тә караган иде, тик моның өн икәнлегенә ышанды. Әллә соң «ычкындым»мы дигән сорау да килде башына. Килде генә түгел, хәтта берникадәр вакыт ул аңа тынгылык бирмәде. Булырга мөмкин! Чөнки акылы җиңеләйгәннәрнең дөньяга карашлары үзгәрә. Алар дөньяны башкаларга караганда үзенчәлеклерәк кабул итә башлый. Иң гаҗәбе: үзләренең әлеге сәерлекләрен табигый дип уйлыйлар. Ул хәтта, үзе дә шундый халәттә түгелме икән дип шикләнеп, берничә катлаулы математик гамәлне күңеленнән эшләп карады. Тик саннарны күңеленнән тапкырлаганда буталып бетте. Шулай да, үзен «ычкынганнар» рәтенә кертүне кабул итмәде, аек акылда дигән соңгы нәтиҗәгә килде.

Логик фикерләвен тагын да тирәнәйтеп, аның каршындагы бәндәләр җиңеләйгән, димәк, дип уйлады ул. Күп кешенең шулай берьюлы акыллары зәгыйфьләнү чынлыкка бик үк туры килми килүен... Артистланалар, дияр идең, кыяфәтләре җитди. Иң оста артистлар да рольләрен шулай тормышчан итеп уйный алмаслар иде. Болар бигрәк! Өстәвенә Аккүзне дә әнә ничек атып ектылар. Кансызлар! Артистлар, күрәләтә торып, андый юлга барыр идеме?! Юк, әлбәттә...

Сорау алучы офицер каш астыннан сөзеп, озаклап аңа карап торды. Ниһаять, сабырлыгы төкәнде булса кирәк, кулын селтәп, үз телендә нидер акырып-бакырып, тышкы ишекне ачты, кемгәдер исеме белән дәште. Күз ачып йомган

арада, ишектән имәндәй таза бер солдат килеп керде. Һәм командирының әмерен тыңларга җыенып үрә катты.

Гауптштурмфюрер әзмәвер солдатка озаклап нидер аңлатты, күрсәтмәләр бирде. Сүз арасында Зөфәр ягына бармагы белән ишарәләп тә алгалады. Аннан соң, кесәсеннән көмеш портсигар чыгарып, папирос алды да, аны бармаклары белән бөтергәләп, йә, ничек, аңладыңмы дигәндәй, солдатка текәлде. Ә тегесе үтә дә тыңлаучан кыяфәт чыгарып, үкчәсен үкчәгә бәреп: «Яволь, гер гауптштурмфюрер!» – дип чатнатып җавап бирде.

Офицер үзе белән ярдәмчесен дә чакырып, ишегалдына чыгып китте. Өй эчендә тәрҗемәче белән әзмәвер генә калды. Солдат Зөфәр ягына борылды. Шул ук мизгелдә аның кыяфәтендәге үшән буйсынучанлык юып алгандай юкка чыкты. Уң як кашы кинәт күтәрелде, ә сулы, киресенчә, аскарак шуды. Йөзе чалшаеп, куркыныч төскә керде. Менә ул җиңнәрен сызгана-сызгана Зөфәргә якынлаша башлады. Һәрберсе бала башы кадәр бу йодрыклар белән тукмый башласа, эшләр яман булачагын аңлаган егерь бер адым арткарак чигенде. Сакланырга теләп, кулларын алга куйды.

– Барысын да яшермичә сөйләп бирсәң, ул сиңа тимәячәк, – диде тәрҗемәче.

– Мин ялганламыйм бит... Әйткәннәремнең барысы да дөрес, – дип кызу-кызу сөйли башлаган Зөфәргә, сүзләрен әйтеп бетерергә ирек бирмәде солдат. Тәрҗемәченең ишарәсен аңлап, шунда ук корбанына ташланды. Аның каты йодрыклары авырттырып, әле күкрәгенә, әле башын дөмбәсләргә кереште. Сугып еккач, аяклары белән типкәләде. Зөфәр аңын югалтты.

* * *

Күзләрен ачканда, ул ниндидер караңгы урында ята иде. Башта берни дә аңламады. Үлде дип, терелэй күмделәрме икән әллә, дигән уй да йөгереп узды башыннан. Бераз яткач, булып узган хәлләр әкренләп күзалдына килеп басты. Куллары белән кармалана торгач, үзенең утын әрдәнәләре өчен ясалган бүлмәдә икәнлеген аңлады. Ул бүлмә, янкорма буларак ясалып, өйдән ишек белән генә аерыла. Тагын бераз капшангач, монда үзе генә булмавын, тагын кемнеңдер барлыгын аңлады. Чыннан да, кул сузымы ара читтәрәк тагын кемдер ята иде. Йоклыймы, яки аңын гына югалтканмы? Зөфәрнең куллары тиюгә, ул ыңгыраша башлады. Һәм гәүдә кузгалып куйды.

– Кем бар монда?

Зөфәрнең соравына шунда ук җавап булмады. Бераздан соң гына:

– Ә син үзең кем? – дигән сорау ишетелде.

– Зөфәр мин.

– Ә-ә-ә. Син әле бүген көндез тотып китерелгән партизан буласыңдыр?.. Сине дә монда яптылармыни?

Зөфәр үзен кайда, ничек япканнарын хәтерләми. Әле менә исенә генә килүе. Кыйнап аңын югалткач, шушында кертеп ташлаганнар, күрәсең. Шулай да, тавыш иясенең «партизан» дигәненә бераз үртәлде. Нигә соң әле барысы да, сүз куешкандай, партизан да партизан, диләр?

– Ник торасың, молодец! – дип сүзен дәвам итте күренмәс әңгәмәдәш. – Сорауларына җавап ала алмаганнарына җен ачулары килә аларның. Сине дә кыйнадылармы?

Нишләп салпы якка салам кыстырып утыра соң әле бу бәндә? Астыртын астан кисә, өстән ямый, диләр, уйлары яхшылыктамы, әллә?..

– Әйе, җәлләп тә тормыйлар. Теге әзмәвере йөземә китереп типте хәтта, – дигән җаваптан узмады Зөфәр.

– Беләм. Миңа да аның йодрыкларын шактый татырга туры килде. Сул кулбашым болай да яраланган иде, ул тибеп бөтенләй имгәтте, кабахәт!.. Ә син кайсы отрядтан соң?

Зөфәр бу сорауга ни дип җавап бирергә дә белмәде. Тагын үзенекен сөйли башласа, теге сорау алучылар кебек үк ышанмавы бар. Кем белгән, бу бәлки сер алу өчен шулар ук махсус керткән берәр бәндәдер? Хәленә кергән булып, әкрен генә эч серләреңне алыр да... Хәер, Зөфәрнең башкалардан яшерер сере юк анысы. Ләкин бер белмәгән кеше белән саграк булырга кирәк. Шунда ук ачылып китсәң, зарлана башласаң, ахыры ничек бетәсен кем белә. Каралты салудан элек түбәсен әзерлә, дигәннәр борынгылар. Бу бәндәнең үзе турында да бераз белергә кирәк. Шуңа күрә ул соңгы сорауны җавапсыз калдырды.

– Иванов отрядыннандыр әле? Алар безгә иң якыннардан иде, ун-унбиш чакрымда гына урнашкан, – дип дәвам итте көтеп тә җавап ала алмаган әңгәмәдәш. – Аңлыйм, сөйләргә теләмәвең миннән шикләнүдән булса кирәк. Курыкма, мин үз кеше. Партизаннар отряды комиссары капитан Захаров Андрей. Ишеткәнең бардыр, бәлки? Мин партизанлыкта күптән инде. Әле 1941 елның ахырларында ук, немецлар Совет гаскәрләрен чигенергә мәҗбүр иткәндә, безнең полк чолганышта калды. Караңгы төндә ул кыршаудан бәреп чыктык без. Тик санаулы гына калган идек. Ул вакытта фронт сызыгы бик еракта иде инде. Урманга качып, шунда партизан отряды оештырдык. Чолганышта калып, тар-мар ителгән башка подразделение калдыкларын да үзебезгә берләштердек. Тирә-як авыллардан качып киткән кешеләр дә отрядыбызга кушылды. Менә шулай итеп, зур гына отряд тупланды...

Захаров әлеге сүзләренә җавап көткәндәй, бераз эндәшмичә торды. Каршы яктан ни хуплап, ни кире кагып сүз әйтүче булмагач, сөйләвен дәвам итте:

– Безнең партизан отряды фашистларга күп бәла-каза китерергә өлгерде. Кинәт кенә һөҗүм ясап, бу тирәдәге хәрби отрядларына тынгылык бирмәдек, машиналарын, күперләрне шартлату, дисеңме, берсе дә калмады. Корал төяп, көнчыгышка баручы бер-ике эшелонны да юк иттек хәтта. Шуңа күрә бу яктагы калын урманнарны партизаннардан чистарту өчен фашистлар баштанаяк коралланган бер каратель ротасы җибәрде...

Боларны сөйләү Андрейга җиңел түгел иде, күрәсең. Ул сөйләвеннән туктап калды. Озаклап уйланды. Шул чакларда еш-еш сулаганы аермачык ишетелде. Яралары әрнидер инде. Хәле дә чамалырактыр.

– Бер сатлыкҗан безнең отряд тупланган урынның кайдалыгын фашистларга җиткергән булып чыкты, – дип дәвам итте сүзен Андрей. – Бу хакта соңгарак калып белдек. Үзебез генә булсак, тиз арада урыннан китеп өлгергән булыр идек. Тик отрядта тирә-як авыллардан җыелган карт-корылар, хатын-кызлар, бала-чагалар шактый иде шул. Беренче чиратта аларны качырырга кирәк. Чигенүчеләрне каплау өчен, минем командалык астында засада калдырып, төп көч, күршедәге отряд белән кушылу өчен, көнчыгышка юнәлде... Безнең кечерәк отряд бер тәүлеккә якын баштанаяк коралланган карательләргә батырларча каршылык күрсәтте. Күпләр башларын салды ул бәрелешләрдә. Исән калган ике-өч кеше, патроннар атылып беткәч, чигенергә булдык. Ул арада безне чолгап алырга да өлгергәннәр. Әсирлеккә төштек. Икебез авыр яралы булгач, фашистлар аларны шунда ук атты. Минем ярам артык авыр түгел иде, мәгълүмат алырга кирәк булыр, дип калдырдылар. Карательләр башка отрядларны эзәрлекләп,

тайга эченәрәк юл алды. Шулвакыт кисәк кенә томан төште. Урман эчендә андый куе томанны минем үз гомеремдә дә күргәнем юк иде. Үзе сөт шикелле ап-ак. Бер метр арадан берни күрерлек түгел. Томан тиз таралды. Ләкин без шуннан соң адаштык. Кая килеп чыкканыбызны мин аңламадым. Немецлар да юнәлешне югалтты. Кая барабыз, ник барабыз – белмәссең. Көннәрдән бер көнне менә шушы аланга килеп чыктык. Өе дә бар... Немец офицеры миннән берничә мәртәбә сорау алды. Партизаннар отряды кайда, имеш. Мин картадан ялганлап күрсәттем. Шул тарафка разведка җибәреп тикшерткәннәр дә, анда беркем дә булмагач, мине кыйнап ташладылар...

Андрей тынып калды. Ул шушылардан артыгын сөйләргә җыенмый иде шикелле. Хәер, сөйләгәннәреннән бар да аңлашыла. Хәзер Зөфәр чираты. Андрей аннан җавап көтә.

– Мин Камалов җитәкчелегендәге партизаннар отрядыннан, – дип ялганлады Зөфәр, ни өчендер үзләренең Күчкән Сала авылы башлыгын исенә төшереп.

– Минем андый отряд турында ишеткәнем юк, – диде Захаров, ничектер сәерсенгән кебек.

– Ишетмәгәнсеңдер. Без әле күптән түгел генә оештык. Отрядның җитәкчесе – Харрас Камалов – татар кешесе.

Зөфәр боларга дөресен сөйләүдә мәгънә булмасын аңлады. Ул рольгә тәмам кереп бара иде инде. Шуңа күрә әйткәннәре ышанычлырак булсын өчен:

– Мин бер иптәшем белән карательләрнең көчен билгеләр өчен разведкага чыккан идем. Засадага эләктек. Тигезсез атыш вакытында иптәшем һәлак булды, – дип тә өстәде.

– Кызганыч, әлбәттә. – Аннан соң әллә сүз уңаеннан, әллә үзенең танышы түгелме икән, дип уйлапмы: – Иптәшеңнең исеме ничек иде? – дип сорап куйды.

Шунда Зөфәр кабат тугрылыклы этен күз алдына китерде.

– Аккүз, – диде ул, әңгәмәдәшенең соравына җавап бирүдән бигрәк, мәгънәсез үлемгә дучар ителгән этен тагын бер мәртәбә жәлләп. Хәер, рус кешесе Аккүзнең татарларда кеше исемеме яисә этнекеме икәнен каян белсен?!

Захаров: «Кызганыч!» – дип тагын бер мәртәбә кабатлады да сүзсез калды. Йокыга китте булса кирәк. Бик нык арыган булса да, бу көндә башыннан узган гаҗәп хәлләр шаукымыннан, Зөфәрнең күзләренә тиз генә йокы кермәде.

* * *

Зөфәрнең мондый аңлаешсыз хәлгә тарыганына менә инде икенче көн. Шушы вакыт эчендә аны утын әрдәнәләре өчен ясалган кысан бүлмәдән дүрт-биш мәртәбә гауптштурмфюрер янына сорау алырга чыгардылар. Калган вакытта алар Захаров Андрей белән икәүләшеп, караңгыда утын пүләннәре арасында утырдылар. Бераз кысанрак булса да, җайлаштылар тагын.

Хәер, сорау алучы бәндәләр янында булуга караганда, монда яхшырак. Юкса әллә нинди мәгънәсез сораулары белән тынгылык бирмиләр. Берничә мәртәбә бәргәләп, кыйнап та ташладылар. Ачтан үлмәскә, үзләреннән калган сөяк-санак ише әйбер, бераз ипи, бер кружка су кертkәлиләр. Ишек артында сакта торучы солдат китерә аларны. Андрейның сорауларга җавап бирәсенә өметләрен өзгәннәр булса кирәк, аны бүтән бер мәртәбә дә «допрос»ка чакырмадылар.

– Мине әрәмтамак итеп озак асрамаслар, алмашка син булгач, тиздән расходка чыгармагайлары, – дип тә әйтеп куйды бер мәртәбә Андрей.

Бүлмә өй эченнән ишек белән аерылып торса да, эчтәге тавышларны Зөфәр яхшы ишетә. Анда көн дәвамында нindидер әңгәмәләр булып тора. Кайчак

тыныч кына сөйләшәләр, ә кайвакыт кычкырып бәхәсләшеп тә алалар. Ят телдә булгач, нәрсә хакында сөйләшкәннәрен аңламый ул. Хәер, аның аларда кайгысы юк, үз уйлары башына тынгылык бирми.

Чыннан да, искитәрлек маҗарага тарыды. Дистә еллар шушы урыннарда йөрсә дә, мондый хәлнең булганы юк иде. Аңа кадәр эшләгән урманчылардан да ишеткәне булмады.

Гадәттә, ул бу маршруттан дүрт көндә әйләнеп кайта иде. Димәк, бүген аны көн ахырында авылда көтәчәкләр. Әгәр кайтмый икән, борчыла башларлар, әлбәттә. Тайга бит! Юлда ни булмас! Хәтта ул аннан соң кайтмаса да, берәр көн көтәчәкләр әле. Аннан соң эзләргә чыгарлар, бәлки. Аркадашы Камилне авылдагы бер-ике кеше белән шушы маршрутка җибәрерләр. Алар бер-ике көннән, «Ерак привал»га килеп җитәчәк һәм... Нәкъ менә Зөфәр белән булган хәл кабатланачак. Аларны да шушында китереп ябачаклар. Монда икедән артык кеше сыймый, билгеле. Хәер, кешесе булса, урынын табарлар. Аландагы берәр агачка бәйләп булса да куярлар.

Менә шуннан соң, эзләргә киткән төркем кайтмагач, «Олы җир»гә, ягъни Южный бистәсенә ярдәм сорап мөрәҗәгать итәр авылдашлары. Анысы тагын бер мәшәкать. Южныйга кадәр телефон линияләре сузылмаган. Кәрәзле телефон элемтәсе турында уйлап та булмый. Күчкән Салада станцияләр төзелмәгән. Рация бар да... Тик бу хакта рация аша хәбәр итеп торырлармы икән?! Чөнки кешеләрнең тайгада адашу очраклары элегрәк тә булгалаганы бар. Адашкан кешеләр йә берәр көннән үзләре кайтып керә, йә эзләргә җибәрелгән кешеләр табып ала иде...

Шулай булгач, ярдәмнең әле тиз генә килеп җитәчәгенә Зөфәрнең бөтенләй өмете юк. Димәк, монда тик ятып эш чыкмас, котылу чарасын карарга кирәк, дигән уй белән яна башлады ул.

Зөфәрне барыннан да бигрәк соңгы мәртәбә сорау алырга чыгаргач, тәрҗемәче Хартман белән ике арада булган кыска гына сөйләшү сагайтты. «Допрос» вакытында гауптштурмфюрерны ашыгыч рәвештә өйдән чакырып чыгардылар. Урынбасары да аның артыннан иярде. Шунда икәүдән-икәү генә калгач, тылмач русчаны вата-җимерә:

– Юкка киреләнәсең, Иван. Партизаннарның кайда икәнлеген яшермичә түкми-чәчми сөйләп бирсәң, гомереңне саклап калачаксың бит. Ә болай расходка чыгарачаклар үзеңне. Аңа карап партизаннар да качып котыла алмас. Монда безнең яхшы коралланган эсэсчылар ротасы. Бер-ике көннән син күрсәткән Күчкән Салада урнашкан партизаннар өерен тар-мар итәргә кузгалачакбыз. Гер гауптштурмфюрер әзерләнә башларга әмер бирде инде, – дигән иде.

Куркыту өчен генә әйттеме? Әллә, чыннан да, походка җыеналармы? Баштанаяк коралланган мондый рота Күчкән Салага кинәттән генә килеп керсә, бөтен авыл халкын ике дә уйламыйча кырып салачак. Боларның кыяфәтендә рәхим-шәфкать күренми. Әнә бит, Аккүзне, кызганып та тормыйча атып үтерделәр. Үзе дә пуля тиюдән очраклы гына котылып калды. Димәк, авылдашларының язмышы, иминлеге бүген аның кулында. Шушы уйлар Зөфәрнең кичекмәстән качарга, дигән фикерен тагын да ныгытты. Һәм ул тоткынлыктан ычкыну турында ныклап уйлана башлады.

Утыннар саклау өчен файдаланыла торган бу бүлмә өйгә янкорма буларак ясалган. Аның бер яктагы ишеге өйгә ачылса, урамга, дөресрәге, урманга караган стенасының бер өлеше шулай ук ачыла. Утын әзерләгәндә, пүләннәрне өй аша түгел, ә тышкы яктан кертәләр. Гадәттә, ул яктагы стенаның агач яркаларыннан эшләнгән бер-ике ниргәсе алырга җайланган. Алар терәк

баганасындагы махсус ырмауга кертеп кенә куелган һәм бик җиңел алына. Кичен шул арткы стена аша иреккә чыгып, качып булмасмы, дигән уй килде Зөфәрнең башына. Дөрес, бер кыенлыгы бар: алына торган яркаларга кадәр ике рәт әрдәнә өелгән. Шуннан утыннарны алып, кеше сыярлык куышлык ясарга кирәк. Аннан соң гына яркаларны ырмаудан тартып чыгарырга була. Моның куркынч ягы бар: утын әрдәнәсенә куышлык ясаганда, үтә сак эшләмәсәң, өстән пүләннәр килеп төшеп, тавыш чыгачак. Ә әрдәнә җимерелсә, эш харап.

Ни булса, шул, дип, Зөфәр тәвәккәлләде. Сәфәргә чыксаң, әүвәл юлдаш тап дигәндәй, Андрейга да серен чиште. Аңа үзенең качу планы турында сөйләп бирде. Захаровка нәрсә, планны хуплады һәм бергәләшеп качарга ризалык бирде. Кемгә-кемгә, вакытны бушка уздыру аның файдасына түгел иде. Фашистларның күңелендә нәрсә икәнен кем белгән? Үзе әйтмешли, ике әрәмтамакны сөйрәп йөрткәнче, аларның берәрсеннән котылу җаен караулары да бар. Әгәр башларына шундый уй килә икән, беренче чиратта яралы Андрейны юк итәчәкләре көн кебек ачык.

Шул кичне, өй эчендәгеләр үз якларыннан ишекне агач терәүләр белән ныклап этеп куеп, барысы да тынгач, әрдәнәнең аскы ягыннан утын пүләннәрен берәм-берәм алып, янәшәгә өя башладылар. Шулай тавыш-тынсыз гына эшләгәндә, кинәт куышның өске ягыннан бер утын агачы шалтырап килеп төште. Моңа өй эчендәге сакчы игътибарсыз калмады, әлбәттә. Ул үз телендә нидер сукрана-сукрана, терәткечләрне алып, ишекне ача башлады. Зөфәр тиз генә куышлыкны арты белән каплап утырды да, йоклаган кыяфәт ясады, Андрейның да хырылдаган тавышы ишетелде: йоклый, янәсе. Солдат ишекнең ачылган өлешеннән фонарь яктыртып, тирә-якны җентекләп карады. Шикләнерлек берни дә күрмәде булса кирәк. «Шваен» дип сүгенде дә, ишекне теге яктан ябып, мыгырдана-мыгырдана тынып калды.

Тик торганга шайтан таягын тоттырган, ди, ярты сәгать чамасы тынып кына утыргач, саклык белән генә эшне тагын дәвам иттеләр. Күпме вакыт узгандыр, алдан юл ярып баручы Зөфәр стена хезмәтен үтәүче агач яркаларына килеп төртелде. Хәзер инде аларның кайсысы алынмалы икәнен тәгаенләргә кирәк. Көн яктысында эшләргә туры килсә, моның бернинди кыенлыгы булмас иде. Ә монда күзгә төртсәң, берни күренми. Кул белән капшанып табарга кирәк. Өстәвенә, саксыз хәрәкәт ясап, тавыш та чыгармаска.

Кирәкле урынны табу өчен тагын шактый вакыт узды. Әрдәнә куышлыгын алына торган ниргәләргә чамалап ачкан булса да, бик үк төгәл туры килмәгән икән. Бармагың сыймаган җиргә, башыңны тыкма, диләр. Куышлыкның бер ягыннан янә азрак пүләннәр бушатырга туры килде. Монысы тагын да куркынычрак, чөнки куыш киңәйгән саен, әрдәнәнең тотрыклылыгы да кими. Пүләннәр теләсә кайсы вакытта дөбер-шатыр җимерелә башларга мөмкин. Бу исә планнар да җимерелә, дигән сүз.

Ниһаять, куышлык ачык. Хәзер аннан чыгарга да, шуышып-үрмәләп аланның буш урынын узып, агачлар арасына кереп шылырга кирәк. Зур мәшәкатьләр артта калгач, монысы артык кыен да түгел шикелле. Тик алан тирәли сакчылар куелган. Аларның берәрсенә килеп чыксаң, шул ук мизгелдә мәхшәр кубачак. Алла сакласын, атып егулары бар. Иң яхшысы дигәндә, өелешеп килеп, икесен дә боргычлап бәйләп ташлаячаклар да, күзәтүне икеләтә-өчләтә арттырачаклар. Аннан соң инде качу турында хыялланып та булмаячак.

Шуңа күрә ул биш-ун минут вакытын кызганмады, тирә-якны яхшылап күзәтте, өйрәнде. Карый торгач, аланның бер читендә, ниндидер хәрәкәт шәйләнде. Чыннан да, кемдер йөренә икән. Димәк, бу урынга шушы сакчы

куелган һәм ул йөренә торган аралык аның карамагында. Шул тирәлекнең аргы башына киткәнен чамалап, урманга кереп качарга мөмкин. Ә аннан соң күз күрер әле... Тайга аның өчен туган йорты кебек.

Зөфәр шуларны уйлап, Андрейның кулына кагылып алды. Бу: «Әйдә, кузгалабыз», – дигән ишарә иде. «Саграк бул, тавыш чыгара күрмә!» – дип пышылдарга да онытмады.

* * *

Урманга кергәч, алар шактый вакыт бик саклык белән генә, ботак-сатакка орынып тавыш чыгармаска тырышып атладылар. Ниһаять, «Ерак привал» аланы шактый еракта калды шикелле. Курыкмыйча, тураеп басып, мөмкин кадәр кызурак барырга да була.

Караңгы. Өстәвенә, вакыт-вакыт агачлар куелыгына туры килеп, алга бару кыенлаша. Зөфәрнең куллары, йөзе агач ботакларына сыдырылып бетте. Кулбашы яралы Андрейның да хәлләре шәптән түгелдер. Берничә мәртәбә җирдә яткан ботакларга абынып та егылды. Шулай булса да, бер мизгелгә дә тукталып калмадылар. Аландагылар аларның юкка чыкканын белеп алганчы, мөмкин кадәр ераккарак качарга кирәк.

Күпме шулай барганнардыр, билгесез. Сулышларына кабып туктадылар. Шунда гына үзләренең кайсы тарафка барганнарын ачыкларга кирәклеге турында уйланды Зөфәр. Кулда компас, карта булмагач, тайгада төнлә түгел, көндезләрен дә юнәлешне билгеләү җиңел эш түгел. Ярый ла, монда килгәндә эте Аккүзгә тагылып барган иде. Хәзер ул да юк.

Дөрес, юнәлешне компас булмаса да, ачыкларга мөмкин. Агач ботакларына карап та якларны төгәл билгеләргә була. Ташларның төньякка караган өлешләрендә мүк үсүен дә күпләр белә. Табигатьтә андый билгеләр шактый. Урманда адашкан очракта юнәлешне чамалау өчен болар – иң гади ысул. Тик әлегә мондый күзәтүләр белән шөгыльләнеп булмый. Көн яктысында да ярымкараңгы булган тайга эчендә төннәрен берәр нәрсә күрермен, димә. Таң атып, кояш югары күтәрелмичә, «табигать компаслары»ннан файдаланып булмаячак. Шулай да, баруны дәвам итәргә кирәк. Арттан куып тотарга җыенсалар, ераккарак китеп калырга...

Бераз хәл алган Зөфәр кабат кузгалырга уйлаган иде, аны Андрей сабыр итәргә кушып туктатты:

– Әйдә, дускай, болай килешик: хәзер син, аңлавымча, үзеңнең отрядыңа ашыгасың. Ә миңа кичекмәстән үземнекеләрне табарга кирәк. Син урман эчендә якларны бераз чамалыйсыңмы? Без хәзер кайсы юнәлештә барабыз?

Зөфәрнең фаразлавынча, ул үзенә кирәкле юнәлештә бара иде кебек. Агачлар арасында торып, урманны күреп булмый, билгеле, хәзер үзләренең кайсы тирәдәрәк икәнлекләрен төгәл генә чамалау кыен. Өстәвенә, тайга гадәти урман да түгел бит әле, анда кайвакыт тәҗрибәле урманчылар да, юнәлешне югалтып, юлдан язгалыйлар. Тайгада йөргәндә, әгәр адашканлыгыңны аңласаң, иң мөһиме, паникага бирелмәскә кирәк. Андый вакытларда үзеңне кулга ала белмәсәң, гел кирәкмәс юнәлешкә кереп китүең бар. Адашып, кечкенә генә мәйданда әйләнеп йөрүең дә мөмкин. Никадәр мәзәк тоелмасын, урман эчендә юнәлешне югалткан кеше кайвакыт гел туры барам, дип уйласа да, бер тирәдән кичә алмый. Соңгы чиктә тәмам арып, атларлык хәле дә калмый. Әнә шулай харап булган кешеләр байтак. Андый чакта эчке сизгерлеккә – интуициягә ышанырга кирәк. Үз-үзеңә ышаныч никадәр зур булса, дөрес барасың дигән сүз. Шуңа күрә Андрейның соравына да кистереп җавап бирде ул:

– Без хәзер төньякка барабыз.

Аның шулай ышанып әйтүенә юлдашы бераз гаҗәпләнеп тә куйды, ахры.

– Ә ничек шулай әйтә аласың?

– Дускай, тумышым белән мин шушы тирәләрдән – тайга кешесе. Ата-бабаларыбыз тайгада яшәгән. Атаклы урманчылар, егерьлар нәселеннән мин. Тайгада йөрү минем өчен шәһәр кешесенең куе агачлы паркта сәйран кылып йөрүе шикелле генә.

Дөрес, аның бу сүзләре бераз күпертү. Ләкин шулай сөйләшми булмый.

– Мин, мәсәлән, кайсы якка баруыбызны якынча да әйтә алмыйм. Һаман бер урында әйләнәбездер шикелле, – диде Андрей.

Зөфәр аның ягына кызганулы караш ташлады. Бу кеше хәзер шушы хәлендә урман эчендә үзе генә калса, сүз дә юк, адашачак һәм кыргый хайваннарга азык булачак. Мондый шартларда аның үзен генә урманга кертеп җибәрү мәгънәсезлек булыр иде. Шуңа күрә ул Андрейга ялганлап тормады, фикерен турыдан ярып әйтте:

– Бер урында әйләнәбездер шикелле, дисең инде алайса?.. Менә, менә, кешенең тайгада адашуы шуннан башлана да инде. Баштан әйләнгән шикелле тоела, аннан соң, чыннан да, әйләнә башлый. Шулай булгач, Андрей, мин берничек тә ялгызыңны гына урманда калдыра алмыйм. Гафу ит. Шулай ук сине үзеңнең партизаннар отрядына кадәр озата да алмыйм. Менә син аларны кайсы якта дип уйлыйсың?

Захаров күңеленнән юнәлешне билгеләгәндәй, берникадәр вакыт эндәшмичә торды. Ул хәтта башын күтәреп, агачларның очлары арасында беленер-беленмәс кенә аксылланып торган урынга да карап алды кебек. Аннан соң шикләнеп кенә:

– Син төньякка барабыз, дидең. Ә безнең отряд хәзер, минемчә, көньяк-көнчыгышта булырга тиеш. Шулай булгач, миңа менә бу якка борылырга кирәк, – дип, сау кулын күтәреп, үзе барачак юнәлешне күрсәтте.

Хәер, караңгы булганлыктан, Зөфәр юлдашының шәүләсен генә күрә иде. Шуңа да ул күрсәткән юнәлешне дә бары тик әйткән сүзләреннән генә чамалады. Гомумән, бер мәртәбә дә яктыда күрмәгәч, Андрейның төскә-биткә ниндирәк кеше икәнлеген ул белми иде әле.

– Аңлавымча, хәзер үзегезнекеләргә бару өчен, сиңа капма-каршы якка ук булмаса да, шул тарафка китәргә туры киләчәк. Ә ул якларда карательләр отряды мыжлап тора. Әле яңа без качып котылган карательләрне дә бер рота эсэсчы башкисәрләр, дип, үзең әйттең түгелме? Кулыңда бер коралың, хәтта соңгы чиктә маңгаеңа җибәрерлек бер патронлы пистолетың да булмаган көе син – капкынга эләккән тычкан, алар кулына килеп керәчәксең түгелме? Тотсалар, расходка чыгарачаклары көн кебек ачык. Бер мәртәбә качкан кешене җәлләп тормаячаклар...

– Ә мин үтә саклык белән генә барачакмын. Аңла, Зөфәр, отрядны карательләр куып җиткәнче, мин үзебезнекеләргә кушылырга тиеш...

– Бу хәлеңдәме? Үзеңнең яралы икәнеңне онытма! Син миннән берничә йөз метр китүгә бер урында таптана башлаячаксың, берәр сәгатьтән хәлдән таеп егылачаксың... Ә безнең отряд якындарак... Сәламәтлегеңне ныгыткач, үзегезнекеләргә озату ягын карар идек әле...

Зөфәр үзе дә сизмәстән, бөтенләй партизан роленә кереп бетте. Тик ничек итсә итте, юлдашын барыбер «үзенең отряды» урнашкан урынга кайтырга ризалаштырды. Андрей нишләсен, кем арбасына утырсаң, шуның җырын

җырларсың, дип, аның белән килеште. Һәм алар тагын алга кузгалдылар. Бу вакытта агачлар очындагы аксыл «утрау» тагын да яктырган иде. Таң атып килә.

* * *

Бүген Наҗия көне буе күзен тәрәзәдән алмыйча ирен көтте. Моннан дүрт көн элек чыгып киткән Зөфәр бүген кайтырга тиеш иде. Тайганың алар карамагындагы «Ерак привал» дип аталган читенә барып җитеп, аннан әйләнеп кайту өчен, иренә аз да түгел, күп тә түгел, нәкъ менә дүрт көн кирәк. Күп еллар дәвамында бергә яшәп, Наҗия моны бик яхшы чамалый. Шуңа күрә бүген иртәдән үк, менә кайтыр, менә кайтыр, дигән өмете бар иде. Кичен кайтмагач, әллә авыл башлыгы Харрас абый белән киңәшләшимме икән, дип тә уйлады. Тик ниятеннән кире кайтты. Бәлки, кичен яисә төнлә кайтып керер, дип өметләнде. Юлда нәрсә булмас?! Тайга – тайга инде ул дип, үзен тынычландырды. Ләкин ире кичен дә, хәтта төнлә дә кайтмады. Ул вакытта Харрас абыйга барырга соң иде инде. Иртәне көтәргә туры килде. Ләкин бу төндә Наҗиянең йокысы йокы булмады. Шуңа күрә иртән үк Харрасларга юл тотты.

Хәл-әхвәл белешкәч, әллә кайлардан әйләнеп, боргалап-сыргалап тормады, ни өчен килүенең сәбәбен әйтеп бирде.

– Аңлыйм, Наҗия, ireңнең «Ерак привал»га киткәнен ишеткән идем. Аның кичә кайтырга тиеш булып та, кайтып җитмәгәнлегеннән дә хәбәрдар. Авыл зур түгел. Һәр йортта телефон булмаса да, «чыбыксыз телефон» яхшы эшли, – диде Харрас.

– Кичә көн дәвамында кайтыр, бәлки, дип өметләнеп көттем. Инде кичен дә, төнлә дә кайтмагач, йокым йокы булмады. Нигәдер бик борчылам. Аның алай озак тоткарланганы юк иде.

Харрасның йөзе күзгә күренеп җитдиләнде. Маңгаенда тирән сырлар барлыкка килде. Шактый еллар авыл башлыгы булып эшләгән һәм шушы җирлектә яшәүче һәр кешенең шатлык-кайгыларын үз күңеле аша үткәрергә ияләнгән өлкән кеше, бүген үзенең борчуын белдереп килгән шушы хатынны юату, тынычландыру өчен күңеленнән генә тиешле сүзләр эзли иде.

– Наҗия, борчылма әле, кайтыр. Зөфәр югалып кала торган кеше түгел. Кем әйтмешли, тайгада туган, тайгада үскән... Берәр нәрсә... э-э, мәшәкате килеп чыккандыр да...

Аның «берәр нәрсә» дигән сүзләрен Наҗия шунда ук элеп алды:

– Шуның өчен борчылам да инде, Харрас абый. Берәр нәрсә килеп чыккандыр, – диде ул. – Тайга белән шаярырга ярамый...

Борчылып төне буе әллә нәрсәләр уйлап бетергән бу хатын белән һәр сүзне чамалап сөйләшергә кирәклеген яхшы белә Харрас. Шуңа күрә, уйламыйчарак әйтеп ычкындырган хатасын төзәтергә ашыкты:

– Гел начарын гына юрарга кирәк түгел, сеңлем. Әле күптән түгел, урманчы өйләренең берсенең түбәсе фәкыйрьләнгән, ныгытып аласы бар, дип сөйләнеп торган иде Зөфәр. Бәлки, салкыннар җиткәнче дип, шуны эшләргә уйлагандыр?..

Наҗиянең монысына да җавабы әзер икән. Төнлә йоклый алмыйча ятканда, ул ягын да кат-кат уйлаган күрәсең.

– Алар андый эшләрне Камил белән барганда, бергәләп эшлиләр иде, гадәттә. Нишләп ялгыз башы керешер икән? Аның ише вакытта, киткән чакта, шундый эшләрем бар, тоткарлануым ихтимал, дип, мине кисәтә иде...

Сүзне озынга сузып торудан мәгънә юк, күп сүз – буш сүз, уйламыйча

әйтелгән һәр сүзнең бу бичара хатынның йөрәгенә барып төртеләчәген Харрас аңлады булса кирәк.

– Сабыр төбе – сары алтын, диләр, әйдә тагын бер көн сабыр итик, Нәҗия. Кайтыр, Алла боерса, кайтмыйча калмас. Әгәр бүген дә кайтмаса, иртәгә Камил белән бер-ике кешене эзләргә җибәребез. Южныйга хәбәр итү җаен да карарбыз... Бу көннәрдә ни өчендер рация эшләми. Аппараты көйсезләнгәнме, әллә станциясендә төзексезлек килеп чыкканмы, әлегә билгесез. Азык-төлек һәм почта өчен вездеход тагын бер атнадан гына Южный бистәсенә китәчәк. Графиктан тыш анда кадәр трактор кууда мәгънә юк, – диде ул хатынны тынычландырып...

Шулай тынычланган кебек булып өенә кайтып утырган иде, Камил килеп керде... Беренче соравы: «Кайтмадымы?» – булды.

– Юк шул, – диде, Харрас белән булган сөйләшүдән соң бераз тынычлана башлаган хатынны тагын борчу биләп алды.

Камил дә ни кылырга белмәгәндәй уйга калды.

– Миннән башка барма, дип әйткән идем югыйсә. Берничә көн көтәргә түземлеге җитмәгән, ялгызы киткән, – дигән сүзләр кысылып чыкты аның теш арасыннан.

– Үзем дә кат-кат шулай, дидем. Юк, сүзләремә колак та салмады. Зөфәрне беләсең бит инде, Камил. Барысын да планда каралганча, төгәл үтәргә ярата. Имеш, «Ерак привал»га барып кайту шул көннәргә билгеләнгән.

Нәҗия, нәрсәсен сөйләп торырга инде аның дигәндәй, кулын селтәде. Шактый вакыт эндәшмичә утырдылар. Ниһаять, Камил телгә килде:

– Болай утырып булмый, Нәҗия. Нәрсәдер эшләргә кирәк. Харрас абый янына барып киңәшләшикме әллә?

– Мин бүген аларга барып, хәлне сөйләп бирдем.

– Нәрсә, ди?

– Нәрсә, дисен, бераз сабыр итәргә кирәк, дип тынычландырган булды. Бүген дә кайтмаса, иртәгә Камил белән берәрсен эзләргә җибәребез, диде.

Тагын тынлык. Аннан соң әнә шул эчпошыргыч шомлы тынлыкны бозып, Камил утырган урыныннан чәчрәп сикереп торды да кискен тавыш белән:

– Иртәгәне көтмим, Нәҗия, бүген үк чыгып китәм, – дип ярып салды.

Зөфәр белән Камил – күп еллардан якын дуслар. Бергә эшләгәч, бер-берсен ярты сүздән аңлыйлар. Сүз дә юк, ул дустының кайтмый калуын авыр кичерә иде. Шуңа күрә аның бу кискен фикергә килүенә Нәҗия артык гаҗәпләнмәде. Хәер, әгәр көченнән килсә, бу минутларда үзе тайгага чыгып йөгерер иде. Камилгә дә: «Барма, бүгенгә сабыр ит!» – дип әйтә алмады, бары тик:

– Аймыл булмассызмы соң? – диюдән узмады.

– Мин аның кайтыр юлына каршы чыгам. Ул шарлама ягындагы сукмактан кайтып керәчәк. Беренче елыбыз гына түгел. Гел шуннан кайтабыз. Аймыл булмабыз. Мин үзем белән этемне дә алам. Шарик – бик сизгер эт. Аның белән ышанычлырак булыр, – диде ул.

* * *

Зөфәр белән Андрей менә инде бер тәүлеккә якын урман эченнән баралар да баралар. Фашистлар лагереннан качып киткәннән соң бер төн үтеп китте. Тагын кич җитте. Урманда караңгы төшә башлады. Бу вакытта алар икесе дә хәлсезләнгән иде инде. Бигрәк тә Андрейның хәлләре шәптән түгел. Күп кан югалтканлыктан һәм көне буе авызына ризык кермәгәнлектән, ул күзгә күренеп хәлсезләнә. Вакыт-вакыт егыла. Хәрәкәтләре дә бик сүлпән. Ава-түнә атлый.

Шуңа күрә Зөфәргә вакыт-вакыт аны көтеп алырга туры килә. Хәер, үзенең дә бөтен тәнендә хәлсезлек. Шулай булса да, туктап калырга ярамый. Ташбака адымы белән генә булса да алга баруың хәерле.

Көн яктысында Зөфәр юлдашының кыяфәтен күрү бәхетенә иреште, ниһаять. Утыз-утыз биш яшьләр чамасындагы саргылт чәчле, чандыр гына ир-ат икән. Өстендә – бик нык таушалган гимнастёрка. Погоннары йолкып алынган. Анысы фашистлар эше, әлбәттә. Сул кулын ниндидер чүпрәк белән муенына бәйләп аскан. Кулбашыннан кан саркып, гимнастёркасында зур кара тап хасил иткән.

Юкка-барга көч сарыф итмәс өчен алар хәтта сөйләшмиләр диярлек. Кирәк булганда, бер-ике мәртәбә сүз алыштылар да, шуның белән бетте. Хәер, артыгы кирәк тә түгел. Алга максат куелган, бөтен көчне шуңа юнәлдерергә.

Караңгы төшә башлагач, Андрей бөтенләй хәлсезләнде. Ул инде вакыт-вакыт онытылып, йокылы-уяулы бара кебек. Сөрлегеп егылулары ешайды. Егылгач, күп вакыт урыныннан үзе тора алмый. Зөфәр кире килеп, аңа күтәрелергә ярдәм итә. Шуңа күрә аны иңнәреннән тотып, янәшә атларга мәҗбүр. Хәзер инде алар бик акрын атлыйлар...

Чираттагы бер егылуында Андрей торырга омтылыш та ясамады. Зөфәрнең ярдәм итәргә теләгән кулын читкә этәрде дә еш-еш сулап:

– Ах, бер йотым гына су булсачы... Барырлык хәлем калмады, Зөфәр, калдыр мине. Мин сиңа авыр йөк кенә. Син тизрәк кайтып, үзеңнекеләрне кисәт. Юкса карательләр сиздертмәстән һөҗүм итеп, барысын да кырып салырлар, – диде ул.

– Син нәрсә инде, Андрей, мин сине бу хәлеңдә ташлап калдырмыйм. Иңнәремдә күтәреп булса да алып кайтам. Аз гына түз инде... Ерак калмады...

Зөфәр үзе дә бик сусаган иде шул. Көндез берничә урында дымлырак урын табып, күлмәген шунда җәеп, кул белән баскалагач, күлмәкнең икенче ягыннан дымын суырган иде. Андрейга да бирде. Ләкин сусау вакытлыча гына басылган кебек булды да янә тамак кипте, иреннәр-иренгә ябышты. Ах, ул су эчәсе килүләр!..

Андрейны алга барырга күндерде. Юлдашын авырлык белән генә күтәреп торгызды да иңнәренә салып, алга атлады. Күпме шулай барганнардыр, Зөфәр кинәт туктап калды. Аның колагына агачлар шаулавыннан тыш, ниндидер үзгә тавыш ишетелеп киткәндәй булды. Ул Андрейны иңеннән төшерде дә янәшәдәге агачка терәп утыртты, тураеп басып, кулларын колакларына куеп, тирә-яктагы тавышларга игътибар итте. Чыннан да, урмандагы гадәти тавышлардан тыш, ниндидер тавыш ишетелә. Күп еллар урманда яшәгән, эшләгән кешенең колагы тавышларга бик сизгер. Гадәти урман шаулавыннан аермалы һәр ым-авазны ул бик тиз тотып ала. Монда да шундый ук нәрсә ишетелеп киткәндәй була. Хәтта моның нәрсә тавышы булуын чамалый да кебек ул. Әллә соң ишетү галлюцинациясе башландымы? Сусаудан андый нәрсә дә булырга мөмкин. Коргаксыган тән, баш мие күзәнәкләре әллә нәрсәләр ишеттерергә мөмкин. Әгәр хәл андыйга китсә, бик начар. Ә инде ишетелгән тавыш чынбарлык икән, анысы яхшы. Кайдадыр шарлап су акканы ишетелә.

Күчкән Сала авылының көньяк-көнчыгыш ягыннан, тайга эчендә тар гына инеш агып ята. Чиста сулы ул елгачык тайга эчендәге кизләүдән башлана. Күпчелек урында салмак кына агучы бу чишмә урыны-урыны белән тирән ерганаклар хасил иткән. Ике-өч метр биеклектән шарлап ага торган урыннар да бар. Менә бу таныш тавыш шул шарламаларның берсеннән ишетелә кебек. Әгәр шул урынны эзләп тапса, ул авылының кайсы якта икәнлеген дә дөрес билгеләячәк.

Яхшылап тыңлый торгач, тавыш ишетелгән юнәлешне чамалый алды ул. Баштан Андрейны монда калдырып, үзе генә барып килергә уйлаган иде. Әмма уеннан кире кайтып, аны кабат иңнәренә салды. Караңгыда ялгызын калдырса, кабат таба алмам, дип курыкты. Бераз баргач, шарлап су аккан тавыш көчәя башлады. Зөфәр ялгышмаган: бу инешнең шарлавыклы урыны иде...

Андрейны инеш читендә калдырып, тирән җиренә ерып керде дә суны кушучлап алып, йотлыга-йотлыга эчәргә кереште. Сусавы басылгач, Андрей янына ашыкты. Күтәреп барганда, соңгы мизгелдә һушын җуйган Андрей да аңына килгән һәм, шарлап аккан су тавышын ишетеп, тырмаша-тырмаша суга таба шуыша башлаган иде. Инеш читенә сөйрәп китерде дә, кушучлап су алып, Андрейның иреннәренә тидерде. Андрей йотлыга-йотлыга эчте. Эчеп туйгач, Зөфәр кулларын, битләрен юды. Андрейны да юындырды. Аңа бераз хәл керде булса кирәк, ул торып ук утырды:

– Син юкка минем белән мәшәкатьләнәсең. Калдыр. Алдагысын үзем карармын, – диде ул өзек-өзек сүзләр белән. Ыңгырашып та алды. Ярасы әрни, күрәсең.

Зөфәр аңа җавап кайтармады. Аның үз уйлары иде. Нәкъ менә шушы урындагы шарламадан авылның кайсы якта икәнлеген ул бик яхшы белә. Монда беренче мәртәбә генә булуы түгел. Шуңа күрә хәзер авылга адашмыйча кайтып җитәсенә шиге юк. Юнәлешне бераз гына төньяк-көнчыгышка үзгәртергә кирәк.

Тик менә Андрейның хәле генә борчый. Авылга кадәр исән-имин кайтып җиткерә алырмы? Үзенең дә көче бетеп бара. Өстәвенә, сусауны баскач, үлеп ашыйсы килә башлады. Андрей да шул хәлдәдер. Мондый караңгыда ризык каян тапмак кирәк?! Шунда гына аның, теге урман аланындагы өйдә чакта, күңеленә качу уе беркеткәч, ишек төбендәге сакчы солдат кертеп ыргыткан ипи кисәген ашамыйча, чүпрәккә төреп, куен кесәсенә салганы исенә төште. Капшап караган иде, ул бүлтәеп, эчке кесәдә тора. Куеныннан төргәкне алып, ашыга-ашыга сүтте. Борынга икмәк исе килеп бәрелде. Ләкин ул ыңгырашып яткан Андрей янында ипи телемен авызына кабарга ашыкмады. Телемнән зур кисәк сындырып, иң беренче аңа каптырды. Андрей ашаганда, валчыгы да коелмасын өчен, аска учын куеп торды, коелган валчыкны үзе капты. Аннан соң кулындагы үзенә тигән өлешне дә авызына озатты. Моның белән генә ашыйсы килүне басу мөмкин түгел, билгеле. Тик нихәл итмәк кирәк, булмаганда, анысы да ярап тора.

Бераз ял иткәч, Зөфәр тагын кузгалырга дигән карарга килде. Юкса монда ятып, йокыга талуың да бар. Тәнгә йомшарырга ирек бирмәскә, ияләнгән ритмны югалтмаска, никадәр генә кыен булмасын, юлны дәвам итәргә кирәк.

Кузгалдылар. Хәтта Андрей да әлегә Зөфәргә тотынып, үзе атлагандай итә. Тик бу озакка бармас, мөгаен. Хәзер алар кызу атларлык хәлдә дә түгел.

Күпме барганнардыр, кинәт якында гына эт өргән тавыш ишетелде. Тиздән корыган ботак-сатакларны сындырып, кемдер бу якка чабып килә кебек тоелды. Бер кавымнан ниндидер кара күләгә килеп, Зөфәрнең өстенә ташланды. Бу кеше түгел иде. Кыргый хайвандыр, дип уйлап алды ул. Ләкин аңа каршы тора алырлык көче юк инде. Ул Андрейны кочаклаган көе җиргә егылды. Хәзер барысы да бетәчәк. Бу ерткыч хайван аларны бугазлап алып, ботарлап ташлаячак. Үлемем шушы икән, дигән уй йөгереп үтте аның башыннан.

Тик ни гаҗәп, ерткыч аны ботарларга ашыкмады. Зөфәр колак кырыенда ук аның сулышын тойды. Шыңшыган тавышы да ишетелде һәм... кызганыч тавыш белән чинап та алды. Аның ерткыч түгел, ә эт икәнлеген шунда гына

аңлады. Башта ул аны Аккүздер, дип уйлаган иде. Чөнки бу вакытта эт аның колакларыннан, битеннән ялый һәм кызганыч итеп шыңшый башлады. Могҗиза белән Аккүз исән калып, аны эзләп тапкандыр, дип уйлады ул.

Бераздан эт өреп куйгач, бу уйларыннан кире кайтты. Аккүзнең тавышы мондый түгел. Аның өрүен йөз, мең эт тавышыннан да ялгышмыйча аера алыр иде Зөфәр. Бу этнең тавышы бөтенләй икенче. Ләкин барыбер таныш.

– Шарик! – дип кычкырып җибәрде ул кинәт. – Каян килеп чыктың син монда?

Шарик – аркадашы Камилнең эте. Аккүз шикелле үк акыллы ул.

Эт аның шатлыгын уртаклашкандай, янәшәсенә ятты да кулларыннан, битләреннән яларга кереште. Шул мизгелдә Зөфәрнең күзләреннән бер-ике тамчы яшь тәгәрәде. Шатлык яшьләре... Ул йөзе белән Шарикның куе йоннарына капланды. Этнең тәненнән килгән тир исе борынына килеп бәрелде. Кыл кебек йоны битләрен кытыклады. Әнә шундый халәт Зөфәрнең бөтен авыртуларын оныттырды. Ул тәнендә нинди дер рәхәт ою тойды. Һәм аңының акрын гына томалана баруын сизде. Шулчак эт кинәт сикереп торды да өрә-өрә кирегә чапты. Менә аның тавышы ераклашканнан-ераклаша бара. Инде бөтенләй ишетелмәс булды. Колакка бары тик агачларның гына тонык шаулавы ишетелә. Башка берни дә юк. Мин саташа башладым бугай, дигән уй йөгереп узды аның баш миенең уяу калган өлешеннән. Төнгә каршы бу урынга Шарик каян килеп чыксын инде?..

Шулчак эт өргән тавыш кабат ишетелде. Ул якынайганнан-якыная иде. Зөфәр агачларга тотынып торырга маташты. «Шарик! Шарик!» – дип кычкырмакчы булды. Эт аны күрмичә, читтән узып китәр дип курыкты, күрәсең. Ләкин ул үз тавышын үзе дә ишетмәде...

* * *

Эсэсчылар лагеренда тоткыннарның качып китүен иртәнге якта гына белеп алдылар. Штаб урнашкан урманчы өенең утын әрдәнәләре саклана торган янкормасы ягында, урман читендә сакта торучы солдат, ничектер, шул якка күз салган иде, стенада ачык урын караеп торганны шәйләде. Якынрак барып караса, андагы яркаларның бер-икесе алынган. Шунда ук фельдфебель Шульц янына йөгерде. Чөнки ул, нинди дә булса гадәттән тыш хәл килеп чыкса, иң беренче чиратта миңа әйтегез, дип әмер биргән иде.

Бу вакытта алан уртасында куаклардан һәм ботак-сатактан корыштырып ясалган шалашта, плащ-палаткасына уралып йоклап яткан кече офицер, йокысының иң тәмле чагында, таң алдыннан уятуларын баштарак ошатып бетермәде. Алай да, солдатның үзен гел кирәкмәскә уятырга җөрьәт итмәсен белгән фельдфебель, нинди дер гадәттән тыш хәл килеп чыкканын аңлап, автоматына ябышты. Тиз генә сикереп торып, палаткадан чыкты.

Солдат тотлыга-тотлыга хәлне сөйләп биргәч, алар икәүләшеп ротаның штабы урнашкан урманчы өенә ашыктылар. Анда, чыннан да, стенадан берәр метрлы ике ярка алынган. Утын саклау бүлмәсенең эчке ягы караеп күренә. Шульц шикләнеп кенә эчке якка башын тыгып карады. Андагы әрдәнәнең утыннарын алып, кеше сыярлык урын ясалган. Эчтә беркем дә күренми.

– Качканнар, – диде ачу белән Шульц.

– Әйе, гер обершарффюрер, качканнар, – дип, аның сүзләрен җөпләде солдат.

Солдатның, үзен үчекләгәндәй, артыннан кабатлап торуына Шульцның бик нык ачуы чыкты:

– Ни карадыгыз?! – дип акырды ул, аның якасыннан умырып тотып.

Гауптштурмфюрер Мартинның бик коры кеше икәнен яхшы белгән һәм

аның йодрыкларын үз сыртында аз татымаган Шульц, бу хәлнең нинди нәтиҗәләргә китерәсен яхшы чамалый иде. Ул ачудан солдатның йөзенә йодрыгы белән орды. Тегесе куллары белән йөзен каплап, җиргә егылды, борыныннан шарлап кан ага башлады. Шульц аның ягына төкереп кенә куйды да штаб ишегенә таба атлады. Үзен дә нәкъ шушы солдат язмышы көткәне көн кебек ачык. Пырдымсыз һәм үз әмерләрен берсүзсез үтәүләренә күнеккән гауптштурмфюрер Мартиннан артыгын да көтәргә була. Бу ике әсирнең качып китүе барыбер мәгълүм булачак. Моның өчен беркем дә түгел, бары тик Шульцка гына җавап тотарга туры киләчәк...

Штаб ишеге төбендә автоматлы ике сакчы тора. Алар гауптштурмфюрер янына теләсә кемне кертми. Ә офицерны вакытлы-вакытсыз тынычсызлап йөрүчеләргә бөтенләй юл ябык. Шуңа күрә алар икесе дә бердән автоматларын аркылы куеп, керергә ярамый, дигәнне белдерделәр.

– Әйтәсе мөһим сүзем бар, – диде Шульц, сүзләре ышандырырлык булсын өчен тавышын күтәрә төшеп.

Сакчы солдатлар бер-берсенә карашып алдылар. Гауптштурмфюрерга кайсыбыз кереп әйтә, янәсе. Вакытлы-вакытсыз борчыганнарын Мартин яратмый. Ачулы чагына туры килсәң, бәргәләп ташларга да күп сорамас. Тик Шульцны да аңларга була. Хәрби дәрәҗәсе үзеннән өстен булган офицер янына килергә җөрьәт итәр идеме? Димәк, җитди сәбәпләре бар...

Чыннан да, сакчы уяткан гауптштурмфюрер сул аягыннан торды булса кирәк. Ул кереп китеп озак та узмады, өйдән Мартинның сүгенгән тавышлары ишетелде. Нәрсәләрдер дөбердәде, шакылдады. Шул ук мизгелдә ишек ачылып китте, аннан абына-сөртенә сакчы йөгереп чыкты да үрә катып, ишек янындагы урынына басты. Аның артыннан ябылып өлгермәгән ишектән Мартинның йомарланган портупеясы очып чыкты. Ул Шульцка бәрелде дә, тезләрен нык кына авырттырып, аның аяк астына килеп төште. Бер минут уздымы икән, ишектән портупея хуҗасының чытык йөзе күренде. Ул бөгәрләнеп беткән эчке киемнән. Чәчләре тузган, күз төпләре шешенгән. Кыяфәтеннән һәм үз-үзен тотышыннан аның кичтән яхшы гына шнапс чөмереп алганы сизелә. Хәзер махмырдан башы авырта, күрәсең. Өстәвенә, нәкъ шундый вакытта, ял итәргә комачаулап йөриләр...

Ул килеп чыгуга, Шульц җирдән үрелеп портупеяны алды да Мартинга сузды:

– Гафу итегез, гер гауптштурмфюрер, портупеягызны рәхим итеп алыгыз!

Мартин, бу портупея ничек синең кулыңа килеп эләкте дигәндәй, гаҗәпләнгән кыяфәт чыгарып алды. Икенче кулындагы фляганы күтәреп, нәрсәдер чөмерде.

– Йә, ни бар анда? – диде ул, флягасының капкачын борып.

– Гер гауптштурмфюрер, рус әсирләре качкан, – дип әйтеп салды Шульц.

Гауптштурмфюрерның авызы ачылган килеш калды, күзләре маңгаена менде. Бераздан соң гына ул:

– Ягъни?.. Ничек инде качкан? – дип сорый алды һәм кырт борылды да ишекне каерып ачып, «штаб»ка кереп йөгерде.

Өй эчендә аның акырып-бакырып сүгенгәне ишетелде. Дөбер-шатыр урындык-бүкәннәр ауды, нәрсәләрдер идәнгә шакылдап төште, өйнең арткы ягындагы утыннар тутырган янкормада утын әрдәнәсенең шалтыр-шолтыр ишелгәне ишетелде...

Өч минуттан артык вакыт узмагандыр, тоткыннар ябылган бүлмәнең ишеге

янында сакта торган солдатны якасыннан тотып, ишектән килеп чыкты ул. Чыккан шәпкә аны җилтерәтеп җиргә томырды. Егылып яткан солдат ягына төкереп:

– Син, дуңгыз, үзеңне үле, дип исәплә. Бу сансызлыгыңны бары тик каның белән генә юа алачаксың. Ә синең, Шульц, җиде кат тиреңне тунаячакмын, – диде.

Аның, ачудан, бурлаттай кызарган йөзенә карарга куркыныч иде бу минутларда. Мартинның холкын яхшы белгән Шульц үрә катты, үкчәсен үкчәгә бәреп: «Яволь, гер гауптштурмфюрер!» – диюдән ары уза алмады. Ниһаять, Мартин хәлсез кешедәй пышылдап диярлек сөйләшүгә күчте. Әле яңарак кына бөтен таләпләрен туры китереп киенеп чыккан эсэс оберштурмфюрерга мөрәҗәгать итеп:

– Ганс, ротаны тревогага күтәрергә! Төгәл унбиш минуттан барысы да алан уртасына чыгып, тезелеп бассыннар, – диде дә киенер өчен өйгә кереп китте.

Ул юынып, ашап-эчеп, киенеп чыкканда, махсус өйрәтелеп, партизаннарга каршы җибәрелгән эсэс гаскәренең ике йөзгә якын солдат һәм офицерлардан торган бер ротасы аландагы мәйданчыкта тезелеп тора иде инде.

Гауптштурмфюрер озак сөйләмәде. Аның әмерләре кыска һәм кискен иде:

– Сакка куелган солдатларның җавапсызлыгы аркасында, бүген төнлә рус әсирләре качып киткән. Кайберәүләргә гаепләрен каннары белән юарга туры киләчәк. Бөек Вермахт армиясендә андыйларга урын юк. Ә без хәзер рус партизаннары урнашкан лагерьга барып, аны җир йөзеннән тулысынча юк итәчәкбез. Лагерьның кайда урнашканлыгы безгә төгәл мәгълүм. Карталары безнең кулда калды. Хәзер барыгызга да тулы хәрби әзерлеккә вакыт бирәм. Төгәл ике сәгатьтән походка кузгалабыз. Һәрбер офицерга, солдатка шуны белдерәм: әсир алмаска, беркемне кызганмыйча юк итәргә. Хайл Гитлер!

Аланда: «Хайл!» – дигән авазлар гөрелдәде.

* * *

Ул, битләренә җиңелчә генә суккалап: «Зөфәр, Зөфәр!» – дигән тавышка һушына килеп, күзләрен ачты. Камилнең тавышын шунда ук танып алды.

– Су бир, су, – дип пышылдады ул, бөтен гәүдәсе белән калтыранып.

Камил, фонарь белән яктыртып, биштәрендәге фляганы ачты да Зөфәрнең авызына тидерде. Зөфәр йотлыгып эчә башлады.

– Сөйлә, нәрсә булды синең белән, нинди бәлагә тарыдың? – дип сорады Камил.

– Нәрсә булганны мин үзем дә әлегә кадәр ныклап төшенеп җитмәдем. Көтелмәгән искитәрлек хәлләргә дучар булдым, дускай. Сөйләсәм дә, ышанмассың, дип уйлыйм.

– Ә син сөйлә! Хәзер дистә елдан артык бергә эшләп, бер-беребезне ярты сүздән аңларлык кешеләр без. Мин дә ышанмасам, тагын кем ышаныр сиңа?!

Их, белсә иде шушы соңгы тәүлекләр эчендә аркадашының башыннанниләр үткәнен! Юк, ул хәзерге вакытта теләсә нәрсә уйлыйдыр, әмма чын дөресен күз алдына да китерә алмаячак, әйтсә дә, ышанмаячак. Ерткыч, җанварлар һөҗүменә дучар булган, өстенә агач ауган, кинәт авырып киткән, юлбасар яки хәтта берәр маньяк һөҗүм иткән, дип әйтсә, шуларның теләсә кайсына ышаначак, ә менә чын дөресенә – ай-һай!

– Мин фашистлар әсирлегеннән качтым...

Әле яңарак кына «сөйлә-сөйлә» дип ялварган Камил, шушы өч-дүрт сүздән торган җөмләне ишетүгә, кинәт тынып калды. Аңлашыла! Мондый сүзләрне

акылы сәламәт кеше әйтә алмас, зиһененә зыян килгән, дип уйлый инде ул хәзер. Башкача түгел, нәкъ шулай.

– Ни булды сиңа, дускай? Авырыйсың түгелме? Саташа ук башладың. Берәр куркыныч бизгәк йоктырмагансыңдыр бит? Мә әле, тагын су йот!

Камил флягасын биштәренә салып өлгермәгән иде әле. Ул аның капкачын кабат борып ача башлады.

– Миңа су җитте. Туйганчы эчтем. Әнә теге егетнең хәле минекенә караганда да мөшкелрәк. Суны аңа эчерт, – дип, Андрей яткан якка ишарәләде Зөфәр.

Камил фонарь яктысын ул күрсәткән якка юнәлтте. Андрей бөтенләй хәрәкәтсез ята иде. Тагын һушын җуйган, күрәсең.

– Кем ул? Сине шушы хәлгә төшерүче улмы әллә?

Камил иңенә асылган мылтыгына үрелде.

– Юк, юк, ялгышып ата күрмә тагын. Ул үз кеше – Андрей. Ул да фашистлар әсирлегеннән качты...

Фонарь яктысы кабат Зөфәр ягына күчте. Шул арада Камилнең йөзе дә чагылып алды. Аның күзләрендә чиксез гаҗәпләнү һәм бераз шомлану да күренде. Фонарь утын Зөфәргә терәп диярлек яктыртты. Әйтерсең, әнә шулай яктыртып, әйтелгән сүзләрнең ни дәрәҗәдә ихлас икәнлегенә ышанасы килә.

Зөфәрнең кыяфәтендә сизелер-сизелмәс кенә елмаю чагылып узды. Ләкин ул шулкадәр урынсыз булды. Һәм шул ук мизгелдә кашлары җыерылып, әрнүле-газаплы кыяфәткә әйләнде:

– Әйттем бит, ышанмыйсың, – дигән сүзләр сытылып чыкты аның теш арасыннан.

– Ә син ышанырдай нәрсәләр сөйлә. Кеше ышанмастайны дөрес булса да, сөйләмә, диләрме әле?

– Чын дөресе шул! Ышану-ышанмау – анысы синең үз эшең. Ә хәзер әйдә, кузгалыйк. Юкса... Калганын кайткач сөйләрмен.

Юкса нәрсә булачагын әйтеп бетермәде. Арттан эзәрлекләүчеләрнең куып җитүләре бар, димәкче иде, барыбер ышанмас дип, туктап калды.

– Юкса менә бу егетнең үлүе ихтимал. Күп кан югалткан... Ашамаган-эчмәгән... Хәлсезләнгән... Мин үз җаем белән әкрен генә атлармын. Ә сиңа Андрейны җилкәңә салып кайтырга туры килер, мөгаен.

– Авылга кадәр ун чакрымлап бар, булдырып булырмы?

– Мин аны шул чама үз иңнәремдә күтәреп кайттым инде. Хәзер монда кадәр кайтып җиткәч, ташлап калдырмаячакмын.

Камил фляганы Андрейның авызына якын китерде. Егет салкын су тәмен тоеп, күзләрен ачты да йотлыгып эчәргә кереште.

– Без кайда? Килеп җиттекме инде? – диде ул, еш-еш сулап. Фонарь яктысында аның газаплланудан кыйшайган йөзе күренеп алды.

– Юк, Андрей, без кайтып җитмәдек әле. Тагын бераз гына түз, ерак калмады. Әйдә, Аллага тапшырып кузгалдык, – дип, урыныннан торды да ава-түнә алга атлады Зөфәр.

Бераздан, кесә фонаре белән уңны-сулны яктырткалап баручы Камилгә:

– Ә син, дускай, фонареңны сүндер, – дип эндәште.

– Нигә? Яктыда кайту уңайлырак бит.

Ут яктысы еразлардан ук күренә, арттан эзәрлекләүчеләр булса, күреп калулары бар, дип әйтмәкче иде Зөфәр. Ләкин кире уйлап, кулын селтәде. Тагын ышанмаячак. Шуңа күрә ул:

– Батареясы бетүе бар, аннан соң иң кирәк чакта янмаса, нишләрбез?! – диюдән артыгын әйтмәде.

– Әле чыгып китәр алдыннан гына зарядкага куйган идем, – дип акланса да, Камил бусында аның белән тиз килеште. Фонарен сүндереп куйды.

Алар алга – караңгылыкка таба атладылар.

* * *

Санаторийда бергәләшеп ял итүләренә бер елга якын вакыт узгач, Геннадий Николаевичка, көтмәгәндә, Александр Левин шалтыратты. Хәл белешеп торырбыз, дип, телефон номерларын алышкан булсалар да, өйләренә кайтып, яшәү рәвеше элекке эзенә төшкәч, ничектер, бирелгән вәгъдәләр онытылган. Тормыш мәшәкатьләре, көндәлек эш-гамәлләр басып киткәч, кая инде ул, әллә кайдагы җәннәт бакчасыдай санаторийда ял итеп яткан чаклар башка кереп чыксын?! Шуңа күрә шалтыратучының кемлеген аңлауга ук, хәл-әхвәл сорашып тормастан, Геннадий Николаевич сүзен акланудан башлады:

– Саша, гафу ит, дускай, шушы көнгә кадәр сиңа бер мәртәбә дә шалтыратырга җай чыкмады. Инде безнең яшьтә дөнья мәшәкатьләреннән бераз арынып, лаеклы ял турында уйларга кирәк булса да, һаман дөнья куабыз...

Александр Васильевич аны тынычландырырга ашыкты:

– Үземдә дә шул ук хәл, Гена. Берничә мәртәбә шалтыратам дип, талпынып карасам да, кулым җитмәде. Нәкъ шулай, синең кебек, дөнья мәшәкатьләре...

Сүз хәл-әхвәл сорашуга күчте. Һәр икесе дә озаклап бер-берсенең туган-тумачасының, бала-чагасының хәлләрен җентекләп сорашты. Бергә укыган курсташларының да күргән-белгәннәрен искә төшерделәр. Телефоннан сөйләшү шул хәл-әхвәл сораштырудан артык булмас иде, кинәт Александр Левин:

– Быел да санаторийга барып, сәламәтлегеңне ныгытып кайтырга исәбең юкмы соң? – дип сорап куйды.

Сазоновның ул хакта уйлап караганы юк иде әлегә. Вакыт тиз уза. Инде бер елга якын вакыт узып та киткән ләбаса.

– Ял итәргә исәп бар барын... Арылды, бик нык ардым. Беләсеңме, Саша, мин инде санаторийга гына түгел, лаеклы ялга ук китәр идем...

– Анысы, әлбәттә, һәркемнең үз эше. Ә менә узган елгы кебек бергәләп ял итәргә каршы түгел мин. Бу хакта ныклап уйлап кара әле, Гена, – диде Левин.

Аннан соң ул кинәт кенә теманы икенчегә борып, ни өчендер Сазоновның эше хакында сораштыра башлады.

– Урман хуҗалыгында эшләр ничек анда? «Лес рубят, щепки летят»мы?..

Геннадий Николаевич, дустының нәрсәгә ишарә ясаганын шунда ук чамалады. Һаман да урманны рөхсәтсез кисү барамы, дип кызыксынуы инде. Ул, үзе дә сизмәстән, әңгәмәдәше белән янәшә торып сөйләшкәндәй, кулын селтәп куйды:

– Әй, нәрсәсен сөйләп торырга инде аның, Саша? Бер кузгатып җибәргән механизмны тиз генә туктатырмын, димә! Урманны талыйлар, дускай. Табигать байлыкларын юкка исраф итү бара. Болар барысы да кемнәрнеңдер кесәләрен калынайту хисабына!

Левин, дустының хәлен аңлагандай, бик мәгънәле генә итеп «М-да!» дип куйды. Бермәл эндәшмичә торгач:

– Кыргый хайваннарны да кыралармы? – дип, әңгәмәсен дәвам итте.

– Браконьерлардан да тынгылык юк, дускай. Киек атуны бернидән курыкмыйча, тартынусыз эшлиләр. Үз абзарларындагы малны чалалармыни?!

– Да-а-а, эшләрегез хөрти икән. Урманнарыгызда киек-җанварлар да бетеп барадыр алайса?

Сазонов дустының ни өчен урман хәлләре белән шулай кызыксынуын аңламады. Югыйсә моннан кырык еллар элек урманчылык институтында биш ел укудан башка, аның урман белән бәйләнеше дә юк кебек. Үзе әйтмешли, инде күптән икенче тармакка күчкән. Урман аның өчен нибары мүкләнеп беткән агачлар һәм кыргый карт аюлар гынадыр, дип аңлый иде Геннадий Николаевич дусты хакында. Ә ул әнә, чыннан да, урман язмышы белән ныклап кызыксынган кебек кылана.

– Хөрти! Браконьерлар азды. Киек хайваннарны кыралар гына... Алай да...

Әйтеп бетерелмәгән соңгы сүзе Левинны ни өчендер сагайтты. Ул дустының сөйләп бетерүен көтеп бераз торгач, тагын соравын бирергә ашыкты:

– Алай да, дидең дә туктап калдың. Нәрсә әйтмәкче идең? Әйдә, сөйлә, Геннадий Николаевич. Берәр искитәрлек хәл бармы әллә?

Сазонов, әйтергәме-юкмы, дигәндәй, бераз икеләнеп торды.

– Искитәрлек дип... Синдәй урман проблемаларыннан ерак торган кешегә ул кызык та тоелмас, бәлки. Алай да әйтим әле. Соңгы вакытта бер-ике мәртәбә аңлатып булмаслык гаҗәп хәлләр ишеттем.

– Йә, йә, – дип ашыктырды Левин.

Аның ни өчен шулай сабырсызлануын Сазонов аңлап та бетермәде. Нәрсә-нәрсә, ә менә башы-аягы белән фән өлкәсенә кереп чумган бу гыйлем иясен ул уйлаган проблемалар бөтенләй кызыксындырырга тиеш түгел иде кебек.

– Ничек дип әйтергә?.. Соңгы вакытта инде күптән «Кызыл китап»ка кертелгән хайваннарны күпләп күргән егерьлар булгалаган. Алар бернидән курыкмыйча, зур төркемнәр белән йөриләр икән...

– Шуннан, – дип, кинәт кенә сөйләвеннән туктап калган Сазоновны ашыктырды Левин.

– Шуннан – шул... Бер яктан браконьерлар кыргый хайваннарны кыра, ә икенче яктан, инде әллә кайчан «Кызыл китап»ка кертелгән хайваннарның саны арта. Ниндидер капма-каршылык килеп чыга түгелме? Парадокс. Бу гаҗәп түгелмени?

– Әйе-е-е, – дип сузды Левин, бик мәгънәле генә итеп. – Ә син үзең моңа нинди аңлатма бирер идең?

Сазонов тагын тынып калды. Аның бу хакта ныклап уйланганы да булмады. Кемнәрдәндер ишетелгән сүзләрне, бик әһәмият бирмичә, колак читеннән уздырган чаклары да бар. Рәсми мәгълүмат булмаганда, һәрнәрсәгә ышанып бетеп тә булмый бу заманда. Шуңа күрә ул дустының соравына туры җавап бирде:

– Колакка кергән һәр сүзгә ышанып, кайсы ялган, кайсы чын икәнен төгәл белмичә, нәтиҗәләр ясарга ашыкмыйм мин, дускай. Бу имеш-мимешләрнең ни дәрәҗәдә дөрес икәнлеген зоологлар өйрәнсен әнә. Минем төп эшем хуҗалык итүгә һәм урман байлыкларын саклауга бәйле...

– Анысы шулай инде, – дип килеште Геннадий Николаевичның сүзләре белән Левин. – Алай да, бергәләшеп ял итү турында уйла әле. Узган ел ялыбызны бик күңелле уздырган идек бит, – дип өстәде дә бик дустанә саубуллашып, элемтәне өзде...

Телефон аша булган әңгәмәдән соң, хис-кичерешләре бераз басылгач, Сазонов үзалдына елмаеп куйды. Карале бу Сашаны, санаторийда очрашкан вакыттан соң бөтенләй үзгә фикер йөртә башлаган түгелме? Хәтта урман проблемаларын күңеленә якын алып, сораулар биреп маташты. Ә үзе әле

кайчан гына: «Мин бөтенләй икенче тармакта эшлим... син эшләгән урман тармагына тыкшына алмыйм. Гафу ит, дускай...» – дип сөйләнгән иде. Элекке курсташының күңелендәге әнә шул үзгәрешләргә бераз гына сәерсенсә дә, үзенең борчуларына аның да битараф булмавы, сүзләр белән генә булса да, ярдәм итәргә теләве күңеленең бер өлешендә шатлану хисләре дә тудырды.

* * *

Зөфәр, Камил һәм Андрей авылга таң алдыннан гына кайтып керделәр. Бу вакытта Күчкән Сала кешеләре йоклый иде әле. Тирә-якта урман шавыннан башка бер тавыш та ишетелми, дияр идең, ара-тирә этләр өреп куя...

Камил башта Зөфәр белән Андрейны медпунктка илтмәкче булган иде. Ләкин уеннан кире кайтты. Бу вакытта кем булсын анда?! Шуңа күрә үзе яшәгән йортны узып, Зөфәрләр ишеген шакыдылар. Тавышка төне буе керфек тә какмаган Нәҗия йөгереп чыкты.

Ишекне ачып җибәрүгә, каршысында сакал-мыек баскан, йөзе тартылып, сулып калган, бик хәлсезләнгән Зөфәрне һәм канга баткан кеше гәүдәсен иңнәренә күтәргән Камилне күргәч, бик гаҗәпләнде. Зөфәрнең күкрәгенә ташланды да иңрәп елый башлады:

– Уйлаган идем аны ниндидер күңелсезлек килеп чыккандыр дип, күңелем дөрес сизгән икән. Ниләр генә булды? – дип сөйләнде.

– Барысы да тәртиптә, Нәҗиякәй. Менә күреп торасың, исән-сау кайтып җиттем.

– Кыяфәтеңнең карарлыгы калмаган бит. Ни булды? Камил, син әйт, ичмасам? – дип ирләрнең әле берсенә, әле икенчесенә ялварулы караш ташлады ул.

– Йә, тынычлан, сөеклем. Минем белән барысы да тәртиптә. Бераз ял итеп алсам, барысы да җайланыр. Тик менә бу егетнең хәле начаррак. Аны сәкегә илтеп салыйк әле, – дип сөйләнә-сөйләнә, Камилгә Андрейны сәкедәге түшәк өстенә салырга ярдәм итте.

Камил фельдшер Светлананы чакырырга чыгып йөгерде. «Берочтан авыл башлыгы Харрас Зариповичка да сугылырсың. Монда, безгә килсен», – дип артыннан кычкырды Зөфәр...

Чирек сәгатьтән аз гына артыграк вакыт узгандыр, ашыгыч медицина ярдәме сумкасын асып, йокылы-уяулы Светлана килеп җитте. Ул нәрсә булганын сораштыра-сораштыра, Андрейның яраларын карый башлады. Зөфәр аңа барысын да җентекләп сөйләмәде. Үзенең башыннан үткәннәрне ул бөтенләй искә төшермәде. Бары тик Андрейның яралануы һәм якынча күпме вакыт элек аңын югалтуы турындагы сорауларга коры гына җавап бирде. Озак та узмады, Харрасны ияртеп, Камил килеп керде.

– Йә, күрик геройларны. Ни булганын сорашыйк, – дип сөйләнде авыл башлыгы керә-керешкә.

Ә үзе Зөфәр ягына, ничектер, сәерсенгән кебек сынап карый. Камил юлда килгәндә сөйләргә өлгергән инде моңа. «Алышынмадымы икән», дигән шик тә белдергәндер әле.

– Харрас абый, минем синең белән сөйләшәсем бар...

– Соң, әйдә, сөйлә. Тыңлыйм. Кара төндә кубарылып, кәмит карау өчен түгел, сүзләреңне тыңлау өчен килдем дә инде монда.

Зөфәр тирә-яктагыларга күз төшереп алды:

– Мин бары тик үзеңә генә сөйләргә телим.

– Монда барыбыз да үз кешеләр. Берсеннән дә яшерен серем юк, – дип, ни өчен үзенә генә сөйләргә теләгәнен аңламыйча, иңнәрен сикерткәләде Харрас.

– Вакыт бик аз, Харрас абый. Әлегә синең белән аңлаша алсак, шул җитәр. Әйдә, кунак бүлмәсенә узыйк әле, – диде дә Харрасны култыклап, күрше бүлмәгә алып кереп китте.

Өстәл артына урнашкач, Нәҗия алар алдына кайнар чәй кертеп куйды. Ә үзенең һаман Зөфәреннән аерыласы килми иде. Аны артыннан гына кочаклап алып, чәчләреннән үпте. Күзләре сөекле иренә яратып та, шул ук вакытта кызганып та карый. Яңагындагы кечкенә генә ярага укмашып каткан канын кулы белән сыпыргалый. Әйтерсең, әнә шулай иренең хәлен җиңеләйтмәкче була. Тик Зөфәрнең генә анда кайгысы юк кебек. Тизрәк башыннан үткән хәлләрне бәйнә-бәйнә Харраска сөйләп бирәсе килә. Шуңа күрә Нәҗиясен читкәрәк тибәрде:

– Бар әле, чыгып тор әле, җаным. Харрас абый белән сөйләшәсе сүзебез бар, – диде ул, хатынына мөмкин кадәр җылырак мөнәсәбәт күрсәтергә тырышып.

– Сөйләшегез, мин сезгә комачауламыйм бит. Сине кочаклап, менә шулай тыныч кына басып торырмын, бәгърем. Юкса бик сагындым...

– Нәҗия, аңла мине, кайчак ирләрнең хатын-кызлардан башка гына сөйләшер сүзләре була. Зинһар өчен, унбиш-егерме минутка гына чыгып торчы. Йоклап алсаң да була. Әле таң атмаган. Инде йоклый алмыйсың икән, ашарга әзерли тор...

Нәҗия – акыллы хатын. Нәкъ менә шушы вакытта ирен никадәр генә ташлап чыгып китәсе килмәсә дә, ир хакын өстен куеп, аның сүзен аяк астына салып таптамады. Әкрен генә атлап, ишеккә юнәлде. Аның артыннан ишек ябылуга, Харрас телгә килде:

– Йә, алайса тыңлап карыйк, нинди хәлгә тарыдың?

– Сиңа – ялган, миңа – чын, дигәндәй, Харрас абый, мин кеше ышанмастай гаҗәп хәлләргә юлыктым бит әле. Ничек кенә сөйләсәм дә, ышанмассың кебек...

Харрас сынаулы караш белән әңгәмәдәшенә текәлде. Зөфәрне бала чагыннан бирле белә ул. Күз алдында үсте, ир-егет булып өлгереп җитте. Эшен яратып, җиренә җиткереп башкаручы бу егетне авылдашлары да хөрмәт итә. Аек акыллы, туры сүзле, төпле фикерле, гадел кеше буларак беләләр аны. Һәм менә шушы кеше нииндидер аяныч хәлгә тарыган.

– Сөйлә. Сүзләрең хак булса, ышанырмын. Мин яшь кеше түгел. Үз гомеремдә яхшысын да, яманын да күп күрергә туры килде. Аңларга тырышырмын.

– Ярый, әйтәм алайса... Тик син мине акылга җиңеләйгән икән бу, дип, нәтиҗә ясарга ашыкма. Харрас абый... мин немец фашистлары әсирлегеннән качтым. Дөресрәге, Андрей исемле икенче бер әсир белән бергәләп качтык...

Әлеге сүзләрдән Харрасның кашлары сикереп өскә күтәрелде. Күзләре зурайды. Авызы ачылган көе калды. Ул Зөфәрнең күзләренә озаклап текәлеп карап торды. Ике арада туган киеренкелекне йомшарту өчен, өстәлдәге чәйгә калак тыгып, аны шикәр салмаган көе генә озаклап болгатты. Бераздан үзен кулга алып өлгерде булса кирәк, өзек-өзек сүзләр белән сөйләп китте:

– Зөфәр туган, аңлыйм... син аргансың. Еллар буе... көне-төне ялсыз эшләү... үзен сиздерә. Әйе, әйе, депрессия шуннан килә дә инде. Аның ише вакытта... э-э-э галлюцинациясе дә... хәтер ялгышулары да була. Тик бу халәттән чыгарга мөмкин. Ныклы ял кирәк сиңа...

Зөфәр утырган көе тезләренә шапылдатып сугып алды. Аның кыяфәте үртәлгән сабыйныкына охшап калды.

– Харрас абый, син мине «ычкынган» дип исәплисең, җүләргә саныйсың бугай?..

Авыл башлыгы аны тынычландырырга ашыкты:

– Сине беркем дә җүләргә исәпләргә җыенмый. Ә менә ял мәсьәләсендә... Гел эшләргә генә димәгән, анысы да кирәк, энекәш. Беребез дә эш аты түгел лә.

Аның күзләре Зөфәргә кызганып карыйлар иде. Шул кыяфәтен күреп, Зөфәр башын куллары белән кочаклап, карашын түбән төшерде.

Шулчак кунак бүлмәсенең ишеге ачылып китте дә анда Нажиянең башы күренде:

– Егетегез саташа башлады. Тыпырчына, нәрсәләрдер кычкырып, торырга азаплана, аңа Светлана белән Камилнең генә көче җитми. Чыгып булышыгызчы, – диде ул, сулышы кабып.

Зөфәр белән Харрас дәррәү урыннарыннан торып, алгы бүлмәгә ташландылар. Чыннан да, Андрей кулларын бутый-бутый: «Гранатаңны томыр! Юкса танк изеп китә!» – дип акыра. Тынычландырырга теләп, кулларыннан тотарга маташкан Светлананы «очыртып» кына җибәрә, Камилгә тибәргә азаплана.

Зөфәр белән Харис та килеп кулларыннан тоткач, Светлана яралыга тынычландыру өчен укол ясады. Андрей тынып калды: йокладымы, аңын югалттымы, белмәссең.

Кабат кунак бүлмәсенә кереп тормадылар. Зөфәр барысы каршында да үзенең башыннан үткәннәрне энәсеннән җебенә кадәр сөйләп бирде. Аның хикәяте тыңлаучыларда Бөек Ватан сугышы турында тарихи кино эчтәлеген хәтерләтте. Һәр сүзен игътибар белән тыңласалар да, аларның күзләрендә ышанмау ярылып ята иде. Сөйләп бетергәч, Зөфәр нидер көткәндәй, карашы белән һәрберсенең йөзен күзәтте.

– Анысы шулаен шулай да... Тик кайсы заманда яшәгәнебезне онытмаска кирәк. Сугыш беткәнгә йөз елга якын вакыт узды. Каян килсен соң монда – безнең тайгага немец-фашистлары?.. Сугыш вакытында исән калган булсалар да, инде әллә кайчан үлеп беткән булырлар иде... Юк, Зөфәр, сөйләгән хикәятең ничек кенә матур булмасын, ышана алмыйм, – дип үз фикерен белдерде Харрас.

Бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Бары тик ара-тирә Андрейның ыңгырашкан тавышы гына ишетелеп куя иде.

– Монда инде бер генә фараз кала, боларның барысы да синең күзеңә генә күренгән, – дип кабат сүз башлаган Харрасны Зөфәрнең тавышы бүлде:

– Минем тәндәге менә бу яралар да, хәзер ыңгырашып каршыгызда ятучы Андрей да – барысы да күзгә күренә, димәк, – дип һаман да ныграк үртәлде аның сүзләреннән Зөфәр.

– Алайса, ул фашистлар киемендәге кешеләр артистлар булгандыр. Хәзер сугыш турындагы киноларны еш төшерәләр бит. Кино төшереп йөрүләредер?

– Үзем дә башта шулай уйлаган идем. Тик беләсезме, аларның автоматлары чын патроннар белән корылган. Беркем дә артистларга чын корал тоттырмас, – дип, дулкынланудан йодрыклары белән өстәлне төеп алды Зөфәр.

– Ә каян беләсең чын корал икәнен?

– Алар минем күз алдында этемне атып үтерделәр. Аккүзнең пулялар теткәләп бетергән гәүдәсе «Ерак привал»дагы аланда ята. Ышанасызмы? Минем үземне берничә мәртәбә тукмап ташладылар. Андрейны әнә, канга батырып, нинди хәлгә китергәннәр. Артистлар шулай эшлиме?..

Кабат тынлык. Һәм шул тынлыкны ярып, Андрейның кинәт кенә:

– Атакага кузга-а-а-ал!.. – дигән саташулы тавышы яңгырады.

Калтыранып тартышкан кулларына килеп ябышкан Светлана аны көч-хәл белән генә тотып тора иде.

Андрейның ул халәте озакка бармады, кабат тирән йокыга талды.

– Бәлки, син үткән заманнарга күчкәнсеңдер? – дип әңгәмәгә кушылды Светлана. – Минем кайдадыр вакыт буенча сәяхәт ясаучылар хакында укыганым бар иде. Әгәр син...

Зөфәр аның сүзләрен бүлде.

– Минем үземдә дә шундый уй булып алды. Бу хакта минем дә укыганым бар. Фашистларда әсирлектә ятканда, төне буе уйлап чыктым. Һәм бердәнбер шундый фикергә килдем. Мин узган заманнарга, сугыш вакытына кайтмадыммы икән, дип уйладым. Шуңа күрә әсирлектән качып киткәч, Күчкән Салага кайтып, сезне күрә алуыма шикләндем дә. Әгәр мин, чыннан да, үткән заманнарга күчкәнмен икән, сугыш чорында яшәгән бабайларны гына күрергә тиеш идем. Инде кайтып сезне күргәч, узган заманнарга күчкәнмен, дигән уйларым бөтенләй нигезсез икәнен аңладым. Мин үзем яши торган заманда.

Тагын авыр тынлык урнашты. Бу хәлдә башлап сүз әйтергә берсе дә базмады. Бераздан Светлана, әгәр Зөфәр узган заманнарга күчмәгән икән, димәк, немецларның безнең заманга күчкән булулары ихтимал, дигән сүзләр әйтте.

Йорттагылар барысы да кинәт кенә аның ягына борылды...

* * *

Карательләр ротасының «Ерак привал»дагы аланнан кузгалып киткәннәренә бер тәүлектән артык вакыт узды. Көн яктысында алар бертуктаусыз хәрәкәттә булдылар. Дөрес, төнлә белән тукталырга туры килде. Гауптштурмфюрер Мартин, төн караңгылыгыннан файдаланып, партизаннар һөҗүм итәрләр дә үзләрен кырып салырлар, дип курыкты. Тирә-якка икеләтелгән сак куеп, төнне вакытлыча оештырылган привалда үткәрделәр. Солдатлар тамак ялгап алды, үзләрен тәртипкә китерде. Юкса көне буе ботаклы чытырманнан барып, кыяфәтләренә карарлык түгел! Тамакларына да аяк өсте капкалаган «сухой паек»тан башка ризык кергәне юк...

Иртән кабат кузгалдылар. Мартинны иң гаҗәпләндергәне шул булды: хәзер дистәләгән чакрым ара узып, ник бер партизан отряды очрасын! Хәтта сыңар мылтык аткан тавыш та ишетелмәде. «Марш бросок»ның башында партизаннар засадасына тап булмыйк, дип шикләнеп кенә атлаган солдатлар да бу хәлдән, ничектер туарылып калдылар, иркенәйделәр. Вакыт-вакыт кычкырып сөйләшкән, хәтта көлгән тавышлар ишетелеп куя. Андый чакларда Мартин «гаепле»не тиз генә табып, зәһәр сүзләр белән сүгеп ташлый.

Соңгы сәгатьләрдә гауптштурмфюрер планшетындагы картага ешрак күз сала башлады. Нәрсәнедер үлчәп, чамалап карый. Компасны алып, юнәлешне билгели. Хәтта агачларның очлары арасыннан агарып күренеп торган күккә дә күз салгалый...

Тагын бер кечне привалда уздырганнан соң, иртән кузгалып, ике-өч сәгать баргач, Мартин унтер-офицерларны – взвод командирларын җыеп, алга таба аеруча сак барырга кирәклеге турында кисәтте. «Картада билгеләнгән партизан отряды урнашкан урынга җитәргә ерак калмады. Засада булырга мөмкин», – диде ул, үзенең шикләрен акларга теләгәндәй.

Ә бераз баргач, бөтен рота белән сизмәстән партизаннар засадасына килеп чыкмас өчен, алдан разведка җибәрергә, дигән карарга килде. Обершарффюрер

Шульц командалыгында «гаепләрен каннары белән юарга» тиешле дүрт солдатны билгеләп, алдан җибәрде. Кире кайтканда, аймыл булмас өчен агачларга тамга салып барырга кушты. Үзләре дә тукталып тормадылар, шул тамгаларга карап, алга баруларын дәвам иттеләр.

Тагын ике сәгатьләп вакыт уздымы-юкмы, разведчиклар әйләнеп тә кайтты. Шульц гауптштурмфюрер каршына килеп, кабаланудан һәм дулкынланудан сулышы кабып рапорт бирде:

– Гер гауптштурмфюрер, партизаннар лагерена кадәр сиздермичә генә барып җиттек. Биш йөз метрлап кала, яхшылап күзәттек!

– Gut, gut[10], – диде Мартин, аның сүзләрен хуплап.

Командирының күзләрендә мәрхәмәт чаткылары күргәч, аның алдагы көннәрдә үзен «утлы таба»га бастыруын бөтенләй оныткан Шульц рапортын дәвам итте:

– Күзәтүләрдән күренгәнчә, лагерь бик зур мәйданны биләп тора. Лагерь булудан бигрәк, ул кешеләр яши торган торак пунктны хәтерләтә. Йортлар төзек, сугыштан зыян күргән, шартлаган, янган урыннар күренми. Шулардан чыгып, мин анда русларның регуляр частьлары яшеренеп ятмыймы икән, дип тә уйлыйм. Дөрес, без күпме генә күзәтсәк тә, беркемне дә күрмәдек. Партизаннар бик нык яшеренгән булырга тиеш...

Гауптштурмфюрер, әйтелгәннәрдән канәгать калуын белдереп, тагын бер мәртәбә «гут», дип кабатлады. Хәтта Шульцның иңнәреннән җиңелчә генә кагып та алды. Һәм алга таба үзенең әмерен көтеп торучы гаскәриләр ягына борылып, оберштурмфюрер Ганска хәзер үк унтер-офицерларны янына җыярга кушты.

Мартинның акылы холкы кебек үк пырдымсыз, кисәк үзгәрүчән һәм кайвакыт көтелмәгән нәтиҗәләр ясаучан. Ул алдан озаклап уйлап, планнар корып тормый. Киресенчә, аның башына иң акыллы уйлар хәрәкәт вакытында килүчән. Нәкъ менә шул вакытта аның баш миендәге «шөреп»ләре тизрәк эшли башлый. Хәер, яртысы «уголовник»лар арасыннан сайлап җыелган башкисәрләрдән торган эсэсчылар ротасы белән командалык итү өчен болар – иң кулай сыйфат.

Бусында да ул үзенең холкына хилафлык китермәде. Чытырманлык арасында булуга карамастан, мөмкин кадәр тигезрәк тезелергә тырышып, каршысына килеп баскан унтер-офицерларга кискен әмерләр яудыра башлады. Һәр әйткән сүзе аны ныграк рухландыра бара иде:

– Партизаннар лагерена ике яктан һөҗүм итәчәкбез. Шуңа күрә оберштурмфюрер Ганс командалыгындагы бер төркем лагерьны читтән әйләнеп узып, төньяк тарафка күчә. Мин монда төп көчләр белән калам. Башта миномётлардан ут ачып, партизаннарны утлы табада биетәчәкбез. Аннан соң, иң беренче Ганс командасы һөҗүмгә күчә. Чөнки качкын әсирләр кайтып кисәткәнлектән, партизаннар безне бу як юнәлештә көтәләрдер, дип уйлыйм. Ә без көтелмәгән яктан һөҗүм итеп, миномёт утыннан соң болай да башлары әйләнгән партизаннар арасында паника тудырачакбыз һәм «пиф-паф» кырып салачакбыз. Һөҗүмне, Ганс төркеме, мин ракета чөйгәннән соң башлаячак.

Үз сүзләреннән Мартин шулкадәр әсәрләнгән иде ки, әйткәннәре канлы бәрелешнең үзе кебек тәэсир итте аңа. Соңгы сүзләрен әйткәндә инде, сугыш булып узган һәм үзен анда җиңеп чыккан кебек иде. Тыелгысыз эчке ярсынудан сулышы капты. Ул, күңелендә баш калкыткан кыргый инстинкттан куркыныч төскә кергән йөзен як-якка боргалап, каршысына басып үрә каткан, үзенә буйсынган хәрбиләрне бер кат күздән кичерде. Аннан уң кулын югары күтәреп, гырылдавык тавыш белән: «Хайл!» дип кычкырды...

[10] Яхшы, яхшы *(нем.)*

* * *

Сазонов санаторийда быел да икәүләп ял итү турында Левинга биргән вәгъдәсен онытмады. Элекке курсташ дусты кайчан барасын әйтеп шалтыраткач, үзе дә бу хакта колагына киртләп куйды. Урман хуҗалыгы белгечләренең киңәйтелгән утырышына баргач, үзенең турыдан-туры җитәкчесенә, сәламәтлеген ныгытып алу өчен санаторийга барып кайтырга теләвен әйтте. Алдагы елда ял иткәненең бик ошаганлыгын һәм быел да шунда ял итәргә теләге барлыгын да искәртергә онытмады.

– Ярый, бу хакта уйлармын. Сиңа кайсы вакытларга кирәк? – дип сорады чиновник.

Сазонов үзенә ял итәргә уңайлы вакытны әйтеп биргәч, «кәҗәләнеп» маташмады:

– Үзең теләгән вакытка юлламасын юнәтербез. Ял ит, көч җый. Синең безгә сәламәт булуың кирәк, – дип, теләктәшлек тә белдерде хәтта.

Чыннан да, билгеләнгән вакытта юллама Сазоновның кулында иде...

Һәм менә алар Левин белән санаторийда. Ашыйлар-эчәләр, кирәкле процедураларга йөриләр, спорт белән шөгыльләнәләр, табигать кочагына чыгалар – кыскасы, вакытның һәр мизгелен файдалы үткәрәләр. Шул ук вакытта узган студент елларын искә төшерергә, төрле темаларга үзара әңгәмә корырга, озакка сузмыйча гына бәхәсләшеп тә алырга, илдәге сәясәткә азрак ризасызлык белдерергә, яшьләрнең эшкә карата мөнәсәбәтләреннән бераз зарланып, «эчләрен бушатырга» да вакыт табалар. Болары процедуралар вакытында яки тренажёрларда шөгыльләнгәндә, үзеннән-үзе башлана.

Менә бүген дә махсус түгәрәк ванна эчендә, кирәкле матдәләр белән баетылган су эремәсендә гидромассаж процедурасы алып яталар. Астан кислород агымын кудырып, суны һава белән баетучы аэратор быгырдап эшләп тора. Су кайнавын хәтерләтүче әлеге процесста, файдалы газлар белән баетылган җылымса суның тәнгә килеп бәрелүе әйтеп бетермәслек рәхәтлек бирә. Гәүдә авырлыгы тоелмас дәрәҗәдә җиңеләеп кала, су агымы ритмына бирелеп чайкала. Күңел әнә шул халәттән ләззәтле мизгелләр кичерә, зур канәгатьлек ала...

Мондый вакытларда дөнья мәшәкатьләрен бөтенләй онытып, бары тик илаһи нәрсәләр турында гына уйларга кирәк сыман. Юк, Левинның теле тик тора алмый. Ул Сазоновның касыгына кулы белән җиңелчә генә төртеп ала да:

– Саша, синең кебек урманга берекән карт аюга монда бераз гына уңайсызрактыр, әйеме? – дип әйтеп куя.

Бу сүзләргә Сазоновның тырнак очы кадәр дә үпкәләмәвен яхшы белә ич ул. Әлбәттә, үпкәләми. Шаярып әйтелгән ярым төртмәле сүзләрне ишеткәч, Геннадий Николаевич процедура бүлмәсен яңгыратып, тыела алмыйча көлде генә. Аның тавышына хәтта, күрше бүлмәнең ишеге ачылып, шәфкать туташының башы күренде. Ул, бу ике карт хөрәсәнгә тагын нәрсә җитми икән инде дигәндәй, сөрмәле матур күзләрен зур ачып, гаҗәпләнеп карап торды да тавышның нәрсәдәр җитмәгәннән түгел, ә «рәхәткә чыдый алмаганнан» икәнен аңлап, ишекне кире япты.

– Хак сүзләр сөйлисең, дускай. Сезнең цивилизацияле дөньяда, мин, чыннан да, үземне азрак уңайсыз хис итәм. Сезнең бит барысы да ясалма. Әнә, стенаның буеннан буена ясалган табигать күренеше – фотопейзаж. Теге пластик чыршы янәшәсендә баласы белән басып торучы болан пыяладан коелган. Әледән-әле колакка ишетелеп куйган кошлар тавышы да чын түгел

– аудиоязма гына, менә без чумылып ятучы шушы су да, нindidер химик матдәләр кушып ясалган сыеклык, аның быгыр-быгыр тавышы да табигый чишмә челтерәвен алыштыра алмый...

Геннадий Николаевич тагын нәрсәләрдер әйтмәкче иде, Левин аны бүлде:

– Сүз дә юк, мондагы ясалма эффектларны син яшәгән табигый тирәлек белән чагыштырырлык түгел. Ләкин һәркемнең дә табигать белән тыгыз элемтәдә яшәргә мөмкинлеге юк. Цивилизация! Фән-техника алгарышы! Кеше табигатьтән читләшә. Хәзерге мәгълүмат агымының тискәре йогынтысыннан котылу, нерв киеренкелеген йомшарту өчен шул ук фәнни алгарыш нәтиҗәсендә барлыкка китерелгән ясалма эффектлардан файдаланабыз. Релаксация, ягъни тәнебезне тирән йомшарту бәрабәренә аңыбызны тынычландыруга ирешү, тискәре эмоцияләрдән котылу...

Фәлсәфәгә бирелгән Левин, никадәр генә ышандырырлык итеп теленә салынмасын, Сазонов өчен болар, акыллы кеше башы белән уйлап, ясалма барлыкка китерелгән цивилизация дип аталучы, тыштан ялтырый, эчтән калтырый торган җәмгыятьне аклау өчен, фәнни сүзләр белән матурлап әйтелгән коры сүзләр генә. Ә чынлыкта...

– Сүз сөрешеңне күңелем белән аңларга тырышсам да, миндә каршылыклы фикерләр туа. Башта табигатьне юк итеп, аннан соң шуны ук кеше акылы белән уйлап табылган ясалма эффектлар белән алыштыру нигә кирәк? Алар никадәр генә камил булмасын, беркайчан да оригинал белән тулы охшашлык булмаячак.

– Әйе, синең белән килешәм. Кешелек үзе утырган ботакка балта белән чаба. Тик фән-техникада алгарышны туктатып булмый. Цивилизация киңәйгән саен, табигатьне кысрыклый. Һәм бу котылгысыз. Беләсеңме, ко-тыл-гы-сыз!

Сазонов, кулы белән өстәл сөрткәндәй хәрәкәт ясап, су өстенә җыелган эреле-ваклы һава куыкларын читкә сыпыргандай итте. Аяклары белән этелеп, гәүдәсен күтәрә төште дә Левин ягына ныграк борылды:

– Ә ни өчен котылгысыз? Битараф булганга шундый хәлгә төшердек табигатьне. Ярар, без – караңгы халык. Цивилизациядән читтә. Ә менә сез, фән эшлеклеләре, галим-голәмалар табигатьне саклауда нәрсә дә булса эшлисезме? – дип дәвам итте әңгәмәсен Геннадий Николаевич.

Левин сорауга җавап бирергә теләп, авызын ачты да кире уйлады. Эндәшми калырга булды.

– Әйдәгез, кешелекнең акыллы катлавы буларак, бу хәлдән чыгу юлларын тәкъдим итегез. Әгәр табигый су чыганакларын саклый алсак, кадерен белсәк, менә шушы чуен ванна эчендә кысылып, быкырдап ятмас идек, – диде Геннадий Николаевич, дулкынлануын яшермичә.

– Кызма әле, Геннадий Николаевич. Кем әйтте сиңа галим-голәмалар берни дә эшләми дип? Көчтән килгән кадәр тырышабыз. Әле менә синең белән беренче очрашканда, урманда хайваннарны кыралар, дигәнеңә бик борчылып йөрим. Ә беләсеңме, дускай, шул көннәрдә минем күңелгә бик акыллы гына уй килде. Һәм мин аны тормышка да ашыра башладым. Әгәр шул экспериментлар уңай нәтиҗә бирсә, без сине борчыган нәрсәләрне хәл итә алачакбыз. Ул вакытта син фән әһелләреннән зарланудан туктарсың.

Сазонов әңгәмәдәшенең тел төбен аңларга теләгәндәй, күзләренә сынап карады:

– Йә, сайра, башыңа тагын нинди этлек килде? Сез акыл ияләрен мин бик яхшы беләм, берәр эшкә тотынсагыз, мөгез чыгармыйча туктамыйсыз...

– Мөгез дә чыгаргалыйбыз, анысы – хак. Чөнки без алдан әйдәп баручылар.

Без дөреслекне ялгышулар аша табабыз. Әлегә нәрсәләр майтарганыбызны сөйләп тормыйм. Зур эшләр майтардык, дускай. Нәтиҗәсе көттермәс, тиздән күзгә күренер...

Әнә шундый күтәренке рухта тәмамлады Левин сүзләрен. Ул арада шәфкать туташы кереп, процедураның төгәлләнүе турында белдерде.

* * *

Зөфәр үзе сөйләгәннәрнең дөреслеген расларга тырышып, нинди генә дәлилләр китермәсен, комнан аркан ишкән кебек кенә булды, Харрас аңа барыбер ышанмады. Дөрес, нindидер гадәттән тыш хәл кичерергә туры килгән, психикасындагы тайпылышларга шул сәбәп булган, дигән шик калды анда. Тирә-яктагыларның, бигрәк тә фельдшер Светлананың Зөфәрне яклап, вакыт аша күчү турында фантастик фаразлар китерүен дә Харрасның күңеле кабул итмәде. Һәрнәрсәгә скептикларча караучы өлкән кеше, җитәкче андый гайре табигый хәлләргә ышана алмый шул...

Берничә сәгатьтән Андрей аңына килде. Аңа комачауламас өчен башкалар кунак бүлмәсенә кереп киттеләр. Бары тик Светлана гына гел аның тирәсендә кайнаша, дару эчертә, уколлар кадый, яраларын сөртеп, кат-кат бәйли. Вакыт-вакыт сөйләшеп тә алалар. Чөнки Андрейның ятасы килми. Ул әледән-әле «отряд командиры» белән тизрәк очраштыруларын сорый. Зөфәр кая соң, ди.

– Сезнең хәлдә торырга ярамый, бераз ныгырга кирәк, – дип, Светлана аны тынычландырырга тырыша.

Андрей аның белән килешкән кебек булса да, бер минут үтүгә, тагын «отряд командиры»н таптыра башлый. Ниһаять, соравын канәгатьләндереп, Харрасны ул яткан алгы якка керттеләр. «Партизан отряды командиры Камалов» ролен башкарырга тиешлеге турында кат-кат кисәтелгән Харрас Андрей яткан агач сәке янындагы урындыкка килеп утырды. Зөфәр белән Камил аның янәшәсенә бастылар.

– Мин – отряд командиры Камалов, – диде Харрас, уйдырма вазифасыннан оялгандай, аның йөзе бераз алсуланды. – Харрас Зарипович булам, – дип тә өстәде бераз карлыккан тавыш белән.

Ләкин Андрейның хәле аның кыяфәтендәге вак-төякләргә игътибар итәрлек түгел иде.

– Мин партизаннар отряды комиссары капитан Захаров, – диде ул хәлсез кулын Харраска сузып.

Бер-берсенә карашып, бераз торгач, «җирле отряд командиры» буларак, үзе сүз башларга тиешлеген уйлап, Харрас:

– Танышуыма бик шатмын, – диде.

– Шатланырга сәбәп юк, иптәш... э-э-э, гафу итегез, сезнең хәрби дәрәҗәгез нинди? – дип туктап калды Андрей.

Харрас хәрби кеше түгел. Моннан кырык еллар элек армиядән өлкән сержант дәрәҗәсендә кайткан иде. Тик сержант отряд командиры булу өчен кечкенә дәрәҗә түгелме икән, дип шикләнде ул:

– Өлкән лейтенант мин, – диде дә астан гына тирә-яктагыларга күз ташлады. Зөфәрнең дәрәҗәне азсынган кебек карап торуын күргәч: – Капитан дәрәҗәсенә боерык булган иде, погоннар алмыйча калдым, чолганышка эләктек, аннан партизанлыкта. – Харрас, әй, нәрсәсен сөйләп торырга инде аның дигәндәй, кулын селтәп, читкә карады. Шулай булмый хәле дә юк, аннан да артыгын барыбер әйтә алмас иде.

Зөфәр җиңелчә генә тамагын кыргалады. Харрас аның бу гамәлен, үзенең оста итеп алдашуын хуплау, дип кабул итте.

– Аңлыйм, иптәш капитан. Димәк, дәрәҗәләребез бер үк икән, – диде Андрей. – Зөфәр сезгә хәлне аңлаткандыр инде. Чыннан да, эшләр шәптән түгел. Бу тирәдәге урманнарны партизаннардан чистарту өчен фашистлар баштанаяк коралланган бер эсэс ротасы җибәргән. Минем отряд көнчыгышка, урман эченәрәк чигенде. Без аларны фашистлар эзәрлекләвеннән каплап тордык. Шактый фашистны кырдык. Барыбыз да диярлек үлеп бетте. Кулга эләккән авыр яралыларны фашистлар атты. Мине калдырдылар. Хәзер минем исәп буенча карательләр отрядында йөз илле тирәсе фриц калган булырга тиеш. Ләкин алар яхшы коралланган. Солдатларының күбесендә автомат. Миномётлары бар. Һәм сезнең өчен иң аянычы: алар хәзер сезнең юнәлештә хәрәкәт итәдер, дип шикләнәм. Чөнки Зөфәр планшетындагы карта алар кулына төшкән. Аның буенча сезне эзләп табу кыен булмаячак. Сез инде карательләрне каршылау өчен чаралар күргәнсездер, – дип сүзен тәмамлады ул.

Харрас ык-мык итте: «Әйе, күрдек. Әзерләнгәндәй иттек инде шунда», – диюдән башканы әйтә алмады. Хәер, нәрсә дисен? «Башны бутап йөрисез шунда. Әле монда Зөфәр сөйләгәннәргә ышанып җитмим, өстәп син булмастай әкият сөйләп баш катырасың», дисенме?..

– Харрас Зарипович, отрядыгызда ничәләп кеше?

Харрас нәрсә дип әйтергә белмәде. Алдан уйланылмаган. Зөфәр дә мондый сорауның булуы турында кисәтмәгән иде. Шуңа күрә Харрас бераз уңайсыз хәлдә калды. Авылда егермеләп хуҗалык. Барлыгы сиксәнләп кеше яши. Аларның яртысыннан артыгы – хатын-кызлар һәм берничә бала-чага. Күбесе – пенсионер. Шуларны уйлагач, авыл башлыгы авылда күпме кеше бар, шуны яшермичә әйтте.

– Сиксәнләп! Хатын-кызлар, карт-корылар да шул исәптә.

– Корал тота алырлыклары, сугышчылар кызыксындыра мине, – диде Андрей.

– Урта яшьләрдәге ир затлары егерме бишләп булыр. Бездә барысы да корал тота белә.

Чыннан да, күпчелеге егерьлар династиясеннән булган авыл кешеләре – гомерләре буе сунарчылык белән шөгыльләнгән кешеләр. Аларның барысын да бик төз атучы мәргәннәр дип әйтергә була.

– Кораллар белән хәл ничегрәк?

– Ау мылтыклары... э-э-э, сугыш кораллары һәркемдә дә бар. Патроннарга да кытлык юк, – диде Харрас, бер яктан мактанырлык нәрсә әйтә алуына куанып.

Каяндыр килеп чыккан бер билгесез адәмнең үзеннән – югарыдагы хакимият тарафыннан билгеләп куелган авыл башлыгыннан допрос алып утыруына аның бераз гына ачуы да чыкты. Авылда иң зур җитәкче буларак, мондагы һәрнәрсәгә ул үзе генә җаваплы. Шуның өстенә «партизан отряды командиры» дигән уйдырма-вазифа! Андрейның алар эшенә тыкшынырга бернинди хакы да юк... Тик менә килеп туган аңлаешсыз хәл Харрасның уйлау сәләтен бөтенләй бетергән иде шул. Мондый көтелмәгән хәлләрдә ул башкаларны өйрәтү түгел, үзе дә нишләргә кирәклеген тәгаен генә төшенеп җитә алмый.

Моның өчен вакытта югарыдагылар белән киңәшләшеп алу комачауламас иде дә бит... Тик элемтә чаралары алга киткән заманда яшибез дип, күпме генә мактанышсак та, тайга уртасындагы кечкенә бер авылдан «Олы җир» белән элемтәгә чыгу бик җиңел түгел. Монда «кесә телефон»нары эшләми. Нибары җиде-сигез дистә кеше яшәгән бер авыл өчен станция төзергә хөкүмәт акча

бирмәячәк. Бердәнбер элемтә чарасы булган кыска дулкыннарда эшләүче рация дә, кирәк бит, нәкъ шундый чакта сафтан чыккан! Тагын бер элемтә чарасы бар барын... ТТ-4 чылбырлы тракторы белән 50 чакрым ераклыктагы Южный бистәсенә хат-хәбәр җибәрү. Тик бу трактор кичә генә Южныйдан кайтканлыктан, аны бүген тагын шунда чыгарып җибәрү бик кулай түгел. Юл чыгымнары үзен акламаячак. Ягулыгы, тегесе-монысы, дисеңме... Авыл җирлегенең андый чыгымнарны күтәрерлек хәле юк.

Хәтта тиз арада элемтәгә чыгу мөмкин булса да, мондый хәлне, әйтик, телефон аша югарыдагыларга аңлатып булыр идеме? «Авылга фашистлар һөҗүм итү куркынычы яный, кичекмәстән ярдәм җибәрегез», – дип хәбәр салсаң, бу «ычкына башлаган», дип, шунда ук туп-туры «сары йорт»ка озатачаклар. Монда ашыгып хәл кылырга ярамый. Алла сакласын, ник әйткәнеңә үкенерсең. Берничә кешенең акылына зәгыйфьлек килеп, күзләренә «фашистлар» күренә башлаган икән, ни өчен Харрас зыян күрергә тиеш соң әле?.. Авыл башлыгы күңеленнән генә әнә шулай фикер йөртте...

– Менә нәрсә, иптәш капитан. Мин үземнекеләр... э-э-э ягъни штабымдагылар белән киңәшләшермен. Уйлашырбыз, – дип инициативаны үз кулына алды Харрас. – Ә сезгә хәзер дәва һәм ял кирәк. Мин сезне э-э-э медицина хезмәте лейтенанты Светлана Сидорова карамагына тапшырам. Ул сезнең сәламәтлекне кайгыртыр. Ә калган оештыру эшләрен безнең үзебезгә калдырыгыз.

– Харрас Зарипович, тик зинһар өчен, отряд урнашкан урынны кичекмәстән алмаштырырга кирәк. Юкса...

– Мин сезне аңладым. Без менә хәзер үк авыл кешеләрен... то есть отрядтагы һәрбер сугышчыны җыеп, шул хакта киңәшәчәкбез, – диде Харрас, һәр сүзенә басым ясап һәм икеләнергә урын калдырмаска тырышып...

* * *

Андрей белән булган сөйләшүдән соң, Харрас янә кунак бүлмәсенә керде. Зөфәр белән Камил сораулы карашларын аңа текәделәр.

– Йә, Харрас Зарипович, ни әйтерсең? – диде Зөфәр.

Харрасның икеләнүе йөзенә чыккан. Андрей белән сөйләшкәнче, ул Зөфәрнең һәр сүзен инкарь итеп килгән иде. Хәзер исә, «шайтан нәрсә белән шаярмас, ә бәлки?..» дигән каршылыклы уйлар йөрәген тырный иде булса кирәк.

– Аптыраган инде. Тәмам башны бутап бетердегез, – диде ул, чарасызлыктан нәрсә эшләргә белмәгәнен аз гына да яшермичә.

– Харрас абый, хәлнең никадәр җитди икәнлеген Андрей да раслап тора. Ишеткәнсеңдер...

– Ишетүен ишеттем. Тик... Халыкка бу хакта ничек аңлатырга? Белеп торам, берсе дә ышанмаячак... Ә югарыдагыларга ни диярмен? Авылга фашистлар һөҗүм итә, дисәм... Иртәгә үк Күчкән Салага ишек-тәрәзәләре тимер рәшәткә куелган «УАЗик» белән килеп алып китәчәкләр мине. Адәм көлкесе!

Үз сүзләрен расларга теләгәндәй, Харрас кычкырып көлеп җибәрде. Акылын югалткан кеше кебек тыела алмыйча озак шаркылдады ул.

– Харрас абый, барыбер нәрсәдер эшләргә кирәк. Болай кул кушырып утырсак, алар иртәгә тимер рәшәткәле «УАЗик» белән килгәндә, сез дә, һәм башка беркем дә калмаган булуы мөмкин.

– Ә сез үзегез нинди киңәш бирер идегез миңа? – дип, башкаларның киңәшенә колак салырга теләге барлыгын сиздерде авыл башлыгы.

– Әгәр берәр хәйлә-мазар уйлап тапсак, – диде, сүзгә кушылмыйча, башкаларның сөйләгәнен генә тыңлап утырган Камил. – Әгәр кешеләргә, төрмәдән бер төркем рецидивист качкан, алар безнең тирәдә урманда яшеренеп яталар икән; авылга һөҗүм итү ихтималлары бар, шуңа күрә берничә көнгә авыл кешеләрен куркынычсыз урынга эвакуацияләргә кирәк, дисәк? Халык андый сүзләргә тизрәк ышаначак. Соңыннан, бернәрсә дә булмаса, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы кушуы буенча үткәрелгән планлы өйрәнүләр генә иде, диярбез. Халыкны ни өчен эвакуацияләүне югарыдагыларга да, гадәттән тыш хәлләр буенча өйрәнүләр үткәрелде, дип аңлатырга була.

Аның сүзләрен игътибар белән тыңлаган Харрас, нәрсәдер үлчәгән-чамалаган шикелле, күзләрен кысып уйланып утырды да үз фикерен белдерде:

– Килешәм. Чыннан да, шулай эшләргә кирәктер, бәлки. Кем әйтмешли, сарык та исән, бүре дә тук. Ул чакта беркем дә болар ычкынган икән, димәс.

Зөфәр дә үз тәкъдимен әйтеп калырга ашыкты:

– Бу эшне участок инспекторы полиция лейтенанты Рафаил Садриев белән берлектә эшләсәк, авылдашларны ышандыру өчен тагын да яхшырак булыр, – диде ул.

– Әйдәгез, кузгалыйк алайса. Монда сөйләшеп утырып кына берни майтарып булмас. Су язып, май төшми.

Харрасның әлеге сүзләре белән барысы да килеште. «Әйе! Әйдә кузгалыйк», – дип сөйләнә-сөйләнә, урыннарыннан тордылар...

Авыл идарәсенә барып, Рафаилгә хәлне төшендереп бирделәр. Ул баштарак: «Бу нинди хәл инде? Мин – участковый, авылда шундый хәлләр булганын иң соңыннан ишетәм? Кемнедер кыйнаганнар, кемнедер утлы коралдан атып яралаганнар. Криминал бит бу. Кичекмәстән «Олы җир»гә хәбәр итәргә кирәк», – дип чыгымчылап маташса да, хәлне төшендереп биргәч, ризалашты. «Гадәттән тыш хәлләр буенча өйрәнү исәбеннән булыр», – дигәч, ел әйләнәсе югарыга отчёт сырлаудан башка бер гамәли эш күрсәтмәгән участок инспекторына үзен күрсәтү өчен менә дигән мөмкинлек иде бу.

Ләкин барыбер авылда гадәттән тыш хәл килеп тууы турында хат язып, Южный посёлогы башкарма комитет җитәкчесенә тапшыру өчен, ТТ-4 тракторын юлга чыгарырга, дигән карарга килделәр. Хатны «грамоталы» итеп язу авыл башлыгы сәркатибе Әлфирәгә йөкләнде...

Харрас күрсәтмәсе буенча авыл кешеләренең барысын да ашыгыч рәвештә клубка җыйдылар. Башта авыл башлыгы үзе чыгыш ясады. Алдан сөйләшенгәнчә, төрмәдән бер төркем рецидивистның качуы турындагы ялган хәбәрне җиткерде. Участок инспекторы Рафаил дә хокук саклау органнары вәкиле буларак, сүз алып, кешеләрне куркынычсыз урынга эвакуацияләп торырга кирәклеген әйтте. Бу хакта югарыдан әмер килүе турында да белдерде. Ул:

– Бер көнлек азык-төлек, ягъни сухой паёк, иң кирәкле документларны һәм мылтык-патроннар алып, бер сәгатьтән бирегә җыелыгыз. Ашыгыч рәвештә, оешкан төстә көнчыгыш якка берәр километр урман эченәрәк эвакуацияләнәбез, – дигәч, залда утыручылардан берсе:

– Ә мылтыклар нәрсәгә? Сугышырга җыенмыйбыздыр ич? – дип, Рафаилнең күрсәтмәләрен көлкегә алмакчы булды.

Көтмәгәндә килеп туган бу хәлдән, күңеле белән үзен «генерал» итеп тоя башлаган Рафаил, сорауга ни дип җавап бирергә белмичә каушап калды. Аның «ык-мык» итеп торуын күреп, Харрас ярдәмгә ашыкты:

– Җәмәгать, нәрсә буласын беркем дә белми. Рецидивистлар да коралсыз

түгелдер. Ә коры кул белән без аларга каршы нәрсә эшли алырбыз?.. Тагын шунысын да онытмагыз: тайгага китәбез бит. Ә анда ерткыч җанварлар очрамас дип әйтеп булмый. Шулай булгач, патроннарны да җитәрлек алыгыз, – дип тәмамлады ул сүзен.

Башлыкның аңлатуы үтемле булды. Каршы әйтүче күренмәде. Бары тик 80 яше белән баручы Габделхак карт кына:

– Ул рецидивистлар миңа – карт кешегә тимәсләр әле. Өемнән беркая да китмим, – дип, каршы килеп маташты.

– Качкыннар – бик куркыныч җинаятьчеләр икән, синең картлыгыңа карап тормаслар. Бүген ТТ-4 вездеходы белән Рафат Южныйга китә. Бәлки сине шуңа утыртып җибәрербез, – дип тә аңлатырга тырышты Рафаил. Карт кулын гына селтәде:

– Яумаган яңгырга чиләк тотмыйлар, дигәндәй, сез әйткән ул качкыннар бармы-юкмы, беркем дә белми. Мин монда калам. Үз өемдә үз көем. Бетте-китте, вәссәлам! – дип, һаман үз киресен сукалады Габделхак...

Берәр сәгать уздымы икән, авыл кешеләренең барчасы да төенчекләр, төргәкләр, биштәрләр күтәреп, ир-атлар мылтыкларын асып, клуб каршына җыелган иде инде. Ирләрнең һәрберсендә «Сайга» тибындагы аучы карабины. Шома көпшәле бу заманча корал бик уңайлы. Сугышчан автомат базасында ясалган үзкорылышлы ярымавтомат карабинның «магазин»ы 8 патрон сыйдырышлы. Күчкән Сала аучыларының күбесенең мылтыгы оптик төзәгеч белән җиһазландырылган. Мондый корал белән 300 метрдан теләсә нинди әйбергә тидерергә була.

Сафларга тезеп барлау узгач, халык Зөфәр һәм Камил артыннан ияреп, урман ешлыгына таба юл алды. Авыл урамнарын, йортларны яхшылап карап чыгып, Әлфирәгә Южный посёлогында хатны кемгә тапшырасын яхшылап аңлаткач, Харрас та эвакуацияләнгән кешеләр киткән тарафка кузгалды. Участковый Рафаил дә аның артыннан иярде. Рафат тракторын ерак юлга әзерли башлады.

Бу көтелмәгән хәл Харраска «авыртмас башка – тимер тарак» кебегрәк тәэсир итте. Тыныч кына яшәп яткан авыл халкына шундый мәшәкатьләр тудырганы өчен, ул күңеленнән генә Зөфәрне битәрләде. Ләкин кычкырып ачуланырга базмады. Чөнки күңеленең бер почмагында: «Ә бәлки?..» дигән шик тамыр җәя башлаган иде.

* * *

Гауптштурмфюрер Мартин һөҗүмне ракета чөйгәч кенә башларбыз, дип алдан әйткән булса да, көтелмәгән хәл килеп чыкты. Һөҗүмне берәр сәгать иртәрәк башларга туры килде. Оберштурмфюрер Ганс төркеме авылның капма-каршы ягына чыгып, урнашып беткән иде, шулчак авылны күзәтергә куелган солдатларның берсе йөгереп килде дә бу якка таба бер танк чыгып килүе турында рапорт бирде. Чыннан да, еракта ниндидер техника күренә. Ганс биноклен шуңа төбәде. Килүче танк түгел иде. Аның башнясы да, тубы да юк. Бронетранспортёр булырга мөмкин. Бәлки солдатлар төягәндер. Бирегә немец ротасы килгәнне күреп, партизаннар аларга каршы десант төшерергә җыеналардыр. Бу хакта элемтә буенча гауптштурмфюрер Мартинга хәбәр итте Ганс.

– Засада куегыз да шартлатыгыз, – дип әмер бирде Мартин.

Шулай эшләделәр дә: бер солдат юл читендәге чокырда посып торды да зур тизлектә килүче «хәрби машина»га граната томырды. Техниканың чылбыры

өзелеп, бер урында зыр бөтерелә башлады һәм алгы ягы белән засадада ятучы солдатка борылып, туктап калды. Кабина ишеге ачылып, аннан йөртүчесе чыга башлаганы күренде. Солдат аңа автоматын төбәп, ут ачты. Йөртүче сөрлегеп куйды һәм аркасы белән җиргә шапылдап төште дә хәрәкәтсез калды. Ул арада тракторның тент белән капланган арткы өлешеннән бер кеше сикереп төшеп, юлның капма-каршы ягыннан агачлыкка йөгерде. Солдат аңа да ут ачкан иде, ләкин тидерә алмады. Теге адәм урман куелыгына кереп югалды. Солдатның аны эзәрлекләргә кыюлыгы җитмәде. Аның уенча, урман партизаннар белән мыжлап тора һәм анда борын тыгу үз-үзеңне һәлак итү белән бер булыр иде.

Трактордан бүтән төшүче булмады. Солдатлар автоматларын әзер тотып, ут капкан тракторга якынрак килеп карадылар. Җирдә яткан йөртүчесенә төрткәләделәр. Техниканы әйләнеп чыктылар. Әлегә кадәр мондый техниканы беркайда да күргәннәре булмагач, ни уйларга дә белмәделәр. Тент белән капланган арткы өлешендә утыргычлар булудан аңлашылганча, бу солдатлар утыртып йөрү өчен файдаланыла торган транспорт булырга тиеш, дип нәтиҗә ясадылар. Тик менә ни өчен аның ике кеше белән генә юлга чыгуын аңлата алмадылар.

Ганс гауптштурмфюрер Мартинга партизаннарның хәрби техникасын шартлатулары турында рапорт тапшырды. Үзенең солдатларының ролен арттырып күрсәтү өчен, «яхшы коралланган партизаннар утырган бронетранспортёр» юк ителде, дип белдерде. «Атышлар вакытында җиде партизанны юк иттек, өч-дүрте табан ялтыратты», – дип ялганларга да онытмады. Аның командирыннан мактау сүзләре ишетәсе бик килсә дә, Мартин артык төчеләнеп тормады. Бронетранспортёрның шартлатылуын ишеткәч, лагерьдагы партизаннар аңга килеп, төп көчләрен шул якка күчергәнче, тизрәк миномётлардан ут ачарга, дип команда бирде.

Ике яктан да өчәр миномёт бер үк вакытта атарга тотынды. Авыл эченә миналар төшеп шартлый башлады. Каралты-кура шартлап, тирәк-якка сибелде, йортлар ишелде, авылда янгын чыкты. Мәхшәр купты.

Унбиш-егерме минутлап барган миномёт утыннан соң, дөнья тынып калгандай булды. Гансны иң гаҗәпләндергәне: шул вакыт эчендә партизаннар ягыннан бер ату тавышы да ишетелмәде, бер хәрәкәт тә сизелмәде. Миналарга туры килеп, партизаннарның бөтенесе кырылып беткән дияр идең, бу мөмкин хәл түгел...

Шулчак Мартин ягыннан күккә ракета чөелде. Бу – һөҗүмгә күчәргә, дигән сигнал иде. Ганс солдатларны авыл ягына куды. Ә капма-каршы яктан гауптштурмфюрер Мартин төркеме килә. Алар авыл уртасында очрашты. Тик авыл урамында да, йортларда да беркем күренмәде. Коралларны бик сак кулланырга, ялгыш атып, бер-берсенә тидермәскә дип, кат-кат кисәтелгән булсалар да, пуля тиеп, бер эсэсчының аягы яраланган булып чыкты. Мартинның моңа бик ачуы чыкты, әлбәттә. Ул зәһәр итеп сүгенде.

Качкын әсирләр кайтып әйткәч, партизаннар отряды авылдан чыгып качарга өлгергәнне аңлады Мартин. Шулай итеп, партизаннарга көтмәгәндә һөҗүм ясап, барысын да кырып салырга, дигән беренче планы барып чыкмады. Алар аз гына соңга калдылар...

Хәзер партизаннарның кайсы тарафка киткәннәрен ачыклап, артларыннан эзәрлекләп, тар-мар итәргә кирәк булачак. Шул сәбәпле, өч-дүрт кешедән торган берничә төркемне тирә-якны тикшереп кайтырга разведкага җибәрергә карар кылды Мартин. Алар килгәнче, солдатлар йорт ишегалларына, сарайларга кереп, күз төшәрлек, кесәгә сыярлык, күтәрә алырлык әйберләр

юкмы дигәндәй, тикшеренеп йөри башладылар. Миналар каралты-куралаларга эләккән кайбер урыннарда янгын чыккан һәм ул һаман көчәя бара. Төтен, ис күзләрне әчеттерә, сулышка керә.

Шулчак кайсыдыр бер йорт ишегалдыннан ике солдат Габделхак картны җилтерәтеп алып чыктылар да Мартин каршына китереп бастырдылар.

– Гер гауптштурмфюрер, менә бер партизанны эләктердек, – диде аны алып килгән солдатларның берсе.

Әле яңарак кына булып узган мина яңгырыннан соң, мондый мәхшәрне үз гомерендә дә күрмәгән картның кыяфәте бик аяныч иде. Аның йөзенә һәм үз-үзен тотышына караганда, бу хәлне ул бөтенләй аңышып бетмәгән. Үтә гаҗәпләнүдән аның күзләре өлкәннәргә хас булмаганча зур булып ачылган. Шундый көтелмәгән хәлдән нык курыккан булса кирәк, бөтен тәне белән калтырана. Миналар төшеп шартлый башлагач, ахырзаман килде, дип уйлагандыр инде, бахыр.

Мартин картны баштанаяк карап чыкты да җирәнгән кыяфәттә җиргә төкерде.

– О, юк! Бу партизан булырга тиеш түгел, бик карт бу, – дип сөйләнде.

– Ул качмакчы иде, гер гауптштурмфюрер, – диде солдатларның икенчесе.

Картның партизан икәнен дәлилләү өчен шуннан башканы әйтә алмады, күрәсең.

– Сезнең бу кыяфәтегезне күрсә, шайтан үзе дә качып китәр, – диде Мартин мыскыллы елмаеп, солдатның мародёрлык белән шөгыльләнеп, иләсләнгән күзләренә ишарә итеп. Аннан соң кабат картка борылды да: – Әй син, карт, әйт әле, партизаннар кай тарафка качып китте? – диде.

Габделхак карт, авылда булган мәхшәргә һәм авыл халкының кинәт кенә тайгага кереп качуына шушы адәмнәр генә гаепле икәнен төшенде, әлбәттә. Харрас әйткән «рецидивистлар»ның ни дәрәҗәдә куркыныч булуларын, соң булса да, менә хәзер генә аңлагандыр бичара. Офицерның сүзләрен тылмач тәрҗемә иткәч, ул бераз уйланып торды. Сорау бирүченең тел төбен аңлау өчен акыллы картка нәкъ менә шул вакыт җитте дә. Кан тамырлары бүлтәеп торган ябык кулын күтәреп, авылдашлары чыгып киткән якка түгел, бөтенләй капма-каршы якка төртеп күрсәтте ул.

Ләкин шулчак разведчикларның бер төркеме әйләнеп кайтты да ашыгып Мартин каршына килеп басты:

– Гер гауптштурмфюрер, без әнә теге тарафка таба киткән бик күп эзләр күрдек. Партизаннар шунда киткән булырга тиеш, – диде.

Мартин ачу белән Габделхак картка күз ташлады.

– Алыгыз бу дуңгызны, – дип акырды ул солдатларга һәм борылып китәргә җыенганда, кулын кискен генә селкеп, барысына да аңлашылырлык ишарә ясады.

Бу ишарәнең мәгънәсе Габделхак картка да барып җитте. Әйе, бу аңа карата хөкем карары иде. Дөрес, сигез дистә ел гомер кичергән татар карты үлемнән курыкмый. Аллаһы Тәгалә аңа үлемнең менә шушындыен билгеләгән икән, аны лаеклы кабул итә белергә дә кирәк... Габделхак булдыра алганча тураеп басты. Кыска гына автомат тавышы яңгырап алды...

Мартин, йорт ишекләрен җимереп ачып, анда мародёрлык белән шөгыльләнгән солдатларын җыю өчен ракета атып сигнал бирде. Тиз генә җыенып, кичекмәстән партизаннар артыннан эзәрлекләүне дәвам итәргә кирәк.

Йорт ишегалларыннан берәм-берәм солдатлар чыга башлады. Берсенең дә куллары буш түгел, кайсы капчык, кайсы сумка тоткан. Бер солдат ике кулына

икешәр тавык эләктергән. Аякларыннан тоткан тавыклар канатларын җилпеп тыпырчыналар, яман каты кытаклап кычкыралар, тирә-якка мамыклары оча. Шульц бер сарыкны өстерәгән...

Гауптштурмфюрер бу кәмитне күреп, ни әйтергә белмәде. Дөрес, бу гамәлләре өчен аларны гаепләргә җыенмый. Моңа кадәр дә басып алынган авылларда җирле халыкны аз таламадылар. Солдат тамак турында кайгырта икән, бу начар түгел. Тамагы тук солдат кына яхшы сугыша. Моны ул бик яхшы белә. Хәер, үзе дә авызны ертып керергә торган ризыкны алырга каршы түгел. Тик нәкъ менә хәзер, шушы мизгелдә Мартин өчен тамак кайгысы икенче урында иде.

– Барлык алган әйберләрегезне ташларга туры килер. Кичекмәстән партизаннарны куып җитәргә кирәк. Ә әйберләрне алырга без монда кабат, партизаннарны тар-мар иткәч килербез, – диде ул, ике сөйләшергә урын калдырмыйча.

Эсэсчылар колоннага тезелеп, көнчыгышка кузгалдылар. Партизаннарның нәкъ менә шул юнәлештә киткәннәренә аларның берсе дә шикләнми иде. Чыннан да, авылның шул башыннан чыгып, тайга эченә кергәч, анда бик күп кеше эзләре күреп, дөрес баруларын аңладылар.

* * *

Күчкән Сала качаклары урман эченә бер чакрымлап кергәннәр иде, аларны йөгерүдән сулышы капкан Әлфирә куып җитте. Аның чәчләре тузган, биткуллары агач-куакларга сыдырылган, киемнәре ертылган, бер аягындагы туфлие төшеп калган. Аны иң беренче төркемнең ахырында баручы полиция лейтенанты Рафаил күреп алды һәм кире борылып каршысына йөгереп килде.

– Нәрсә булды, Әлфирә? – диде ул, хатынның иңнәреннән тотып.

– Аттылар... Юлдан бара идек...

Әлфирә тыела алмыйча кычкырып елый башлады. Бу тавышны ишетеп, төркем ахырында баручылар да борылып карады һәм тукталып калды. Бераздан кешеләр колоннасы тукталды, һәм һәркем Әлфирә ягына төбәлгән иде. Алдан баручы авыл башлыгы Харрас та йөгереп килеп җитте.

– Нәрсә булды? Рафат кайда? – дип сораулар яудыра башлады ул килә-килешкә.

– Рафатны атып үтерделәр... Тракторны шартлаттылар... Мин тиз генә йөгереп, юлның икенче ягындагы урманга кереп качып котылдым, – диде Әлфирә, өзек-өзек сүзләр белән.

Ул әле һаман тынычланып җитә алмыйча, калтырана-калтырана үзләре белән булган хәлне сөйләп бирде. Ул башта авылга кайтмакчы булган. Ләкин тиздән авыл өстенә ике яклап миналар яудыра башлаганнар. Ачы сызгырып төшеп шартлаучы миналар авылның астын-өскә китергәннәрен үз күзләре белән күргән Әлфирә. Аннан соң, авыл кешеләре киткән көнчыгышка таба йөгергән, эзләрдән бара торгач, куып җиткән...

Әлфирәне фельдшер Светлана карамагына тапшырып, Харрас тиз генә авыл активы белән киңәшмә уздырып алырга дигән карарга килде. Зөфәрне, Камилне һәм участковый Рафатны бер читкә чакырып алды. Хәле бик шәптән булмаса да, тиешле дарулар һәм уколлар алган, ярасын бәйләткән һәм тамагын туйдырган Андрей да шунда килеп җитте. Ул инде хәлне чамалап алган иде. Димәк, фашистлар арттан куа килә. Шуңа күрә Андрей тизрәк үз тәкъдимен кертергә ашыкты.

– Уңайлы урын табып, кичекмәстән оборона оештырырга. Юкса, алар безне куып җитеп, аерым-аерым кырып салачаклар. Ә хатын-кызлар, карт-корылар һәм бала-чагалар юлларын дәвам итсеннәр. Бәлки үзебезнекеләргә барып чыгарлар. Ә без – кораллы партизаннар – монда фашистларны тоткарлап торыйк...

Дары исен татыган, күп мәртәбә бәрелешләрдә катнашкан һәм хәрби эшне мондагыларга караганда яхшы белүче Андрейның сүзләренә колак салмыйча калмадылар, әлбәттә. Ул хаклы. Ә оборона өчен корал белән эш итүче, урта яшьләрдәге көчле ир-атларны сайлап алырга туры киләчәк. Андыйларны табарга була. Егермеләп кеше җыелыр. Тик хәлнең бик җитди булуын авыл кешеләренә ничек аңлатырга? Ярар, юлны дәвам итәргә кушып, аларны алдан җибәрергә дә була. Ә менә корал тотып биредә – оборонада калган ике дистәләп ир-атка ни дияргә? Төрмәдән качкан бер төркем җинаятьчегә мондый көч белән каршы тору мөмкин эш тә бит... Тик баштанаяк коралланган, сугыш һөнәренә махсус өйрәтелгән бер рота гаскәриләргә каршы, сугышка бөтенләй өйрәтелмәгән егермеләп ир-ат каршы тора алырмы? Андрейның әйтүенә караганда, хәзер немецларда 150ләп кеше булырга тиеш. Көчләр тигез түгел. Аерма – җиде-сигез мәртәбә...

Харрас авыл кешеләренә мөрәҗәгать итеп:

– Җәмәгать, авыл кешеләре – карт-коры, хатын-кызлар, бала-чага хәзер алга таба юлларын дәвам итәчәк. Алар берәр километр арырак китеп, шунда безне көтәрләр. Ә без – мылтыклар белән коралланган иң көчле ир-атлар – монда җинаятьчеләргә каршы оборонада калабыз, – диде.

Авылдашлар арасыннан сайлап җыя торгач, чыннан да, егерме ике ир-ат табылды. Хәтта дүрт хатын-кыз да шулар сафында корал тотып җинаятьчеләргә каршы көрәшергә теләк белдергән иде, Харрас аларны тиз туктатты. «Корал белән эш итү – ирләр эше. Сездән башка да хәлдән чыгу җаен табарбыз», – дип, аларның теләкләрен кире какты. Бары тик фельдшер Светланага гына калырга рөхсәт бирде. «Корал кулланырга туры килеп, берәребез яраланса, яраларны бәйләрсең», – диде Харрас аңа.

Хәер, ул әйтмәсә дә, Гиппократ анты биргән Светлана моны үзенең бурычы дип саный иде.

– Алга таба юлны дәвам итүче авылдашлар төркеменә җитәкче итеп, Зөфәрне билгелим, – диде Харис, үзенең кыска гына чыгышын йомгаклап.

Харрастан моны көтмәгән Зөфәр ни әйтергә дә белмичә, гаҗәпләнеп калды.

– Харрас Зарипович, мин сезнең бу тәкъдимегезгә каршы. Мин монда оборонада торучы егетләр белән калачакмын. Чигенүчеләргә җитәкче итеп башка кешене куегыз, – диде ул, сүзләреннән аз гына да ваз кичмәячәгенә ышандырырга теләгәндәй.

– Нәрсә, әллә алар белән китсәң, җиңел булыр дип уйлыйсыңмы? Анда сиңа, әнә, әллә ничә дистәдән артык кеше карап тора. Аларның гомерләре өчен җаваплылык зуррак та әле.

Ләкин бу сүзләр генә Зөфәрне кире чигендерә алмый иде. Ул болай да фашистларның Күчкән Салага килүләрендә үзен гаепле саный. Әгәр ул «Ерак привал»да фашистларга әсир төшмәгән һәм аннан качып китмәгән булса, бу авылны алар беркайчан да эзләп табасы түгелләр иде. Шуңа күрә бүген авылдашларына уңайсызлыклар тудыруда бары тик үзен генә гаепле санап, фашистларга каршы көрәшүчеләрнең иң алгы сафында үзе булырга тиеш, дип уйлый иде.

– Мин моннан беркая да китмим. Өлкәннәр һәм хатын-кызлар белән Камилне җибәрегез әнә, – диде ул, икеле-микеле сөйләшүләргә урын калдырмыйча.

Камил каршы килмәде. Гәүдәсен хәрбиләрчә төз тотып: «Тигезләнеп тезеләргә!» – дип башлаган иде, каршысында хәрбиләр түгел, карт-коры да хатын-кызлар икәнен генә күреп, кулын селтәде.

– Кузгалдык, җәмәгать, – диде ул тыныч кына һәм үзе, иңенә асылган мылтыгының каешын тотып, салмак кына агачлар куелыгына атлады. Төркем аның артыннан иярде...

Алар агачлар арасына кереп күздән югалуга, оборона өчен уңайлы урын сайлый башладылар. Ерак түгел инеш ага. Аның ярлары сөзәк, ләкин өскәрәк менеп бассаң, агачлар сирәгрәк үскән елга үзәне уч төбендәге кебек күренә. Әнә шул калкулыкның өстендә үзара тигез аралар калдырып тезелеп ятарга кирәк, дип киңәшен бирде Андрей. Чыннан да, стратегик яктан караганда, бу бик уңышлы урын булыр иде. Харрас аның белән килеште. Егетләрнең кайсы агач кәүсәсе артына качты, кайсы чокырлы урынны сайлап, шунда сузылып ятты. Һәрберсе коралларын корып, әзерләп куйды.

Андрейның бер кулы яралы булганлыктан, ул мылтыктан ата алмаячак. Бердәнбер пистолетлы кеше – участковый Рафаил. Андрей аннан пистолетын биреп торуын сорады. Син мылтыктан да ата аласың, диде ул.

– Бу минем табель коралым. Аны теләсә кемгә бирергә закон кушмый, – дип аңлата башлаган иде, Харрас сүзләрен бүлдерде:

– Рафаил, пистолетыңны бир инде шуңа. Чыннан да, үзең мылтыктан да ата аласың ич, – диде ул.

Рафаил үзе корылышлы МП пистолетын кобурасыннан алып, теләр-теләмәс кенә Андрейга сузды һәм ничек кулланырга кирәген өйрәтте. Хәрби кеше булса да, әлегә кадәр мондый коралны күрмәгән Андрей, пистолетны әйләндерә-әйләндерә карады:

– Немчуралардан кулга төшерелгән трофеймы әллә? – дип сорамыйча түзә алмады.

Рафаил аңа гаҗәпләнеп карап торды да:

– Әйе, немец генералыннан алдым, – дип мыскыллы елмайды.

– Мин бу операциядә хәрби эшләр буенча ярдәмчем итеп, гвардия капитаны Захаров Андрейны билгелим, – диде Харрас.

Башкача мөмкин дә түгел. Чөнки килеп туган шушындый хәлдә, хәрби эштә тәҗрибәсе булган Андрейның гына дөрес карарлар кабул итә алачагы һәркемгә мәгълүм. «Гадәттән тыш хәлләр буенча өйрәнүләр» буларак, операциягә үзем җитәкчелек итәрмен, дип уйлаган Рафаилне гаҗәпкә калдырып, Харрас бу вазифаны үз өстенә алды. Ә аны башлык итеп түгел, хәтта ярдәмчесе итеп тә куймады. Монысы Рафаилнең ачуын китерде, билгеле. Теткәләнеп беткән гимнастёркалы Андрейны исәпкә алмаганда, монда форма кигән кеше бары ул гына. Дөрес, дәрәҗәсе лейтенант кына. Ә аңа калса, Харрас үзе дәрәҗәсе белән кем соң ул кадәр?! Эченнән генә шулай үртәлсә дә, Рафаил тыштан сер бирмәде. Башкалар белән бергә оборонага ятты.

– Минем команда буенча гына атарга. Бер пуляны да юкка әрәм итмәскә, – дип соңгы күрсәтмәләрен бирде Харрас.

– Нәрсә, ул кешеләргә чынлап атарга тиеш булабызмыни без? – дип сорады кайсыдыр.

– Ике-өч качкын җинаятьчене засадага ятып каршыламасак та, кулга алырбыз әле, – дип кушылды икенчесе.

– Атаргамы-юкмы икәнен хәлгә карап гамәл кылырбыз. Ә хәзергә барыгыз да тулы әзерлектә, җинаятьчеләрне көтәбез, – диде Харрас.

* * *

Александр Левин элекке курсташы һәм дусты Сазоновның санаторийда беренче очрашуында: «Тайгада кыргый җәнлекләрне исәпсез кыралар, кайбер хайваннар «Кызыл китап»ка кертелгән», – дигән сүзләрен күңеленә якын алып, озак кына уйланып йөрде. Гел башка тармакта эшләсә дә, ул да кайчандыр урман хуҗалыгына кагылышлы һөнәр сайлаган кеше ләбаса. Тик яшьлек хыяллары тормышка ашмыйча гына калды. Дустының хәленә керергә тырышуы, аңа яхшы сүзләр белән генә булса да теләктәшлек күрсәтүе шуңадыр, бәлки.

Санаторийдан кайтып, озак та узмады, Сазоновны борчыган мәсьәләгә кагылышлы бер гаҗәп хәл турында ишетергә туры килгән иде аңа. Ванна процедуралары алып яткан вакытта Сазоновка: «Сине борчыган нәрсәләрне хәл итә алачакбыз», – дип шапырынуы да турыдан-туры үз эшчәнлегенә кагылышлы түгел иде. Яшь галимнәрнең нинди «мөгез чыгарулары» турында тәфсилләп сөйләсә дә, Сазоновның үзен аңламаячагын яхшы белә ул. Ә эш менә болайрак булды.

...Берничә ел элек фәнни-тикшеренү институтында халыкара симпозиум уздырдылар. Анда катнашкан бер төркем яшь галим-энтузиастлар фән өчен шактый гына кыю гипотеза белән чыкты. Вакыт-пространство өлкәсендә тикшеренүләр алып баручы бу гыйльми хезмәткәрләр әлегә кадәр фантастик әсәрләрдә генә киң чагылыш алган, ә тормышта чынга ашмастай нәрсә – «Вакыт аша күчеш» теориясен гамәлгә ашыруга ныклап керешмәкчеләр, имеш. Бу башлангычны күпчелек галимнәр: «Булмастайга тотынганнар», – дип, кул гына селтәсәләр, кайберләре бөтенләй көлкегә алды. Берничә көн барган һәм күп акыл хезмәте таләп ителәторган мондый олы фәнни чарада, киеренкелекне йомшарту өчен, бераз мәзәге дә кирәк, дип, бот чабып шаркылдап көлеп утыручылар да булмады түгел. Шуңа күрә, симпозиумны оештыручылар, бу яшь галим-голәмаларның кыю фаразларын артык җитдигә алмыйча, көн тәртибенә кертелгән башка мөһимрәк темаларга күчү ягын карадылар. Шулай итеп, «Вакыт аша күчеш» теориясе симпозиум беркетмәсенә дә нибары бер-ике җөмлә белән генә теркәлү хокукы алган әһәмиятсез мәсьәләләр рәтенә кертелде.

Симпозиумны оештыруда гына түгел, аның эшендә дә актив катнашкан Александр Васильевич Левинның моңа бераз гына үпкәсе калды, әлбәттә. Әлеге яшь галимнәр үзе эшләгән шушы институттан һәм, өстәвенә, элекке укучылары да әле. Яшьләрне әлеге эшчәнлеккә этәрүдә аның да берникадәр өлеше булды. Гыйльми даирәләр арасында бу эшнең җитдилеге шик астына алыну әнә шуңа да аның күңелендә авыр тәэсир калдырды. Бу эшләрнең уңышлы чыгуына шөбһәләнә калды ул. Соңыннан фәнни институтта уздырылган гыйльми киңәшмәләрнең берсендә яшьләргә үзе дә:

– Киләчәге өметсез эшләрне ташлап, җитдирәк тикшеренүләргә алынсагыз, әйбәтрәк булыр, – дигән сүзләр дә ычкындырды.

Киләчәккә зур өметләр баглап, яңа ачышлар ясау белән янган яшь галимнәр, остазлары авызыннан чыккан бу сүзләрне бик авыр кабул иткәннәр. «Кемнән-

кемнән, сездән мондый кискен сүзләр ишетергә теләмәгән идек», – диделәр алар. Өч-дүрт ай үттеме икән, яшьләр, сүз куешкандай, бөтенесе бергә эштән китәргә гариза язды. Ялгышын соңга калып кына аңлаган Левин, калуларын күпме генә үтенсә дә, «киребеткән» яшьләр риза булмады. Сүз дә юк, үзләренә теләктәшлек күрсәтә торган башка «җылы урын» тапканнардыр. Нихәл итмәк кирәк, бу хәл институт тарихына «Яшьләр бунты» дигән исем белән кереп калды. Әлбәттә, фән йорты өчен зур югалту иде...

Бу хәлләрдән соң биш еллап вакыт узгач, көннәрдән бер көнне Левин көтмәгәндә, элеге яшь галимнәрнең берсен – Сергей Поповны очратты. Элекке үпкәләрне онытып, җылы гына күрештеләр. «Кайда? Ничек?» – дип сораштыра башларга теле бик кычытса да, остаз галим бу юлы ашыкмады. Әңгәмә үз җае белән башланды.

– Уңышларыбыз шактый, Александр Васильевич, – дип башлады сүзен Сергей.

Левин, бик игътибар белән тыңларга җыенгандай, карашын әңгәмәдәшенә төбәде. Сергей исә сүзен әллә кайлардан әйләндереп башлады:

– Теге вакытта ярый әле халыкара симпозиумда катнаштырдылар һәм ярый әле безнең «Вакыт аша күчеш» теориясен юкка чыгарып, бөтенләй бетереп ташладылар, – диде ул, биш былтыр булган симпозиумда үзләренең фәнни эшләрен бертавыштан кабул итмәүләренең хаклы булуын таныгандай.

Левин үзалдына елмаеп куйды.

– Әйе, ул чынга ашмас теориягез аркасында без ул чакта дөнья галимнәре арасында аздан гына көлкегә калмадык. Тикшеренүләрегезнең уңышсыз булганын хәзер үзегез дә төшендегезме инде?

Бу минутларда Александр Васильевич яшь галимнән: «Әйе, без ялгышканбыз. Хәзер институтка яңадан кайтырга җыенабыз», – дигән сүзләр ишетергә теләде. Тик Сергейның тел төбендә икенче мәгънә ята икән. Ул остазына бөтенләй икенче яктан китереп төрттерде:

– Юк, Александр Васильевич, киресенчә, без нәкъ шул көннән соң эшкә тагын да ныклабрак, җиң сызганып керештек. Ул чакта безнең хезмәтләрнең җитдилеген шик астына алмаган булсалар, бүгенге нәтиҗәләргә ирешмәгән дә булыр идек.

Аның үз-үзен тотышында ниндидер тәкәбберлек чагыла иде.

– Сез бу өлкәдәге тикшеренү эшләрендә алга китеш бар димәкче буласызмы?

– Әлбәттә!

Левин егеткә каш астыннын сөзеп, сынаулы караш ташлады. Шаярып кына сөйләшмиме, янәсе. Яшьләргә ышансаң, алдын-артын уйламыйча, мөгез чыгарып куюлары да бар. Гомерләрен акыл хезмәте белән бәйләгән булсалар да, яшьлек үзенекен итә. Кайчак артык хисләнү өстенлек ала. Хис-тойгылар акыл эшчәнлегенә тискәре йогынты ясап, аны чикли. Бу очракта да шулай түгелме икән? Ләкин ашыгып нәтиҗә ясап, бер мәртәбә авызы пешкән Левин шикләрен белдерергә ашыкмады.

– Йә, сөйләгез алайса, нәрсәләр майтардыгыз соң?

Теге чакта институттан китүчеләрнең кайберләре, яшь булуларына карамастан, гомуми гыйльми эшләрдә катнашып, үз сүзләре белән әйткәндә, уңышларга ирешкән, фән өлкәсендә чирканчык алган кешеләр. Барып чыкмастай кебек тоелган эшләргә дә курыкмыйча алынганнары өчен хөрмәт итә дә инде аларны Левин. Чыннан да, кайвакыт нәрсәдер барып чыкмый икән, әнә шул яшьлекләрен сылтау итеп, күңеленнән генә аларның хаталарын кичерә

иде. Бусында да шундый хәлдер дип, озакка сузылачак ялыктыргыч әңгәмәгә әзерләнгәндәй, яшь галимгә текәлде Александр Васильевич.

– Без вакыт аша күчеш теориясенең буш сүзләр генә түгеллеген исбатлауга ирештек. Тормышка ашардай нәрсә икәнен тәҗрибәдә күрсәтә алабыз...

– Туктагыз, тукта... сез вакыт аша күчешне гамәлдә була торган эш, димәкче буласызмы әллә? – дигән сорау белән бүлде аның сүзләрен остазы.

– Нәкъ шул хакта әйтмәкче булам да инде сезгә, Александр Васильевич. Без, чыннан да, тәҗрибәләр үткәреп, вакыт аша күчешнең мөмкин эш икәнен исбатладык.

Сергейның кыяфәте тагын да тантаналырак төс алды. Аның бу халәте ниндидер яхшы гамәл кылып, атасыннан хуплау сүзләре көткән бала-чаганыкын хәтерләтә иде. Ләкин Левин эшнең асылына төшенеп җитмәгән көе генә аны мактарга җыенмады.

– Бу «сенсация»гезне киң катлау халык арасына чыгарганчы, гыйльми киңәшмәгә куйганчы, башта минем белән сөйләшүегез яхшы анысы. Менә сез, вакыт аша күчешнең мөмкин эш икәнен исбатладык, дисез... Моны ничек аңларга?.. Вакыт машинасы уйлап таптык, дип әйтергә җыенмыйсыздыр бит?

– Әйе, таптык!

– Сез нәрсә?!

Левин шаркылдап көлә башлады. Бу халәтендә аны нәрсәгә дә булса ышандырырга тырышу бик авыр булачагын әңгәмәдәше бик яхшы аңлый.

– Ташлагыз әле бу беркемгә кирәк булмаган шөгылегезне, – дип дәвам итте сүзен кинәт кенә көлүеннән туктап, җитдиләнеп калган Левин. – Алдыма формулалар белән сырланган һәм ахырында, «вакыт аша күчеш бар ул» дип нәтиҗә ясалган берничә томлык фәнни хезмәт китереп куйсагыз да, мин «вакыт машинасы»на ышанмаячакмын. Бүгенге фән үсеше күзлегеннән караганда, әлегә бу мөмкин эш түгел. Вакыт барьерын үтү турында уйлау өчен, ким дигәндә тагын йөз ел кирәк. Аңлыйсызмы, бер гасыр!..

– Александр Васильевич, ә ни өчен бер гасыр көтәргә? Бу теория өстендә эшләүчеләр моннан бер гасыр элек тә булган...

– Булган, ләкин берсе дә уңышка ирешә алмаган. Юкса әллә кайчан «экспресс-вакыт машиналары»нда үткәннәргә кунакка йөрер идек.

Левинның мыскыллы елмаеп әйтелгән репликасы егетнең күңеленә барып кадалмыйча калмады, әлбәттә. Сергей үз карашын тагын да тырышыбрак якларга кереште.

– Уңышка ирешкәннәре булмаса да, әлеге теориягә кагылышлы кыю гипотезалар әйткән галимнәр турында ишетеп беләбез. Фән тарихында 1943 елдагы «Филадельфия эксперименты» дип аталган күләмле эксперимент хакында барыбыз да хәбәрдар.

– Филадельфия экспериментында, белүемчә, вакыйгалар вакыт аша күчешкә кагылмый булса кирәк. Әлеге эксперимент вакытында «Элдридж» судносы үзенең торган урынынннан юкка чыгып, икенче урында пәйда булган. Бу пространствода күчеш, ягъни телепортация була. Аннан соң, шәхсән үзем, ул экспериментның чынлыгына бик үк ышанмыйм. Рәсми чыганаклар бу хакта берни дә дәшми. Шулай булгач, аның имеш-мимеш булуы бик ихтимал.

– Әлеге экспериментта хәрби кораб, күзәтүчеләр күзеннән югалып, шул ук мизгелдә 320 километр ераклыктагы бөтенләй икенче портта пәйда булган. Бер караганда, чыннан да, пространствоның бер ноктасыннан икенче

ноктасына күчеш шикелле. Монда вакытның бернинди катнашы да юк кебек. Ләкин төптәнрәк уйласаң, вакыт та, пространство да материянең яшәү үзлеге булганлыктан, аларның бу экспериментта рольләре тигез булгандыр, дип уйлыйк.

– Ягъни сез, пространствода гына түгел, вакытта да күчеш ясалган, димәкче буласызмы?

– Һичшиксез шулай!

– Ләкин минем мәгълүмат буенча, корабль бер порттан юкка чыккан һәм шул ук мизгелдә икенче портта пәйда булган. Шунысы кызыклы: моңа аз гына да вакыт сарыф ителмәгән, – дип үз фикерен белдерергә ашыкты Левин.

– Бөтен хикмәт тә шунда, Александр Васильевич. Чынлыкта, әнә шул югалып торган мизгелдә, корабль вакыт аралыгы аша башка чорларга күчкән һәм анда берникадәр вакыт торган булуы мөмкин. Ә кире күчеш ясаганда, юкка чыккан мизгелдә пәйда булган. Әгәр шул вакыт эчендә судноның пространствода урын алыштыруы хакында сүз бара икән, вакыт аралыгы тоннеленең безнең җир масштабында гына түгел, галәм масштабында булуын онытмаска кирәк. Шулай булганда, судноның пространствода урынын үзгәртүе аклана. Чөнки башка чорларга күчеп, ул анда күпмедер вакыт узган була инде.

– Димәк, сез Филадельфия эксперименты булган, дип раслыйсыз һәм аны кабатлап карамакчы буласыз? Ләкин теориягездә ялгышлык булып, эксперимент кабат уңышсызлыкка очраса, аңа тотылган чыгымнар үзен акламаса? Андый шикле экспериментларга акча бирергә теләүчеләр табылырмы?

Сергей хәйләкәр генә елмайды. Левинга сынаулы караш ташлады.

– Ә без, Александр Васильевич, экспериментны эшләп карадык инде. Ул уңышлы чыкты.

– Моны ничек аңларга?

– Теләсә ничек аңлагыз. Ләкин лаборатор шартларда эксперимент уздырылды.

– Кайда? Нинди лабораториядә? Андый глобаль эшләргә акча каян таптыгыз?

– Әлеге проект белән кызыксынучылар табылды. Һәм, иң мөһиме, аларда шуның шикелле биш, ун проектны тормышка ашырырлык акча бар. Матди яктан шулар ярдәм итте.

– Кызык! Ничек тормышка ашырдыгыз инде ул проектны?

– Көчле электромагнит кыры хасил итеп, бер урында ясалма гравитация тудырдык. Андый урыннарда пространство бик нык кәкрәя һәм вакыт тоннеле барлыкка китерү өчен уңай шартлар туа. Тоннель аша теләсә кайсы вакытка күчәргә була. Безнең заманнан яки, киресенчә, узган заманнардан безнең вакытка да күчәргә мөмкин. Ә беләсезме, Александар Васильевич, вакыт өермәсенең ешлыгын яисә тоннельнең радиусын теләгәнчә үзгәртү юлы белән без үзебез теләгән вакытка күчә алачакбыз...

Сөйләгәндә, Сергейның күзләре очкынланды. Әлеге эксперимент белән ул шулкадәр илһамланган иде, күрәсең. Дулкынланудан ул тотлыгып-тотлыгып алды, тавышы калтыранды.

*(Ахыры киләсе санда)*



Ренат
Харис

# УНӨЧКӘ УНӨЧ

ПОЭМА-БӘЯН

*Татарстан комсомолының 100 еллыгына.*

Безнең гомер узып бара...
Уйлыймын яшьләр турында –
алар минем йөрәгемә
ялан уч килеш орынган.
Йөрәк ритмнарын саныйм,
үлчим үземнеке белән...
Яшьләр безне кабатларлар,
диеп ышанасы килә.
Әйтәсе килә нәрсәдер,
нидер калдырасы килә...
Юк, алар кабул итмәсләр
безнең киңәшләрне – беләм:
киңәшләр туа тормыштан,
ә тормыш үзгәрә тора...
Ләкин мин үтә беркатлы
истәлек сөйләп калдырам.
Көлсәләр көләрләр, бәлки...
Мин вәгъдәмне кире алмыйм...
Яшьләр беләләр дип уйлыйм –
үткәннән көлү макталмый!..

Ренат ХАРИС (1941) – *Татарстанның халык шагыйре; Россиянең Дәүләт премиясе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Җиде томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Комсомол билеты алу
һәм беренче үбешүем
искә төшә дә ешлата
минем йөрәк тибешемне...
Күз алдыма кабат кайта,
төсле кинотасма сыман:
зур чана таккан трактор,
без – трактор чанасында,
шаярыша-шаярыша,
сигез-тугыз кыз һәм малай
Буага сәфәр тотабыз
кырлар буйлап, юл ягалай,
борылышларны турайтып.
Ярыймы соң соңга калу?!.
Безне анда шатлык көтә –
комсомол билеты алу...
Без укуда тырыш булдык,
төрле ярышта катнаштык,
тәртиптә – сүз тидертмәдек,
күксагызларны[1] саклаштык,
булыштык солдаткаларга[2] –
утын ярдык, су ташыдык,
«Комсомол билеты» дигән
олы шатлыкка ашкынып...
Гранаталар да ыргыттык,
противогазлар да кидек –
Ватан өчен хезмәткә дә,
көрәшкә дә әзер идек.

Товарлар Буадан кайткан
безнең авыл сельпосына[3],
җәен-көзен – машинада,
кышын – трактор чанасында.
Ә бу юлы, бер уңайдан,
безне дә чанага төяп
җибәрделәр «Корыч шулай
чыныга ул!» дия-дия...

Ниһаять, билет кесәдә –
гел карыйсы килә үзен –
аның дүрт орденлы[4] битен
минем сурәтем дә бизи!

Күкрәгемдә значогы –
куанычымның чәчәге –
бишмәтемне ычкындырсам,
бар галәмгә нур чәчәр кук...
Өч-дүрт сәгать райкомолда[5]
тантаналы рәвештә без
билетлар алып йөргәндә,
гыйнвар ае фәрештәсе
буран көтүен тугарган –
карга баткан юллар, өйләр...

Безнең кайтасы юл озын –
утыз километр, диләр!..
Чылбырлы тракторыбыз
көтә-көтә арыгандыр –
алка-алка төтен чөя,
пошкыргалап куя дыр-дыр...
Ә чанасы җилкән киргән
зур бер корабка әйләнгән –
мичкәләр, ящик, капчыклар
брезентлар ябып бәйләнгән.
Брезентларны җилфердәтә
җиле җәяүле буранның...
Без тезелешеп утырдык,
брезентларына урандык,
арканнарына ябыштык
диңгезче хисенә кереп...

Шул чакның романтикасы
әле булса миндә тере...

Якты күздә йөзеп киттек.
Көрт дулкыннарын ярабыз.
Туңсак, төшеп йөгерәбез,
талгач, утырып барабыз...
Агач башына сырышкан
чәүкәләр өере сыман
чәңгелдәшәбез туктаусыз
зур трактор чанасында.
Чана йөзмә утрау кебек!
Карамель конфет хуш исе,
бөтнекле прәннек тәме
ач карынны ала кисеп...

[1] Күксагыз – колхозлар каучук бирә торган үсемлек игәләр иде.
[2] Солдаткалар – ирләре сугышта һәлак булган тол хатыннар.
[3] Сельпо – (рус.) сельское потребительское общество. Авыл кибетләрен товар белән тәэмин итүче сәүдә оешмасы.
[4] Ул елларда комсомолның дүрт кенә ордены бар иде.
[5] Райкомол – комсомолның район комитеты.

Ящикны ачасы килә...
Ярамый! Без нык торабыз –
җәяүле буран җилендә
«корычны чыныктырабыз!»

Салулап киткәндә чана,
селёдка сиздерә үзен –
әйтерсең, кар диңгезендә
безнең арттан бара йөзеп;
Икенче якка янтайса,
керосин исе тарала.
Тимер мичкәләр олауның
алгы ягында баралар.

Кич җәелде кар өстенә.
Төн куерды. Ай калыкты.
Җилсез якка җыйды суык
комсомол дигән халыкны.
Арканнарга ябышып, без
бер-беребезгә елышып,
иснибез бер-беребезнең
дулкынландыргыч сулышын.
Ә мин янымдагы кызның
куенына ук кергәнмен –
бишмәт аша иңем тоя
ике җып-җылы төргәген...
Йөрәкнең татлы тибешен
ул кыз да ишетә кебек...
Кая туңу – тирләп чыкты
бүрек астында чәч төбе!
Әллә нәрсә булды миңа –
аптыраш зәхмәте тиде...
– Минем билетның саннары
унөчкә унҗиде[6], – дидем,
башка сүз таба алмыйча,
чыга-чыга куеныннан.
Ә ул мине үзенәрәк
тартып куйды кыю гына.
– Туңасың бит... Калтырыйсың,
шулай гына утыр, – диде...
Аның да йөрәге дулый,
ул да калтырана иде.
– Синекенең саны нинди? –
дип сорадым чарасыздан, –
шәт, бәхетле сандыр әле?..
Һәм аңлатып бирдем аңа:

– Билет сигез саннан, – дидем, –
беренче дүрт сан суммасы
икенче дүрт санныкыннан
ким дә, артык та булмасын...

...Ай балкый. Кораб-чанабыз
кар диңгезен ярып бара...
– Билетым куен кесәмдә,
сиңа җайлы – ал да кара, –
диде миңа «җылы куен»
шаярыпмы, ихластанмы...
Киез итек үкчәсенә
төшеп китте кебек җаным –
ничек итеп тыгыласың
кыз кешенең куенына?!.
Анда бит әллә нәрсә бар –
уйлавы да кыен миңа!

«Комсомол ул – кыю кеше!» –
дип әйтүем райкомолда
искә төште. Хисләремнең
дилбегәсен урап кулга,
әрсезлеккә ирек биреп,
билет алырга тыгылдым...
Нидер булды... Икәү бергә
Кар диңгезенә егылдык,
ә трактор китә бирде
җәяүле буран эченә...
Ул туктады комсомоллар
кычкыргач та бар көченә...
Безне уратып алдылар –
кагалар өсләребезне...
Ә кыз, түшен капшый-капшый,
борчылып, нәрсәдер эзли.
Мин комсомол билетына
барып җитә алмый калдым...
– Кызлар, значок югалды,
кызлар, значок югалды, –
диеп ачыргаланды ул
битен сөртеп шәле белән, –
тотып карамакчы идем,
төшеп китте әле генә...

Һәм без эзләргә керештек
значокны, кар актарып,
өреп җылыта-җылыта
боздай каткан бармакларны.

[6] Авторның 1955 елның гыйнварында алган комсомол билетының номеры 18041097.

Салкын күктә – бозланган Ай,
ә җирдә – җәяүле буран,
кар диңгезе уртасында
трактор гөрелдәп тора.
Без эзлибез тырнак зурлык
ун тиенлек значокны –
кар астыннан камыл чыга,
башак чыга, ә ул чыкмый...
Тракторчы йөгереп килде
шахтёр фонарен кабызып,
укытучы апабыз да
карны или кызып-кызып.
«Төкер башына, кузгалыйк,
мәктәптә дә бар ул!» диеп,
беркем дә ашыктырмады
һәм тормады башка төеп...
Бу минутта бар дөньяда
моннан да зур югалтуның
булуын да уйламыйча,
эзләгәндәй комнан алтын,
йә аятле йөзек кашын,
йә пәйгамбәрләр дисбесен,
эзләдек без комсомолның
алтын профильле билгесен.
Эзлибез... Йөрәкләр тибә:
кайда инде, кайда, кайда?
Йолдызлар да эзләшәләр,
нурын сибеп тора Ай да.
Җәяүле буран да бераз
юашланган булып акты...
Һәм мин бар көчкә кычкырдым:
– Таптып значокны, таптым!..
Бөтенесе туктап калды...
Урнашты кыркүләм тынлык.
Трактор да ишетелми –
әйтерсең, тынлыкны тыңлый,
әйтерсең, минем кулымда
Хоттабыч бикләнгән чүлмәк,
Яки Галәтдин лампасы,
йә күренми торган күлмәк,
Яки метеорит булып
күктән иңгән бөек хәбәр...
Ә юеш учымда бары
маникюрлы тырнак кадәр
нәрсә ята. Ай да аңа
исе китеп карый кебек –
нинди шатлык! Кайгы иде
ярты гына сәгать элек...
Мине уратып алдылар...
Торам серле карга батып,
беркайчан да булмаганча
кайнар шатлык хисе татып,
бу кадерле табылдыкны
кызның алъяпкыч түшенә
беркетүемне күзаллап,
хыялланып үзтөшемә...

Елый-елый арып беткән
кыз да тынычланып калды...
Значокны аңа суздым...
Һәм ул мине
үбеп алды
укытучыбыз алдында,
тракторчыбыз алдында,
һәм комсомоллар алдында,
кыр уртасында, салкында...
Керфекләре карлы-бозлы,
иреннәре кайнар, тозлы
иде шатлыгыннан шашкан,
бәхетен учлаган кызның...

Әле булса мин шаккатам:
шундый бирелеп эзләдек,
без таптанган урында кар
он була язды – түзмәде.
Юкса һәр кибеттә, өйдә
бар ич комсомол билгесе!..
Кар-бураннан өстен иде
ул чак романтика хисе.
Экзотик сәяхәтләрдән,
яхталардан ерак иде,
ул – бөек төзелешләрне
рухландырган йөрәк иде!
Ул билгене түшкә таксак,
йөрәгебез горур типте!
Күпләребезне комсомол
илебезгә бизәк итте,
максаты булган кешегә
шул тарафка эзләште юл,
тормышта үз урыныңны
табарга да булышты ул...
Беләм лә, беләм – комсомол
һич тә күк капусы түгел,
ләкин аңарга торырлык
бирәр нәрсә бармы бүген –
яшьләрне күмәк максатта
берләштереп төйни торган,
йөрәкләрен ил йөрәге
тибешенә көйли торган?!.

Исән-имин кайтып җиттек...
Һәммәбезне инде күптән
өйдәгеләр, горурланып,
тәмле табын корып көткән...
Каникул бетми йөдәтә,
мәктәпкә ашкына йөрәк,
комсомол билгесе тагып,
күренәсе килә тизрәк –
безгә кызыгып караган
пионерларга бигрәк тә!
Комсомол ул малайларны
егет булырга өйрәтә!

Ниһаять, каникул бетте...
Тагып комсомол билгесен,
мин мәктәпкә барып кердем...
Газаплы сагыну хисе
әллә нишләтә йөрәкне,
кайларгадыр талпындыра...
Гөлле тәрәзә янында
шул «кайларга» басып тора.
Мине күрү белән ул да
талпынып куйды шикелле –
чак-чак бәреп төшермәде
кышын чәчәк аткан гөлне.
Ашкындым аның янына –
әллә чаптым, әллә очтым...
Түшендәге значогы
сибеп тора кебек очкын.
Комсомол билетын тоткан,
күзләрендә сихерле көч.
Колагыма пышылдады:
– Минеке – унөчкә унөч!..
Билетын ул дүрт кешегә
миннән алдан алган иде –
аныкы – унөчкә унөч,
миндә – унөчкә унҗиде.
– Чыннан да мин бәхетледер –
значогым да табылды! –
диде ул, һәм иреннәре
утлы битемә кагылды.

Каушап калдым – үбешергә
әле өйрәнмәгән ич мин!..

Бүгенгәчә хәтеремдә
шуннан калган үкенечем...

Бәхетле булды микән ул?..
Язмышы миңа билгесез...
Шул ук көздә бу авылдан
күченеп киткән идек без...

Ахры, шул вакыттан бирле
яратамындыр унөчне –
комсомолга керүем һәм
беренче үбешү өчен...

Беркем дә абайламады,
Ай гына хәйләмне күрде –
теге чакта
мин үземнең
значокны «табып» бирдем.

Хәтер күпме ел саклаган
шул серем һәм «үбешүем»
искә төшә дә матурлый
талган йөрәк тибешемне,
сугара романтиканың
җанымдагы гөлчәчәген...
Шул үткәнемне сагынам!..
Юк! Сагынам киләчәкне...
Без киләчәкне сагынып,
Заманга җигелеп үстек!..
Шуннан калган романтика
меркантиль хисләрдән өстен!
Янә теге кырга барып,
туфрагын иләктә иләп,
табып комсомол билгесен
күкрәккә тагасы килә.



Кәрим
Кара

# ҖИЛӘКЛЕ АЛАН

ПОВЕСТЬ

Көннәрдән бер көнне Хәтимәнең гомер иткән ире Сабир гаип булды. Башка сыймастай яңалык иде бу хатын өчен. Сабирның эш вакыты беткәч, гадәттәгечә, тәмәкесен пошкытып, капкадан кермәгәненә дә артык исе китмәде. Ник дигәндә, Хәтимәнең җене кузгалып тора иде, тегесе күзгә күренгәч тә шәрран ярып, күңелендәгесен ачып салырга ниятләп куйган иде. Төгәл вакытында кайтып кергән кешегә тавыш күтәрү бик килешеп тә бетмәс төсле тоелды аңа. Бераз соңлабрак кайтса, күкрәк киереп талаша башларга була, ичмасам.

Шулай ун-унбиш минутлап вакыт үтте, йорт як тәрәзәдән Сабирының сарыга манылган төсле бөдрәләре һаман күренмәде. Хәтимә җилләнеп болдырга чыгып басты, кулын каш өстенә куеп, елга аръягына күз салды. Юк иде теге хәшәп, аръякта да, басма өстендә дә, өйгә таба кыеклаган үрдә дә. Хәтимә очлы күзләре белән шундук танып ала иде аны. Басмага якыная башласа, ашыгып кереп, куна тактасына учлап он сибеп җибәрә, бит алмаларына, ияк очларына он сөртеп куя, янәсе ул күптәннән иренең тамагын туйдырыр өчен җан-фәрман тырыша, кадерен белүче генә юк... Бу юлы таныш сын күренмәде, ике кыз бала чыелдашып бозауларын куалыйлар да малай-шалай балык кармаклап булаша...

Бүген куна тактаны кузгатуның кирәге юк иде, хәер, планына да кертмәде хатын аш-су белән кайнашуларны. Тавыш башлаган булып, тегене ачтан интектерергә уйлап куйган иде. Ниемә көннең көне шуның өчен сызылырга, күңелне җылытырлык бертөрле сәбәп тә бирми бит ул, чукынчык. Алып кайткан акчасы – ташка үлчим, атасыннан калган йорты ишелергә җиткән, төсе-башы күңел кайтарырлык җирән шайтанның башка якларын телгә дә аласы килми. Мондый тормыштан тәмам туеп, гарык булып тавыш башларга җыена да иде инде хатын. Каны кайнап, нәрсәгә барып тотынырга белмичә, ишекле-түрле йөрде Хәтимә, телевизорны бар көченә акыртып куйды. Бар вөҗүде киеренкелектә иде аның, түземсезлек белән көтте теге адәм актыгының ишекне ачып керүен. Ничек үч аласын күзаллап рәхәт кичерде, берсеннән-берсе усалрак сүзләрне сайлап күңеленә беркетеп куйды.

---

Кәрим КАРА (1956) – *прозаик; «Без әнкәйнең йөрәгеннән чыктык» исемле китап авторы. Тәтештә яши.*

Ни гаҗәп, стенадагы герле сәгать җидене сукканда, бар дөньяда тынлык иде. Бу инде Сабирның тимерлектән китүенә бер сәгать үткән дигән сүз. Бер-бер хәл булдымы икән әллә, Ходаем? Хәтимә сикереп торып телевизорны сүндерде, чак боргычын сындырып чыгармады. Тагын болдыр алдына чыгып басты, куллары белән үз-үзен кочаклады, зәңгәр күзләрен таныш сукмакка юнәлтте. Юк, юк, барысы да аңлашылды болай булгач, аңын югалтканчы эчкән инде ул «ыштан балак тамак». Үзенең акчасы юк, берәр юмарты сыйлагандыр. Ә бу «күргәндә кормить надо» дип, коенгандыр җирбит, ятадыр берәр куак төбендә аяк-кулын сизми. Башка сәбәп булуы мөмкин түгел! Эштә тоткарлаганнары юк аны, җыелышлары биш елга бер тапкыр булды, ахрысы. Анысында да алдан кисәтеп кайтарганнар иде. Арадагы елга ташымаган, йөргән сукмагына таш яумады, сугыш башланмаган, әнә телевизор туктамый бытылдап тора. Шул бер генә сәбәп! Ну җирән шайтан, кайтып күзгә күренсен генә, өстенә менеп утырып иманын укытачак аңа Хәтимә, ник туганына үкенерлек итәр!

Күк йөзенә кичке шәфәкъ кызыллыгы йөгерде, урам тутырып көтү кайтты, суга төшкәндәй юкка чыкты Сабиры. Тәмам түземлеге төкәнгән Хәтимә телефон каршында кыбырсып бер тын утырып алды. Чишмә катындагы Гөлсарага шалтыратудан чак тыелды. Гөлсараның ире Ринат аның Сабиры белән бер тимерчелектә эшли иде. Кайткач та сайрагандыр хатынына соңгы яңалыкларны, тәгаен beләдер Гөлсара аның Сабирының кайда икәнлеген. Әмма, әмма... Болай дустанә мөнәсәбәттә алар Гөлсара белән. Очраша калсалар, сөйләшеп сүзләре бетми, үз тиңнәренең сөякләрен юарга өлгерәләр. Шул сөйләшкән арада да Гөлсара үзенең кемлеген искәртергә форсат таба, өстәнрәк карап сөйләшә. Шулай булмый соң, аларны чагыштырырлыкмы Хәтимәләрнең гаиләләре белән? Кызыл кирпечтән урап чыккысыз итеп өй салып керделәр, ире машинада җилдерә, аның һушсызы кебек җәяүләп элдертми елга аша, Гөлсараның эше дә бар – почта тарата. Анысы да эш бүгенге көндә. Менә шуңа шалтыратасы килми Хәтимәнең, тормышыннан зарланасы килми. Нигә шатландырырга?

Ничә еллар яшәп, Сабирның бер тапкыр да өенә кайтмый, читтә кунып калган чагы булмады. Яшерен-батырын түгел, эчкәли анысы, кайчакта чамасын онытып җибәрә, чукынган нәрсә, гуҗ тамак. Анысы өчен хисап тотасылары әле алда, кырык костырыр әле монысын Хәтимә. Бүген аңа нәрсәдер сөйләүнең мәгънәсе юк, әмма кайткан вакытын төгәл белгеләргә кирәк.

Тамагына ризык бармады Хәтимәнең, ут алып тормады. Яңа бозаулаган сыерын күптән ашатып-эчертеп, савып, бозавын туйдырып куйган иде. Бары чыгып аяк астында чыбалган үрдәкләрен ояларына куып кертте дә күптән төнәгән тавыкларының ишекләренә арата салды. Йолдызлар калыктымы, авылны тынлык сара, ник бер тавыш ишетелсен, хәтта этләр дә тынып кала, ахрысы. Бүгенге тынлык аерата нык тәэсир итте Хәтимәгә, никтер шомлы тоелды.

Урын-җирен таратмый гына, бер кат япмага капланып, башын мендәргә төртте ул, әмма бар халәтен киеренкелек чорнаган иде. Хәзер менә шыгырдап капка ачылыр, йөткергәләп Сабиры үтәр, авыр куллары белән чолан ишеген дөбердәтергә тотыныр кебек иде.

Җәйге кыска төн үтеп, каршыдагы тәрәзә агара башлагач кына, бераз онытылып китте ул. Йокысы да йокы булмады, саташулы төшләр җанын җәфалады. Имеш тә Сабир басма аша чыкканда, елгага төшеп, агымга каршы көрәшә, кулларын сузып, Хәтимәдән тартып чыгаруын сорый... Көлеп үләрсең

төшенә дә, язгы ташуларда да авылны бүлеп аккан елганың суы тубыктан югары күтәрелми, нинди агып китүләр, ди анда...

Төн шулай үтте, ә менә аның Сабиры кайтмады. Нәрсәгә дә юрарга белмәде хатын. Иртән һушына килеп, үрмәләп булса да, тупсасына кайтып егыла торган иде бит ул. Әллә чынлап та берәр бәлагә тарыганмы хәләл җефете? Монда Хәтимә аны эттән эткә салып сүгә, ә бәлки иң авыр минутларын кичерәдер Сабиры. Юк, нидер кылырга кирәк, болай өйдә җәелеп утырып эш чыкмас, дигән ныклы карарга килде хатын. Торып, бер чынаяк чәй эчеп алды, йөгерә-атлый өй эшләрен караштырды, өс-башын алыштырып, ишеген бикләп, өй алдына чыгып басты.

Чыгып басты Хәтимә, әмма кай тарафкадыр атлап китәргә икеләнеп калды. Мондый халәттә булганы юк иде шикелле аның әлегә кадәр. Үткәне-сүткәне иренең гидайлыкта йөргәнен, өйдә кунмаганын беләдер кебек тоелды. Хәзер тирәләп алып сораша башларлар, читкә карап ирен читләре белән генә елмаерлар, ах-вах килеп хәленә кергәндәй кыланырлар... Эче тулы ялкын иде хатынның, әмма бар көчен туплап, башын югары күтәреп атлап китте ул, сәлам биргәннәргә баш кагып кына барды. Дөресен генә әйткәндә, беркемнең дә эше юк иде Хәтимәдә, бары нишләп таңнан урамда киләп-сарып йөри, дигәнрәк кыяфәттә артыннан карап калдылар. Бу җитешсезлек барыбызда да сизелә: һәркем синең кайда басканыңны тикшереп тора, дип фикер йөртәбез, кырык төрле фаразлар кылабыз, янабыз, көябез... Баксаң, беркемгә дә кирәгебез юк икән, иң якын дигәннәребез дә безне үзебез исләренә төшерсәк кенә, телгә алалар икән.

Гөлсараларның кызыл өе үзенә тартты Хәтимәне. Горурлыгын җиңеп, сырлы тимер капканы ачып, эчкә үтте ул, тавышына мөмкин кадәр йомшаклык салып, ачык тәрәзәгә эндәште:

– Гөлсарау-у, ахирәткәй, өйдәсеңме?

Аның тавышын ишетеп булса кирәк, абзар капкасыннан тубык башлары чыккан трико киеп куйган, ялбыр чәчләренә хан заманындагы шәл ураган Гөлсара башын тыкты:

– Кем бар анда? – диде ул төксе генә. Туктамый кулларынниндидер төсен югалткан чүпрәк кисәгенә сөрткәләде. Тәрәзә каршында киенеп-ясанып куйган Хәтимәне күреп алгач кына, йөзенә ясалма елмаю җәелде:

– Әйкәем! Синмени бу?.. Танырлык түгелсең, чукынчык...

Резин галушларын лаштырдатып кунакка таба атлады, күрешергә кулларын сузды:

– Кәртинкә кебексең дә, дускаем. Бу кофтаны кайдан алган идең соң? Бер дә күргәнем булмады.Үзеңне карыйсың син, яңасы өстенә яңасын алып кына торасың. Мин менә карачкы төсле киенеп куйдым да... Бозауларны эчерә идем, харап холыксызлар, кигән киемнең карарлыгын калдырмыйлар, рәхмәт төшкерләре...

Күрешкәч тә, куллары белән Хәтимәнең яңа кофтасын чеметкәләп карады әле Гөлсара. «Шакшы бармакларының эзен калдыра инде», – дип хафаланды Хәтимә. Әмма аны-моны сиздермәде, сандугач булып сайрады:

– И-и, яңа түгел инде ул, үткән ел шәһәр универмагында юлыккан идем. Шуннан бирле ятты, менә бүген кияргә булдым әле. Хәлләрең ничек, ахирәткәем, эшләп буламы? Ринат эшкә киткәндер инде...

Телләреннән бал тамса да, ахирәтен күзәтте ул. Нәрсә белгеле икән моңа? Сабирның эштән кайтмый калуы турында хәбәрдармы? Нигә Хәтимәне

бүлдереп, шул яңалыгын уртаклашырга ашыкмый? Әллә юри сузамы, озаккарак сузылсын әле газаплары, диме? Иртәдән бизәнеп-төзәнеп куйган, дип тә ошатмады, ахрысы... Ә карашында берни сизелми...

– Син кием сайлый беләсең инде ул, нәрсә алсаң, сыланып кына тора гәүдәңә. Мин менә ничә тапкырлар барып алыштырам, сәгатьләр буе сайланам, бер күңелгә ятканы табылмый. Йә киң булып чыга, йә тар шунда, озын-кыска, һич килештерә алмыйм. Әле үзең кая киттең болай купшыланып вакытлы-вакытсыз? Ирне эшкә озаткан да инде бу...

Гөлсара тагын нәрсәләр әйткәндер, калганнарын ишетмәде Хәтимә. Бары аның сүзләренә елмаеп, баш чайкап торган булды. Ник дигәндә, иң кирәген ишеткән иде инде ул! Сабиры турында берни белми бу пумала баш, чәчләрен әзрәк җыярга өйрәнсен иде, ичмасам...

Сөйләргә Гөлсарага куш инде, хәер, бар хатын-кыз бер чыбыктан сөрелгән. Әле менә бернинди мантыйксыз икенче нәрсә турында сөйләргә тотынган иде ул.

– Кара әле, әйкәем, бит алмалары, маңгай тигез булсын, дисәң, сыер тизәге беренче ярдәм, имеш. Аны күптәннән чит илләрдә кулланалар икән. Безнең илдән поездлар вагон-вагон ферма тизәген французларга ташыйлар, ди. Ә без, юка башлар, шуны белмәгәнбез. Миңа рецептын өйрәттеләр: бер аш кашыгы яңа төшкән беленнән...

Калганын Хәтимә тыңлап тормады.

– Ашыга идем, ахирәт. Автобуска соңга калырмын, дип куркам. Икенче юлы иркенләп сөйләшербез әле. Ярый, сау бул... – дип, җил-җил атлап чыгып та китте.

– Нигә килүең иде соң? Сиңа әйтәм, Хәтимә-ә... – дип аның артыннан кычкырды тәмам аптырашка калган Гөлсарасы. Шундый шифалы рецептны белергә теләмәгән кеше булуы да гаҗәпләндергән иде аны.

Шәп-шәп атлаган Хәтимәнең өрфия косынка каплаган башында капма-каршы уйлар чәкәләшә иде. Бер яктан Гөлсараның ире турында хәбәрдар булмавы аның күңелен күтәреп җибәрде. Димәк, Сабир эчеп, дуңгыз фигыленә кереп йөрмәгән дигән нәтиҗә чыгарырга була иде моннан. Икенче яктан, билгесезлек утларга салды хатынны. Тәртәгә типмәгән икән, эшеннән вакытында кайтып киткән икән, нигә үз бусагасына кайтып җитмәгән? Әллә... әллә берәр нечкә сыйрак яулаганмы Сабирның күңелен? Башка берәү белән бер юрган астында йоклаганмы? Мыштым гына Хәтимәне аерып, яшь сөяркәсенә никахланырга йөриме?

Барган җиреннән туктап калды Хәтимә. Һушына килеп як-ягына каранды. Берәрсе күреп калмасын аның шулай исәрләнеп атлаганын. Бу уйны бер тын уңга-сулга куалаганнан соң, җиңел сулап куйды. Булмас ул үшәннән башка хатын-кыз белән кети-мети уйнаулар. Бигрәк сүрән бит ул мәхәббәт эшендә, барып чыккан ялкау. Төскә-башка да алдыра алмаган: эре-эре сипкелләр каплаган битен-башын, зәңгәрлеге җуелган күзләрендә моң әсәре юк, буйга да кайтыш. Бик тә ир-атка сусаган хатын-кыз тап булса гына инде. Анысы да араларны тизрәк кырт өзәр иде, менә Хәтимә түзгән була әле. Хәер, аның да түземлеге төкәнгән инде...

Олы юлдан кырт борылып күпергә таба китте Хәтимә. Турыдан суктырырга иде исәбе Сабирның эш урынына. Ишетсә, анда төгәл җавап ишетер, дөреслекне белер. Шуннан башка ничек күңеленә тынычлык табарсың? Кеше кадәр кеше аяз җәйге көндә зым-зыя юкка чыксын да, син кул кушырып утыр имеш.

Тимерчелек урнашкан Солтан авылына кадәр өч чакрым ара иде. Хатын үз уйларына уралып, килеп җиткәнен сизми дә калды. Тимер коймалар артында урнашкан гаражга якынайгач кына адымнарын әкренәйтте. Гел ирләр чуалган бу ят урынга барып керүләре авыррак иде аның өчен. Шулай да белгәннәрен укып, сырлы тоткага тотынды. Рәхмәт төшкере, башлап авылдашы күреп алды. Эш киемнәре киеп куйган Ринат бар тешләрен елтыратып каршысына килеп чыкты.

– Оп-ля, кайдан адашып килеп чыктың монда, чибәркәй? Әллә үзебезнең Хәтимә инде? Сабир үзе урынына сине җибәрдеме эшкә? Вәт рәхәткә чыккан минем авылдаш. Ятадыр өйдә түшәмгә төкереп, әйдә хатыны чүкеч белән тимер кыйнасын...

– Шаярма әле, Ринат, шаярудан узган монда, – дип, Хәтимә тегенең авызын япты, йөзенә җитдилек чыгарып, – бар, үзен чакыр әле монда. Ашыгыч эш килеп чыкты.

Бу сүзләрдән Ринатның йөзе дә җитдиләнде:

– Сабир бүген килмәде. Әллә чирләп-фәлән киттеме?

Мондый җавап көтмәгән иде Хәтимә. Шаяртуымы, дип сынап карап куйды да, Ринатның гөнаһсыз карашын тоеп, бу уеннан кире кайтты. Кинәт кенә тамагы кипте, тубык буыннарының хәле китте. Боларның барысын нәрсәгә юрарга икән инде?

– Ә кичә, кичә эштән соң ничек аерылыштыгыз сез? – диде ул карлыгып калган тавыш белән.

– Ничек дип ни... эш киемнәрен алыштырганнан соң, егетләр белән контор кырында җыелышып берәр тәмәке тарттык әле. Эш хакын күтәрәләр, имеш дигән сүзләр йөри, шул хакта хыялланып утырдык. Аннан соң мин Сабирга бергә кайтыйк, дидем. Ә ул киребеткән: «Юк, саф һава сулап кайтам, турыдан синнән алдарак кайтып җитәм», – дип тешен ыржайтты. Мин машинага юнәлдем, ул әнә теге каеннар арасындагы сукмактан эре-эре атлап кереп китте. И шуның белән... Ә-ә, тагы...

Тагын нәрсә икәнен әйтеп өлгермәде авылдашы, алар каршында энәдән-җептән киенгән таза гәүдәле ир пәйда булды.

– Ник эш урынында түгел, Кәбиров? Нинди ят кешеләр йөри территориядә, пынимаешь? – дип тезеп китте ул. Тавышыннан ук бу бәндәнең иң җаваплы түрә икәнлеген чамаларга була иде. Коелып төшкән Хәтимә тизрәк чыгып китәргә борылып баскач, хәерсез Ринат кирәкмәгән сүзләр ычкындырды:

– Бу иптәш Сабирның хатыны була, иптәш завгар. И как раз иренең кайдалыгын белешеп килгән...

Шып туктады Хәтимә, кызарып чыккан йөзе түбәнгә иелде. И күрәселәре бар икән шул адәм имгәге хакына бу фани дөньяларда…

– Эш урынында юк, дидегезме әле Мөнировны? Как так? Прогул бүгенге көн өчен, пынимаешь, премиядән лишать итәргә квартал азагында. Самый кызу эш вакытында, коллективны подводить итеп, так сказать... Кстати, үзе кайда соң әле ул?!

Хуҗа күзләренең агын әйләндереп, Хәтимәгә текәлде, чабып туктаган ат төсле пошкырынды. Куркудан сыны катты Хәтимәнең, авыз эчендә ботка пешерде:

– Чирләп тора иде ул. Шуны хәбәр итәргә килгән идем дә...

Бу сүзләргә отыры кабарып китте хуҗа кеше:

– Как так? Самый кирәк чакта Мөниров юк. Чакырасың, ул салмыш баштан

имеш. Кичә капмаган идеме алай? – дип, бу сөйләшүне хозурланып тыңлап торган Ринатка таба борылды. Тегесе аякка аякны бәреп алды, кулларын төз тотып, хәрбиләрчә төгәл җавап бирде:

– Кайтып киткәндә фәрештә сурәтендә иде, калган өлеше хакында бихәбәрмен...

Тәртип өчен янган-көйгән түрә турында аерып берничә сүз әйтеп китәргә кирәктер. Автомеханиклыкка укып чыккан сыек кына яшүсмерне профсоюз линиясе буенча үрләтеп куйдылар. Бик тә килешле булды ул яңа урында. Югарыдагыларның авызларына гына карап торды, фәрманнарын үтәп көн чапты, төн чапты, барысына да ярый белде. Шунысы бар – ул башлыклар арасына бер кереп эләксәң, синә калган тормышыңда җил-яңгыр тидермиләр, үзләре ашаган тагарактан коелганнарны чүпләргә рөхсәт итәләр. Профсоюз лидерын да онытмадылар, вакыты җиткәч, менә завгар итеп үрләттеләр. Бу инде чын-чынлап түрәләр чутына кердең, дигән сүз иде. Шундый зур коллектив белән җитәкчелек итәргә, ай-һай, зур осталык кирәк. Шулайрак уйлап, шөлләп тә калган иде ул: хәлемнән килерме, сөйри алырмынмы бу саллы йөкне? Юкка хафаланган. Атна җылытты ул кабинетындагы кәнәфине, ай узды – кырган эше күзгә күренмәде. Әмма һәр эш майланган төсле барды. Аңа кадәр булган хуҗаның да бишенче тәгәрмәч булганын чамалап алды ул. Бу коллективта кирәкле кадрлар үз урыннарында, эш тәртибен нечкәлекләренә кадәр беләләр, ул ел буе килеп күренмәсә дә, бер үзгәреш тә булмаячак. Вәләкин үзенең түрә икәнлеген акларга кирәк иде аңа. Белеп торсыннар кемнең кем икәнлеген! Һәм яңа тәртипләр урнаштырырга алынды яңа хуҗа. Ә тәртип урнаштыруның иң җиңел ысулы – өстәл сугу, тавыш күтәрү, кара исемлеккә теркәү, барысын да куркыту. Моңа ул җиңел ирешә. Гадәтенә сеңдереп, бу алымны бар кешеләргә карата куллана башлады. Өйдәгеләрне бер йодрыкка йомарлады. Хатыны, мескен, башын күтәреп карарга курыкты, балалары телсезгә әйләнде. Туган-тумачаларына очрашкан саен акыл өйрәтте, тегеләрнең сүзләрен колагына элмәде. Кайчандыр дуслар исәпләнгән тиңдәшләре белән араларны кырт өзде. Алар кем дә, ул кем?! Әнә шулай утрауда ялгыз калган адәм төсле тормыш алып барды ул. Кашлар җыерылган, иреннәр кысылган – шундый кыяфәттә булды кешеләр арасында. Бары йоклаганда язылса язылып киткәләгәндер чырае. Якыннары арасында яшеннәр яшьнәтте, ятлар арасында ни әйтергә белми җәфа чикте. Бары җыелышларда утыру, кемнәрнеңдер акыллы нотыкларын тыңлау күңеленә тынычлык бирә иде. Иң курыкканы – өйрәнгән кәнәфине калдыру һәм чиргә тару иде. Эштән китәсе килмәгәнлеге аңлашылса, икенче сәбәпнең үз сере бар. Укол куйдырудан курка иде ул, шул ук вакытта мондый җаваплы эштә эшләгән кеше, ниндидер «сестра» кызыкай алдында чалбарын салып, очасын ялтыратып ятсынмы? Хурлыгыннан үләргә кирәк бит... (Әнә шундый тузга язмаган куркулар булгалый адәм балаларында!) Аңлашыла булса кирәк, үзенең сәламәтлеген кайгыртып яши иде түрә.

– Бер атна срок аңа. Чирлисен чирләп, как «свежий огурчик» килеп бассын минем каршыма аннары. Килмәсә – үзенә үпкәләсен. Аның илке-салкы йөрүләре во кайда минем!

Завгар җәлпәк учы белән шап та шоп киң җилкәсенә суккалады да, үзалдынаниләрдер сөйләнеп китеп барды. Тын алырга да куркып торган Хәтимәнең йөзенә бераз алсулык керде.Ул тирә-якны чамалый башлаганчы, Ринат юкка чыкты. Хәтимәгә таныш сырлы капкадан чыгып китүдән башка чара калмады.

Башка барып егылыр кешесе юк иде аның. Эш урынында да берни белмәгәч, тагын кем нинди яңалык өсти алсын?

Кайтканда басма аша кайтты ул, бәлки, Сабиры үткән сукмак буенда бер-бер билге калгандыр... Өметләнүләре юкка гына булды. Нинди билге булсын инде, монда барысы күз алдында, авылдан караганда, сукмак салынган болын таба кебек ялтырап ята. Тәмам әлсерәп кайтып егылды хатын өенә. Авыр уйлар фигылен какшатты, көне дә иртәдән кыздыра иде бүген...

* * *

Аруы җиткән булган, күрәсең, беразга баш терәп торам, дигән иде, эленеп киткән. Күзләрен ачып җибәргәндә, кояш төшлеккә күтәрелгән иде инде. Тиз генә өс-башын алыштырды, чыгып, кош-кортларына күз салды, сыерына су бирде. Вак-төяк мәшәкатьләрдән арынгач, кереп чәй куйды. Кичә кичтән бирле рәтле-башлы тамагын караганы юк иде. Ашыйсы килмәсә дә, йомырка тәбәсе кыздырып алды. Кем әйтмешли, ашаган малда гына өмет бар. Өстәл каршындагы сары нарат бүрәнәләренә карап, икмәк күшәде, чәй чупырдатты. Кичке якта гел Сабиры биләп ала торган телефон янындагы йомшак кәнәфигә күчеп утырды да тынып калды.

Хәлләр... Кеше ышанмастай тарих бит бу, ныклабрак уйласаң. Кайда гаип булды икән соң хәләл җефете? Явыз бәндәләргә юлыгып, корбан булдымы? Кайдан килгән ди бу өч өйдән торган авыллар янына җан кыючылар, ни калган аларга монда? Төн уртасында югалса, бер хәл, ә монда көпә-көндез, берсе күрмәсә, берсе күрер иде фаҗигане. Бу фаразны уйлап та тормый сызып ташларга була. Тамагын тыя алмый берәрсе белән парлашып йөриме? Юк, тагын бер кат юк. Сабир һуштан язганчы эчкән булса да, әз генә айный башлау белән һәрвакыт өенә кайтырга тырышты. Гаебен танып, Хәтимәсе каршына килеп тубыклана иде ул, төзәлергә антлар эчә иде. Хәзер генә үзгәрмәс, шикләнәсе дә түгел. Берәр тарафка китеп олакканмы? Андый хәл турында ишеткәне бар иде Хәтимәнең. Әнә ике өй аша торган Сәриянең апасы Казан уртасында бер дигән фатирда ире белән чөкердәшеп яшәгәннәр. Карап туйгысыз кызлар үстергәннәр. Ире ниндидер заводта инженер вазифасында хезмәт иткән имеш, ә апасы зур кибеттә – товаровед. Гомумән, абруйлы кешеләр кайсы яктан карасаң да. Менә шул Сәриянең апасының инженер ире бердәнбер көнне туган авылына кайтып килергә булган, әллә Сабага, әллә Актанышка шунда. Ялгызы гына. Аны-моны уйламаган беркатлы хатын ризалашкан, яхшы киемнәрен юл сумкасына дыңгычлап тутырган, күчтәнәчкә-фәлән кирәк булыр дип, үз куллары белән мул гына акча да биргән. Хушлашканда ир, хатынының алма битләреннән чуп-чуп үпкән. Һәм шуннан соң суга төшкәндәй юкка чыккан. Актанышында да күрмәгәннәр үзен, сөекле хатыны янына да кире кайтмаган. Вәссәлам! Теге Сәриянең апасы чирек гасыр яши шундый хәлдә: ирле хатын да түгел, аерылмаган да. Бар киемнәрен, кәгазьләрен һаман өф-өф итеп саклый имеш. Ә бәлки, иртәгә тып итеп кайтып төшәр сөйгәне?!

Көлсәң көл, еласаң ела, Хәтимә үзе дә шундый хәлгә калды түгелме? «Ну кайтып кына керсен, женен чәчәм мин аның, ник туганына үкенерлек итәм», – дип зәһәренә буылды хатын. Бераз вакыт үткәч, бу фаразның булуы мөмкин түгеллеген аңлады. Беренчедән, кесәсендә бер тиен акчасы юк, тәмәкесенә дә хакны тиене тиенгә җитәрлеген көнләп биреп бара Хәтимә. Икенчедән, барыр җире юк ул хәсрәт капчыгының, читтә-миттә беренче зуррак авылда

ук адашачак. Шушы авылда туып-үскән, туганнары шушында, барысы бер чыбыктан куылган мыкыйлар. Ничектер армиягә барып кайткан әле. Кайдадыр Сахалин утравына җибәргәннәр дә, стройбатта ике ел раствор изгән. Ике елдан соң район үзәгенә кадәр бер служагына ияреп кайткан. Бу турыда Хәтимә аның үз авызыннан ишетте. Бераз төшереп алса, гел шул хезмәттәшенә рәхмәт укый торган иде. «Шулай да башлы малай иде, җирнең бер читеннән икенче читенә кадәр исән-имин алып кайтты бит мине. Бер күреп, рәхмәт әйтәсе үзенә», – дип кабатлаганы һаман колак төбендә яңгырый. Ә-ә, сеңлесе чынлап та читтә гомер итә түгелме? Анысы да абыйлары сыңары иде. Әмма ахирәте белән ничектер Италиянең үзенә барып эләккәннәр имеш. Барганнар, эшкә урнашканнар: урында яткан бер карчыкны коляскада этеп йөри икән авылдаш кыз, астын алыштыра, шешәдән сөт эчертә. Ни эшләсә дә, акча түлиләр бит! Яшәгән җире дә тегенди-мондый гына түгел – Италия! Әллә диңгез күрәсе килеп, шыпырт кына сеңлесен эзләп киттеме Сабир?...

Уен-көлкегә борып утырасы түгел, бер-бер чарасын табарга тиештер бит инде никахлы хатын. Сәвиткә барып, башлыкка хәбәр салыргамы? Шулай-шулай, ир дигән адәм югалды, эзләп-табып бирегез, дип гариза язаргамы? Кызы Юлиягә ничек хәбәр итәргә соң бу хакта?

Тормышының яме булган бердәнбер кызы Юлия бүгенге көндә ерак Краснодар якларында стройотрядтагы ахирәтләре белән әрҗәләргә җиләк-җимешләр тутыра иде. Кемгә охшаптыр, бер тиктормас булды кызы. Тыңлаучан бала, уку елын уңышлы тәмамладым, рәхәтләнеп ял итим, дип, әти-әниләре янында, өйдә җәй үткәрер иде. Юк, моның яңа җирләр күрәсе килә, кызык эзли. Син аның өчен ут йотып утыр монда. Билгеле карарга килеп урыныннан кузгалды Хәтимә, кесә телефонын алып, кызының номерларын җыйды. Шул кадәр баш җитмәс ара, ә мизгел эчендә янында торган шикелле җавап бирә кызы, әкәмәт. Башта хәл сорашып, исәнлеген белешеп аралашканнан соң, Хәтимә яңалыкны кызына әйтергә батырчылык итте:

– Әтиең югалды бит, кызым. Нәрсә уйларга да белмим инде, – дип борынын мышкылдатырга тотынды. Күңеле тулышып китте кинәт кенә, шулай да бәхетсез зат булды инде ул. Ичмасам, кызы да янында түгел бит, җәһәннәмгә чыгып китте. Аңа әни кайгысы кайгымыни, аның үз тормышы, үз хыяллары...

– Ничек югалды? Уйлап чыгарырга синә куш инде, әни. Әллә бераз эчкән идеме? Булыр аннан. Шуннан син Сафура бураннары куптаргансыңдыр инде. Син гел шулай, сүзләреңне сайлап тормыйсың. Ачуланыштыгыз, әйеме?... Үпкәләп чыгып киткәндер, әти, аның серкәсе су күтәрми бит. Холык күрсәтеп, абзар башында печәнлектә йокы симертеп ятадыр әле. Телефонны сүндергәч тә менеп кара, мин әйткән иде, диярсең...Үзеңнең хәлләрең ничек, әни? Һаман базар юлларына тузан кундырмыйсыңдыр инде? Ярар, менә үзем укып чыгып эшли башласам, бераз җиңелрәк булып китәр әле...

Кызы печәнлекне теленә алгач та, чак чыгып чапмады Хәтимә. Чынлап та, ятадыр әле шунда аунап, ә ул монда әллә ниләр уйлап бетерде, әллә кайларга барып җитте. Ярый әле берсенә дә тешен агартмады, тәгәрәп көләрләр иде. Күз алдында иреннәреннән төкереген агызып, гырылдап йоклап яткан Сабир төсмерләнде. Шуңа да сөйләшүне озакка сузмады, тизрәк тәмамларга ашыкты.

– Ярар, кызым, кичке якта иркенләп сөйләшербез әле. Синең дә эш вакытыңдыр. Яңалыклар булса, хәбәр итәрмен, – дип, телефонын сүндерергә теләде. Кызы әнисенең тынгысызлануын тойганга, ничек тә бердәнберен тынычландырырга тырышты:

– Ә без бүген эшләмибез, тараларны кайтартмаганнар. Помидорларны тутырырга тартмалар юк. Менә кызлар белән җыелышып, су буена кызынырга төшеп яттык. Син, әни, юкка борчылма, үз-үзеңне бетермә. Кайда китсен, ди, безнең эти? Сиңа береккән бит ул, тигез картаерга язсын, парлашып. Ну әнә шул тамак йомшаклыгы бар инде, олыгая бара, котылыр әле ул начар гадәттән... Ярар, чао...

Телефонда озын-озын пипелдәүләр ишетелүгә, Хәтимә урыныннан сикереп торып, тышка омтылды. Абзарның капкасын каерып ачып, озын баскыч буйлап лапас башына үрмәләде. Башта караңгылыкта берни шәйләми торды, кармаланып алгарак үтте. Күзләре өйрәнә төшкәч, лапас башы буш икәнен күрде. Булган печән дә ике-өч сәнәктән артмас иде монда. Әле быел печәнгә төшмәгәннәр, үткән елгысын очын очка ялгап чак җиткерделәр. Юк иде монда Сабир. Хәер, абзар тирәсендә күпме кайнашты Хәтимә кичә кичтән бирле, анда тере җан булса, барыбер берәр төрле тавыш ишетелер иде. Помидорга яшник юк, диме, вәйт чукынчык кызыкай, төпсез көймәгә утыртты әнисен. Үзе дә инде бигрәк беркатлы...

Кулларын кушырып, өметсез уйларга бирелеп утыра торган кеше Хәтимә түгел иде. Ярар, ни булса да булыр, язмышыңа язылганыннан узып, беркая да китә алмыйсың. Менә болайрак дип җырлыйлар иде алар яшь чакларында:

Суга салсаң, калкып чыгар
Безгә насыйп яр булса-а-а...

Нәрсә булган ул кадәр, күкнең бер чите кителгәнме? Хәтимә, шөкер, саусәламәт, дүрт саны төгәл, буй-сыны башкаларныкыннан ким түгел, эшкә алынса, кемгә дә ал бирмәс, сүзгә дә кеше кесәсенә керми. Теге ярым ир, ярым хатын бәндә ничек җырлый әле? «Все будет хорошо!» диме?

Әнә шулай үз-үзен тынычландырып, Хәтимә зурдан кубып кер юарга тотынды.

* * *

Дөресен генә әйткәндә, керле әйберләре дә җыелмаган иде. Андый хатын тузан да кундырмый дөньясына. Әмма теләк булса табыла ул. Эленеп торган тәрәзә пәрдәләрен алды, ишек чаршауларын шунда өстәде, тагын ниләрдер табылды. Кемгәдер бу кыланышлар ят тоелыр. Әмма минем өчен бер сер дә юк монда. Без, ир-атлар, тормыш китереп кысса, кибеткә йөгерәбез, «зәм-зәм» суы, кызарып-бүртенеп язмыштан зарланып утырырга гадәтләнгәнбез. Ә менә хатын-кыз авыр чакта йә кер юарга алына, йә чыгып, бакчасын казып чыга. Бигрәк зур аерма капма-каршы затларда. Әллә без төрле планеталарда яралып, җирдә генә аралаша башлаганбызмы икән, дип тә уйлап куям кайчакларда...

Хәтимә соңгы кисәк керен элгәндә, шыгырдап капка ачылганга дерт итеп китте. Түбән оч Нәгыймә апасы икән, соңгы араларда бик тә якынайды аралары.

– Әттә-тә, кызыкай, зур эшләр майтарып ята икән монда. Нигә безнең түгәрәктә күренмәдең, дип баш ватсам...

– Сарымай әзерләргә дигән уйга килдем әле, көн дә зарыгып автобус көтәсе түгел, – дип күзен дә йоммый алдашты Хәтимә, гөнаһсыз карашын апасына төбәп. Хак сәбәпне ачып булмый бит инде иптәшеңә. Бар хатын-кыз да сүз тотмый, иртәгәгә кадәр яңалык бар авылны урап чыгар. Сакланганның сагы ятар дигән борынгылар...

– Һич риза түгелмен, – дип бармакларын селеккәләде Нәгыймә, – ул очракта, кызыкай, акчада оттырасың. Менә санап күрсәтәм мин сиңа, – дип кызып башлаган иде дә, үзен-үзе туктатты. – Һәй баш дигәнең, икенче юлы тәфсилләп аңлатырмын, наныем. Әле ашыгып кына килешем иде сиңа. Кырык эшем кырык якка тырым-тыракай кырылып ята. Фирдүс әйткәч, келт итеп синең сүзләрең искә төште дә, тукта әле, мин әйтәм, эш качмас, көтеп тә торыр. Иң башта таварканың хәленә керергә кирәк, дим.

– Бернәрсә дә аңламыйм, Нәгыймә апа, нинди Фирдүс соң, ишеткән кешем түгел. Минем аңа ни катнашым бар? – диде Хәтимә көлеп.

– Хәзер тезеп салам барысын, – дип, шунда өелеп куелган такталар өстенә кунаклады Нәгыймә, яулык очы белән тирләп чыккан маңгаен сөрткәләде. – Син сыер алырыем, дип сөйләнгән идеңме?

– Кайчандыр әйткән идем, – диде Хәтимә, икеләнә төшеп. Килеп туган яңалыклардан соң, ул планнары үзгәргән иде аның.

– Таптым мин сиңа сыер, – диде Нәгыймә, ирәя төшеп. Кемгәдер яхшылык эшли алганына кәефе булган сыман. – Сыер түгел, үзе бер дәүләт. Күндәм холыклы, мулла песие инде менә, сөтне дә мулдан бирә. Үзем савып караганым бар. Сава-сава куллар тала, малай, бер чиләк тулып, икенчесен алыштырасың... Әйдә, җыен, барып күрерсең, савып та карарсың. Бер-берегезне килештерерсез, язган булса... Мал гына, димә син аны, беренче эш итеп, бер-берегезне аңлау кирәк.

«Ә»дә димәде, «җә» дә димәде Хәтимә, билгеле карарга килмәгән иде әле ул. Сыер алырлык акчасы бар иде аның. Үзләренекен итләтә сатканда, бераз акча керде, җыеп килгән маясы да бар. Теләсә кайсы малны бәяләп, сатулаша белә. Тик менә Сабир бар планнарын җимереп куйды. Үзе белән киңәшләшкәндә, икенчерәк булыр иде, ни әйтсәң дә, ир кеше. Аннан соң, бу югалу көтелмәгән чыгымнар китереп чыгармасмы икән, тьфү, тьфү, әйттем исә кайттым...

«Күкерт» кушаматы йөрткән Нәгыймә ахирәтенең эндәшми торуына кабынып китте, такта өстеннән сикереп торды.

– Йә, нәрсә, әллә кире уйладыңмы? Мин – дивана, йөргән булам аның артыннан.

– Юк, юк, мин риза, – дип каударланды Хәтимә. Барып күрергә иде шундый сөтле сыерны. Караган өчен акча сорамаслар әле. Соңыннан кайсыдыр ягын ошатмаган хәлдә, кире кагарга сәбәп табарга була. – Ә кая барабыз соң без? – дип сораштырырга тотынды ул алъяпкычын салып, өс-башын ипкә китергәндә.

– Әйдә, юлда аңлатырмын, – дип, җилтерәтеп урамга сөйрәде аны түземсез Нәгыймә. Ишеген дә бикләп тормады Хәтимә, капкасына аркылы чылбыр гына салды. Алай тыныч иде авыл, салынган чылбырны күрә торып, берсенең дә этеп кергәне юк әлегә кадәр.

– Минем күрше Шәмгыя карчык казага калды бит – аяклары йөрмәс булды. Өй эчендә генә бераз талпына, анда да тотынгалап. Менә кичә улы Фирдүс Казаннан алырга кайткан. Өзми дә куймый, калдырмыйм үземнән, ди. Эш арасында гына йөри. Ә терлек нәрсә эшләргә тиеш? Әлегә кадәр сыерын күршеләр алмашлап тарткалап йөрдек. Әйтәм бит, акыллы хайван, көтүдән туп-туры өйгә кайта, эзләп йөрисе түгел. Менә шул хайванкайны арзан гына хакка булса да, ышанычлы кешегә сатып китәсе килә Шәмгыя карчыкның. Келт итеп, син искә төштең... Бәхетең бар икән, юраганың юш килеп тора.

Каудар Нәгыймә артыннан чак өлгереп атлады Хәтимә, тиз барып җиттеләр. Кереп тын алырга өлгермәделәр, ишектә өрлектәй гәүдәле, сөйкемле йөзле бер

ир күренде. Капка тавышына килеп чыкты, ахрысы. Керүчеләргә карап, утыз ике тешен дә күрсәтеп, киң елмайды. Битләре чокырланып китте, күзләрендә очкыннар чәчрәде, килешә икән үзенә елмаю.

– Әллә шушы чибәркәй безнең Карлыгачның хуҗабикәсе булырга телиме? – дип ягымлы карашы белән Хәтимәгә текәлде ул. Бу караштан хатынга әллә ни булды: башы әйләнеп китте, йөрәге кош баласыдай талпынырга тотынды. Шундый ирләр була, бер генә сүз әйтсен – теләсә кайсы хатын-кыз дөньясын онытып, аның артыннан Каф тауларына китәргә дә ризалаша. Бу Фирдүс дигәне шундыйлар калыбыннан булды шикелле. Беренче күрүдән уйлары буталды Хәтимәнең, кайдадыр адашып йөргән хәләл ире Сабир да хәтереннән чыгып очты. Әйтерсең, аның унсигезе яңа гына тулган, алда бетмәс-төкәнмәс бәхет тулы гомер, менә шул иркәй белән җитәкләшеп барасы да барасы...

– Син башта безгә сыерыңны күрсәт, телеңә салынма. Барыбер артыгын бирмәбез, без малның хакын бер күрүдән тамгалыйбыз.

Нәгыймә апасының дорфарак эндәшкән сүзләре хатынны айнытып җибәргәндәй булды, мамык болытлар арасында адашып йөргән җиреннән кабат тупас чынбарлык чорнаган газиз җиргә төште.

– Кайда торганын үзең дә яхшы беләсең, Нәгыймә апа, – дип эшлекле кыяфәттә сөйләшә башлады ир. Әмма вакыт-вакыт Хәтимәгә сынап карап куя иде. Ирнең утлы карашыннан аяк астында җир убылып киткәндәй була иде аңа.

Кирпечтән салынган иркен, чиста абзарга керделәр, яшел печән күшәп торган холмогор токымлы бура кебек зур сыер каршына килеп бастылар. Сыер акыллы күзләрен боларга төбәп, тынып калды, нидәндер авыр сулап куйды. Алдагы үзгәрешләрне сизенә иде булса хайванкай.

– Марс килгән иде, теге сезнең авылның фермеры, хакын күпме сорасаң, шуны бирәм, ди. Әни ризалашмый. Печән өстендә бригадтагыларны ашатырга ит кирәк икән.

Аның сүзләреннән Нәгыймә ачуланып кулларын болгарга тотынды:

– Чү, юләр, нәрсә сөйлисең хайванкай каршында!

– Аңлыймыни ул әйткәнне? – дип гаҗәпкә калды Фирдүс.

– И шәһәр наданы, – дип өзгәләнде Нәгыймә, сыерны муеныннан сөеп, – аңлый, әлбәттә. Синең белән миннән акыллырак ул. Их, үзем алып калыр идем дә акча юклыгы бәкәлгә суга. Бурычка кереп җыештырсаң, соңыннан барыбер түлисе... Йә, савып карыйсыңмы, Хәтимә? Ышан сүземә, дастуин мал керергә тора кулларыңа.

Шунда әллә нәрсә булды Хәтимәгә, үзе дә уйламастан кирегә сукаларга тотынды. Дөресрәге, үз-үзенә ачуы килеп киткән иде аның чит-ят ир каршында мәлҗерәп төшүенә.

– Акча ягы безнең дә такыррак. Үзе дә өйдә юк әле, Сабирны әйтәм. Өй хуҗасыннан башка мондый сату-алуга ничек батырчылык итим? Булмас, юкка кеше ышандырмыйм, – диде дә карашларын идәнгә төбәде һәм чыгып киткәнче, теге иргә күтәрелеп карамады.

– Ничек була инде бу? Мин кеше ышандырып йөргән булам! – дип тузына башлаган иде Нәгыймә, иреннәрен бөрештереп, Фирдүс тыныч кына аны туктатты.

– Кемнедер гаепләргә кирәкми, Нәгыймә апа, көчләп тага алмыйбыз инде кешегә. Рәхмәттән башка сүз юк, килеп карап йөргәнегезгә. Ә сиңа, күрше буларак, икеләтә рәхмәт. Чәй эчәргә керерсез, бәлки? – дип сүзне икенчегә борды.

– Чәйләр чәйләп утырырга вакытыбыз юк, наныем. Кичке якта озатырга керермен әле, – дип кызу-кызу капкага таба юл тотты Нәгыймә. Хәтимә аннан да алдарак ешлаткан иде адымнарын.

– Ярар, үзең беләсеңдер инде, мин үземнең хәлдән килгәнен эшләдем, – дип йомшара төште Нәгыймә. – Нәрсә, иртәгә дә бармыйм, дисеңме чатка? Көтәсе түгелме үзеңне?

– Алдан әйтмим әле, Нәгыймә апа, барырга уйласам, тукталышта очрашырбыз, – дип шомартты Хәтимә.

– Әйдә, кереп чык, ничек яшәгәнемне күрерсең. Җиләк вареньесы кайнаткан идем, телеңне йотарлык булды.

– Ю-у-ук, – дип каршы төште Хәтимә, – көн уртасында өстәл артында утырырга монда.Үзеңнең дә кырык эшең көтеп торадыр.

– Ярый алайса, – дип, тиз ризалашты тагын Нәгыймә, – утырган чаклар булыр әле. Иртәгәгә кадәр, тукталышта көтәм. Юләрләнмә, әллә күпме акчаңны югалтачаксың.

Шулай сөйләнгәләп, үз капка төбендә басып калды Нәгыймә, Хәтимә юлын дәвам итте. Нindidер җиңеллек тойды хатын бар вөҗүдендә. Бу үзгәрешләрнең нидән икәнен ул әле үзе дә ныклап төшенеп җитмәгән иде.

* * *

Тарихыбызны алга таба үстерер алдыннан Хәтимәнең тормышына бераз ачыклык кертеп китү урынлы булыр. Авылда эш юклыгына зарланып алган идек инде. Әмма кешеләр үзләренә берәр шөгыль табып, җан асрарга тырыштылар. Хәтимәнең дә Сабиры алып кайткан тиеннәргә тилмереп утырасы килмәде, күпчелек хатыннарга ияреп, әзме-күпме акча эшләү юлын тапты. Шәһәргә кадәр кул сузымы ара иде аларның авылларыннан, зур юл авыл кырыннан гына үтә. Шуңа да анда барып кайту берни тормый, теләсәң, юлга чыгып, узып баручы машиналарны туктатасың, автобус та еш йөреп тора. Чаярак авыл хатыннары бу уңайлыкларны файдаланырга тиз өйрәнеп алдылар. Элек-электән абзарда мөгрәп торган сыер гаиләнең төп байлыгы булып саналган. Бүгенге авыр заманнарда да шул хайванкай ярдәм итте, рәхмәт төшкере. Тырыш хуҗабикә иртәрәк уянып, таң сарысыннан вак-төяк эшләрен эшләп куя, өстәлен хәстәрли. Көтүне озатканчы, ул эшлисе эшләрне тәмамлаган була. Шуннан йөгерә-атлый балаларны уята, киендерә, олысын ныклап кисәтә. Ул арада үзе берәр чынаяк чәй йотып куя һәм ике кулына ике дәү сумка йөкләп, автобус тукталышына ашыга. Ул сумкаларда яңа савылган сөт тутырылган полиэтилен шешәләр, ярты литрлы банкаларда кичтән аертылган каймак, эремчек. Бер көтү булып «таваркалар» автобуска тыгылышалар. Туганнар, ахирәтләр, таныш-белешләр аерым-аерым төркемнәргә берләшә. Базарлар эзләп йөрмиләр, гадәттә, һәр төркемнең үз почмагы бар. Хәтимә Нәгыймә апасы, Гөлсирә кодачасы белән бергәләшеп йөри. Бер грузинның яшелчә сата торган ларёгы янына елышырга өйрәнделәр. Якында гына автобус тукталышы, кибетләр тезелеп киткән, гомумән, халык күп йөри монда. Якын-тирәдәге күпкатлы өйләрдә яшәгән таныш сатып алучылары да барлыкка килгән үзләренең. Төшкә сумкалары бушый, ә алырга җайлы булсын өчен изүгә кыстырылган кәшилүкләр, киресенчә, бар гәүдәгә ләззәт биреп кабара төшә. Артыгы булмый да соң, сөт сатып кына кем баеган, ди әле? Шулай да иш янына куш инде. Өйләдән соң үз эшләреңне карарга да вакытың кала.

Йөргән-йөргән, барыбер йөрисе, дип, тагын бер сыер башын арттырырга исәп тота иде Хәтимә соңгы араларда, тик менә көтелмәгән бәла аяктан екты аны, уйлаган уйлары челпәрәмә килде...

Юк кына нәрсә дә кеше кәефен үзгәртеп җибәрергә сәләтле. Йә, нәрсә булды соң әле ул кадәр телгә алырлык? Сыер карап кайтты да Нәгыймә апасы белән ләчтит сатты – бары шул гына. Ә-ә, теге майлы күз – шәһәр ире күзләренә чалынды бит әле, хәерсез. Ни нәрсә хәлдер инде, шәһәр ирләре аерыла авыл мокытларыннан. Бер карауга кемнең кайдан икәнен бер хатасыз әйтеп бирергә була, валлаһи. Безнекеләрнең кигән киемнәре кайда эшләгәнлекләрен чакрым ярымнан кычкырып тора, шофёр-трактористларыныкы майга баткан, ферма тирәсендә йөргәннәре, билгеле инде, нәрсәгә буялган. Барысында да тубык башлары чыккан Кытай ыштаннары. Шуның өстенә айлар буе алынмаган чәчләрен, җиткән тырнакларын, коелган тешләрен өстәсәң, авыл гыйбады тып итеп килә дә баса каршыңа. Тешсез авызларын ерып, туктамый тәмәке төтәткән булалар бит әле.

Ә шәһәрдә кемнең кайда эшләгәнен әүлия булсаң да, аера алмыйсың. Барысы энәдән-җептән киенгән, киемнәре чиста, үтүкләнгән, сакал-мыек кырылган, кулда портфель, кыланышлары ихтирамлы, карашлары тыйнак. Кайсысы профессор да, кайсысы фрезеровщик – егылып үлсәң дә әйтә алмыйсың. Ул эшенә әнә шулай кунакка баргандай бара, кайтыр алдыннан душ кереп, тагын яхшы киемнәрен киеп кайта. Шундый кәртинкә кебек ирне эштән каршы алу үзе зур бәхеттер инде ул! Әлеге Фирдүс тә әллә ни кимәгән иде төсле: гади футболка да спорт чалбары. Әмма бик тә килешле, нәкъ үзенә үлчәп тегелгән, төсләре дә бер-берсенә тиң. Шуларны кат-кат күзаллап, кабат-кабат һәр ишеткәнен исенә төшереп, дулкынландыргыч карашларны яңартып исләп йөри-йөри кич җиткәнен сизми дә калды Хәтимә. Бүген күңеле дә урынына утыргандай булды, борчылулары юкка тиң иде. Кызына шалтыратканда да шулай диде:

– Йөридер әле, берәр маҗарага тарып. Йөреп аргач, кайтыр, шуны уйлап йөрәк бетерергә монда. Син ул яктагы тормышны сөйлә, анысы күпкә кызыклырак булыр...

Кичке ашка нидер ашыйсы килмәде, үзен иркәләп, сары майда гына кетердәп торган коймаклар пешереп алды. Шуның белән тәмләп кенә куе чәй эчте. Эшлисе эшләр эшләнгән иде, телевизор кабызасы итмәде, шәфәкъ кызыллыгы сүнмәс борын юрган астына чумды. Урын өстендә назланып, үз уйларына уралып ятасы килә иде аның.

Хыялында әлеге дә баягы Сабир иде. Ире шул киткән җиреннән бөтенләй кайтмый калса да, яхшы буласыдыр. Бер рәхәт күрсәткәне булмады бит газиз хатынына, ничә еллар бер кыек астында яшәп. Яшьрәк чагында кешегә дә чутламаган сыман кыланды, эчеп даулашуны гадәт итте. Кул күтәрмәде күтәрүен, мәгәр хайван сурәтенә кереп дулый торган иде инде. Чак балалыктан чыккан Хәтимә, ир дигән нәрсә шундый буладыр инде, дип, дер калтырап торды тегенең каршында. Бераз акыл кергәч, барысын да кире кайтарды анысы, тәртә арасына кертте. Үзе баш, үзе түш. Әмма, әмма... Бөкрене кабер генә төзәтә диләр бит, шул ук Сабир булып калды ире. Үшән, ялкау, салмышбаш, тамактан башканы белмәгән нәрсәкәй. Җылы сүз әйтә белмәде, күтәрелеп карамады, яңа күлмәк кигәнсеңме син анда, чәчеңне кистергәнсеңме... Ә хатын-кызга наз кирәк, мактау кирәк. Әллә тормышны үзгәртү турында ныклап уйлап карарга мы Хәтимәгә? Әллә югары көчләр идарә итәме бу вакыйга белән? Син ялгызсың,

үзең турында уйларга вакыт, дип кисәтәләрдер. Чынлап та, бу адәм имгәгенең югалуы хак булса, бер талпынып карарга кирәк! Ни нәрсә бәйләп тота аны бу өч өйдән торган авылда? Елап утырган баласы юк, барып сыенырга бер туганы калмаган, яшәгәне кызыгырлык өй түгел, ичмасам. Булган мөлкәтне кырып-себереп сатсаң, биш йөз мең җыеп буламы-юкмы? Күзне йомып, шәһәргә чыгып китәргә кирәк. Анда эшнең ниндие кирәк, шундыен табарга була. Акчаны да яхшы түлиләр, ди. Яңгырда, карда авыл җирендә резин итекләр, төпле пималар сөйрисең, абзар исе канга сеңгән, кешедән уңайсыз. Анда елның теләсә кайсы фасылында биек үкчәләрдә тек-тек басып йөрисең. Баштарак берәр ятакханәгә урнашыр, йә булмаса, бүлмә табар: кыйммәт алмыйлар, белешкәне бар. Үзе акча эшләячәк лә ул, ә Хәтимә эштән курыкмый, теләсә кайда сытып эшләр. Анда, бихисап күп кешеләр арасында, берәр ипле генә ир-ат белән аралар да ялганып китәр тора-бара. Монда авылда гына ирләрне бармак белән санарлык, арыш арасындагы бодайлар кебек. Кайсысы калыкса, анысына хуҗа табылган имеш: Гөлбикәнең ире, Зәмзәмбикәнең абышкасы, Гайникамалның тормыш иптәше... Тьфү! Ә шәһәр җирендә башкача, анда урманда үскән агачлар санынча көчле затлар. Машиналы, фатирлы, белемле. Хәтимәгә тиешле бәхет өлеше бардыр бит бу җирдә, гомеренең икенче яртысында бераз кешечәрәк яшәп карарга тиештер бит инде.

Ул кемнән ким, ди, күпләрдән артыграктыр да әле...

Гәрәбә йолдызлар күк йөзенә сибелгәч, әнә шундый алсу хыялларга чорналып онытылды Хәтимә.

* * *

Матур хыяллар алар җылы юрганга төренеп, тәрәзә аша серле күк йөзен күзәткәндә генә яхшы, ә кырыс чынбарлык адәм баласын утларда яндыра, дәрьяларга сала. Тормыш көтүләре, ай-һай, авыр вазифа. Хәтимә туйганчы йоклап, нәкъ кирәкле вакытта уянгач, шәһәргә барырга җыена башлады. Юк ирне көтеп, сарыга сабышып утырып булмас монда, үз көнеңне үзең күрергә кирәк. Яңа савылган сөтне сак кына полиэтилен шешәләргә тутырды. Суыткычта җыелган сөтләрне җылытырга куйды. Берәр литр булса да, каймак аерту иде теләге, шәһәр хатыннары авыл каймагын егылып китеп ала. Йөз илле сумны кесәдә, дип исәплә. Җылынырга өлгергән сөтне салды да сепараторның борынын борды. Бераздан сыек кына булып каймак сузылып төшә башлаячак... Бу көнгә кадәр карышуны белмәгән сепаратор кинәт ниндидер ят тавышлар чыгарды, бүксәсендә тимерләре шатыр-шотыр килде дә ике юлыннан да чапырдатып сөт агарга тотынды. Менә сиңа мә! Белер-белмәс куллары белән бу шөребен боргандай итте тирләп чыккан хатын, теге колагын борды. Идән сөт белән тулды, хет утырып еламыйсыңмы шунда! Шартлар чиккә җиткән Хәтимә калган сөтне җилтерәтеп бозаулар ләгәненә чыгарып каплады, ашыга-ашыга идәнне сөрткәләп алды. Янында Сабиры булса, ялт иттереп төзәтер иде шул сепараторның килешмәгән җирен.

Бер җыенгач, барып кайтырга уйлады. Шешәләр тутырылган сумкасын йөкләде, туңдырылган эремчек капчыкларын иш янына куш булыр дип алды. Һи-и, ләгыйнь шайтан каравыллап кына тора бит ул сине! Киенеп-ясанып чыгып китәм, дигәндә, чолан ишеген катырак япты, ахрысы. Һәм... тупсаны тоткан кадаклар дәррәү яшел чирәмгә сибелде, ишек каерылган каз канаты сыман салынып төште. Шул кулы черегән нәрсә нигә вакытында яхшылап кадакдап куймагандыр инде. Хәзер нәрсә эшләргә? Беравык тапангалап басып

торды ул, уңга чыгып карады, сулга барып күз салды. Соңыннан үҗәтләнеп такта ишекне урынына сөяде дә кул астына эләккән көрәк белән терәтте. Йә ярар, ул кайтканчы канатланып очмас әле. Соңыннан ни эшләтергә чамалар.

Бераз вакыты бар иде әле аның. Ашыга-ашыга тукталышка таба китте. Үч иткәндәй, тыкрык башында аңа Хисмай иярде. Салмыш баштан икәне йөзенә чыккан иде үзенең.

– Кодача, Хәтимә, дим, – дип сүз салып булашты әле. Борылып та карамады хатын.

– Гар буендагы люцернагыз өлгергән. Сабир чаптырырга уйламыймы? Менә бер чүллилек бирсәң, ярты хакына чабып бирәм, егет сүзе бер булыр. Минем юмарт чак сирәк була, үзең беләсең... Нәрсә, өч сум акчаң жәлкеме? Ну кара аны, әйттем исә кайттым...

Хәтимәгә иярә алмый, үзалдына нидер сөйләнгәләп, артта торып калды ул. Әмма ишеткән кадәресе дә Хәтимәнең саруын кайнатырга бик җиткән иде.

Печән өсте бит авылда, яше, карты, сәламәте, гарибе кышкылыкка малкайларга печән хәстәрләп калырга ашыга. Әлбәттә, барысының да гозере тракторы булганнарга төшә. Әлеге Хисмайның да өр-яңа тракторы бар, үткән ел гына яңартты. Башкалар белән чагыштырганда, ул алынган эшен җиренә җиткереп эшли, вакыт белән исәпләшми, кем әйтмешли, үз һөнәренең остасы. Әнә шул адәмнең үзенә генә хас берничә гадәте, диикме, холкымы бар. Кешегә зыяны юк, аны бот буе баладан башлап бер аягы белән кабергә баскан карткорыга кадәр белә. Белмәслекмени? Хисмай авыл очында яши, тау өстендә. Салгалый, әлбәттә. Әмма салу белән салу арасында зур аерма бар. Кырлы стаканны каплап, шым гына үзалдыңа берәр җыр ертыгын көйләп, йорт тирәсендә эшләп йөрергә була. Соңыннан итле аш ашап, мыштым гына үз почмагыңда әвен базарына китәсең. Анысы бик исәпкә керми. Ә менә Хисмай кондициягә җиткәнче салган булса, кырку үзгәрә, Салсал батырга әйләнә. Үз өе кырындагы тау башына менеп, авыл өстенә күз сала, киң күкрәген тутырып сулыш ала да кинәт бар җиһанга иңри:

– А-а-а-а-а-а...

Бу авазны бернәрсә белән дә чагыштырып булмый. Шәхсән миңа ул борынгы бабаларыбызның гасырлар төпкеленнән килгән тавышы төслерәк яңгырый. Урмандагы киек-җанварлар да моны ишеткәч алга-артка карамый, урман төпкеленә чаба торганнардыр.

– А-а-а-а-а-а ...

Ләңгелдәп өргән этләр тынып кала, һавада талпынган каргалар мизгел эчендә юкка чыга, урамнарда бала-чага чыр-чуы бетә, сөйләшеп торган хатыннар сүзләреннән бүленеп тауга текәлә.

– А-а-а-а-а-а...

Аяз төндә кайдандыр болытлар пәйда булган кебек, валлаһи. Ә йокыга талганнар саташулы төшләрдә онытылалар, сөйгән парлар зык булып талашалар ул төндә, ирләр, хатыннар урыннарын аерым җәяләр.

Әнә шулай ике-өч тапкыр кычкыра да, тынып кала ул. Аннан соң ни кылана торгандыр, беркем белми. Хатыны аның гаилә серен сөйли торганнардан түгел, сүзләрен келәшчә белән дә тартып ала алмассың. Өч-дүрт көн урамга төшми әле ул. Аннан соң син күр дә мин күр, берни булмагандай авыл тормышына кушылып китә. Берәр җор теллесе әлеге улаганны исенә төшерсә, күзләрен шарландырып: «Нәрсә сөйлисең? Гүпчим мин түгел идем, колагыңа ишетелгәндер», – дип, сүзне икенчегә борырга ашыга.

Хисмай телгә беткән кеше, халык белән аралашырга ярата. Шунысы да бар, бәйрәм итсә, бервакытта да үз кесәсеннән чыгарып эчми. Әйтергә кирәк, аны сыйлаучылар табыла. Хәтта күңелен күрергә чират торалар. Анысының да «әтнәкесе» бар. Хисмай нинди хәлдә булса да, үзен сыйлаучыларны онытмый. Ипкә-сапка килгәч, авыр чагында ярдәм итүчеләрнең эшен беренче чиратта эшли. Акча турында да артык сүз куертмый, ярты хакына да риза. Айнык чагында йомышың төшсә, ул комарның да комары, бер тәңкә өчен ярты көн сатулашырга мөмкин. Әнә шуңа күрә авыл халкы аның йомшарган чагын туры китерергә тырыша.

– Хисмай гастрольгә китмәгәнме?

– Урам киләпләргә тотынмаганмы әле Хисмай? – дип бер-берсеннән белешеп торалар.

Менә әле уңыш Хәтимәнең каршысына чыкты: шул дерелдәвекнең сал иде учына биш сумыңны, Сапый таудагы люцернаны чабып, тюкларга салып бирер иде. Сыерга кышлык печән әзер дигән сүз. Әмма чыгырыннан чыккан иде хатын. «Үзе эшләтсен, үзе җаен тапсын. Кем монда ир: улмы, Сабирмы? Өй хуҗасы кайдадыр кәеф-сафа корып йөрсен, ә монда Хәтимә телен аркылы чәйнәп печән хәзерләсен...»

Тукталыш каршында хатыннар шау-гөр килде. Никтәндер Хәтимәнең якынлашканын күргәч, тынып калдылар, колактан-колакка нидер шыбырдаштылар. Төкергән, ди аларга Хәтимә, башын югары чөеп, Нәгыймә апасы янына барып басты, косынкасы белән бит алмаларын җилләткән булып:

– Иртәдән кыздыра бүген... – диде. «Тагын нинди гайбәт уйлап чыгардылар икән инде минем турыда?» – дип кара янды үзе. Арада «алаша» кушаматы йөрткән ирдәүкә ялгыз хатын сузып кына Хәтимәгә эндәшкәндәй итте.

– Хәтимә-ә-ә-ү, абышкаң сине калдырып, икенче берәүгә ияреп киткән, диләр, хак сүзләрме шу-ул?

Кирпечтәй кызарып чыкты Хәтимә. Ирнең нәрсә икәнен белмәгән бер хөрәсән йөзеңә бәреп шундый сүзләр сөйләп торсын әле? Хурлыгыңнан егылып үләрсең, валлаһи...

– Мине ташлап китәрдәй ир бу дөньяга тумаган әле. Кирәксә, без үзебез чүплеккә илтеп аударабыз аларны. Кайберәүләр барып сайлап алсын, дип.

– Ә кайда соң ул? Эшкә дә йөрми, диләр.

– Ял йортына озаттым. Бераз ял итеп кайтсын, дидем. Өзлегә көн-төн эшләп. Печәнгә кадәр бераз ныгынып, көч-гайрәт җыйсын.

– Анда ятулары кыйммәткә төшәдер бит? – дип кушылды бер нечкә тавышлысы.

– Акчаны үзебез эшләп табабыз. Ир тазалыгы кыйммәтрәк.

Хәтимә «таварка»ларның авызларын әнә шулай япты. Ул арада автобус та килеп җитте...

Ирсез хатынны каккаларга-суккаларга гына торалар инде ул. Кем әйтмешли, кыяфәте чурт с ним, башында бүреге булсын. Ул чакта аркаң терәр кешең барында, кулларыңны биленә таянып сөйләшәсең. Шәп әйтте әле Хәтимә теге нечкә сыйракка, авызы тиз йомылды.

Сату-алу шома гына барды. Тик бер адәм Хәтимәнең тоз сипте йөрәгенә. Алса алмады товарын, әйләнде дә килде, гел аның тирәсендә боргаланды.

– Исемең ничек, чибәркәй? Кайсы якка кайтасың? Минем машинада урын буш, җилдереп кенә кайтарып куям, – дип, кырыкка төрләнде. Исең китәр, кайдан сизеп ала бу каһәр төшкән ир-ат хатыннарның ялгызлыгын?

– Йөрмә әле монда, мөртәт, сатып алучыларны өркетеп, ире килеп чыкса, сөякләреңне җыеп ала алмассың! – дип, Нәгыймә апасы кычкырганнан соң гына каядыр китеп югалды.

Җыелганнары Хәтимәнең кәефен төшерергә бик тә җиткән иде инде. Кешегә дә санамый башладылар бит үткән-сүткәне. Аннан соң Сабир зым-зыя юкка чыкса, ялгыз башы ничек печән чабар икән ул? Хатын-кыз эшеме бу? Менә бәрәңге күмәр вакыт җитәр. Берзаман анысын да алырга кирәк булыр, нәүрәпкә ташырга. Бакчаның бер киштәсе авар хәлгә җиткән, кадак, чүкеч тотып үзе чыксынмыни? Ир-атсыз эш бармый инде ул авыл җирендә...

Кайтып җиткәч, тагын зарланырга сәбәп көтеп торган икән әле: кайгы килсә капкаңны ач, диләр бит. Чәй эчеп, бераз тын алып, терлекләре янына чыкса, иң зур үрдәге чак тынын алып утыра. Туймас тамак әллә берәр нәрсә йоткан, әллә берәр кизү чире эләктергән? Күзе яртылаш йомылган бахыркайның, тынын да гыжлап кына ала, адәм буласы юк. Сабир булса: «Суй! » – дип җикерер иде дә кичке якта бер дигән бәлеш өлгерер иде. Хәзер бу үрдәкне култык астына кыстырып урам буйлап китсенме? Сарайның караңгы почмагына тегене ябып куйды да алдына су, җим салды. Язган мал булса, терелер, терелмәсә, чүплеккә чыгарып ыргытасы гына кала инде, чукынчыкны...

Балта-пычкы алып, чолан ишеген үзенчә әвеш-тәвеш китереп куйган булды. Бала-чага да алай эшләмәс. Ярый инде, үзе кайтканчы торып торыр.

Бүгенге кич аерата озын тоелды. Һәр шырт иткән тавышка сикереп төште Хәтимә, йөрәге ярсып тибәргә тотынды. Әллә нинди уйлар килде башына. Әнә берсе чолан ишеген каерып керергә азаплана төсле, аш өе ягындагы тәрәзә дә сыек кына. Пычак тоткан әзмәверләр килеп керсәләр, «эх» диярге дә өлгерә алмый калырсың, җаныңны җәһәннәмгә олактырырлар, Алла, Алла... Белгәннәрен укып, баштан аша юрганына чорналды коты очкан хатын.

Үзе дә инде бигрәк каты булды Сабирына. Эткән булды, төрткән булды, теге эшен ошатмады, бу төшен яратмады. Күктән төшкән ирләр сирәк инде алар. Кемнәндер ишеткән гыйбарәне күңеленнән үткәрде. Хәтимә кебек бер пырдымсызы хәзрәткә барган икән: «Аер безне, хәзрәт, түзәрлегем калмады», – ди икән. Хуш, тыңлап торган киленнең зарларын акыллы хәзрәт һәм болай дигән:

– Кем, ни, Китап яшәр мөмкинлекләре калмаганда, ир белән хатынны аерырга рөхсәт итә. Ярдәм итәрмен мин сезгә. Вәләкин минем бер шартымны үтәрсең. Иртәгәсе көнгә миңа бер түтәрәм ипи пешереп алып кил. Икмәк өчен онын, тозын, чүпрәсен күрше хатыннарыннан ал. Аларның һәрберсенә минем шартым турында сөйлә...

Шатланып чыгып китә хатын, кайтышлый ахирәтләренә сугыла. Керә-керүгә иренең начар якларын тезә башлап кына өлгерә, тегеләр моны уздырып үз хәләл җефетләренең холыксыз якларын санарга тотына:

– Һи, синеке нәрсә, менә минеке ул сараннарның сараны...

– Бер адым өйдән чыгарга рөхсәт итми, үлеп көнләшә...

– Һәр сүзгә бәйләнә, кул күтәрүдән тайчанмый, фәлән-фәсмәтән...

Хатын кире муллага йөгерә:

– Аера күрмә, мулла абзый, минем иремнән яхшысы юк икән!.. – ди.

Шуның кебек, аның Сабиры кеше ирләреннән ким түгел иде бит әлегә кадәр. Ничек тә үз кубызында биетә иде бердәнберен. Тормышлары да башкаларныкыннан ким түгел, өс-башлары бөтен, ашаганнары ит тә май

дигәндәй. Кайта калса, җаена торып, кадерен белеп кенә торыр иде, валлаһи. Тик исәнме икән инде бу көнгә кадәр җанкисәге? Әллә усал кешеләрнең корбаны булганмы, киек-җанварлар ботарлаганмы үзен?

* * *

Исән иде Сабир, әмма бик каты хәлдән тайган иде, мескенкәй. Болай булды хәлләр. Гараж капкасын чыгып, каенлыкны үткәч тә, шоссе юлда туктаган ялтырап торган иномарка үзенә җәлеп итте аны. Фырт киенгән шофёр борчулы йөз белән машинасы тирәсендә әйләнгәли иде. Ул да Сабирны шәйләп алды, елмаеп аңа таба кул болгады: зинһар, килеп кит, янәсе. Сабир горур кешеләрдән түгел, вакыты күп иде аның, әллә чынлап та берәр төрле ярдәм кирәктер. Ярдәм итсәң, хакын бирер. Шофёр кара чутыр йөзле тау кешесе иде.

– Ыслушай, колесо воопше мяхкий стал. Одежду марать не могу. Памаги, друг, угошшу.

Көпчәк алыштыруны күз йомып та башкара ала иде Сабир. Ике әйттереп тормады. Багажниктан запас көпчәкне сөйрәп чыгарды, кирәкле ачкычлар сайлап алды, учларына төкереп эшкә тотынды. Биш минут вакыт үтмәде, яңа көпчәк урынында иде.

– Вай-вай-вай, джигит, джигит, – дип кулларын угалады шофёр. – Век не забуду, я – Сосо, – дип кулларын сузды.

– Сядем подкрепимся после работы, – дип, внедорожнигының ишеген ачты. Кереп утыргач, кайдандыр бер шешә коньяк тартып чыгарды, алсуланып пешкән алманы уртага куйды.

– Тара нет, давай ты начинай, – дип, шешәне Сабирга сузды. Мондый чакта ялындырып тора торган кеше Сабир түгел иде. Голкылдатып ярты шешәне бушатып куйды, таза тешләрен алмага батырды.

Шуннан соңгысын хәтерләми: алманы тешләп алдымы, юкмы, нindидер караңгы чоңгылга чумды...

Һушына килгәндә, ул нindидер зур ангар эчендәге тактада ята иде. Башы чатный, күз алдында аллы-гөлле бөҗралар биешә, һәр сөяге сулкылдап сызлый. Ничек итсә итеп, тирә-якка карашын йөгертте. Чиге-чамасы булмаган зур склад иде, ахрысы, бу, бер башыннан икенче башы күренми. Тонык кына лампочкалар яктысында күреп бетереп булмый иде. Такталардан әмәлләнгән ятаклар дүртәү икән, урта җирдә өстәл тора, башка җиһаз әсәре юк. Әнә шул почмак тимер таяклар белән уратып алынган. Ишек кебек нәрсәгә такта йозак салынган. Калган такта ятаклар да буш түгел иде. «Өнме бу, төшме? Саташам, ахрысы... – дип, уйларын тәртипкә китерергә тырышты ул. – Юк, өн шикелле. Их, бу тамакка йозак саласы. Башым исән котылса, башка тамчысын да алмас идем авызга...»

Сабирның кыбырсынганын күреп, күршесендә яткан бер «доходяга» тавыш салды:

– Чё, очухался, земеля?

– Кайда мин? – диде Сабир, кипкән иреннәрен ялаштырып.

– Ты человеческим языком говори, шалай-балай не понимаем, – диде теге битараф кына. Сабир соравын русча кабатлады.

– Кайда икәнебезне белер өчен мин ярты гомеремне бирер идем, братан. Без дә очраклы килеп эләктек монда. Как раз бер фанфурикка акча җитми иде. Бер изге җанлысы туктады да: «Ике йөзне бирәм. Икенче катка җиһаз менгерешегез әле», – ди. Без ни шатланышып кереп утырдык аның машинасына. Ә ул,

паскуда, монда алып килде дә рәшәткә эченә тыкты. Үзе сызгыра-сызгыра китеп барды. Ярты сәгатьләп үткәндер инде.

– Өчегезне дәме? – диде, төбенә тоз коярга теләп Сабир.

– Юк, без Зема белән. Ә теге... – ул такталар өстендә йокы симерткән бугайга ымлады, – безнеке түгел. Бераз тегеләйрәк шикелле, шулай сизелә. Син саграк кылан аның белән.

Шулчак аяк тавышлары ишетелде. Әлеге бугай ялт итеп сикереп торды да өстәл артына килеп утырды. Маскхалат киеп куйган урта яшьләрдәге ир ике кулына ике термос тоткан икән.

– Ужи-ин, ужи-ин, – диде ул көйләп. Барысының эчләре аркаларына ябышкан иде, ике әйттермәделәр. Ашау байларныкы иде: ашнакчы зур алюминий табакларны өеп, гуляш салды, кружкаларга куе кара чәй агызды, аркасындагы биштәрдән юмарт теленгән ак икмәк чәчеп салды. Аның белән генә бетмәгән икән әле. Теге серле арка сумкасыннан алып, һәрберсенең алдына берәр шешә вермут утыртты.

– Һа, – дип авызын иңенә җәйде Зема, – «вертит, мутит» ди торган идек без бу «зәмзәм су»ын яшьрәк чакларда. Чәйне дәррәү кире бушатабыз. Салдык затлы эчемлекне. Йә, очрашу хөрмәтенә. Хых...

Салып куйгач, аппетит та ачылып китте. Әле генә антлар эчеп яткан Сабир алдында шәрабтан баш тартуны начар тәрбия дип кабул итәрләр дип, башкалардан калышмады. Теге бугай гына үз шешәсенә күтәрелеп тә карамады.

– Командир, өстәлгә кунаклагач, әрәм итмик инде, бүлик өч борынга.

Киң күңелле ашнакчы кул гына селтәде. Тәмам күңелләре булып, үз топчаннарына сузылдылар. Бары бугай гына термосларны ялап, ипи валчыкларын чүпләп авызына озатканчы, өстәл артыннан тормады.

– Нәрсә хөрмәтенә безне сыйларга булдыгыз, командир? Чакырылган кунаклар түгелбез лә, – диде кызарып чыккан «доходяга». Ул монда үзен башлык итеп тоя башлаган иде шикелле.

– Чакырылган, чакырылган, – диде капчык авызын бәйләп булашкан «маскхалатлы». – Сәбәбен иртәгә аңлатырлар.

Ул читлекнең йозагын бикләп караңгылыкка кереп югалды. Шкаф киңлеге егет үз урынына сузылды да шундук йокыга китте. Калган өчәүнең күңелләре урыннарында түгел иде.

– Нәрсәгә дә юрарга белмим, – дип сүз башлады тагын теге «доходяга». – Ашау – первый сорт, өстәп эчәргә салалар. Ни-нәрсәгә кирәк булдык икән без боларга?

– Минтон, минем ишеткән бар, – дип пышылдап кына сүзгә кушылды Зема дигәне. – Менә шулай атна буе ашаталар икән дә бомжларны, бераз ит кунгач сарык урынына тау халкына саталар, ди...

– Нәрсә, таулар арасына сарык көтәргә җибәрер өченме?

Сабирның күз алдына үзенең сакалы биленә җиткәнче таулар арасында чыбыркы өстерәп йөрүе килеп басты. Бала йоннары кабарып чыкты аның.

– Нигә көтү көтәргә? – Зема топчаныннан иелә төште. – Базарларда шашлык ясап сатарга. Этем дә сизмиләр кешеләр, өстәп, чили соусын ягып җибәрсәң... Кеше ите сарык итеннән берни белән дә аерылмый, ди. Безне шундый язмыш көтмиме икән? Атна-ун көн тыгындырырлар да унлата хакын кайтарырлар...

Бу фараздан күзләреннән яшьләре өркелеп чыкты Сабирның. Хәтта стенага таба борылып ятты. Ярар, ул адәм әүлиясе булмасын да, ди. Кылган гөнаһлары юып бетерерлек кенә түгел, үзе дә аңлый. Бәхетсез гомер кичерүенә буйсынган иде. Әмма... Әмма бу фани дөньядагы соңгы минутларын үз өенең чиста

япмасында якыннары белән бәхилләшеп үткәрер, дип күзаллый торган иде һәрвакыт. Ә бу зобаныйның сүзләре хак булса, аның җәсәден шашлык итеп күмерләрдә кыздырырлар, сөякләрен ялтыратканчы кимерерләр. Бр-р...

– Зема, синдә, әлбәттә, хыял көчле, сатулашмыйм. Тик бу очракта бездән саллырак кешеләрне ашатып-нитеп тормый кызыл күмерләрдә кыздыра алырлар иде. Әнә кара, шәһәр тулы тротуарга сыялмый йөрүче хатыннар. Йөге белән төяп алып кит тә илдәге ашау проблемасын хәл ит. Аларны эзләп йөрүче дә булмас иде. Ирләре, мәсәлән, кайтып керә күрмәсен дип, чиркәүләрдә шәмнәр куяр иде. Ю-у-к, монда икенче мәсьәлә. Җавабын белергә баш кына җитми. Йә, ярар, иртәгә барысы да билгеле булыр. Ә бүгенгә тамак тук, кәеф күтәренке, ятар урын бар. Шулай булгач, нәрсә эшләргә кала, Зема?

– Кемдер уятканчы йокы симертергә, Минтон.

– Алтын сүзләр! Хәерле йокылар, тәмле төшләр барыгызга да...

Ике дус киерелгәләп йокыда онытылдылар. Сабир гына уңга-сулга әйләнгәләп һич йоклап китә алмады. Хәтимәсен искә алды, нәрсәләр уйлый икән аның хакында? Тетмәсен тетәдер инде, әле авыл башлыгына хәбәр иткәндер, эзләүләр башлангандыр. Әгәр бердәнберенең сүзеннән чыкмый гына яшәсә, аннан акыллырак кеше булмас иде дөньяда. Могҗиза булып үз бусагасына кайта алса, тезләнер иде сөйгәне каршына...

* * *

Иртән читлек эчендәге тоткыннар ангар ишекләренең шыгырдап ачылганыннан уянып киттеләр. Арты белән чигенеп кереп килгән прицеплы «КамАЗ» машинасының фаралары күзләрен чагылдырды. Авыр йөк машинасы стенага терәлеп дигәндәй туктады да тынып калды. Шулчак читлек янында «маскхалат» пәйда булды.

– Завтрак! – диде ул калын тавыш белән. Иртәдән аның кәефе күтәренке иде. Тагын өстәл тутырып тәгамнәр тезелде. Шешәләр генә күренмәде. Доходяганың сораулы карашын дөрес аңлап, «маскхалат»:

– Анысы да булыр, ләкин соңрак, ә хәзер дыңгычлап тутырыгыз бүксәләрегезне. Сезне бөек эшләр көтә!

Ашауның артыгы булмый, дип, тагын өстәл кырыена елыштылар. Теге Бугай барысыннан алданрак тотынды. Ул арада машина шофёры арткы бортны ачты да ангардан чыгып ук китте. «Маскхалат» ашыктырмады, җәелеп китеп ашадылар, күбенгәнче кайнар чәй эчтеләр. Теге Бугай савытларны ялап-ялтыратып куйганчы кузгалмадылар.

– Инде бер-ике сәгать черем итеп алырга да була, – диде Зема, авызын ачып иснәп. – Кояш чак күтәрелеп килә...

– Анысы кичкә. Хәзер мин әйткәнне тыңлыйсыз. Менә сезгә бияләйләр. Эчәсе килгән кешегә менә бу краннан чиста су агып тора. Кеше башына берәр кап тәмәке. Безнең бурыч нинди? Менә шул КамАЗдагы капчыкларны бушатырга, тигез итеп унбиш кат итеп өеп барырга. Әнә тегендә, стена буенда, траплар бар, шулардан файдаланырсыз. Прицеп бушагач та, баганадагы кызыл төймәгә басарсыз. Шофёр кереп прицепны читкә алып ычкындырыр, бортын якынга җайлар. Башка проблемалар туса да, шулай аралашабыз. Сафый, син беләсең, төймәгә басарсың, пип-пип...

Теге Бугайның исеме Сафый булып чыкты. Ул аңлаганын белдереп, кат-кат баш какты, тешсез авызын ерып көлгәндәй итте:

– Гы-гы... пип-пип...

Чынлап та, килделе-киттеле бәндә булды, ахрысы, кайчандыр монда тамак туйдырган әле.

– Әйдәгез, башлап карыйк эшне, – диде «маскхалат». – Алдан ук кисәтәм: кояш төшлеккә күтәрелгәнче машина бортлары бушаган, капчыклар өелгән булырга тиеш. Өйләдән соң икенче машина килеп җитәчәк. Әгәр сачковать иткән сантый табылса, урталай өзәм. Шаяра дип уйламагыз. Мин болай тыштан караганда гына изге күңелле. Марш, марш...

Башлап китүләре авыррак булды. Бераздан эш җаена төшенделәр. Көч барда, егәр барда илле килолы капчыклар очып кына йөрде. Сафый бөтенләй ике култыгына ике капчык кыстырып ташыды. Эшләр болай рәткә салынгач, «маскхалат» бик риза булып, үз эшләре буенча китте.

Шактый вакыт тигез генә эшләделәр, капчыклар саны күзгә күренеп кимеде. Авыр эшкә күнеккән Сабир артык талчыгу сизмәде. Әмма бераздан Минтон белән Зема хәлдән тайдылар. Атлап йөрүләренең рәте китте, кулларыннан капчыклары шуып җәфалады. Фанфуриктан артыкны күтәреп өйрәнмәгән «доходяга»лардан тагын нәрсә көтәсе?

Прицепны ничек итсә итеп, бушатып бетерделәр. Әле алда тулы бер кузов бар иде. Капчыкларны югарыга мендереп өюе дә бик авыр. Бары Сафый гына мамык ташыгандай эре-эре атлап йөрүен белде. Тагын бер нәрсә нык комачаулый иде эшкә. Әлеге капчыкларга ниндидер химикатлар тутырылган иде булса кирәк. Шул нәмәрсәкәй авыз-борыннарга тулып төчкертте, күзләрдән туктамый яшь акты. Шофёр прицепны күчереп, машинаның бортын өемгә җайлаганчы бераз ял иткәндәй булдылар. Шулай да теге ике дусның гыжылдап тын алулары бар ангарга яңгырап тора иде. Тәмәке тартып, унбиш минутлап утырып алгач, тагын капчыкларга барып ябыштылар. Ничек тә ярты сәгатьләп тырыштылар-тырмаштылар Зема белән Минтон. Соңыннан, кул селтәп, стена буена барып сөялделәр.

– Чукынып китсен, барыбер бер үләсе. Капчык күтәреп тәгәрәп киткәнче, аягүрә басып үләрбез, шулаймы, Зема? – диде Минтон еш-еш тын алып.

– Мин риза, безнең өчен ни кызык бар бу дөньяда? Шул капчык сөйрәүдән ләззәт алабыз, дисәк кенә инде. Иртән уянасың – баш чатный, көне буе нидер капкалау хакында хыялланасың, фанфурик эләксә, түбә күккә тия. Әнә Сингапурларда ял иткән, иномаркаларда җилдергән, талчыбыктай кызларны кочкан, акчада коенган байлар яшәү өчен дер калтырап торсыннар. Ә миңа җитте, булды! Алдагы көннәремдә, могҗиза булып, череп баеп китәсем юк, таркалган бавыр ипкә-сапка килмәс, калтыравык йөрәк яшәрмәс. Килдем, күрдем бу фани дөньяның ни икәнен, бигайбә. Башкалар шатлансыннар кояш астында. Әнә теге ару белмәс экскаватор, мәсәлән, – дип килеште дусты белән Зема. Экскаваторның, ягъни Сафыйның, боларның бернинди киртәгә сыймаслык холыклары канын кайнатып чыгарды. Ул тегеләр каршына басып үз телендә ниләрдер аңлатырга теләде.

– Гы...гы ... – дип куллары белән бер машина кузовына, бер таудай өелгән капчыклар ягына ишарәләде.

– Кит әле моннан, Муму, ичмасам син җанны җәфалама, – дип бөтенләй читкә борылып утырды Минтон дигәне. Беравык басып торгач, Сафый башына акыллы фикер килде.

– Пи-пи... – дип теге кызыл төймәгә таба бара башлады ул. Монысының тәэсире булды. Кеше теле белән ничек кенә шәпләнмәсен, аның җаны һич тә тәненнән аерыласы килми, соңгы сулышка кадәр көрәшә.

– Башына капчык төшерәсе моның, – дип өстен-башын каккалады Зема. – Соңыннан рәхәтләнеп ятып йоклар идек. Чыгып шыларлык тишек тә бардыр әле бу складта...

– Сез, егетләр, бер капчыкны икәүләп сөйрәргә яраклашыгыз. Җиңелрәк булыр, – дип киңәш итте Сабир. Чынлап та икәүләшеп тотынгач, җайлы гына эшләп китте Ишәй белән Кушай.

Бер-ике тапкыр «маскхалат» килеп урады, эшләрен тикшерде. Зема белән Минтонның берләшкәннәрен күреп, тавыш куптарырга уйлаган иде, суынды тагын.

– Миңа димәгәе тешләрегез белән тарткалагыз капчыкларны, мәгәр өйлә җитүгә машина бушаган булсын!

Ярый әле араларында Сафый бар иде, ул көче белән исәпләшмәстән, төп йөкне тартты, капчыкларны биек катка ташыды, ару-талуны белмәде.

Һәрнәрсәнең азагы була. Ниһаять, КамАЗ куе төтеннәрен таратып ангардан югалды. Эшчеләр сөйрәлеп килеп үз топчаннарына аудылар. Җеп өзәрлек тә хәлләре калмаган иде үзләренең. Бераздан ризыклар төяп, тагын «маскхалат» килеп җитте. Гадәттәгечә, ашау мулдан иде, боткасы да куе, итен, маен да җәлләмәгәннәр. Бу юлы да шешәләр күренмәде.

– Дару итеп кенә салмыйсыңмы, командир? – диде Минтон ялынып карап.

– Һәрнәрсәнең үз вакыты. Давай, тыгыныгыз, бөртеге дә калмасын. Ашамаган кешедә нинди көч? Сәгать ярымнан икенче машина килеп җитәчәк. Аңа кадәр – ял!

Авызына капкан ризыгын чәйнәп бетерә алмыйча онытылып китте шикелле Сабир, аруы да җиткән иде аның...

Тагын капка ачылуга уянып киттеләр. Машина урынына җайлашканчы, «маскхалат» өстәлгә ике шешә вермут утыртты, икесен Сафыйга сузды.

– Кызып эшләргә бу бераз, каннарыгыз тизрәк агар. Ару басса, калган икесен Сафый бирер, ул үзе вакытын чамалый.

Чынлап та, шәраб кыздырып җибәрде, эшкә җиңелрәк тотындылар. Хәтта Зема белән Минтон да баштарак һәрберсе берәр капчыклап йөрттеләр. Соңрак тагын ару басты, хәл китте, минут саен салкын су чөмерделәр, ешрак тәмәке тарттылар. Иртәнге яктан күпкә әкренрәк барды эш. Сафый кыздырып җибәргәч, алай да тагын бер талпынып алдылар.

Җәйге көн озын. Шуңа карамастан, кояш батар алдыннан гына эштән туктадылар алар. Мәгәр җелекләре суырылган иде инде барысының да. Ачуым да килмәгәе, ике-өч кило авырлыкларын югалтканнардыр бүген...

* * *

Адәм баласының түземлеге искитәрлек. Тәкъдир китереп кысса, эт тормышына да күнегә ул. Икенче көнне безнең төяүчеләр җиңелрәк кичерделәр. Әнә шул тәмугка тиң газаплар атна буе дәвам итте.

Җиденче көнне төштән соң көткән КамАЗ күренмәде. «Маскхалат» та никтер әбәт белән соңлады. «Бер-бер хәл булдымы икән әллә? – дип фикер йөрттеләр егетләр. – Бәлки, хокук сакчылары койрыкларына баскандыр боларның? Иреккә чыгабыз болай булгач», – дип шатланыштылар.

Бераздан «маскхалатның» капчык күтәргән гәүдәсе күренгәч, кикрикләре шиңде тагын. Бер бәхет агачыңа күркә үссә, яхшы якка үзгәрешләр көтмә инде син. Иртә уңмаган кич уңмас...

Ни сәбәптәндер «маскхалатның» авызы ерык иде. Ул уен-көлке сүзләр

сөйләп, барысының тамагын туйдырды. Аннан соң тегеләр топчаннарга сузылгач, ишеккә сөялеп:

– Ша, братва, воля ждёт вас! – дип, һушларын алды. Төрлесе төрлечә кабул итте бу яңалыкны. Сафыйның, мәсәлән, керфеге дә селкенмәде. Минтон белән Зема кочаклашып, бер-берсенең аркаларыннан кактылар. Сабир шатланырга да, кайгырырга да белми, икеләнеп калды. Ирекккә чыгу кем өчен дә шатлык, әлбәттә. Ә менә Хәтимәсенең күзләренә ничек кайтып күренер?

– Ну, бераз эш калды әле, егетләр, – диде «маскхалат». – Территорияне тәртипкә китерәбез, ялт итеп торсын. Хуҗа бик строгий безнең. Өелеп бетмәгән капчыкларны урнаштырасы булыр. Аннан соң инде иркенләп хушлашу кичәсе. Вәгъдә – иман!

Алдагы шатлыклы минутларны күзаллап дәррәү эшкә тотындылар. «Маскхалат» та алар арасында кайнашты, нәрсәләр эшләргә күрсәтмәләр бирде. Дүртләр тирәсендә тирә-як ялт итеп тора иде, тигезләп өелгән капчыклар күзләрне шатландырды.

Өс-башларны каккалап, яраткан урынга әйләнгән өстәлне тирәләп утырдылар. Бүген бигрәк тә юмарт кыланды «маскхалат»: табында күгәрчен сөте генә юк иде. Башлап стаканнарга рубин төсле вермутны салдылар.

– Йәгез, исәнлеккә-саулыкка! – дип, «маскхалат» үзе беренче булып күтәрде. Сабир гадәт буенча сузылган кулын корт чаккандай кире тартып алды.

– Юк, миннән булмый, егетләр, үзегез генә хәл итегез.

Барысы шаркылдап көлеп җибәрделәр.

– Хатыныннан шөлли, ничек кайтып күренер, ха-ха-ха... – дип хахылдады Минтон.

– Шыр җибәрде, чалбарын юешләмәдеме икән? Ярый әле безнең андый кайгы юк... – дип кушылды Зема. «Маскхалат» елмаеп куйды, кинәт йөзе җитдиләнде.

– Көлер урын юк монда. Дөрес юлдан бара, пацан. Кешенең үз хуҗалыгы, эшләгән эше, кочаклап йоклаган хатыны, «әти»дип торган балалары бар. Гаилә башлыгы бит ул. Барысы өчен җаваплы. Кара әле, – ул Сабирга таба борылып утырды. – Синең монда килеп эләгүеңдә минем бер гаебем дә юк. Хәзер берни үзгәртеп булмый. Ничек тә проблеманы хәл итәргә тырыш.

«Маскхалат» тынып калды һәм кинәт тавышын күтәрде.

– Слушайте, сез тагы дөреслек эзләп, кемгәдер зарланып йөрергә уйламагыз! Сезгә беркем дә ышанмаячак, арада нәрсәдер исбатлый алырдаегыз юк. Ә минем кулга эләгә калсагыз, азагы начар тәмамланыр...

Күтәргән шәрабтан соң, кызарып чыккан Минтон сүзгә кушылды:

– Үткән-беткән, ну, шунысы бар бит әле, командир. Атна буе тир түктек, бераз юллык булса да акча бүлмәссеңме икән безгә? Синең яхшылыгыңны искә алып, бер гөрләтер идек пивнушканы...

«Маскхалат» хәйләкәр елмаеп үз җавабын бирде.

– Менә син үзең ничек уйлыйсың, акча түләр булсак, сезнең кебек «доходяга»ларга ауга чыгар идекме без? Шуңа күрә май кап, исән-имин котылам, дип шатлан. Ну икенче вариант бар. Ашау-эчү шәп идеме монда?

– Ул ягына сүз тидерерлек түгел, – диде Зема чын күңелдән.

– Авыр чакка юлыгып, туйганчы ашап, рәхәтләнеп эшләп китәргә уйласагыз, мин сезгә кесә телефонымның номерын бирәм. Бу урынга шулай машиналар килеп-китеп тора, һәрвакыт кабул итәрбез иске танышларны. Әнә Сафый еш кына булгалый монда...

– Юк, рәхмәт, командир, без ничек тә тамак туйдыруның башка юлларын табарга тырышырбыз инде, – диде Минтон тыйнак кына.

Шактый кәефләнгән Минтон белән Зема чалыш-чолыш атлап, үз юлларына киттеләр. Сафый һаман калган ризыкларны ура иде әле. Сабир да авыр сулап урыныннан кузгалды: кайчан да булса бер кайтып егылырга кирәктер инде туган тупсасына. Ассалар асарлар, киссәләр кисәрләр...

Шунда «маскхалат» яхшылык кыласы итте.

– Син болар арасына ялгыш килеп эләккән. Грузинны да әйтер идем, кеше таный белми. Әйдә, мин сине утырып киткән җиреңә кадәр алып барып куям. Җәяү атлый башласаң, ярты төн җитәр... Тагын бер киңәш сиңа миннән. Мин дә кайчандыр хатын белән яшәп караган кеше. Дөресен әйтмә җанашыңа, бөтенләй булмаган нәрсә уйлап чыгар. Тузга язмаган хәбәргә тизрәк ышана алар заты. Чекистлар белән шпион аулап йөрдек. Иң куркыныч агентлары, нәкъ миңа ошаган икән диген. Йә булмаса, бер чегән хатыны күз буып таборына алып кайтты, дип шыттыр. Беткәнмени...

Машина күз ачып йомганчы таныш сукмак янындагы шоссега китереп куйды аны. Дәшми-нитми төшеп басты таныш сукмакка Сабир, елгыр машина мизгел эчендә күздән югалды.

Басты Сабир сукмакка, күкрәк тирәсен угалады, тын җитми иде аңа. Авырайган аякларын сукмак буйлап көчкә сөйрәп китте. Инеш буена җиткәч, битен-башын юып алмакчы булды. Ул туктаган тал төбе ышык иде, кеше-кара күрерлек түгел. «Көн җылы, киеме дә өстә кибәр, бөтенләй карарлыгы калмады» – дип, башта чалбар-пинжәген агым суда чайкап, яшел чирәм өстенә җәйде. Соңыннан, үзе елга уртасына кереп, тәнен ышкырга тотынды.

Теге әкәмәт химикат сабын төсле нәрсә икән, ышкыган саен сылана гына барды тәнгә, юылырга уйламады да. Шактый азапланганнан соң, шул килеш чыгып киемнәренә төренде дә Сабир бөкрәя төшеп, өенә таба элдертте...

* * *

Хәтимә бу вакытта шкафтагы киемнәрен диван өстенә таратып ташлап, үзе белән шәһәргә ниләр алырга, дип баш ватып утыра иде. Өмете өзелгән иде инде хатынның Сабирыннан. Тәки яңа тормыш башларга карар иткән иде ул. Ни көтә аны шәһәрдә? Анда өеп куйганнар, дисеңме әллә? Кеше тупсасында килмешәк булып күпме гомерләр кичерер? Яхшы эш табылса ни... Берәр юньле генә абышка очрату бәхете тисә ни...

Яхшы, акчалы эшләргә күптән хуҗалар табылгандыр, адәм рәтле ирләрне дә күптән сайлап алып бетергәннәрдер, тешләре-тырнаклары белән ятлардан саклап кына торалардыр үзләренең кәкре сыйраклары.Үлгәнче ир җылысы тоймый ялгызлыкта гомер кичерергә язганмы икән әллә аңа?

Ни булса да тәвәккәлләп карарга кирәктер, ахрысы, тәвәккәл таш йоткан, диләр бит. Монда бер сыерның җиленен тарткалап көннәр үткәргәнче...

Шулчак ян тәрәзәдән бер адәмнең шым гына үтеп киткәнен чамалап калды ул. Сабир ич бу, аның Сабиры! Әллә түгелме? Нигә сары бөдрәләре ак төскә кереп, бозау ялаган төсле артка ятып тора? Суырылган йөзе дә он сипкәндәй ап-ак. Кигән киемнәре акка мангандай шыкраеп каткан. Мең төрле уйлар үтте сыны каткан хатын башыннан. Ул арада чолан ишегенең шатырдап килеп төшкәне ишетелеп калды, бусага артында теге бәндә күренде.

– Исәнме, Хәтимә, исән-сау гына тордыңмы? – дигән сүзләрне ишеткәч,

Хәтимә чынлап та бу актан килешле бәндәнең үзенең хәләл җефете Сабир икәнен танып алды.

– Ләхәүлә... – диде ул кулларын күкрәгенә кушырып. Тагын нидер өстәп әйтергә белми тынып калды. Берсеннән-берсе ярсурак тойгылар кайный иде күңелендә. «Исән икән әле, Ходайга шөкер», – дип уйлады ул беренче мизгелдә. Икенче мизгелдә күзләрен кан басты: «Җанын җәһәннәмгә очырам бу җирбитнең, миңа шул кадәр хәсрәтләр китергәне өчен... Утыртсалар утыртырлар, ничава, анда да кешеләр ич».

– Керергә рөхсәт итәсеңме, Хәтимә? Ышан, тырнак очы кадәр дә гаебем юк минем синең алда... – диде Сабир күзләрен яшьләндереп. Чынлап та, әллә ул үзе теләп, атна буена арка чиләндереп, чутсыз КамАЗлар бушатып яттымы?

– Шуннан гына сөйлә! – дип әмер бирде аякларын аерып басып Хәтимә.

Күз чите белән генә саплы табаның кайдарак торганын чамалап куйды. Әле үз уеннан кире кайтмаган иде ул. «Андый гаярь хатыннар да очраштыргалый бу кояш астында, шуңа күрә бик сак булырга кирәк без ир-атларга», дип фикерләде Сабир.

– Дөресен генә сөйлә! Алдашканыңны сизсәм, җаныңны җәһәннәмгә олактырам, холкымны беләсең! Аннан уйлармын: кертергәме син юньсезне бусага аша, әллә юкмы…

– Валлаһи, алдашмыйм, җаным. Кеше ышанмас хәлләр! Үзем дә һаман ышанып бетә алмыйм әле...

– Кыскарак тот. Эчкәнеңнән башлап җибәр, – диде түземсезләнеп Хәтимә.

– Нинди эчү, нинди эчү? Ринаттан сора әнә, ул белә, кайтыр сукмакка ап-аек аяк бастым. Киләм шулай посадка буйлап. Теге без синең белән җиләк җыйган аланлык бар бит әле. Шуның уртасында тәрилкә...

– Уф ,үләм. Тәрилкә! Табак түгелме? Шул тәрилкәгә карап басып тордыңмы атна буе?

– Атна буе?! – дип гаҗәпләнгән булды Сабир йөзен дә чытмый. – Күп булса ярты сәгать вакыт үткәндер. Әле сәгать ничә соң?

– Ну, тилебәрән орлыгы ашаган нәрсә, мине сантыйдан салдырырга булдыңмы? – Хәтимә үрелеп табаны кысып тотты. – Йә, дәвам ит әкиятеңне...

– Тукта, тукта, тәрилкә дигәч тә. Ул бит өй биеклеге ялтыр нәмәрсәкәй, төзелеше генә тәрилкәгә охшаган. Ә янында яшел тәнле бер җанвар басып тора. Ике аяклы, ике күзле, тегеләй, куллары бераз озынрак анысы...

– Исереп ятканда төшеңдә күрдеңме боларны? – диде Хәтимә. Әмма күңелендә кызыксыну уянган иде аның. Белмәссең, телевизордан да сөйлиләр күктән төшкән затлар хакында. Нигә, алар авылы янында булуы гаҗәпмени?

– Син башта тыңла. Теге нәмәрсәкәй чәшке зурлык күзләре белән бер генә тутырып карады, аяклар үзләреннән үзләре шуңа таба киттеләр. Бар җаным-тәнем белән карышырга тырышам, юк, булмый гына. Теге нәмәрсәкәй кырына барып җиткән идем, мамык урынына күтәреп җилкәсенә салды да баскычтан менеп китте.

– Барып керсәң, анда шешәләр тезелеп утыра инде, иеме? Атна буе коендың да, өең исеңә төштеме?

– Сиңа көлке, Хәтимәкәем. Алар бит мине ялтырап торган караватка сузып салдылар.Тагы икесе бар икән әле эчтә. Кузгала да алмыйм, ант менә.

– Нәрсәгә кирәк булгансың син аларга? – Хәтимәнең тавышы бераз йомшара төшкән иде.

– Кискәләгәннәрдерме, бүлгәләгәннәрдерме – һич хәтерләмим. Мин шул килеш онытылганмын... Күзләремне ачып җибәргәндә барлык эчке әгъзаларым ут булып яна иде. Шуннан почмакка бастырдылар да баштанаяк бер ак сыекча белән коендырдылар. Берәр төрле химикаттыр, дип уйладым, үземчә.

– Шакшы исең белән бөтен өй эчен тутырдың, сасы көзән. Әкиятеңнең азагы ничек тәмамлана инде?

– Мине баскычтан төшерделәр дә, үзләре күтәрелеп киттеләр. Әкренләп буыннарга хәл кергәндәй булды. Үрмәләп дигәндәй кайтып киттем инде. Менә каршыңда басып торам. Үзем дә иләс-миләс хәлдә, Хәтимәкәй, әллә булды, әллә юк ул тәрилкә дигәне. Бар күңелем курку хисенә уралган. Нәрсә эшлим мин, сиңа кайтмый, кая барыйм? Бер син адәм кыяфәтенә кертә алырсың мине. Түлке берәрсенә ычкындыра күрмә инде, зинһар. Минем тел озайтканымны сизеп калып, йә тагы эзләп килеп җитәрләр. Зинһар өчен, Хәтимәкәем, үтенеп сорыйм синнән...

– Пычак астына яткырып, ун килолап итеңне кисеп алганнар булса кирәк, как сөякләрең генә калган.

– Хәтимә, зинһар гафу ит мине, – дип, Сабир тупса аша атларга уң аягын күтәргән иде, Хәтимә табаны аңа таба сузып, бер генә сүз әйтте:

– Стоять!

Ике ут арасында иде ул. Кичерергәме бер юлга бу дуңгызны, әллә, әнә бара юлың, дип кире борыргамы? Ныклап уйлап карасаң, сүзләрендә дөреслек тә юк түгел кебек. Ябыккан ябыгуын, әмма аракы исе сизелми. Өйрәнгән яу сугышырга яхшы дигәндәй, барыбер яраклашканнар бит инде алар бер-берсенә. Ирсез яшәүләре дә ай-һай авыр бу кырыс дөньяларда. Нинди булса да, арка терәр кеше шушы. Әнә чолан ишеге дә килеп төште, бер сәнәк печән юк абзар башында... Ярый әле, авыл өстенә ялга җибәрдем, дигән хәбәр таратты. Тик моның йөзен күргәч, ял итеп йөргәненә беркем дә ышанмас инде. Сөтне-каймакны җәлләми тәненә бераз ит кундырып алырга кирәк булыр...

Бу вакытта өмете өзелгән Сабир күтәргән аягын кире төшергән иде. Себер якларына чыгып китәсеме? Анда вагонда кунып йөрсәң дә, тамакны карыйлар, акча да шактый төшә, диләр. Тормыш әкренләп җаена килер...

– Инде мине тыңла! – диде Хәтимә каты гына. – Өйгә керү мәсьәләсе ачык кала. Беренче шарт: башкача авызыңа бер тамчы да шайтан суын алмыйсың!

– Юк, юк, – дип туктамый башын селекте Сабир. – Анысыннан дәваладылар, ахрысы, инде мине.

– Икенче шарт: очраган берсенә, ял йортында булдым, диярсең. Нindидер дарулары килешеп бетмәде, шул җелегемне суырды, алдан ташлап кайтып киттем, дип шыттырырсың бераз. Ә хәзер кыздырып мунча як, бу киемнәреңне дә шуның утына ташла, өч сәгать чыкмый шакшыларыңны кыр. Моннан соң йоклау урының верандада булыр, мин башкача синең белән түшәк уртаклашырга уйламыйм. Өченчесе: иртән как штык эшкә! Сагынганнардыр анда сине.

Бу сүзләрдән Сабирның ак йөзе тагын да агарып киткән төсле булды.

– Түлке тимерчелеккә бармыйм. Терәп атсаң да, бармыйм, гөлкәем. Лутчы фермерга ялланам. Күптән чакыра, акчаны да күбрәк түләргә вәгъдә итә...

– Ну, акчасы күбрәк булса, мин каршы түгел, – диде Хәтимә йомшап.

Шуның белән сөйләшүләрнең беренче раунды тәмамланды.

* * *

Хатынының әмерләрен берсүзсез җиренә җиткереп үтәргә алынды Сабир. Яңа эшендә янып эшләде, өйдә дә йөгереп кенә йөрде. Чолан ишеге яңартылып үз урынына кадакланды. Җаен табып, чабынлык җирләрен дә вакытында чаптырып, печәнен абзар башына тутырып куярга өлгерде. Гомумән, хатынының күзләренә генә карап торды.

Әмма әлегә кадәр йокы урыны веранда диванында иде. Хәтимә чакматаш кебек хатын, тәки сүзендә торган булыр иде. Ләкин вакыт үткән саен, ул иренең сөйләгәннәренә бар күңеленнән ышанды һәм ничектер шайтан ләгыйнь аның уйларын чуалтты. Теге күктән төшкән кунаклар берәр төрле үзгәрешләр кертмәгәннәрме икән иренең фигыленә? Булмас, димә, галәмне иңләп очкан нәрсәләр барысын да булдыралардыр. Тыела алмады, хисләренә ирек бирде: иренә елмаеп карады, янынннан сырпаланып үтте. Хикмәти Хода, бик тә килеште аңа бер юрган астында төн үткәрүләр. Чынлап та, үзгәрешләр булганмы, әллә бер-берсен артык тансыклаганнармы, анысы безгә караңгы.

Сабир хатыны каршында бер карышка үсеп китте. Тегенди-мондый гына түгел бит аның ире, ерак йолдызлардан килгән затлар белән аралашкан. Тагын кем бар авылда андый күренекле бәндә? Нәрсә авылда? Районда, хәтта республикада көндез шәм яндырып эзләсәң дә, таба алмассың Сабир кебекне.

Сер ул бер кеше белсә генә сер булып кала, ике кеше белдеме – бетте диген. Хәтимәне дә көне-төне корт кимерә башлады: кем белән бүлешергә бугазны ярып чыгып килгән бу яңалыкны? Кем бар сер сакларлык?

Киңәшчесе итеп тиңдәше Гөлсараны сайлады. Сабирының да төшеп калганнардан түгел икәнен белгертәсе килде шул почык борынга. Теге ялгыз чагында юк сәбәпне бар итеп барып керде дә, сүздән-сүз чыгып, түкми-чәчми сөйләп бирде ахирәтенә иренең башыннан үткәннәрен. Кат-кат кисәтергә дә онытмады:

– Бер син генә беләсең, кара аны, тешеңне агартсаң, борылып та карыйсым юк! – диде.

– Юк, юк, юләрме әллә мин шундый хәбәрне кемгәдер сөйләргә? Ипекәйдер менә, йөзем саргайсын, телем корысын, бер кәлимә сүз әйтсәм...

Билгеле инде, көтү кайтканда, авыл халкы бергә бишне кушып, искитмәле яңалыкны тикшерә иде. Шул көннән башлап ахирәтләр кан дошманга әйләнде...

Ә халыкның авызына яулык каплап булмый. Йолдыздан төшкән кунаклар турында хәбәрләр еракларга таралды. Сабирның дәрәҗәсе бермә-бер артып китте.Теге җиләкле аланлыкны тикшерергә әллә нинди белгечләр килеп тулды, гәзитләрдә мәкаләләр басылды. Хәтта телевизорда Сабирның җитди карашы чагылып калды.

Шуннан артыгы булмады шикелле. Сабир туры килгәндә, тагын әз-әзләп тоткалый башлады. Хатынына тоелган үзгәрешләр дә эреп юкка чыкты, бик кыска вакытлы булган, ахрысы, тегеләрнең тәэсире. Шулай да, күгәрченнәрдәй гөрләшеп яшәп яталар әле Хәтимә белән Сабир. Ни әйтсәң дә, берәүгә берәү кирәк, таянырга терәк кирәк.

Тагын шунысы бар икән әле. Сабир теге грузинның машинасына утырып киткән урын паранормаль зона дип йөртелә башлады...



Фәйрүзә
Мөслимова

# ҖӘЙНЕҢ ҖЫЛЫ, КОЯШ ТУЛЫ АЯЗ КӨНЕ...

## Исән булсак...

Күбәләктәй очып кына йөргән чакта,
Дус-туганнар булган чакта яныңда –
Килер заман, берьялгызым калырмын, дип,
Ялгыш кына килми хәтта уеңа.

Ярты сүздән аңлашырдай фикердәшләр
Адым саен очрап тормый юлыңда.
Гаепләмә, кемдер сиңа үпкәләсә –
Аңлашырдай кешесе юк аның да.

Серләреңне димим әле, гади генә
Сүзләреңне сөйләп булмый читләргә.
Һәр кешенең бар нәрсәгә үз карашы.
Туры килә телләреңне тешләргә.

Юксындыра дус-туганнар, аңлашулар,
Шаярып та сөйләшүләр үзара.
Намаздан соң дога кылыр кешеләрнең
Исемлеге озая да озая.

Кемнең нәрсә язылгандыр тәкъдиренә?
Насыйп түгел безгә моны белергә.
Хәзер инде берәр план кора калсак,
Онытмыйкчы: «Исән булсак», – дияргә.

---

Фәйрүзә МӨСЛИМОВА (1954) – *шагыйрә, прозаик; «Ярату яралары», «Апрель кары», «Алтын йозак» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. С.Сөләйманова, А.Алиш исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

## Җырчы кызга

Һай, гүзәлсең! Кыйгач кашлар!
Чәчәк кебек иреннәр..
Калфакка япкан яулыгың
Сарылып төшкән иңеңнән.

Ефәк яулык – челтәр-челтәр,
Калфагың – энҗе-мәрҗән.
Сылулыгыңа сокланып
Язып тордым телемнән.

Гүзәллегеңне үзең дә
Яшисең кебек белеп.
Җыр башладың. Калырсыңмы
Күңел түренә кереп?

Ә җырың бит... ә җырың бит –
«Тәфтиләү» иде, сеңел!
Тик нигә соң ул сагышны
Кичерәсең бик җиңел?

«Очты дөнья читлегеннән
Күңелем кошы», – диясең.
Моңлы җыр сузасың юкса,
Үзең балкып көләсең.

«Аерылабыз», – дип җырлыйсың,
Елмаясың ник кенә?
Үз-үзеңә соклануны
Яшерче чүт-чүт кенә.

«Очты дөнья читлегеннән...»
Бигрәк авыр күңелгә.
Чәлпәрәмә килде җаным.
Елмаясың син нигә?
Елмаясың син нигә?

## «Сак булыгыз!..»

Җәйнең җылы, кояш тулы аяз көне.
Күңелдә дә һичбер болыт юк сыман.
Күзем төшеп, бер кисәтү сискәндерде:
«Сак булыгыз, кар ишелү ихтимал!»

Таш бинаның диварына кыш көнендә
Эленгән дә онытылган бөтенләй.
Шул белдерү көлә кебек кешеләрдән:
«Ашыгасың? Бер мизгелгә туктал, әй!»

Зиһенеңә тиз арада барып җитми
Җәй көнендә кар ишелмәү өстеңә.
Ишелүләр ишетелеп тора ләкин...
Кар гынамы? Төшер, төшер исеңә!

Искә алып, борчыласы киләмени?
Бу дөньяга без бит мәңгегә туган!
Тик диварда ник тора соң ул кисәтү –
«Сак булыгыз, кар ишелү ихтимал»?

## Сагынып кайту

– Кайтыйк, улым, өебезгә,
Кайтыйк инде үзебезгә, –
Дип инәлде кабат-кабат
Җиткән чакта өзелергә.

Югыйсә бит үз өендә,
Үзе корган нигезендә
Соң теләген әйтү иде
Багып улы күзләренә.

– Әткәй, ахры, саташасың,
Ник каядыр ашыгасың?
Күз сал инде як-ягыңа:
Элеккечә бит бары да.

Без яшәгән өй бит инде,
Үстердегез монда безне.
Һәм озаттык шушы өйдән
Мәңгелеккә әниебезне.

Балаларың синең янда,
Барыбыз да, әткәй, кара. –
Дөрес әйтә кебек улы,
Ник күзеннән яше тама?

– Кайтыйк, улым, үз өемә,
Минем өем авылымда. –
Балачагы бүген шулай
Килә бугай күз алдына.

...Һәм оча ул авылына,
Ирешә җаны хыялына:
Үзенең йорты – мәңгелеге –
Сыендыра кочагына...

## Ялгыз

Китсәм – ялгыз, кайтсам – ялгыз,
Күтеп алыр кешем юк.
Берәүгә дә үпкәләмим,
Берәүгә дә үчем юк.

Тәкъдиргә каршы бардыммы
Сынауларда сынатып?
Очкан чакта егылып төштем
Канатларым канатып.

Мин күкләргә ашкан чакта
Елап калды кемнәрем?
Күрмәү – бер хәл, томаланган,
Күрәсең, зиһеннәрем.

Яшьлектә акыл бирмәгән,
Акыл кергәч – яшьлекне.
Чачак-чуктан арындырдым
Хыялларны, өметне.

Юк! Бу – дөнья йөкләреннән
Вакытлы ару гына.
Ялгызлыкны сылтау итеп,
Моңаеп алу гына.

## Самавыр

Кисәү агач белән тартып
Кызарып янган кузны,
Җырлатып кына җибәрәм
Сагынылган самавырны.

Мин авылдан киткәнче үк
Күчкән идек чәйнеккә.
Ә самавыр чыгып китте
Картаерга – чиннеккә.

Каникулга кайткан саен,
Мин аны алып керәм.
Самавырлы балачакны
Хәтеремә төшерәм:

Әнкәй, энем, мин – чагылып
Самавыр көзгесендә,
Сөтле чәйләр эчә идек
Иртәсен дә, кичен дә.

«Үтүк» тә булып торды ул
Тасмамны шомартырга:
Ялт иттерде  бер-ике кат
Кайнар йөзенә ышкуга.

Кунак каршылау тәртибен
Өйрәткәндә дә миңа,
Әйтте әнкәй: «Әүвәл тотын
Самавыр колагына».

Самавыр капкачын ачып,
Йомыркалар да тездек.
Микро, мульти-пешергечләр
Самавыр иде элек.

Еллар үтте, самавырны
Кайнаткан чагым кайда,
Кузлар тартып мич алдына,
Кайтканда каникулга?

Самавырлар үткәннәрдә!
Ләкин күңел түрендә
Кайнап тора, җырлап тора,
Чәйгә дәшә бүген дә.

## Вирус

Уемда юкны гөманлап,
Тактылар миңа гаеп.
Акланудан нинди мәгънә?
Тик бераз төште кәеф.

Читтән ят вирус кертелгән
Компьютер булды башым.
Күтәргәме бер белгечнең
Киләсен, коткарасын?

Замана алга китсә дә,
Компьютер бит – бичара.
Мәгълүматын үзгәртергә
Ничек тапсын ул чара?

Бирешимме шул вируска?
Мин бит компьютер түгел! –
Борчылсын гаеп тагучы,
Вирус кертеп маташучы!
Миңа хәзер бик җиңел...

## Кышкы күренеш

Ап-ак карга төренеп оеганнар
Чыршыларның зифа сыннары.
Янәшәдә тора көязләнеп
Бизәнешкән миләш кызлары.

Алсу-кызыл миләш төймәләре
Песнәкләрне дәшә еракtan.
Шул түгелме кышның хозурлыгы –
Йоклап яткан җанны уяткан?

Чистартылган тигез аллеядан
Узулары җайлы булса да,
Шаян малай, көрткә бата-чума,
Кар өстеннән яңа юл сала.

Нигә мин дә йөрмим аның кебек,
Ник аунамыйм яңа карларда?
Бу эшемнән һичкем илһамланмас,
Әйтерләр тик: нинди дивана!

Ә балага килешә, уйламый ул
Ни әйтер дип моңа башкалар.
... Вакыт арты вакыт алышына,
Ява гына, ява ак карлар.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Рәмис
Латыйпов

# КӨРӘКСЕЗ НЕФТЬЧЕЛӘР

ПОВЕСТЬ

## Бөек Сер

Без Агу өенә таба барабыз. Без – өчәү: Пикули, Пипип һәм замлА. Ике туган һәм гел безнең белән йөри торган бер күрше малае.

Ике туган бер-беребезне Пикули һәм Пипип дип йөртәбез. Бервакыт без гәзиттә пикули дигән әйбернең рецептын күрдек. Нәрсә икәнен дә хәтерләмибез инде. Ул сүз безгә бик кызык тоелды да, без бер-беребезгә Пикули дип әйтешә башладык. Икебез дә Пикули булгач, кызык түгел икән. Шуңа охшаган башка исем уйлап таптык. Тагын гәзит актардык. Программада «Пи» дигән фильм күрдек. Нәрсә турында икәнен дә белмибез инде. Шуны үзгәртеп, Пипипкә әйләндердек.

Күрше малаен без замлА дип йөртәбез. замлАны кирегә укысаң, Алмаз була. Алмаз – аның чын исеме. Без бөтен кешеләрнең исемнәрен киредән укып, шулай атап йөртәбез. Фәрит икән, тирәФ була. Мансур икән – руснаМ. Бу сөйләмебез безнең телдән башка малайларныкына да күчә. Алар да бездән күреп, шулай сөйләшкәли. Әмма безнең кебек оста сөйләшә алмыйлар. Без башка әйберләрне дә шулай киредән укып сөйләшәбез. Ияләшеп беткәч, ә дигәнче аңлашабыз. Ә башкалар аңламый, безгә рәхәт.

Менә безнең кулда камрак белән кәлич, кычпак. Кармак, чиләк, капчык. Шулай дип сөйләшеп барабыз. Кычпак эмәднис? Капчык синдәме?

Без шулай сөйләшәбез, кешеләр безне ишетсә дә, аңламый. Бөтенесе дә безне балыкка бара, дип уйлый. Чынлыкта без балыкка бармыйбыз. Өчебезнең дә бөек Сере бар.

Безнең кесәдә – карта! Без нефть казырга барабыз!

Бөек Сергә барырга без озак әзерләндек.

Җәйге җылы көндә балыкка барган малайлар үзләрендә нәрсә яшерә ала? Берни дә яшереп булмый кебек. Ә безнең үзебез белән ике көрәк, бер чиләк бар. Җәйге кием астына кеше күрмәслек итеп көрәкләрне яшереп карагыз. Бөек Серне тормышка ашыру өчен без җаен таптык.

---

Рәмис ЛАТЫЙПОВ (1977) – *журналист, публицист. Казанда яши.*

Көрәкләрне сабыннан аердык. Кеше безнең кулдагы капчыкны кәҗәләргә тал ботагы алып кайтыр өчен кирәк, дип уйлый торгандыр. Чынлыкта ул капчык эчендә ике тимер көрәк бар.

Кешеләр бу эссе көндә малайлар курткаларны, калын чалбарларны черки тимәсен өчен кигән, дип уйлый. Ә чынлыкта ул киемнәр астында көрәк саплары! Көрәк сабының бер очы тубыкка тиеп тора, чалбар, куртка эченнән кулбашына кадәр килеп җиткән. Шулай кием астында яшереп алып барабыз. Атлаганда комачаулый. Аякны бөгеп булмый, аннары көрәк сабы күлмәк эчендә селкенеп бара. Әмма чыдыйбыз. Бөек Сер хакына!

Көрәк сабын кулга тотыйкмы әллә, дип тә уйлаган идек башта. Булмый. Кеше сизенер, дидек. Башкалар күрсә, Бөек Сер ачыла! Шуңа күрә кыска булса булсын дип, аяктан иңбашына җитәрлек итеп үлчәдек тә көрәк сабын кисеп аттык.

## Көрәк эзләү

Көрәкне алдык, дип әйтүе генә җиңел. Алганчы, аларны табарга кирәк.

Без әби белән яшибез. Ул – әнинең әнисе. Безнең әни дә бар. Әмма без әби белән күбрәк яшибез. Әнине бөтенләй күргән юк, дисәң дә була. Безнең әни – җырчы. Ул безне әбигә калдыра да айлар буена китеп югала.

Бу юлы да әни безгә: «Әйбәт торыгыз. Без җылы якларга китәбез. Тәмле әйберләр алып кайтырбыз. Әбиегезгә акча калдырдым. Кирәк нәрсәләр булса, аннан сорарсыз», – диде. Бер кочаклап сөйде дә сары мыеклы баянчысының машинасына утырып чыгып китте.

Без беләбез – чынлыкта әни әбигә акча калдырмый. Дөресрәге, әби әнигә акча калдырырга рөхсәт бирми. Ристан малайларыңа акча калдырсаң, алып калмыйм, дигәнен ишеткәнебез бар.

Безнең әтиебез дә бар. Ул да җырчы. Кайдадыр җырлап йөри. Телевизор карауччы малайлар әтиегезне күргән бар, дип әйтәләр – концертларда аны күрсәткәлиләр икән. Безгә телевизор карарга рөхсәт юк. «Шайтан тартмасы» карап күзсез каласыз, ди әби. Әти турында әбидән дә, әнидән дә сораган бар.

– Әтиегез еракта, – диләр иде башта.

Аннары:

– Аңа сез кирәкми. Аның башка кешесе бар, – ди башладылар.

– Башта бит сез еракта ул, кайтыр, дип әйтә идегез, – дибез.

– Сез ул чакта кечкенә идегез. Хәзер инде сезгә әйтеп була, – диләр.

Авылдагы малайларга уенчыкларны әтиләре сатып ала. Әти булмагач, уенчыкларны әбидән сорыйбыз. Әмма әбидән нәрсә генә сорасаң да, ул аны сатып алмый, акча юк, ди. Ул әле үзе генә түгел – әнигә дә уенчыклар сатып алырга рөхсәт бирми.

– Балаларны бозасың. Аларга уенчык түгел, син кирәк, – ди.

Әни аның сүзен тыңлый.

Безгә көрәкләр кирәк. Безнең ике генә көрәк бар. Берсе – яңа, икенчесе күгәргән, иске. Аларны алсак, әби сизәчәк.

ЗамлАларның лапасларында әллә ничә көрәк бар.

Без аңа әйтәбез:

– Көрәкләрне син тап, замлА.

– Каян алыйм?

– Сездә көрәкләр күп.

– Мин көрәк алганны белсә, әти үтерә! – ди замлА.

– Без нефть тапкач, сиңа яңа көрәкләр сатып алырбыз, – дибез аңа. Ул ризалаша.

Әниләре өйдә булмаганда, замлАларда без. Лапасларына кереп актарынабыз. Почмакта сөялеп торган ике көрәкне алабыз. Кием эченә тыгып алып барабыз, дип хәл иткәч, кайсы җиргә качып кыскартырга икән, дип уйлыйбыз. Лапаста андый урын юк, печәнлеккә менәбез. Чүкеч, кадак суыргыч белән азаплана торгач, көрәктән сапларын тартып чыгарабыз. Хәзер шома сапны кул пычкысы белән кисәргә кирәк. Түгәрәк һәм шома көрәк сабын кисүе бик авыр. Беребез тотып тора, беребез кисә. Көрәк сабы шуып йөри, пычкы эзгә керми. Икебез тотып тора, беребез кисә. Тырыша торгач, пычкы эзгә керә, әмма сикереп, замлАның кулына тия. Ул «а-ай!» дип кычкырып җибәрә, шул ук вакытта астан куркыныч тавыш ишетелә.

– Нишләп йөрисез анда, малайлар?

Яраланган дию кычкыра, диярсең, шундый куркыныч ул тавыш. Без нишләргә дә белми, өнсез калабыз. Бөтенебез берьюлы бармакларны иреннәргә китерә: «Т-сс, тавышланмагыз!»

– Малайлар, төшегез!

ЗамлАның әнисе. ЯирәС. Сәрия апа инде.

«Ишетте ул безне», – дип пышылдый замлА. Без аңа сөйләшмәскә кушабыз.

– Малай актыклары, төям яныгызга менсәм, төшегез хәзер үк!

ЗамлА төшәргә дип кузгала. Без, икебез ике яктан атылып, замлАның авызын кысып, печән өстенә егып салабыз. Безнең кыштырдашканны ишетмәс дип уйлаган идек, ул ишеткән булып чыкты. Печәнлек авызыннан яирәСнең башы күренә:

– Шайтан малайлар! Ут белән уйныйсызмы монда?

ЗамлА безнең кулдан ычкынып, әнисенә таба китә.

– Юк, әни, без болай гына менгән идек, уйнарга.

– Уйнатырмын мин сиңа менә! – Әнисе замлАның башына ялт-йолт кына сугып ала.

Малай акырып елый да башлый. ЯирәС аны җилкәсеннән тотып җилтерәтә:

– Елап тор менә! Тагын берне өстәргә кирәкме?

Тагын берне өстәргә кирәк түгел замлАга. Ул шып туктый.

Якты лапастан караңгы печәнлеккә менгәнгә, замлАның әнисе көрәкләрне күрми. Ул малае белән маташкан арада Пикули көрәкләрне печән астына тыгып куя.

– Нишлисез сез монда? – дип ачуланып сорый яирәС. Чынлап менә яраланган дию инде!

– Без уйныйбыз, – дибез.

– Шырпы сызып уйныйсызмы?

– Юк, без шырпы белән теш кенә казыйбыз, – дибез.

– Кая, кесәгезне карыйм әле, шырпыгыз бардыр. Алайса, әнә, күрше авылда малайлар пожар чыгарган.

– Юк, кесәләрне карама. Без үзебез күрсәтәбез, – дибез һәм кесәләрне әйләндереп күрсәтәбез.

Шырпы күрмәгәч, яирәС тынычлана.

– Әйдә, ятмагыз монда. Төшегез. Уйнарга урын бетмәгән.

– Ярар, төшәбез, – дибез.

Без төшәбез. Көрәкләр өстә кала. Без берни булмаган кебек ишегалдына

таба атлыйбыз. Шунда замлА безне сата. Ул һаман да печәнлеккә карап тора. ЯирәС женләнеп китә:

– Нәрсәгез калган иде анда? Нәрсә яшердегез? Йәле?

Ул печәнлек баскычына таба атлый. Пикули белән без күзгә-күз карашабыз. Көрәкне таба бу!

– Ран! – дип кычкырабыз без. Барыбыз да бу сүзне аңлый. Өчебез дә капкага таба йөгереп китәбез. Капкадан чыккач, Пикули бармагы белән сул яктагы тыкрыкка төртеп күрсәтә һәм без монысын да аңлыйбыз. Өйне тыкрык аша урап узып, арт якка чыгабыз.

Арт якка чыгарга да кирәк булмаган. Печәнлектә яирәСнең кычкырган тавышы урамга кадәр ишетелеп тора. Тавышына караганда, Сәрия апа көрәк сапларын түгел, сугыш кырында яралы ирен тапкан... Әнисенең кычкырган тавышын ишетүгә үк замлА еламсырый башлый.

– Кирәкне бирә-ә...

Без Пикули белән аңа нефтьнең зуррак өлешен бирергә вәгъдә итәбез. ЗамлА ризалаша, елаудан туктый.

Әмма яирәС печәнлектә тапкан көрәкләрен безгә бирми. Башка җирдән көрәк табарга кирәк.

## Дуеш

Дуешның чын исеме Ринат. Аның әнисе немец теле укыта. Немец теле китабының тышлыгына Deutsch дип язылган. Шуңа күрә Ринатны авылда Дуеш дип йөртәләр.

Дуеш – әшәке малай. Аның Джек исемле эте бар. Ул шул этне велосипедына бәйли дә чаптырып йөртә. Без этне кызганабыз. Туктагач, Джек телен асылындырып хәл алып ята. Без эткә су бирәбез. Ул мондый чакларда суны насос кебек эчә. Дуеш шундый әшәке малай булганга, без аны таниР, дип йөртмибез. Дуеш, дибез.

Башка вакыт булса, без Дуеш янына бармас идек. Әмма аның акчасы бар. Шуңа күрә без аңа акцияләрне сатарга барабыз. Бернишләп тә булмый. Көрәк кирәк.

«Акча була», – дигәч, Дуешның күзләре яна. Ялгыз гына барган булсак, ул чәчтән йолкып, кулны каерып, акчаның кайда икәнен әйттерер иде. Өчебезгә каршы сугышырга курка. Чөнки безнең бер тапкыр өчәү аңа каршы сугышкан бар. Без Дуешны җиңдек.

– Каян килсен сезгә акча, – дип көлә Дуеш. Ә үзенең акчалы буласы килә.

– Безнең акча булса да, булмаса да, сиңа көрәк бәясен кире кайтарабыз. Син безгә хәзер көрәклек акча бир, – дибез.

– Хәзер акчагыз булмагач, аннары каян килә соң ул сезгә? Әйдә, сез миңа акцияләрне түгел, уенны бирегез... Менә уенны сатып алам.

Дуеш ике көрәк өчен бездән «Акционер» уенын алып кала. Әле нефть тапкач, без аңа тагын ике көрәклек акча бирергә тиеш булабыз. Ул көрәккә акча бирми. «Әтигә күрсәтмәгез», – дип, ике иске көрәк чыгарып бирә.

– Кычкыртып талады бу безне, – ди Пикули.

Аның каравы саплары куелган көрәкләр! Без аларны арт яктан гына алып кайтабыз, лапаска алып кереп, такталар арасына яшерәбез. Шунда безнең буйга үлчәп, кыскартып кисәбез.

Көрәкләр булды. Безгә хәзер нефтьне казырга гына кирәк. Безнең кулда карта бар!

## Нефть

Безгә бакчадагы тәрбиячеләр дә җир астында нефть бар, дип сөйлиләр иде. Малайлар да нефть бар, ди. Җир астында нефть ятканын хәтта динозаврлар заманында туган әби дә белә! «Нефть-нефть», дип сөйлиләр телевизордан да. Без нефтьтән бензин ясаганнарын беләбез.

– Хәзер бөтен нәрсә нефтедән. Ипине дә химиядән ясый башларлар әле. Минем янда яшәгәндә, рәтле ризык ашыйсыз, – ди әби.

Безнең җир астындагы ул нефтьне күрәсе килә. Күрәсе генә түгел, безнең аны табасы һәм акча эшлисе килә!

Әни киткәндә, Пикули: «Әни, китмә!» – дип елый.

Әни әйтә:

– Ә акча каян килә? Мин бит җир астыннан нефть сатып баемыйм! Миңа җырламасам, акча килми!

Әни киткәч, без нефть табарга кирәк, дип сөйләшәбез.

## Без нефть эзли башлыйбыз

Безне нефть эзләргә этәргән ике вакыйга булды.

Берзаман әби «бабагызның елы» дип йөри башлады. Аш үткәрәбез, ди. Нинди аш һәм аны кая үткәрәләр?

Дуештан сораган идек, ул әйтә:

– Кешеләр җыелыша, дога укыйлар да ашыйлар, аннары сезгә вак акча бирәләр, – ди.

Ул дөрестән дә шулай булып чыкты.

Бабайның елын укытырга килгән кешеләрнең күбесе әби-апалар иде. Бер абзый гына бар, ул әбисен машинасына утыртып алып килде. Абзыйга һәм безгә кухняда ашарга бирделәр. Ул телевизорны кабызды, үзе ашый, үзе телевизор карый. Телевизорда нефть турында сөйлиләр.

– Әһ, шушы нефть каланчасының берсе генә миңа булса! – ди. Телевизорда кәкрәеп-бөкрәеп торган каланчалар күрсәтәләр.

– Кан суырып торган черки шикелле, – ди Пикули.

– Һәй, миңа димәгәе!

– Ә нәрсәгә кирәк ул?

– Һәй, улмы! Җирдән акча чыга бит! Каерып акча алыр идем, эшләмичә генә.

– Ул әйбер акча чыгарамыни?

– Әлбәттә! Нефтең саттың-җибәрдең! Күпме кеше череп баеды бит инде шуның белән. Вәт бакчаңда нефть чыкса!

– Ул бакчада да чыга аламыни?

– Нишләп чыкмасын? Бәхетең ташып торса... Кайда икәнен генә белеп булмый бит аның. Менә мин урынын таптым. Кайткач казыйм, – дип көлә.

Без әбинең «акчасы җитсә, әниегез гел сезнең белән булыр иде» дигәнен гел ишетәбез. Безнең башта күптән план бар – акча табарга да, әнине безнең янга кайтарырга. «Акча булса, бәлки әти дә кайтыр иде», – ди Пикули. Ничек акча табарга икәнен генә белмибез. Шуңа күрә, бакчада да нефть бар, дигәч, безнең колаклар тора. Абзыйдан нефть турында сорашабыз. Аның бүтән сөйлисе килми. Нәрсәдер мыгырданып кулын селти дә урамга чыгып китә.

Нефть ул кайдадыр якында гына. Аны казып табарга гына кирәк! Тапсак,

әни дә әллә кайларга җырларга чыгып китмәс иде, өйдә генә җырлап торыр иде!

– Нефтьнең картасын табарга кирәк, – ди Пикули.

– Теге абзыйда картасы булырга тиеш!

Абзый арт якка чыгып киткән. Без урамга чыгып, аның машинасын карыйбыз. Аның машинасы бик кыйбат. Ялтырап тора.

– Бу инде нефтьне тапкан булырга тиеш, – дибез.

Ул арт якта һава сулап йөри. Без, машинасын ачып, карта эзләмәкче булабыз. Машина бикле, ачып булмый.

Бераздан ул китеп бара. Без нефть турындагы уйлар белән калабыз.

## Карта

Карта бөтенләй көтмәгәндә табыла. Ул безгә үзе килеп керә. Аны безгә бер пират бүләк итә.

Без үзебез генә өйдә чакта кап-кара сакаллы, озын чәчле бер кеше ишегалдына килеп керде.

– Пират! Ран! – дип кычкыра Пикули һәм бакчага таба йөгерә.

– Тукта, атам! – ди сакалбай һәм «пух-пух» итеп авызы белән «ата». Без көлә башлыйбыз. Пикули да көлә.

– Су бирегез әле, балалар, – ди.

Без аңа чүмеч белән су алып чыгып бирәбез.

– Әти-әниегез кайда?

Безгә чит кешеләргә өйдә үзебез генә икәнне әйтү тыела.

– Әни дә, эти дә хәзер кайта, күршеләрдә генә.

– Миңа трос кирәк иде. Машина батты, – ди Сакалбай.

– Бездә трос бар, – ди Пикули.

Без өйдәге әйберләрне кешегә бирмәскә өйрәтелгән. Әмма бу абзыйны безнеңчә «атышлы» уйнагач, үз кеше дип кабул иттек. Безнең аны ничек булса да үзебезнең янда озаграк тотасы килә.

– Әтиегезне чакыра алмыйсызмы?

– Әти киткән иде шул...

– Трос кирәк иде бит... Күрсәтә алмыйсызмы?

Без аны лапаска чакырабыз. Ул лапаска килеп кергәч, сызгырып куя:

– Ай-яй. Әтиегез кайда, дисез?

Безнең лапаста нәрсә генә юк! Бөтен нәрсә дә бар, атлап йөрергә урын гына юк. Ул әйберләр арасыннан бик оста итеп кәҗәләр генә йөри ала. Кеше йөри алмый. Әтиләре шундый бардакта тота икән сарайларын, димәсен өчен әтине яклый башлыйбыз.

– Әти еракта ул. Әни күршеләрдә.

– Ә, ярар. Мине ачуланмас микән? Тросны гына күрсәтсәгез...

Пикули яшергән урынынннан авыл чүплегеннән табып алып кайткан нечкә трос күрсәтә. Сакалбай көлә:

– Әй, энем, мин бит чынлап сорыйм. Ярар, шундый яхшы трос табып биргәч, мин дә сиңа берәр затлы бүләк бирәм инде.

Ул кесәсеннән чыгарып, ручка суза. Ак ручкадагы язуны укыйбыз. Анда «Татнефть» дип язылган.

– Абый, син нефть табасыңмыни?

– Әйе.

– Кайда?
– Сездә түгел, моннан еракта...
– Ә син монда нигә килдең?
– Сездә дә нефть табарга.
– Бездә нефть бармыни? – Без икебез дә әсәрешәбез.
– Әйе. Өлгермәгән генә.
– Ничек өлгермәгән ул?
– Шулай инде. Менә өлгермәгән җиләк кебек.
– Өлгермәгән булгач, ничек өлгертәләр аны?
– Аның берние дә юк. Таба белән духовкага тыгып аласың да, өлгерә ул!
– ЙаблакаС, – ди Пикули. «Сакалбай» дигән сүзе. ЙаблакаС аны аңламады.
– Нәрсә дисең? Сүгенәсеңме әллә?
– Юк, сүгенмим мин, – ди Пикули.
– Безгә нефть кайда икәнен әйт әле! Безнең дә нефть казыйсы килә.
– А-а... Ә сез миңа нәрсә әйтәсез аннары?
– Мин сиңа зур үрмәкүч оясын күрсәтәм! – ди Пикули
– Үрмәкүч кирәкми аңа... Трос кемдә икәнен әйтәбез! Әйт инде! – ди Пипип.
– Әйтәм, нигә әйтмәскә. Өйләнгәндә, мине туйга чакырырсың, кәләшеңне биергә чакырырмын. Басуда минем машина батып калды, менә шул баткан машинадан төгәл өч йөз адым уңга атлап барсаң, нефть күмелгән урын була, – ди йаблакаС.
Ул китәргә дип капкага борыла. Аның аркасына «Татнефть» дип язылган.
– Пипип, кара, аның аркасына да «нефть» дип язылган, ул ялганламый! – дип кычкыра Пикули шунда.
– Юк, нигә алдалыйм ди мин? Чын, казысагыз шунда нефть чыга.
– Тирән казырга кирәкме? – дип сорыйбыз аннан.
– Менә минем кадәр казырга кирәк була инде. Мин үзем тагын да тирәнрәк казыйм.
– Ә нефть нинди була?
Ул кесәсеннән без моңарчы күрмәгән рәвешле, озынча шешә тартып чыгара.
– Менә ул нефть.
Нindидер сыек көрән, яшькелт төстәге сыекча. Без әсәрләнеп карыйбыз, суларга да куркып торабыз. ЙаблакаС шешәнең бөкесен ача. Бармагына тидереп күрсәтә. «Миңа да, миңа да!» Бармакларга тидерелгән майлы нефтьне иснәп карыйбыз. Тәмле.
– Ялый күрмәгез тагын. Кая, монда машиналы күршеләрегез бармы?
Без замлАларга төртеп күрсәтәбез.
– Аның әтисе машинада йөри. Ә, Йабла... абый, ә машинаң кайда батты?
– Әнә теге якта инде, – ЙаблакаС ашыгып раниД абыйга таба китә.
– Аның аркасына да нефть дип язылган иде! – ди Пикули, шатланып сикеренә, бармагындагы нефтьне исни. – Беләсеңме?! Нефть дип язылган! Ул безгә нефтьнең кайда күмелгәнен әйтте! Без аны хәзер казый алабыз!
– Ә аның машинасы кайда батканын без белмибез!
– Аннан картаны алырга кирәк иде! Тылсымлы карта!
Без өйгә кереп, дәфтәр алып чыгабыз. Әмма соңга калдык, раниД абый, машинасына утыртып, йаблакаС белән китеп бара инде. Без артларыннан карап калабыз.
Пикули йодрыгы белән башына суга.
– Нишләп уйламадың син, аңгыра баш! Уйламагансың! Хәзер без картасыз калдык.

– Пикули, башыңа сукма. Хәзер без аларны көтәбез. Алар, бәлки, кайтыр.

ЙаблакаС кайтмый. Бераздан раниД абый үзе генә кайтып керә.

Без аның янына йөгерәбез.

– Динар абый! Ул машина кайда баткан иде?

РаниД абый безгә сәерсенеп карый.

– Имәнлек янында, инеш аркылы чыкканда... Берәр нәрсәгезне алып киткән идеме әллә?

– Юк... Әйе...

– Нәрсә ул? Барырга кирәкме анда? Нәрсәгезне алган? Китте инде ул...

– Алмаган... Безгә аның кайда батканы кирәк иде.

– Ә-ә. Кызык күрәсегез киләмени? Әйе, шәп баткан иде ул. Яңгырдан соң инеш тулган анда, шунда шәп итеп утырган иде ул. Чыгардым инде, китте.

– Динар абый, ул нефть казыганмыни?

– Казымаган әле, тикшереп йөри.

– Ә ничек белә ул нефтьнең кайда икәнен?

РаниД абый көлеп җибәрә.

– Иснәптер... Сезгә җавап табып бетерә торган түгел.

– Динар абый! Шул баткан машинаның рәсемен ясa әле безгә! Кырыендагы агачлары белән!

– Ай, балалар... Әтиегез... Кая китер, ясыйм!

РаниД абый иренеп кенә ясамакчы. «Монысы нәрсә», «монда агачмы, ташмы» дип сорап, картаны аңлашылырлык итеп ясатабыз.

Ул кичтә Пикули шатлыгыннан ишегалдында капкалы-түрле йөгереп йөри. «Ура» кычкырып, тамаклары карлыгып бетә. Карта табу шатлыгыннан йоклый да алмыйбыз. Пикули ишегалдында юынгыч янында йоклап китә. Әби күтәреп алып кереп сала.

## Сугышу

Без менә шулай карталы булдык.

Аннары нефть табарга әзерләндек.

Хәзер безнең бөтен нәрсәбез дә бар. Хәзер нефть казырга барабыз.

Машина баткан урынның кайда икәнен якынча гына беләбез. Безне былтыр замлАның әтисе шул урынга каен суына алып барды. Лапас түбәсенә менеп, барасы юлыбызны карыйбыз. Өебез янында юл, юлдан соң кукуруз басуы башлана. Теге ягында каен полосасы, полоса уртасында Агу өе күренә. Без аның нәрсә икәнен белмибез, әби шулай дип йөртә. Без Агу өе тирәсенә барып чыгарга тиеш. Ә нефть урыны шуннан ерак түгел.

Иптәшкә замлАны да алабыз. Беренчедән, ул – безнең дус. Икенчедән, картаны аның әтисе ясады. Өченчедән, аның әтисе безнең әти белән дус булган, ди. Дүртенчедән, җир казышырга.

Өйдән чыгып китүе җиңел түгел. Без балыкка барабыз, дибез. Әбинең балыкка җибәрәсе килми, суга төшеп, батып үләрсез, дип курка. Безгә гаҗәп – анда батып үләрлек су юк кебек. Сазлыкка төшеп китсәң генә инде. Шуны озаклап аңлатабыз. Әби фәлән-фәлән эшләрне эшләсәгез, барырсыз, ди. Без фәлән-фәлән эшләрне эшлибез.

Көрәк сапларын киeм эченә, көрәкләрне капчык астына яшереп, чиләк эченә чүкеч-кадакларны салып, нефть казырга китәбез.

– Беренче барганда гына авыр булыр ул. Аннары көрәкләрне калдырып кайтырбыз, шунда яшереп, – ди замлА.

– Чынлап дөрес әйтәсең син, – ди Пикули.

– Дөрес әйтәм шул. Беләсеңме, мин ник дөрес әйтәм? Чөнки минем әти машина йөртә.

– Безнең әти дә машина йөртер иде, аның бит җырлыйсы бар...

– Машина йөртү әйбәтрәк инде, җырлауга караганда.

«Кемнең әтисе әйбәтрәк» дигән темага бәхәс башланса, Пикули белән замлАны дуслаштыруы кыен була. Елашу белән тәмамлана. Бу юлы да шулай буласы иде, каршыга Исай чыга.

Исай ул – Илшат.

Нигә Исаймы? Чөнки ул исәр малай. Ул «Ну, погоди» фильмындагы бүре кебек. Үзенең кулыннан бөтен эш килә. Әллә ниләр ясый белә, теләсә нәрсәне – велосипедмы ул, өч көпчәкле сәпитме – ремонтлый. Теләсә нинди текә ярга менә. Инеш суына кереп, ялан кулы белән су күсесенә кадәр тота ала. Бер ел элек алар Түлик малае белән кем текә ярдан сәпит белән төшә ала, дип бәхәсләштеләр. Исайның текә ярдан сәпит белән төшкәнен карарга ярты авыл баласы җыелган иде. Төште! Егылмады да. Түлик малае җиңелгәч, бәхәстә килешкән буенча бейсболкасын да бирде, аннары Исай аның маңгаена ун тапкыр чиертте. Без Түлик малаен кызгандык.

Түлик малае, дип йөрибез без аны. Ул – мари малае. Әтисе Анатолий. Үзе Александр.

Исай бик җәберлекле малай. Әллә ниләр эшли белә, гел зыян сала. Рогатка ясап, һавада очып барган чыпчыкларны атып төшерә. Әллә нинди яңа уеннар уйнатам, дип, малайларны котыртып елата. Малайларга шырпы тотарга куша да «кайсысының сынганын күрсәтәм» дип, шырпыны сызып җибәреп, бармакларны пешерә. Аннары үзе шаркылдап көлә. Шуңа без аны яратмыйбыз. Сәпит ремонтлатасы булса гына барабыз. Ул аны ремонтлап бирә, әмма берәр «бик кызык» уенын уйнатып, елатып җибәрә.

Без нефть казырга Исайны да алмакчы идек. Ул булса, без тизрәк казый алачакбыз. Әмма бәйләнер, дип куркып, серне аңа әйтмәдек.

Менә хәзер каршыга чыккач та, без куркып калабыз.

– Исәнмесез, балалар! – Без авылда һәркем белән шулай күрешәбез. Исайга да шулай диябез. Ул исәнләшми. Шунда ук бәйләнә башлый.

– Кая барасыз балыкка?

– Инешкә, – дибез.

– Ә мин үләксә базына күсе тотарга барасыз, дип торам, ха-ха.

– Бик кызык.

– Нәрсә?!

– Кызык түгел.

– Нәрсә тыктыгыз капчык эченә? Күрсәтегез әле?

ЗамлА куркудан артка чигенә башлый, күзләре яшьләнә. Ул шундый елаграк малай инде. Исай капчыкларны да тотмакчы була, без артка китеп калабыз.

– Кием астына нинди таяк тыктыгыз?

Бу Исайның бер күрмәгәне юк. Кием астындагы көрәк сабын да күреп алган. Моннан хәзер котылмасак, җанны алачак!

– Берни юк күлмәк астында, – ди Пикули.

– Ха-ха. Абзаңа әкият сөйләмә, әкиятне әбиеңә сөйлә. Әнә ыштан балагыннан күренеп тора.

Көрәк сабын кием астына әйбәтләп яшергән кебек идек. Атлап бара торгач, аның бер кырые чыккан, күренеп тора икән.

– Безне әби җибәрде. Инештә чишмә дә ясап кайтабыз, – дибез.

– Ха-ха. Инештә чишмә ясарга әбиең кушкан булса, нигә яшердегез соң? Яшермәс идегез. Кая барасыз, дөресен әйтегез?!

– Күрсәт әле капчыгыңны! – Исай ялт кына капчыкның бер читеннән эләктерә, без аны-моны абайлаганчы, тартып та ала. Җиргә тимер көрәкләр шалтырап төшә.

Без җиргә ташланып, көрәкләрне алабыз. Хәзер ялганлап маташу файдасыз. Исай безнең ниндидер бөек сер белән йөргәнне аңлый. Хәзер аның максаты – шуны белү.

– Әһә! Көрәк чәлдереп чыктыгызмы? Динарга әйтеп, иманыңны өшкертәм!

ЗамлА атаңа әйтәм, дигәннән куркып, чырылдап елап өенә таба йөгерә. Ул куркак малай шул. Без андый түгел. Аннары без аның кебек гел «әтигә әйтәм», дия алмыйбыз. Хәзер җиңелсәк, бетәбез. Без хәйләгә күчәбез.

– Илшат, безнең сер бар. Син аны белә алырсыңмы икән, дип уйлаган идек. Белә алсаң, сиңа ун сум.

Ун сум һәм сер дигәч, моның колаклары тора. Шулай да ышанмый.

– Каян килсен сиңа ун сум?

– Әби бирде.

– Бирер әбиең! Сезнең әбиегездән кышын кар да алып булмый.

Исайдан котылыр чара юк. Ни дип әйтергә дә белмибез. Шунда Пикули бер ялгыш җибәрә.

– Әти бирде!

Исай кычкырып көлеп җибәрә.

– Сезнең әтиегез юк! Әниегез җырлап йөргәч, ул аны ташлап чыгып киткән.

Бу сүздән соң безнең башка чара калмый. Сугышырга кирәк. Пикули белән безнең күптән килешеп куйган бар. Беребез чәнчә бармакны тырпайтып күрсәтсә, икенчебез дошманның артына чыгып, аяк астына ятарга тиеш. Беребез кесәдә казына башлый, Исай шунда текәлә, Пикулида эше юк. Ә ул кисәк кенә Исайның аяк артына сузылып ята. Аны-моны көтмәгәндә, Пипип Исайны төртеп җибәрә. Ул Пикулига сөртенеп, артка ава. Ул оешканчы без, капчыкларны күтәреп, басуга таба чабабыз. Исай торып арттан йөгерә, үзе акыра:

– Җаныгызны алам!

Исай бездән зуррак булса да, сугышу осталыгы юк. Ул куып тотам гына дигәндә, җиргә чүгәлибез. Ул тагын бер тапкыр шул ук капкынга эләгә – сөртенеп егыла. Исай торганчы, без кукуруз басуы эченә йөгерәбез. Биек кукурузларның яфраклары биткә бәрелә. Без кулга-кул тотышып чабабыз да җиргә тезләнәбез.

Пикули бераз шыңшый. Җиргә таянганда, пыялага эләккән булган, ахыры – кулы бераз канаган. Аңа төкерек сөртә. Исай пычранган киеменнән тузаннарны кага. Без кукуруз арасыннан аны карап торабыз. Исай тагын да катырак котырып, басу эченә кереп китә:

– Үтерәм икегезне дә!

Кулында көрәк сабы, болгап бара. Көрәк сабы тигән урында кукурузлар өзелеп оча. Әле ул җирдән иелеп кәзләр ала, шуларны кукуруз эченә ата.

ЗамлАның эзе дә юк. Өенә качкан бугай.

Без җиргә посабыз. Акырган тавышына караганда, Исай туп-туры безнең өскә килә. Пикули кулны нык итеп кыса.

– Беттек! – ди.

– Тавышланма, алайса ишетә, – ди Пипип.

– Өскә килеп чыкса, нишлибез? – ди Пикули.

– Икебез ике якка качабыз. Кемнең артыннан йөгерә, шул кача, икенчебез артыннан куып, өстенә сикерә. Аннары икебез дә аңа ябышып, кыйныйбыз.

Шулай дип әйтеп кенә бетерүгә, Исай өскә килеп чыга:

– Менә кайда ятасыз икән, сасы көзәннәр! Эләктегезме?

Пикули, чыр итеп кычкырып йөгерә, Исай куян артыннан чапкан бүре кебек аның артыннан ташлана. Пипип тиз генә кукуруз сабагы сындырып ала, шуны кулына сөңге кебек итеп тотып Исай артыннан йөгерә. Исай Пикулины тотып ала, шул вакытта Пипип аның аркасына кукуруз белән кадый. Нәкъ индеецлар турындагы фильмнардагы кебек!

Кукуруз белән суккан булсак, авыртмас иде. Ә кадагач, бик авырттыра, Исай яраланган аждаһа кебек кычкыра. Пикулины җибәрә. Пикули кача. Пипип тә икенче якка йөгерә.

Әмма яраланган аждаһа да үз аңына кайта.

– Әй, малай актыклары! Нәрсә сугышып йөрисез анда?

Беттек дигәндә генә, безне рунмиР коткара. Исайның әтисе.

– Чүпне кем утап бетерә? Нәрсә дидем мин сиңа? Хәзер колагыңнан өстерәп алып киләм, малай актыгы!

Атасы кычкыргач, Исай Пикулины оныта. РунмиР аны каеш белән яра, дип сөйлиләр. Курка. Без дә кыюланабыз. Тураеп басып, аның басудан чыкканын карап торабыз. Исай инде безне куа алмый. Курыкмыйбыз.

– Мин сезне эләктерәм әле, денегезне алам, – дип яный-яный, Исай әтисенә таба китеп бара.

Без кукуруз арасына ыргытылган көрәкләрне эзлибез. Чиләк – бер, капчык икенче урында. Көрәкләр дә кукуруз арасында ята. Табып бетергәндә, замлА килә.

– Мин тыкрык янына качып карап тордым, – ди.

– Куркак икәнсең, – ди Пикули.

– Куркак түгел мин, яме! Куркак булсам, кайтып китәр идем. Минем киемнәр яңа иде, шуңа күрә сугышмадым мин аның белән. Алайса киемнәр буяла. Ә сезгә нәрсә, киемнәрегез иске. Ә сугышсам, берүзем җиңәм мин Исайны.

– Әйе, җиңәсең! – дибез без аңа.

Көрәкләрне, көрәк сапларын, чиләкләрне инде яшереп торасы юк. Без шат. Безнең бөек серне дошманнар да чишә алмады. Без җиңдек. Үзебезнең әйберләрне кулга тотып, кукуруз арасыннан полосага таба китәбез.

## Кукуруз басуы

Кукуруз басуыннан йөрүе җайлы. Ул рәт-рәт итеп чәчелгән, арасыннан атлап барып була. Кукуруз бездән биек. Биткә яфраклары бәрелә. Яфрак асты йомшак, өске ягы кытыршы. Очында себерке кебек чугы бар.

Исай белән сугышуыбыз турында сөйләшеп барабыз. Аның ничек итеп җиңелгәнен кат-кат искә төшереп көләбез. Рәхәт. Без якын-тирәдәге малайларны куркытып торган Исайны да җиңә алдык.

Кукуруз арасыннан бераз барганнан соң, авыл күренми башлый. Кая барганыбыз да, кая барачагыбыз да күренми. Яфраклар гына.

– Без адаштык бугай, – ди замлА.

– Юк, без адашмадык, – дибез.

– Мин куркам, – ди замлА.

– Юк, син курыкмыйсың, – дибез.

ЗамлА курыкмасын өчен тагын төрле кызык әйберләр сөйләшеп бара башлыйбыз. Исайның аркасына кукуруз сөңгесе кадау замлА белән Пикулига аеруча кызык тоела. Аны кат-кат искә төшерәбез. ЗамлАның сугышканда куркып качканын телгә алмыйбыз.

Көрәкләр авыр. Кулны баса. Без арып туктыйбыз. Туктагач, замлА тагын куркынып сөйләшә башлый.

– Без адашмадыкмы икән?

– Юк, без адашмадык. Кукуруз туп-туры чәчелгән. Без шул эздән барабыз.

– Ә монда бүреләр бар микән?

– Бүре кукуруз ашамый. Ул сарык ашый, – ди Пикули.

– Ә кукуруз ашыйсы килсә?

– Кукуруз ашыйсы килсә, ул аны кибеттән сатып алып ашый, – ди Пипип.

Без көләбез. ЗамлА да көлә.

ЗамлА машина йөртүче этисе белән мактанып үлә инде. Чөнки безнең машинабыз юк. Шуңа күрә аннан этисенең машинасы турында сөйләтәбез. Шуны сөйләгәндә, ул дөньясын оныта. Ә без аны бик үк тыңлап та тормыйбыз. Чөнки гел бер әйберне тыңлау безгә кызык түгел.

Тагын торып китәбез. Без инде арып беттек. Кукуруз арасыннан барсак та, кояш җилкәләрне кыздыра. Кукуруз арасында ниндидер чүп үләне үсә, ул тигәнәк кебек киемгә ябыша. Шуны киемгә ябыштырып, уйнап барабыз. Арыйбыз. Тагын туктыйбыз.

– Коймакны ашыйбызмы әллә? – ди замлА.

Безнең ашарга алган коймакны әйтә. Пикули да кызыгып, ашарга салган чиләккә карый.

– Без бит әле казый да башламадык.

ЗамлА борынын төшереп, атлап китә. Алар Пикули белән дөньяда иң тәмле әйбер нәрсә, дигән темага сөйләшәләр.

– Пилау, – ди Пикули. Ул пылауны гел шулай әйтә.

– Юк, гөбәдия, – ди замлА.

– Гөбәдия ашаганда коела ул, – ди Пипип. – Иң тәмлесе – бәрәңге боламыгы.

Бара торгач, иң тәмле әйберләрнең бик күп булуы ачыклана.

– Без адашмадыкмы? – ди замлА.

– Юлны сорарга кирәк, – ди Пикули.

– Кемнән? Тургайлардан сорасак кына...

– Тургайлар, без дөрес барабызмы? – дип кычкыра Пикули. Без көләбез.

Барып җитеп булмый.

– Монда бүреләр бар микән? – ди Пикули.

– Монда аюлар да бар! – ди Пипип.

ЗамлА курка.

– Чынлапмы? Алар безгә тимиме?

– Бүре кукуруз ашамый ул.

– Ә аю?

– Аю да ашамый.

– Аю нәрсә ашый?

– Җиләк.

– Ә-ә. Аннары бал ялый, име?

– Әйе.

Без бал кортларын кызганабыз. Аю аларның балларын ялый. Ә бал кортларына нәрсә кала? Аю үзе бал җыйса да, була бит инде. Аю җиләк ашый, ди, ә ничек җыя икән ул аны? Беркем дә белми.

Пиратлар корабларда йөзеп йөргәндә, җир күргәч, «Җир!» дип кычкырганнар, ди. Пипип шул турыда сөйли. Телевизордан караган. Җирне беренче күргән пиратка бүләк биргәннәр икән. Кукуруз басуын чыгып, беренче булып җирне күргән кешегә нәрсә бирәбез, дип сөйләшәбез.

– Мин ул кешегә акча бирер идем, – ди замлА.

Безнең акча юк. Әби безгә акча бирми.

– Юк, ул кеше маладис була, – дибез.

ЗамлА бәхәсләшә. Аның маладис кына булып каласы килми.

– Әйдә ул кешегә берәр тәмле әйбер бирәбез, – ди.

– Ярар, – дибез.

– Мин малаең җирне күрде, дип әнисенә әйтер идем, – ди Пикули.

– Нигә?

– Әнисе мактасын өчен.

– Юк инде, акча әйбәтрәк, – ди замлА.

Ул әнисе белән яши. Аны әнисе гел мактап тора. Шуңа күрә ул безне аңламый. Шулай да һәркемнең җирне беренче булып күрәсе килә. Кукуруз арасыннан бик тырышып алга карап барабыз. Кукуруз яфраклары гына күренә.

– Әнә, әнә!!!

Пикули әче тавыш белән кычкыра. Без аңа карыйбыз. Ул кулын югарыга сузган. Алга таба күккә күрсәтеп тора.

– Нәрсә ул?

– Агач! Мин агач күрдем!

Без алга карап барганбыз. Пикули өскә караган да полоса каеннарының очын күргән икән. Без басуны узып бетергәнбез.

– Ура!!!

Без кукуруз арасыннан алга йөгерәбез. Басу беткән урында кеше биеклеге алабута үсә. Шулар аякларга чуала, битләргә бәрелә. Җир! Йөгерешеп чыгабыз. Басу бетте. Безнең каршыда – полоса! Ә полосада – нефть! Без җиңдек!

## Нефть урыны

Полосага йөгерешеп чыгып, җиргә авабыз. «Җир! Җир! Җир!» дип акырышып, көлешеп җирдә аунашабыз. Безгә рәхәт. Без, ниһаять, басуны чыктык. Нефть булган якларга барып җиттек. Нефть шушында, кул сузымында гына булыр кебек. Җирне беренче күргән Пикулига маладис, дибез. Ул шатлана.

Полосада җиләк бар икән. Без җиләк ашый башлыйбыз. Җиләк дигәч, замлА ник килгәнен дә оныта.

– Әйдә, нефть эзлисе бар, – дибез.

Аның барасы килми, әмма безгә иярә.

Полоса читендә Агу өе булырга тиеш. Басуга берни чәчелмәгән вакытта Агу өе безнең өйдән күренеп тора. Басуда нәрсәдер үссә, лапас башына менгәч кенә күренә. Әби әйтә, аның янына барырга ярамый, ди. Безгә шул Агу өен табарга кирәк. Шуңа күрә полоса буйлап китәбез. Көрәкләр тагын да авырая. ЗамлА җиләк ашамакчы була. Монда Агу өе бар, мондагы җиләкләрне ашарга ярамый, дибез. «Агуланып үләсең», дигәч, ул ашамый.

Кызыл җиләкләрне күзләре белән ашап бара. Алай димәсәң, ул дөньясын онытып җиләк ашый башлый.

Без дөрес барганбыз икән. Бераздан Агу өе күренә башлады. Агач өй. Тәрәзәләре юк. Без өй янына киләбез. Күзләрне әчеттерә торган ис килә. Язын чәчү вакытында тракторлар зур кисмәкләрдә аммиак ташый. Бу өйдән дә шуның исе килә.

Өйне әйләнеп чыгабыз. Бер ишеге бар, анда зур йозак.

– Монда кем яши икән? Агу шушында яши микән? Агу чыкмасын өчен аны бикләп куйганнар микәнни?

Безгә куркыныч булып китә.

– Әйдә, моннан китәбез, – дибез.

Агу өеннән имәнлеккә таба китәбез. Каен полосасы бетеп, имән полосасы башланган урында ачыклык, шуның аркылы юл уза. Шул юл борылып, инеш аша уза һәм басуга таба кереп китә. Инеш читендә таллык.

– Әнә, әнә!!! – дип яраткан сүзен кычкыра Пикули, инешкә таба төртеп күрсәтеп.

Нефть шул таллык янында булырга тиеш. Без шунда йөгерәбез. Килеп җитәбез – инеш аша чыккан юлда баткан машина эзләре. Көннәр коры торгач, зур-зур чокырлар кибә башлаган, кайбер чокырларда су җыелып калган әле. ЗамлА этисенең машина тәгәрмәче эзен таный:

– Менә бу минем этинең машинасы эзләре булырга тиеш. Эти менә моннан өстерәткән. Монда теге кешенең машина эзләре, – ди ул.

ЙаблакаС нефтьне шушы тирәдән эзләгән булырга тиеш. Без инеш буендагы болынны, шул болын янындагы басуны тикшерә башлыйбыз. Нефть хуҗасының нефтьне кайдан эзләгәнен карыйбыз. Машина баткан урынга арт белән басып, өч йөз адым атлыйбыз. Берни дә юк... Тагын карап йөрибез. Бераз баргач, тигез болын уртасында чирәм актарылган урынга килеп чыгабыз. Шул тирәдәге басуны да кемдер казып киткән. Арпалар тамырлары белән өскә карап ята.

– Нефть! Нефть таптык!

– Менә! Шунда!

Без шатланабыз. Картадан тагын бер тапкыр карыйбыз. Чокырдан машина баткан урынга атлап китәбез. Дүрт йөз илле адым килеп чыга. Дөрес кебек...

– Шунда бит инде, шунда! – дип тарткалаша Пикули белән замлА.

– Карыйм әле, – дип тарта кәгазьне Пипип.

Тарткалаша торгач, кәгазь ертыла. Кәгазьне ерткан өчен аларга эләгә. Үпкәләшәләр. Юк, дус булыйк, алайса казып булмый, дип дуслашабыз. Башка бәхәсләшмәскә сүз куешабыз.

– Ә-ә. ЙаблакаСның адымнары зур, безнеке кечкенә! Шуңа күрә шулай чыгадыр!

Болындагы казылган сәер чокырлар бишәү. Аларның һәрберсе бертөрле кебек. Без комда кул белән чокыр казыйбыз бит, шуның кебек алар. Ниндидер зур тимер белән ерткалап киткән кебек. Без җирне ятып иснәп тә карыйбыз. Аннан җир исе генә килә. Ә замлА ниндидер йон кисәкләре таба.

– ЙаблакаС монда сакалын өзеп калдырган бугай, – ди Пикули.

– Монда микән ул нефть? – ди замлА.

– Нефть булмаса, басуны казымаслар иде, – ди Пипип.

Болында ермачлап кителгән чокырда без бер ят тимер кисәге табабыз. Ялтырап торган тимер. Аны йаблакаС калдырып киткән булырга тиеш.

«Ватра! Ватра!» – дип кычкыра замлА.

Чокырларның берсе янында ул тәмәке төпчеге тапкан.

– Теге Сакалбайның да тәмәкесе шундый иде, – ди ул.

– Каян беләсең?

– Ничек белмәскә? Әти белән сөйләшкәндә карап тордым!

Без аңлыйбыз – йаблакаС шушында булган. Димәк, монда нефть бар.

– Басуда казырга ярамас, безне күрерләр. Болында казыйк, – дибез.

Без шул урынны таяк белән шакмаклап сызып алып, казырга әзерләнәбез.

## Нефть казыйбыз

Нефтьне казыр өчен башта көрәкләрне әзерлибез. Көрәк сабына тимер көрәкләрне тыгып куеп, кадакларын кагабыз. Көрәк сабы шома, кадак керми. Яңа кадаклар булса кирәк иде, алар иске такталардан суырып чыгарып, турайтылган кадаклар. Әби һәр нәрсәне экономияләргә куша. Кадак какканда, һәрберебез чүкеч белән бармакка сугып чыгабыз. Бармаклар канап бетә. Кадак керми.

– Беребез тотып торырга тиеш, икенчебез сугарга, – дибез.

Сугарга теләүчеләр бар. Беркемнең дә кадакны тотып торасы килми.

Аптырагач, көрәкнең тимере белән генә казып карыйбыз. Алай авыр. Бөтен тырышлыкны җыеп, тимер көрәкне кадаклыйбыз.

Шул эшне башкарып бетергәч, ашарга утырабыз. Өйдән алып килгән коймак бик тәмле.

Безнең урамда кое казыганны күргән бар. Шакмаклап казып төшәсе аны. Аннары, тирәнәйгәч, берәү улак кебек көрәк белән балчыкны өскә ата. Без дә шулай кирәктер, дибез. Чокыр кырыен сызып чыккач, балчыкны казый башлыйбыз.

Чирәм үскән урынны казуы читен. Бер кат балчыкны алып бетергәнче, хәлдән таябыз. Сузылышып ятабыз. Күктә тургайлар сайрый. Алар бик биектә. Күзгә күренмәслек биеклектә сайрыйлар да җиргә атылышып төшәләр. Яңадан менеп китәләр.

– Болар нәрсә ашый икән, күктән төшмиләр дә, – ди Пикули.

Ашау искә төшә. Утырабыз. Ашыйбыз.

– Нефть чыккач, аны кая куябыз? – ди замлА.

– Без әнигә бирәбез. Аннары ул концертларга йөрми, акчасы күп була да, безнең белән генә тора. Ә син?

– Ә мин машина сатып алам, – дип замлА. – Әти машинасын гел ремонтлый. Яңасын ремонтлыйсы булмас иде, ди. Менә аңа машина алам. Үземә дә алам. Сезне утыртып йөрим.

– Нефть чыкмады микән әле ул?

Казыган җирне карыйбыз. Җирнең өсте генә алынган, бик озак казыйсы әле. Без җир астыннан чыккан балчыкны иснәп тә карыйбыз. ЙаблакаС савытыннан килгән кебек нефть исе юк.

– Нефть исе киләме?

– Юк, килми.

Тагын бер кат казыйбыз да ашыйбыз, дип килешәбез.

Казыганнан соң ашагач, ипи бик тәмле була.

– Әби югалткандыр, кайтырга кирәк, – ди Пикули.

– Ә кайчан казып бетерәбез?

Без казыган урынны үлчибез. Көн саен шулкадәр эшләсәк, ике ай казырга тиеш булабыз.

Әмма без ул кадәр вакыт казый алмыйбыз. Аннан соң көз башлана.

– Башка вакытта күбрәк казырга кирәк, – дибез.

Көрәкләрне, чиләкне таллыкка яшерәбез. Кармакларны җыеп, кайтырга әзерләнәбез.

– Ә без адашмыйбызмы? – ди замлА.

– Юк, адашмыйбыз, килгән юлдан кайтабыз, – дибез.

Баруга караганда, кайту күпкә кыенрак. Басудан полосага чыккан урынны бик озак эзләгәч кенә табабыз. Кукуруз арасыннан кайтып җиткәндә, тәмам хәлдән тайган булабыз.

Инде авылга кайтып җиткәч, кабат басуга кереп, кәҗәләргә үлән җыябыз –  кукуруз арасында йомшак үлән үсә.

## Әби

Без болай да көн буе урамда. Кояшта янып беткәнбез. Бу юлы безнең йөзләребез кып-кызыл булып янган. Шул ук кояш кебек, әмма басудагысы күбрәк яндыра икән.

– Балыгыгыз кайда? – ди әби.

Без инде алдан килешеп куйган сүзләрне әйтәбез.

– Вак балыклар гына эләкте. Без аларны кире суга җибәрдек.

– Йөрисез инде шунда, вакыт әрәм итеп. Бик озак йөрдегез, бүтән барып йөрисе булмагыз.

– Без кәҗәләргә печән алып кайттык, – дибез.

– Кәҗәгә печән алып кайтыгыз, балыкка бармыйсыз, – ди әби.

Әби җәй уртасында да җылы куртка киеп йөри. Аягында йон оек. Безгә киенмәсәк тә, эссе. Ул ничек чыдый торгандыр? Үзеннән сорасак, ул көн эссе түгел, дип әйтә.

Әбинең йөзендә тирән-тирән җыерчыклар. Чәче ап-ак. Ул җыерчыклар сезнең аркада барлыкка килде, чәчемне сез агарттыгыз, ди.

Әбинең бик күңелсез дуслары бар. Алар аңа киләләр дә гел бер сүзне сөйләшәләр. Кемнең кайсы җире авырта, кемнең килене яки кызы нәрсә эшләгән. Бик сирәк кенә алар үзләре белән булган кызыклы хәлләр турында сөйләшә. Без аптырыйбыз: алар әллә никадәр кызыклы вакыйгаларны беләләр, нигә шуларны сөйләмиләр икән?

Әби безне нефть казырга җибәрми. ЗамлАның әнисе дә, әтисе дә эштә, әмма ул үзе генә барырга курка.

Без план корабыз. Балыкка җибәрмиләр икән, үлән җыярга барабыз. Әбинең ике кәҗәсе бар. Без әби белән бергә аларны су буена арканлыйбыз. Кәҗәләр өйдә торса, аларга чирәм кирәк.

– Әби, Акбикә бүген авырып тора сыман, – дибез.

Әби борчыла:

– Ни булды икән, кичә генә әйбәт иде, – ди.

Әби кәҗәне чыгып карый. Бернинди авыруын да тапмый. Әмма безнең сүзгә ышанып, болынга чыгармый.

– Печән алып кайтырсыз, – ди әби.

Безгә шул гына кирәк.

– Алып кайтырбыз!

Безгә кармаклар аласы юк. Капчыкны тотабыз да замлАга йөгерәбез. Бергәләшеп тагын кукуруз арасына шылабыз.

Кукуруз арасында йомшак чирәм бик күп. Өчәү җыйгач, капчык тиз тула. Капчыкны тутырабыз да нефть казырга йөгерәбез.

Нефть урынына килеп җитүгә, җирне иснибез. Бернинди ис тә килми. Көрәкләрне алып, җирне казый башлыйбыз. Бер рәт казыгач, авылга ашыгабыз. Чөнки без печән җыярга гына киттек. Вакытыбыз күп түгел. Кайткач, кәҗәне ашатабыз.

Әби икенче көнне кәҗәләрне болынга арканлый. Без нефть казырга бара алмыйбыз. Әби гел эш кушып тора. Өйдән чыгып китеп булмый.

Без замлАны нефть казырга үзең генә бар, дип үгетлибез. Ул курка, бармый.

– Мин анда ничек барыйм, анда бит төлкеләр бар.

– Анда төлкеләр юк, – дибез.

Ул ышанмый.

Яңгыр ява.

Пикули кайгыга бата.

– Без казыган чокырны су баскандыр, – ди.

Көннәр кайгырып үтә.

## Әби китә

Беркөнне кәҗәләргә су эчереп керсәк, әби китәргә җыенып йөри.

– Кая барасың, – дибез.

Әбинең башка авылдагы апасы авырып киткән. Ул шуны карарга бара икән.

– Мин сезгә өч көнлек ашарга пешереп китәм. Сез үзегез генә торасыз. Кәҗәләр, тавыклар сезнең өстә. Чүп утыйсыз. Эшлисе эшләрне язып калдырам. Өч көннән мин кайтам. Барысы да тәртиптә булсын, – ди.

Пикули кулны кыса:

– Йес, – ди.

Без нефть казырга бара алабыз.

Әби китә. Ул киткән көнне без беркая да бармыйбыз, ЗамлАны да алып кереп, караңгы төшкәнче чүп утыйбыз.

– Авыр эшне алдан эшләп куярга кирәк, – ди Пикули.

Караңгы төшкәч, без чүпне фонарь яндырып утыйбыз.

Икенче көнне иртән иртүк шалтырарлык итеп, будильникны куябыз. Салкын чәй эчәбез. Әби кичә пешереп калдырган бәрәңге белән итне пакетка салып алабыз. ЯирәС кәҗәләрне савуга, аларны болынга илтеп, бәйләп куябыз. Үзебез нефть казырга китәбез. Кукуруз арасына кереп югалганчы, Пикули замлА ягына таба борылып, кулын болгый:

– ЗамлА, ачуланма, без сине алмадык.

Үләннәргә салкын чык төшкән. Без барып җиткәнче юешләнеп бетәбез.

Шул рәвешчә инде өч көн буе нефть казыйбыз. Ул зур чокырга әйләнә. Чокырга төшсә, Пикули күренми дә. Шулай казый торгач, чокырдан аткан балчык кире коела башлый. Теге йаблакаС машинасы баткан урыннан берән-сәрән машиналар уза.

– Ул машинадагы кешеләр безне күрә микән? – ди Пикули.

Без шул урынга барып карыйбыз. Чокырдан кызыл балчык чыга башлаган, безнең нефть урыны юлдан күренә.

Безнең тагын бер эш барлыкка килә. Казылган балчыкны чиләк белән тал төбенә ташыйбыз.

Әби өч көннән соң да кайтмый. ЯирәС керә.

– Әбиегезнең апасы авыр хәлдә. Әбиегез миңа ашарга пешерергә кушты.

Күрше апасы көнгә бер тапкыр безгә ашарга пешерә. Без үзебез генә яшибез, әбиебез дә юк.

– Без хәзер үзебез генә, – ди Пикули.

– Әниләрегезне телевизордан күрсәттеләр, – ди яирәС. – Ниндидер бер шәһәрдә иде, анысын ишетми калдым. Аны бик мактадылар. Ул әле бик күп шәһәрләргә барабыз, диде.

Без шатланабыз. Ничек-ничек булганын Пикули яирәСтән кат-кат сөйләтә. Без шатлыктан ул көнне үзара сөйләшкәндә дә, яирәСне Сәрия апа дип әйтергә сүз куешабыз. Ул әнине күргән!

Безнең нефть казырга вакыт күп. Тавыклар белән кәҗәләрне карыйбыз. Көнгә бер тапкыр яирәС ашарга алып керә.

– Юынырга килегез, бүген мунча яктым, – ди.

Без аларның мунчасына керәбез. Сезне кем юындыра иде, дип сорый яирәС. Үзебез юына идек, дибез. ЯирәС ышанмыйча гына карап, мунчадагы чиләкләрдә су тигезли.

– Без инде зур, – дибез.

– Мин сезнең башларыгызны юам, калганын үзегез юыгыз. Карагыз аны, әйбәтләп юыныгыз, – ди.

Безнең аяклар яирәСләрнең кара сарыгының тәпие төсле.

– Нигә болай пычрак сез? – ди.

Ул киткәч, без үзебез юынабыз. Бездән чыккан пычрак мунча идәнендә кап-кара эзләр булып сузыла.

Без көн саен ишегалдындагы су белән юынырга кирәк, дип сүз куешабыз.

## Дуеш Серне ачыклый

Нефть казырга көн саен йөрибез. ЗамлА да безнең белән.

Чокыр тирәнәя барган саен эш авырая. Ниндидер эш башкарып йөрүебезне кешеләр дә сизенә башлый. Чокыр казып кайтышка безне Дуеш каршы ала.

– Көн саен басуга кереп китәсез. Кая барасыз сез анда?

– Кәҗәләргә кукуруз арасыннан печән җыябыз.

– Юк, сез кукуруз җыясыз. Мин дурак түгел.

– Без кукуруз җыймыйбыз, – дибез һәм капчыкны күрсәтәбез. Ул капчыкны актарып карый. Ышанмый.

– Ә нишләп йөрисез сез кукуруз арасында шул гомер? Мин беркөнне карап тордым. Сез анда көн буе булдыгыз.

– Безнең әби өйдә юк. Безгә күңелсез, – дибез.

Ул ышанмый. Текәлеп-текәлеп карый. Берни аңлый алмый китеп бара.

## Таяк тартыш

Кичен таяк тартыш уенына төшәбез. Болынның уртасында чирәмне чокырлап казып, шакмаклап алынган урын, шул шакмак урталай бүленгән. Бу – таяк тартыш уены урыны. Ике командага бүленәләр. Пикули белән Пипип – бер командада. Уен мәйданының як-ягына таяк кагыла. Уенда малайлар да, кызлар да уйный. Әмма без бөтенебез дә бер-беребезне «малайлар» дип йөртәбез.

Каршы яктагы команда таякны талап алып, үзенә алып кайтырга тиеш. Уенның кагыйдәсе шундый – күрше якка чыкканнан соң аңа дошман командасы кешесе сукса, ул «ката» – кулларын ике якка сузып, катып кала. Аны «җебетер» өчен үз командашың сугарга тиеш. Әгәр кеше үз командасындагы кешегә тотынып торса, ул «катмый».

Уенда ике төрле җиңеп була. Беренчесе – малайлар бер-берсенә тотыналар да озын «җеп»кә әйләнәләр. Шулай һөҗүм итеп, таякны талап алып була. Әмма җепне дошман ягы җимерә – җептәгеләрне төрле якка тарткалап, кулларын аералар да «катыралар».

Тагын бер ысул – команданың бер өлеше җеп итеп тезелә дә дошманнарны котыртып тора. Бөтенесе җепне тарату белән мәшгуль булганда каты йөгерә торган малайлар дошман җиренә чабып керәләр дә таякны алып чабып чыгалар. Моның өчен шәп йөгерергә кирәк.

Зур малайлар каты уйный. Җепне җимергәндә, бер кулыңа биш малай, икенчесенә биш малай асылына да төрле якка тарткалыйлар. Уртадагы малай шыр акыра.

Пикули әкрен йөгерә. Ул әле зур түгел, шуңа да аны җепкә дә тезмибез. ЗамлА, Пикули кебекләрне дошманнан таяк алып кайтырга йөгертәләр. Таяк алып кайта алмаса да, дошманның ачуын китереп, вакытын алсын.

Пипипны җепкә куялар.

Каршы якта Исай уйный. Җыен зурлар – тараМ, тарйА, энилА, яилА шул якта. Алар җеп булып тезелеп бәреп керәләр дә безнең таякны урлыйлар. Без аларны таратмакчы булабыз, көч җитми.

Рәттән өч тапкыр җиңелгәч, безнең малайларның кәефе төшә башлый. Талаш китә:

– А-а, сездә зур малайлар! Бездә җыен бала-чага, – дибез.

Тегеләр каршы чыга. Сез тырышып уйнамыйсыз, диләр. Сезнең якта көчле малайлар, дип тавыш чыгаргач, безгә Баканы бирәләр. Аны бөтен кеше Бака дип йөртә. Хәтта зурлар да.

– Безгә Бака кирәкми, ул сугыша белми, – дип кычкырышабыз. Бака зур малайларга да кирәкми. Ул – зур, әкрен кыймылдый. Аның белән булуга караганда, булмавың яхшырак. Әмма зур малайлар, төрткәләп, Баканы безнең якка чыгаралар.

– Әйдә, аларны корыга кәҗә калдырабыз! – ди энилА.

Корыга кәҗә калдыру – без бер тапкыр да җиңмибез, дигән сүз ул. Ун тапкыр рәттән җиңәләр икән, икенче тапкыр таяк тартыш уйнаганчы шул командадагы малайларны «кәҗә», дип үртәп йөртәләр.

Тагын уйнап карыйбыз. Тегеләр тагын-тагын безнең шакмакка бәреп керә. Без, җептәге малайларны аермакчы булып, кулларына асылынабыз. Аларны җиңеп булмый. Иң алдан энилА бара. Безне төртеп кенә ега.

– Әйдә, тартып егыгыз Алинәне! – дип кычкыра Бака.

ЭнилАга берьюлы ташланабыз да, ул кулын ычкындырып егыла. Без аның өстенә өелешеп егылабыз.

ЭнилА катып кала. Тегеләр энилАны азат итәргә тырыша башлый.

– А-ааа!

Безнең котыбыз оча. Әйтеп бетергесез каты тавыштан сискәнеп карасак, без маташкан арада Пикули тегеләрнең шакмагына йөгереп кереп, таякларын алып чыккан.

– Таяк миндә, таяк миндә! – дип кычкыра.

Пикули начар йөгерә дип, калганнар аңа игътибар да итмәгән. Ул шуннан файдаланып, таякны алып чыккан.

Тегеләрнең бирешәсе килми.

– Син уен зонасыннан чыгып йөгереп кердең, – дип кычкырышалар.

Пикули:

– Юк, мин моннан кердем, моннан чыктым, дип, кайдан чабып кереп, кайдан чыкканын күрсәтә.

Исай котырып китә:

– Кая, кил әле монда, – дип Пикулига таба йөгерә. Пикули, таягын атып бәреп, чабып китә. Исай ике атлауга аны куып җитә.

– Аһ, бетерде бу моны! – ди кемдер.

Кызык, Исай Пикулига тими. Куып җитеп, җиргә егып сала да:

– Маладис икәнсең! Кая, бир бишне! – дип, кулын суза. Аннары кулын каты итеп кыса.

– Ай-ай, авырта! – ди Пикули.

– Җибәр! – ди Пипип.

Исай тагын бер:

– Маладис икәнсең! – ди. Пикулиның аркасыннан кагып, таякны алып килә.

Ахырда тегеләр бирешәләр. Исәп 9:1. Алар җиңде, әмма без коры кәҗәләр түгел. Юлда кайтканда, барысы да Пикулины мактый.

– Кара, хәтта Исай сезне мактады, – ди әнилА.

Без беләбез – ул Исайны ошата. Ул бервакыт Исайны үпкән, дип сөйлиләр. ЗамлА күргән. Ул бездән көнләшә. Шуңа күрә Исай мактаганны яратмый.

– Ул Пикулины гына мактады. Башкаларыгызны мактамады, – ди.

Без барыбер шат.

ЗамлА да куана.

– Моннан соң Исай сезгә тимәс инде. Ул Пикулины маладис, диде. Аның әле беркайчан да кечкенә малайларга «маладис», дигәне юк иде, – ди.

– Исай сиңа тисә, без аңа әйтербез, – дибез.

Без ул көнне лапас бүрәнәсенә кадак белән язу язабыз. «Исай Пикулины маладис, диде. 31 июль».

## Бөек Сер ачыла

Әби һаман кайтмый. Әмма буш вакыт азая. Әби, яирәСкә телефоннан шалтыратып, приказлар бирә. Ул керә дә безгә эш куша. Без чүп утыйбыз, су сибәбез.

Авылда сигез җан иясе безнең дусларыбыз: Эт. Мәче. Кәҗә. Сарык. Сыер. Тавык. Үрдәк. Каз.

Күркә, индоутка бик сирәк кешеләрдә генә бар.

Эшләр беткәч, чокырга барабыз. Чокыр әкрен казыла. Нефтьнең исе һаман килми. Өске якны казыганда, җир башта коры иде. Аска төшкәч, чокырдан нindидер кызыл балчык чыга башлады, ул көрәккә нарат сагызы кебек ябыша.

Инде чокырга болай гына төшеп тә, менеп тә булмый. Чокыр стенасына агач чөйләр кагабыз, шуларга басып менеп-төшеп йөрибез. Беребез казый, икенчебез кечкенә чиләк белән балчыкны өскә ташлап тора.

Казыгач, чокыр төбенә утырып ял итәбез. Шунда әллә нинди тавыш ишетелә.

– Вертолёт! – ди Пикули. Икебез дә сикереп торып, күккә карыйбыз. Астан гына вертолёт очып үтә.

– Безне күрде бугай, – ди Пипип.

– Күрсә, кешеләргә әйтер микән инде? – ди Пикули.

Без борчыла башлыйбыз. Вертолёт безнең нефть казыганны кешеләргә әйтсә, безнең байлыкны тартып алачаклар. Чокырны яшерергә кирәк, дигән фикергә киләбез. Таллыкка барып таяклар сындырып, чокыр тирәсенә кадап куймакчы булабыз. Монда агач үсә икән дип уйласыннар. Тал ботакларын сындырып булмый. Алар бөгелә генә. Икенче килгәндә, пычкы алып килергә кирәк. Тагын чокырга төшеп казый башлыйбыз.

– Әй, нишләп ятасыз анда!

Тик эшләп ятканда, каты итеп кычкырган тавыш ишетәбез. Өнсез калып, чокыр төбенә посабыз. Чыгып чабып булмый. Чокырдан чыга башласаң, күрәчәкләр.

– Вертолёт кешеләре күрде безне, – ди Пипип.

– Нефтьне табарга да өлгермәдек. Казып бетерәбез, дигәндә генә, – ди Пикули.

– Җаныгызны алам, чыгыгыз чокырдан! Мин күрдем сезне, әбиегезгә әйтәм! – Теге кеше һаман кычкыра. Үзе күренми. Ул арада ул безнең чокырга балчык ата башлый.

– Безнең әби бар икәнен каян белә ул? – ди Пикули.

– Өчкә кадәр саныйм, чыкмасагыз, шул чокырны өстегезгә ишәм!

– Бер!

– Нишлибез? – дип сорый Пикули.

– Әйдә, чыгабыз да сугышабыз! – ди Пипип.

– Бер ярым!

Без көрәкләрне тотып, сугышырга әзерләнәбез. Чокыр безнеке, нефть тә безнеке. Без казып бетергәч кенә аны алмасыннар.

– Ике!

– Ике ярым! – тавыш инде бөтенләй якын ишетелә.

– Өч! – Вертолёт йөртүче безнең чокыр янына килеп баса. Ул кояш ягында баскан, шуңа күрә йөзен күреп булмый. Без күзләрне кысып, аны күрмәкче булабыз.

– За то что сез яма казыгансыз, суд приговорил вас к расстрелу! – ди вертолёт хуҗасы. Ул нәрсәдер атарга кулын күтәрә.

– Пикули, в атаку! – Без чокыр төбеннән балчык кисәкләрен атабыз. Теге кеше безгә кукуруз чәкәне ата. Ә без аңа чокыр төбеннән балчык атабыз. Ул безнең һөҗүмне көтмәгән икән, артка таба чигенә дә чүп үләннәренә сөртенеп егыла. Без чокырдан чыгабыз.

– Иса... – Исай диясе килсә дә, телне тешләп калабыз. Җир өстендә Исай ята. Егылганына исе дә китми, торырга да тырышмыйча үлән өстендә ята.

– Менә тоттым мин сезне, ха-ха. Нәрсә казыйсыз монда?

Без инде хәзер казымыйбыз, дип әйтә алмыйбыз. Ул безне тотты.

– Безгә сөйләшергә кирәк, – дибез аңа.

– Ха-ха. Мин сезгә ияреп бардым. Әйдә, сөйләгез, нәрсә казыйсыз монда? Штабмы?

– Без башта икебез сөйләшәбез, аннары сиңа сөйлибез. Шулай ярыймы?

– Ярар.

Гаҗәп, Исай үзен бик гади тота. Теге кукуруз басуында үзен екканны да искә төшерми. Монда бит басу, рәхәтләнеп икебезне дә кыйный ала. Ә ул чокырны карый.

– Фьюттүтүтү! Шушыны икегез генә казыдыгызмы?

– Әйе.

– Нәрсә казыйсыз соң сез?

– Без сөйләшеп килгәч, сиңа әйтәбез.

– Бу чокырдан казылган балчык кайда соң?

– Барысын да сөйләрбез.

## Исай да нефть казый

Без Пикули белән сөйләшергә китәбез. Таллар янында басып торабыз, ә Исай чокырга төшеп китә. Чокыр инде шулкадәр зур – Исай күмелә.

– Без тапкан нефтьне үзенә ала, – ди Пикули. Ул инде еларга җитешкән.

– Без бит әле тапмадык.

– Әйтәбезме аңа? – ди Пикули.

«Әйтәбезме-юкмы» дип киңәшәбез. Шунда без уртак уйга киләбез:

– Әйдә, Исайны замлА урынына алабыз!

– Әйдә! ЗамлА барыбер җир казыша алмый. Ә бу казый!

Без Исай янына киләбез.

– Илшат! Без сиңа сөйлибез. Ә син башта безне ничек тапканыңны сөйлә.

Без яирәС пешереп биргән бәрәңгеләр белән Исайны сыйлыйбыз. Ул безне ничек тапканын сөйли.

– Дуеш әйтә, алар көн саен кукуруз эченә кереп китеп югалалар, ди. Ул сезнең арттан барып караган, таба алмаган. Мин башта сезне кукуруз урлап йөрисез, дип уйладым, аннары күзәттем. Сез гел өйдә була идегез. Хәзер юк. Аннары кич мин сезнең кукуруз эченнән чыгып өегезгә кереп киткәнне карап тордым. Бүген иртән сезгә кердем.

– Безгә кердең?

– Әйе. Сезне эзләдем, ә сез юк. Аннары эзегездән киттем.

– Нәрсәгә?

– Миңа да кызык бит. Кайда йөргәнсез икән?

– Аннары?

– Аннары мин кукуруз эчендә сезнең сукмакны күрдем. Шуннан киттем. Агу өенә килеп чыктым. Сез анда юк. Полоса буйлап киттем. Сез анда да юк. Аннары имәнлектән өске полосага бардым. Шуннан кайтып барганда, бу якка караган идем, басу эчендә ак башлык күреп алдым. Мин аны сез, дип тә уйламаган идем. Чокыр янына килгәч тә, сез дип белмәдем. Мондый зур чокыр кемнеке икән, дип уйладым. Аннары шыпырт кына килгән идем, сезне күрдем. Сез мине күрмәдегез.

– Аннары?

– Аннары миңа һөҗүм итеп, ектыгыз!

Без көләбез. Исайның безнең белән дусларча сөйләшүе рәхәт.

– Әйдә, сөйләгез. Сез нигә штабыгызны шулай еракта ясарга булдыгыз?

– Бу штаб түгел!

– Штаб түгел? Ничек?

– Штаб инде. Бу гадәти штаб түгел.

– Ә нинди?
– Монда без нефть табабыз!
– Нинди нефть?
– Җир астындагы нефтьне.
– Шушында казыйсыз да, нефть чыгамы?
– Әйе!
– Кит инде.
– Чынлап!

Исай ышанмый. Тегеләй дә әйтеп карыйбыз аңа, болай да. Ул барыбер ышанмый. Без аңа карта күрсәтәбез. Исай мәктәптә начар укый. Картаны бөтенләй аңламый. Шулай да караган була.

– Монда кем нефть бар, дип әйтте?

Без аңа нефтьче йаблакаС турында сөйлибез. Ул шаккатып тыңлап тора.

– Аннары ул нефтьне нишләтәсез?
– Сатабыз. Безнең күп итеп акча була.

Акча дигәч, Исайның да күзләре яна башлый.

– Мине дә үзегез белән алсагыз, нефтьне тизрәк табабыз.
– Әйе, Илшат. Без сиңа әйтмәкче булып тора идек.

Ашап бетергәнче, без сүз куешабыз. Җир казырга үзебезнең нефть компаниясенә Исайны да алабыз. ЗамлАны да кумыйбыз. Исай аны куарга куша. Без сатулаша торгач, кумыйбыз, дип килешәбез.

– Ул иң башта безнең белән казышырга килде.

Исай шунда ук җирне казырга керешә. Ул шулкадәр тиз казый, без Пикули белән икебез балчыкны ташып өлгерә алмыйбыз.

Ул берүзе бездән өч тапкырга күбрәк казый. Ул ял иткәндә, без икәү аска төшеп казыйбыз.

## Исай исемен үзгәртә

Исай юл табарга, дигәндә бик акыллы малай. Ул эт кебек – теләсә нинди тишектән юл таба. Безгә нефтькә барырга туры юлны өйрәтә. Без кайтканда, Агу өе яныннан урап түгел, кукуруз басуын турыдан кистереп кайтабыз.

Адашмас өчен кукуруз басуы эченә маяклар тезәбез. Маяк дигәнебез – ашарга алган пакетлар һәм гәзитләр. Борылырга кирәкле урыннарга шуларны куеп чыгабыз. Безнең бару-кайту юлы күпкә якыная.

Өйгә кергәч, Пикули әйтә:

– Әйдә, Исайны моннан соң Исай, димибез.
– Әйдә, ташлИ булсын.

Пикули әйтә – замлАга әйтергә кирәк ди. ЗамлА – елак малай. Исайны алдык дигәч, еламсырый башлый:

– Мине төшереп калдырасызмыни?
– Без алай димәдек. Без үзебез белән Исайны да алабыз.
– Нигә инде? Кирәкми ул! – замлА киреләнгән сарык кебек аягы белән тибеп ала.
– Син бит барыбер казый алмыйсың. Аннары инде синең ничә көн безнең белән барганың юк. Без хәзер аның белән дус.
– Ул безгә нефть бирмәс, – ди замлА.
– Бирер. Без дуслаштык.

## Эш тизләнә

ТашлИ белән дуслашканнан соң, икенче көнне без нефть казырга туры юлдан барабыз. Шуңа да тиз барып җитәбез. ТашлИ үзе белән җир казырга яхшы көрәк алган. Нигәдер күп итеп такталар алган.

– Нигә ул такталар? – дибез без.

– Балчыкны казырга, – ди.

Без аптырашып карап торабыз. Ул такталардан балчык ташырга носилка ясый.

Безнең җир казу хәзер күпкә тизрәк бара. ТашлИның көрәге яңа, ул җирне дә тиз казый. Без ташып торабыз, ул казый.

Инде бер атна тирәсе казыйбыз. Чокырга хәзер баскыч белән генә төшеп, менеп була. Баскычны ташлИ ясады. Безнең исәп буенча, тагын Пикули тирәнлегендә казысак, нефть чыгарга тиеш.

Алай дигәч, ташлИ тагын да кызурак казый башлый. Чокыр тирәнәйгән саен безнең «нефть күренмиме» дигән сорау ешая бара. Юк. Берни юк.

Ул казып аргач, без казырга төшәбез. Теге көрәккә сылана торган кызыл балчык тагын да әшәкеләнде. Аны икенче көрәк белән кырып төшерүе дә читен.

Ял иткән вакытларда без җирне иснәп карыйбыз. Озак иснәгәч, җирдән йаблакаС савытыннан килгән нефть исе сизелгән кебек була. Нефть ничек итеп чыга икән, дип сөйләшәбез. Безнең фикеребезчә, ул чишмә кебек бәреп чыгарга тиеш.

Тал буена сузылып ятып ял иткәндә, ташлИ бездән сорый.

– Менә без нефтьне тапкач, аны ничек итеп ташыйбыз?

– Чиләк белән, – ди Пикули.

– Чиләк белән генә аз булыр ул. Мин әтинең бидонын алып киләм. Аннары бездә иске «Жук» сәпитенең тәгәрмәче бар. Мин арба ясыйм да шуның белән ташыйм. Ә бездән нефтьне кем сатып ала?

Менә анысын уйламаганбыз.

– Гәҗиткә нефть сатам, дип игълан бирергә кирәк, – ди Пикули.

Шулай хәл итәбез. Хатны Пипип язарга тиеш була. Чөнки аның хәрефләре матур чыга.

– Кайткач та, гәҗиткә хат язам, – ди Пипип.

Тал буенда утырабыз, шунда без бер гөрелте ишетәбез. Ни булды, дип карасак, Агу өе яныннан тезелешеп комбайннар килә. Алар бик күп. Алар таллык буендагы юлдан борылып, каядыр китеп югалалар. Без таллар арасына качып, аларны карап калабыз.

– Болар кая китте икән? – дип сөйләшәбез.

– Берәр ерак басуга уракка киткәннәрдер, – ди ташлИ.

Шул көннән таллык янындагы юлда йөргән машиналар саны арта. Кайта торган машиналарга ашлык төялгән. Бодай бөртекләре юл читенә дә коелып кала.

– Әһ, бу машиналар ишегалдыннан узса икән! Тавыклар рәхәтләнер иде, – ди Пикули.

Казуы читенләшә. Башта машина тавышын тыңлыйбыз. Аннары гына носилканы күтәреп алып китәбез. Кайсы вакытта ярты юлда булганда, машина тавышы ишетелә. Андый чакта бик тиз йөгерергә кирәк, чөнки әкрен

мыштырдасаң, таллыкка барып җиткәнче, машиналарның килеп тә җитүләре, күреп тә алулары бар.

– Безнең штаб машинадан күренәдер, – ди ташлИ.

Ул дөрес әйтә. Без нишләргә кирәген белмибез. Ул белә.

– Безгә штабның өстен капларга һәм балчык белән томаларга кирәк.

– Ә балчыкны ничек казыйбыз?

– Чокырның ярты ягын ачылмаслык итеп каплыйбыз. Ярты ягы ачыла торган була. Ишек итеп ясыйбыз. Яңгыр яуса да, зыяны юк...

## Чокырны яшерү

ТашлИ өеннән такталар алып чыга. Алар иске абзарларын сүткәннәр иде, шуңа күрә иске-москы такталар әллә никадәр. Ул шуларны кеше күрмәгәндә, кукуруз арасына ташый. Аннары без шуларны чокырга күтәреп барабыз.

Без шул такталар, полиэтиленнар белән чокырның өстен каплыйбыз. ТашлИ өйләреннән чеби оясының ишегенә кадәр алып чыга. Чокырның бер читенә шул чеби оясының ишеген беркетәбез. Такталарның өстенә полиэтилен, рубероид, аларның өстенә, рәт-рәт итеп кисеп, туфракның чирәмле өлешен җәябез.

– Киселгән үлән тиз үлә ул, – ди ташлИ. Без чокыр өстендәге тактага җәелгән кәзләргә үлән шиңмәсен дип су да сибәбез.

Хәзер, читтән карап торганда, болында чокыр бар икәне бөтенләй күренми.

Кайбер көннәрдә замлА да килә. Ул безнең нефть чокырына инде әллә нәрсәләр алып килеп бетерде. Савытлар, кашыклар, кәнфитләр, прәннекләр, уенчыклар, шәмнәр дә бар хәзер безнең. Чокыр эчендә караңгы түгел – шәм яндырып утырабыз.

Без хәзер ашлык ташыган машиналарның эш сәгатен белеп бетердек. Шуңа күрә алар күп йөргән вакытта балчык ташымыйбыз. Нефть чокырына төшеп утырабыз.

– Илшат, сиңа нигә кирәк соң нефть? Синең бит бөтен әйберең дә бар.

– Акчам күп булса, мин энекәш яки сеңелкәш алып кайтырга әниләргә бирер идем. Мин әти белән әнидән сорыйм, алар гел акча юк, диләр.

– Нигә кирәк соң ул сиңа?

– Хы. Менә сез бит икәү, сезгә кызык. Ә мин сезнең белән йөрим. Энем булса, мин энем белән йөрер идем.

Безгә кызык. Без бәбәй алып кайтыр өчен күп акча кирәк икәнен белмибез.

– РуннәФкә сеңлесен алып кайттылар, алайса аларның акчалары күп инде, – ди Пикули.

Без тагын бәбәй алып кайткан кешеләрне барлыйбыз. Берсе дә бай түгел кебек.

– Алар да бай түгел бит, – дибез.

– Әти белән әни акча булса, бала алып кайтабыз, дип әйтте, – ди ташлИ.

Без ташлИны кызганабыз. Нефть табылгач, энесен алып кайтырга акча җитәчәген әйтәбез. Ул куанып китә. Без тагын эшкә тотынабыз.

## Нефтькә күп калмады

Шунда өеннән замлА килеп җитә. Ул бер ягы очланган озын тимер алып килгән. Нефтькә күпме-азмы икәнен белер өчен борау алып килергә кушкан идек. Шул тимерне җиргә кагып кертәбез, аннары чүкеч белән як-

якка авыштырып, мең бәла белән тартып чыгарабыз. Тартып чыгарганда, тимергә ияргән балчык кисәкләре безнең өстебезгә оча, савытларга төшеп бетә.

Тимернең очына ияреп чыккан балчык юеш. Иснәп карыйбыз – нефть исе килә кебек. Бөтен җир коры, ә тимер очы – юеш.

– Су түгел микән? – ди Пикули.

– Су була алмый. Кое казыганда, су нихәтле тирәнлектән чыкты. Без бит ул кадәр тирәнлектә казымадык, – дибез.

Безнең күңелләр күтәрелә. Тагын бер көн бик тырышып казысак, безнең нефтебез чыгарга тиеш.

## Нефть табыла бугай

Икенче көнне без иртән басуга җыенабыз. Безгә ташлИ кирә.

– Мин сезнең белән бара алмыйм. Безгә кунаклар килде. Миңа өйдә торырга куштылар, – ди ул борынын тартып.

– Алайса без үзебез генә барабыз.

ТашлИ иренен тешләп тора. Аның нефть чыкканда, шунда буласы килә.

– Без өске ягын гына казыйбыз, – дибез.

– Өске ягын гына казысагыз да, чыгар инде ул бүген.

– Чыга башласа, туктыйбыз. Анда казыйсы моның кадәр бит әле, – дип кул белән күрсәтәбез.

ТашлИ риза була. Чыгып китә. Бүген казырга баруыбыз бөтенләй икенче төрле. Без шат, кукуруз арасыннан барганда көлешәбез. Кукуруз чәкәннәре дә зур инде. Чәкән өсләреннән сары, кызыл чәчләр асылынып төшкән. Кызыл чәч булганнарының чәкәннәре тәмле, өлгергән.

Нефть чокырының авызын ачып төшкәч, беренче эш итеп җирне иснибез. Үзебезнең өебездән дә якынрак ул безгә. Без бит аны ничә көннәр буе казып ясадык.

– Нефть бүген чыга башлар микән? – ди Пикули.

– Бүген башласа, ул урынны каплап куярбыз. Аннары ташлИ белән замлА килгәч, ул урынын чистартып, чиләкләр белән ташый да башларбыз, – ди Пипип.

Без казыйбыз. Аннары туктап ял итәбез. Тагын казыйбыз. Җир астында казуы читен, эш акрын бара. Без ташлИ кебек тиз казый алмыйбыз. Әмма инде өйгә дә кайтып йөрисе юк, тизрәк нефть чыкканны күрәсе килә.

Балчыкны ташырга, дип чокырдан башны чыгарсак, арпа басуына комбайннар килгән икән. Әллә никадәр комбайн! Басу гөж килеп тора. Нindидер яңа төрле сары комбайннар да бар. Башта таллык төбенә утырып, комбайннар карап ял итәбез. Аннары безгә уй төшә: безнең монда икәнне күреп, берәрсе нефтьне тапмасын тагын! Шуңа күрә, таллык янындагы юлдан машиналар үтмәгән чакта йөгереп барып, чокырга төшәбез. Без эшләгән арада комбайннар гөрелтесе тагын да якыная.

ЗамлА алып килгән көзгене таякка бәйләп, чокыр ишегеннән өскә чыгарып карыйбыз. Безнең шулай иткәннәрен бер кинода күргән бар. Бик тырышсаң, көзгедә комбайннарны күреп була.

Бераздан казып булмый башлый, чөнки чыгарасы балчык күп. Ул чокыр төбенә тау итеп өелә, казыган урынга ишелә башлый. Чыксак, безне күрерләр кебек. Без, чокыр төбендәге шул тауга киемнәребезне җәеп, сузылышып

ятабыз. Эш бик арыткан. Түшәмгә карап ятабыз. Чокырның ишеге турысындагы ярыклардан сызык-сызык булып яктылык күренә. Караңгы, салкынча, рәхәт.

– Минем йокым килә, – ди Пикули.

Ятабыз шулай... Җир астында комбайннар гөрелтесе бөтенләй башкача ишетелә. Әмма безгә берни дә куркыныч түгел. Тычкан балалары кебек кочаклашып ятабыз.

– Без торып казыгач, нефть чыгачак инде, – ди Пикули йокы аралаш. Шундый татлы уйларга бирелеп борыннар белән мес-мес сулап, эленеп китәбез. Озак эшләгәннең әҗере булуын белү бик рәхәт.

– Бүген ничәсе?

– Унбише...

– Бүген әниләр кайтмый микән? Унбишләре кайтабыз, дигәннәр иде.

Башка вакыт булса, Пикули сикереп торып шатланыр иде. Ул йокыга тәмам эленеп киткән, шатланыр хәле дә юк.

– Нефть тә табыла, әниләр дә кайта икән алайса. Бер килсә, килә бит ул! Нефть табылгач, әни бүтән китеп йөрмәс инде. Әйдә, йоклыйбыз, – ди ул.

Без бүтән сөйләшмибез. Гаҗәп, чокыр караңгы, күзне йомгач, тагын да караңгырак. Ә күз алдында сары комбайннар.

## Илшатка кунаклар кайта

Илшат үзләренә килгән кунакларга үпкәләгән иде башта. Кунакларга гына түгел, әтисенә дә. Нефть табыла торган көнне килмәсәләр, ни була инде? Шуны әнисенә дә әйтте. Күрше малайлары белән уйныйм әле, дип сорады.

Әмма әнисе ачуланып:

– Йөз елга бер кайта торган кунаклар ул безнең! Синең әле аларны күргәнең дә юк! – диде.

Аннары ул Илшатны куандыра торган ике әйбер әйтте. Аларга кайтачак кунак машинада күрше малайларының әниләрен – җырчы Гөлчәчәкне утыртып кайтырга тиеш икән. «Сөенчесен алырсың шул малайлардан», – диде әнисе.

Аннары аны шатландыра торган тагын бер хәбәр әйтте:

– Син әйбәт булсаң, сүзне тыңласаң, энекәш тә алып кайтырбыз.

Илшат, шатлыгына чыдаша алмыйча, күршеләргә йөгерде – дусларының җырчы әниләре кайтканны күрү иде теләге. Ул аларга чабып кергәндә, урамнан зур ак машина кайтып туктаган гына иде. Машинадан җырчы Гөлчәчәк белән тагын бер апа һәм абый төште. Җырчы апа нәкъ телевизор экраныннан чыккан шикелле. Шундый ук чәч, шундый ук елмаю. Ә үзе гап-гади кешеләр кебек сөйләшә. Илшатны таныды хәтта!

– Илшат бит син? – диде Гөлчәчәк апасы. Абый исә зурлар кебек кул биреп исәнләште.

– Безнекеләр кайда соң? – диде Гөлчәчәк.

– Алар болында, хәзер алып кайтам! – дисә дә, малай тиз генә китә алмады әле.

Аның артыннан әниләре йөгереп килеп җиткән иде, барысын да үзләренә чәй эчәргә чакырды. Илшатны да табынга утырттылар. Әллә никадәр ят кәнфитләр, нииндидер җимешләр алып кайткан иде кунаклар. Шуларга алданып, малай үзенең кайда икәнен дә онытып торды.

– Безнең малайлар кайда икән? – дип Гөлчәчәк апасы кабат сорагач,

яшен тизлегендә урамга атылды Илшат. Кукуруз арасыннан болынга – нефть казып яткан малайлар янына йөгерде. Басудагы чүп үләне аякларга чорнала, кукурузның кытыршы яфраклары кулларны кырып-кырып ала. Әмма Илшат аны-моны күрми йөгерүен белде – хәзер-хәзер, йөгереп килеп җитәр дә малайлардан сөенчесен алыр! Бәлки, алар нефтьне инде тапкандыр, дип тә уйлады ул. Тапканнар икән, икеләтә шатлык бит! Тапмасалар да, зыяны юк – кич белән килеп, һичшиксез, табарлар... Аз гына калды, аз гына чабасы...

## Комбайн

Быел Фәннур яңа комбайнга утырды. Аңа сокланып бетә алмый – эшлисе түгел, җырлап барасы. Баштагы мәлне, шулкадәр бәягә комбайн сатып алалар, дип шаккаткан иде хуҗалыкта барысы да. Әйберне ала белмәсәң, бәясенә карап ал, ди бит. Бәясе шәп булса, үзе дә бик шәп икән шул.

– Нефтьчеләр бүләге! – диде хуҗалык җитәкчесе Рәшит Ганиевич.

Иске комбайннан соң монда эшлисе дә юк кебек тоела иде аларга. Ике сәгать саен ватылып та тормый.

Фәннурның ярдәмчесе – энесе Фәнис. Алар эшли башлаганнан бирле бергә. Күрсәткечләре дә әйбәт. Яшь егетләргә яңа комбайн бирүгә өлкәнрәкләр көнләшебрәк карады, билгеле, әмма нишлисең, хуҗа әйткәч, димәк, шулай дөрес дип тапкан. Туганнарның максаты – хуҗалыкта беренче урынны алу! Рәшит Ганиевич ышанып тапшырган икән, ышанычны акларга кирәк! Һәм әлегә беренчелек аларда.

Арпа басуының уңышы әйбәт, әмма бераз чүплерәк. Фәннур яр буеннан урып кереп китте. Урыны-урыны белән басу уртасында актарылып ташланган җирләр бар.

– Әрәм иткәннәр никадәр ашлыкны, – диде Фәннур.

– Кемнәр ул?

– Кабан дуңгызлары. Басуны актарганнар бит.

Шулай дип әйтеп кенә бетерде ул – комбайн «жатка»сы белән актарылган балчыкны эләктереп алды. Машинаны үзенең бер кисәге кебек яраткан комбайнчының тәненә пычак белән сызып җибәргән кебек булды. Зыян килмәдеме икән инде? Алар комбайнны туктатып, җиргә төштеләр, «жатка»ны карадылар. Берни дә булмаган кебек, тешләргә балчык кына тулган. Аларны чистарттылар. Иске комбайн булса, бернигә дә карамыйча, урып китәрләр иде. Ә моңа берәр ни булмадымы икән?

– Абый, әйдә, теге техниклар монда гына бит. Барып сорап килик! – диде Фәнис.

Фәннур да бу фикерне хуплады. Иң яхшысы: бер киңәшү, аннары үзләре белеп эшләрләр.

Фәннур комбайнны бераз артка чигерде. Басу янындагы тигез болынлыкка кереп борылып, юлдан ерак булмаган урында кайнашып яткан ремонтчылар янына барырга уйлады.

Комбайн күккә кара төтен чөйде, ажгырып борылды. Болын чирәменнән тулы көченә барганда, зур гәүдәле комбайн җиргә кадалган кебек булды. Гөрселдәгән тавыш белән комбайнның сул тәгәрмәче ниндидер чокырга төшеп китте, авыр техниканың арткы тәгәрмәчләре күтәрелеп куйган кебек булды хәтта. Комбайн сул якка авышкан килеш сүнеп туктап калды.

– Бетте, чокырга төштек!

Комбайнның алгы тәгәрмәче тип-тигез урында ниндидер чокырга төшкән. Ул чокыр бик тирән булган – шул яктагы тәгәрмәч күчәре белән җиргә тигән, ярдәмсез генә чыгарырлык түгел.

Ике егет җиргә ятып, тигез болында нинди чокыр барлыкка килгәнен аңларга тырышты. Кемдер казып киткән чокыр булса, кырыенда балчыгы булыр иде. Нәрсә икән бу?

– Кара, Фәнис, анда ниндидер такталар да бар, – диде Фәннур. Чыннан да, комбайн тәгәрмәче астында ниндидер такта кисәкләре чыгып тора иде.

Икесен дә комбайн ватылмады микән, дигән уй борчыды.

– Моны болай гына чыгарып булмый, буксир чакырырга кирәк.

Шунда алар кукуруз басуы ягыннан чабып килгән ак күлмәкле малайны күреп алдылар.

## Күмелү

Илшат, кукуруз басуы эченнән йөгереп чыгуга, нефть чокыры янында туктап торган комбайнны күрде:

– Беттек!

Комбайн басуда түгел, чокыр янында туктаган иде. Димәк, нефть казыган урынны тапканнар! Мөгаен, малайлар нефть тапканнар да, болар шуны урларга килгән. Комбайннарына салалар да, алып китәләр хәзер! Алар җәй буе казып тапкан нефтьне! Эшләгәндә, берсе дә булышмады, табылгач кына алырга килгәннәр. Үзе дә сизмәстән, Илшатның күзеннән яшьләр бәреп чыкты. Ул елый-елый комбайнга таба чапты:

– Бирмим, безнең нефть ул! Без таптык аны!

Таллык янына килеп җиткәндәрәк, аның хәле бетте. Йөгерүдән туктап, куллары белән күзләрен сөртеп алды.

Тукта!

Кайда соң нефть чокыры?

Чокыр өсте күренми иде.

Аның өстендәге үләннең төсе бүтәнчәрәк иде.

Комбайн чокырның өстендә туктаган.

Илшат сулышы кабып, чокырга таба йөгерде. Бу комбайн нигә нефть чокыры өстендә туктаган соң? Комбайн кырыенда ике абый йөренә. Ә малайлар юк. Ул таллыкка карады – малайлар анда да юк. Алар кайтып киткәнме әллә? Ул комбайн янына барасы җиреннән бераз читкә каерылып, таллык яныннан узды. Алар кайтып киткәндә, көрәкләрне шунда калдыра иде. Яшерелергә тиешле урында көрәкләр юк. Димәк, малайлар чокырда! Комбайнга якынрак килгәч, малайның куркудан чәчләре селкенеп куйган кебек булды – комбайн сул тәгәрмәче белән чокыр өстенә төшеп киткән иде.

– А-а, китегез аннан! Нишләттегез малайларны?!

Комбайнчылар, кычкырган малайны күреп, сәерсенеп киттеләр. Малай үзе йөгерә, үзе чебен куган кебек селтәнә, гүя бәләкәй куллары белән зур комбайнны читкә күчереп куймакчы була.

– Нәрсә ди ул? – дип аптырады комбайнчы егетләр.

– Малайлар, малайлар! – диде ак күлмәкле малай. Комбайн янына килеп җитүгә, тәгәрмәченә карады да, тыпырдап, елап җибәрде:

– Алыгыз... чокырдан! Анда... анда малайлар!

Комбайнчылар, ни турында сүз барганын аңлап бетермәсәләр дә, ниндидер куркыныч хәл булганына төшенделәр.

– Нәрсә дисең соң син?

Малайның елау аралаш нәрсәдер әйткәнен алар аңламады. Ул арада бәләкәй малай тузынып китеп, куллары белән комбайн тәгәрмәче астындагы җирне казый башлады.

– Нәрсәгә карап торасыз, казыгыз тизрәк!

Фәннур, малайны җирдән йолкып алып, үзенә таба каратып бастырды:

– Нәрсә бар анда? Нинди чокыр иде ул?

– Карап тормагыз инде, казыгыз! – Малай кабат казымакчы булган иде, Фәннур аны җилкәсеннән тотып каты гына селекте:

– Тукта, елама! Тының чыкмасын! Әйт әле, нинди чокыр бу?

Малай сулкылдау аша җавап бирде:

– Нефть... Нефть...

– Син казыдыңмы аны?

Малай башын какты.

Комбайнчылар бер-берсенә караштылар. Кечкенә генә малайның шундый зур чокыр казый алуына ышанып бетмәде алар.

– Син генә казыдыңмы соң аны?

– Юк-юк.

– Тагын кемнәр? Еламыйча гына әйт.

– Малайлар...

– Нинди малайлар соң ул?

– Җырчы Гөлчәчәк малайлары... ы-ыыы.

Фәннур тураеп басты.

– Йә, шуннан нәрсәгә елыйсың инде? – дип сорады Фәнис каты гына итеп. – Монда син түгел, без еларга тиеш! Комбайн ватылды әнә чокырыгызга төшеп!

– Алар шул чокырда-а-а.

– Кемнәр ул?

– Малайлар! Алар шунда! Алар аста калган!

– Нәрсә дисең? Чокырда кеше бар идеме әллә?

– Малайлар шунда иде!

Фәннур белән Фәнис бер-берсенә караштылар. Икесенең дә йөзләре ап-ак булган иде.

– Тавышланма! – Фәнис комбайн тәгәрмәче янына сузылып ятып, колагын җиргә терәде. Аннары, башын күтәреп, йөзе ап-ак булган абыйсына карады:

– Анда кеше тавышы ишетелә бугай...

## Нефть бу!

Малайлар ни булганын аңламый да калдылар. Аларның моңарчы да чокырда йоклаганнары бар иде. Анда бик рәхәт һәм уңайлы. Күләгә, чебен-черки дә юк. Кинәт коточкыч зур гөрселдәү ишетелде, алар аны-моны абайлаганчы, өсләренә балчык, такталар төшеп, ябык тәннәрен җиргә сылап та куйды. Тавыш ничек кисәк барлыкка килгән булса, шулай ук тиз генә тынлык та урнашты.

Бер малайның куллары өстә калган иде. Аякларын селкетергә тырышып карады – юк, алары күмелеп калган.

– Пикули!

Пикулиның тавышы ишетелмәде. Кайда соң ул?

– Әй!

Бернинди тавыш та юк. Әллә ул йоклаганда чыгып киткән инде? Пипип куллары белән капшанып карый башлады. Чәч! Пикулиның чәче! Юеш!!! Ә үзе? Үзе кайда соң ул? Ул куллары белән малайның битен капшамакчы булды. Кулы тагын юеш әйберне тойды. Кан! Димәк... Димәк... Үлгән?

– Бармагыңны күзгә тыкма, – диде Пипип акрын гына.

– Куркытып үтерә яздың бит. Нигә эндәшмисең?

– Авызга балчык тулган минем.

– Нәрсә булды соң бу?

– Белмим бит. Без күмелеп калдык. Нефть чокыры ишелде бугай.

– Әллә шартлаттылар микән?

Малайлар үзләрен баскан балчыктан котылырга азаплана башладылар. Әмма чокырның бөтен ягына да балчык ишелеп, аның аскы ягы шактый күмелгән иде. Җитмәсә, чокырны каплап торган такталар сынып төшеп, аякларны казып бушату бөтенләй мөмкин түгелгә әйләнгән. Чокырның тишеге турысындагы ярыклардан сызыклар гына булып күк күренә иде. Ә хәзер исә чокырда тоташ караңгылык. Малайлар стена уемтасына куелган шәмнәрне алырга азапланып карадылар, әмма кая ул, нәрсәдер табармын, димә. Башлары өстәрәк булу аркасында гына алар бөтенләй күмелеп калмаган иде.

Үзләрен баскан балчыктан котылырга кат-кат тырышып карасалар да, барып чыкмады. Нәрсә күмеп киткәнен дә аңлый алмады алар.

– Без моннан ничек чыгарбыз икән? – диде малайларның берсе, куркынып.

– Бүген безнең әни кайта. Ул кайта, ә безнең монда икәнне белми. Ә без монда күмелеп калабыз.

– ТашлИ белә. Ул килергә тиеш.

– Әйе. Ул килер дә коткарыр...

– Чокыр җимерелгәнен күргәч, ул күңелсезләнер инде...

– Ә сиңа кызганычмы?

– Миңа да кызганыч. Әни кайтышка нефть табып булмады...

Шулай дип әйтеп кенә бетерүгә малайның кулына ниндидер кайнар тамчы тамып, пешереп алды.

– Ай! – ул кулын авызына капты. Эссе һәм ниндидер майлы тамчы иде ул. Ул кулын авызыннан алып, иснәп карады. Кулдан... нефть исе килә иде!

– Пипип! Мин нефть таптым! Нефть!

Ул ашыгып кулы белән җирне капшый башлады. Һәм чыннан да – бармаклары белән эссе майга тиде.

– Пипип! Нефть бу!

Малайларның икенчесе дә бармаклары белән нефтьне кармалап исни иде.

– Нефть таптык! Ура! ТашлИ килеп безне коткара, аннары без нефть табып өйгә кайтабыз!

***

Болында туктап торган комбайнны күреп, хуҗалыкның бригадиры да килеп җитте. Башта комбайнны кызганган иде, «Тәгәрмәч астында малайлар калган» дигәнне ишеткәч, өне алынды. Тиз генә ашыгыч ярдәмгә шалтыраттылар, комбайнны чыгарырга техника алып килергә фәрман бирделәр. Зур комбайнны чыгарырга техника килгәнен көткәндә, чокыр янына сабан туе кадәр кеше җыелган иде инде.

Комбайнны урыныннан кучергәнче, Фәннур ярым үле хәлгә килгән иде.

«Күзем күрмәсен ичмасам», – дип, ул таллар янына барып, башын тотып утырды. Фәнис чокыр янында калды. Барысы да чокыр төбендә изелеп беткән бала гәүдәләрен күрергә әзерләнде.

...Трактор комбайнның тәгәрмәчен урыныннан күчерүгә барысы да әкәмәт күренешкә тап булды. Чокыр төбендә балчык, аннан ике сары баш тырпаеп чыгып тора. Озак караңгыда ятып яктылыкны күргәч, пычракка буялган йөзләрендә күзләре кысылган. Чокыр уртасына зыян килгән комбайн күчәреннән май тамган, малайларның куллары шул майга буялып беткән.

Тракторчы, комбайнны күчерүгә, техникасын сүндереп, җиргә сикерде.

– Без нефть таптык! – диде чокыр төбендәге малайларның берсе.

– Әйе. Менә, ышанмасагыз, иснәп карагыз.

Малайларның икенчесе, чокыр уртасына тамган машина маена кулын тидереп, чокырга иелгән кешеләргә сузды.

## Нефть көтә!

Кешеләр техника эзләгән арада Илшат авылга чабып кайтып, малайларның әниләрен урыннан күчергән булып чыкты. «Балаларыгызны комбайн таптаган», – дип шөбһәле тавыш белән кычкыргач, алары чәй өстәлен ташлап, кукуруз басуы арасыннан болынга йөгергән иде. Алар чабышып килеп җиткәндә, малайларны чокырдан чыгарып кына яталар иде әле. Бәхеткә, малайларга берни дә булмаган иде – таяклар төшкән урыннары сыдырылган, кара көйгән дә башларын такта кырып, канаган гына, баш сөякләре исән ташбашларның... Тузан, пычрак һәм машина маена баткан малайлар, әниләренә атылдылар, аякларын кочаклап алдылар. Берсен-берсе уздырып, нефть таптык, дип кычкырыналар иде алар:

– Әни, без нефть таптык! Безнең күп акчабыз була!

– Әни, әллә кайларга китеп йөрмә инде бүтән. Акча менә монда, казып алып була!

– Һай, улларым, ничек исән калдыгыз, мин үзем үлеп беткән идем бит инде! – дип әниләре тыела алмыйча елый иде.

Алай-болай кеше абайлаганчы, Илшат та чокыр төбенә төшеп менде. Бармагын машина маена тидереп, Алмазның борынына төртте:

– Нефть менә шундый була. Тәки алар тапты.

Илшат бармагын кояш нурына куеп карады. Майлы бармакка кояш төшеп утырган кебек иде.

– Менә шушысы ничә сум була икән аның? Прәннек үк булмаса да, бер кәнфит сатып алырга җитә торгандыр инде?

***

Ул көнне җырчы гаиләсеннән кунаклар өзелмәде. Әллә кемнәр килеп, хәлләрен белешеп киттеләр. Участковый да кереп җиткән иде. Малайларның үзләрен генә караусыз калдырмаска кирәклеге турында авыл башлыгы белән икәүләшеп лекция укып киттеләр. Комбайнны ремонтларга кирәк иде. Фәннур белән Фәнис бу уракта алдынгы була алмаячакларын аңладылар – бер атна эчендә ремонтласалар, шат булырсың, яңа техника... Үзен бик гаепле санаган җырчы Гөлчәчәк гаебен йолар өчен авыл хезмәтчәннәре өчен бушлай концерт оештырырга вәгъдә бирде. Үзенчә шулай «штраф» түләде

ул балалары өчен.

Шунысы кызык: ул көнне бу басуларга нефтеразведка вәкилләре кабат килгән иде. Авыл башлыгы нефть казып йөрүче малайлар турында сөйләгәч, аңа ияреп, җырчы хатынның өенә килде. Мунчада кырык кат ышкып юылып чыккан малайлар ишегалдында таныш йөзне күргәч, шатлыктан чинаштылар:

– ЙаблакаС! Без бит син күрсәткән урыннан нефть эзләгән идек.

– Һәм таба яздык.

Малайларга инде бу вакытта үзләренең дөрес эшләмәгәннәрен җиткергәннәр иде.

– Күрдем, күрдем, – диде Сакалбай. – Мин бер әйбер әйтергә килдем сезгә.

– Әйт-әйт! – дип куанышты малайлар.

– Нефтьне табасыгыз киләме?

– М-м... – Малайлар әниләренә караштылар.

– Табасы килә иде дә...

– Аны табасыгыз килсә, зур үсегез дә безгә килегез.

– Тагын зур үсәсе!

– Әйе, әйе, зур үсәсе! Ә әлегә сездән уку гына сорала! Ә менә әниегезгә шуны әйтәм: бу яшьтән балаларыгыз нефть табарга тели икән, теләкләренә каршы килмәгез инде, шул юнәлештән китәм дисәләр, китсеннәр.

– Юк-юк, берүк җырчы гына була күрмәсеннәр. Безнең кебек балаларын күрми яшәүләрен теләмим, – диде әниләре.

Җырчы ханым авылда җәй азагынача – уку елы башланганчы торды. Малайларга «нефтяниклар» дигән кушамат тагылды. Ике сары башлы малайны күрүгә, «нефтяниклар», дип кенә дәшәләр иде. Гаҗәп, малайлар моны үртәү дип кабул итмәде. Нефть казыганнар икән, димәк, нефтяниклар бит инде.

Укулар башланып, концерт сезоннары ачылгач, әниләре тагын китеп югалды. Начар билге алган чакта малайлар бер-берсенә дәшә иде:

– Нигә өйрәнмәдең? Нефтяник була алмыйсың бит! Аннары еллар буе төрле сәхнәләрдә җүләр кебек җырлап йөрисең була!

Малайларның икесе дә матур җырлый булып чыкты. Тавышлары да бар иде. Әмма мәктәп сәхнәсендә җырлаудан ары китмәделәр. Мәктәпне тәмамлаганда, аларның кая укырга китәчәкләре билгеле иде инде – нефть институты!

Мәктәпне тәмамлап, авылдан укырга киткәндә, болындагы Нефть чокырына барып саубуллашты алар. Анда кычыткannар гына үсеп утыра иде.

Бу вакыйгадан соң күпмедер вакыт узгач, мин дә бардым. Нефть юк иде анда. Әмма нефть табу компаниясенең геологик карталарында шул тирәдә билге тора. Җырчы малайлары казып чыгара алмаган нефть үз хуҗаларын көтә.

*2018 ел.*



Хәбир Ибраһим

# ЧАЙКАЛА ҖӘЙГЕ РӘШӘ...

## Сиртмәле кое

Башланды һич көтмәгәндә
Һавада торна туе.
Пыр туза...
Тик тып-тын калды
Никтер сиртмәле кое.

Очып китмәс микән диеп,
Карап торам коега.
Торнага бик охшаса да
Юк очарга уе да...

## Авылга кайту

Түзеп буламыни инде
Җанның ярсу давылына?!
Берәр нәрсә булды исә
Кайтам туган авылыма.

Ул бит минем бердәнберем,
Туганым да, якыным да,
Тормыш биргән атам-анам,
Сөелердәй хатыным да.

Улдыр тәүге йөрәк җырым,
Бишектәге сабый балам.
Анда алтын балачагым,
Күптән мәрхүм әби-бабам.

Кайда гына йөрсәк тә без,
Яшәсәк тә кайсы якта,
Кем булсак та кайтабыз без
Күңел белән туган якка...

Хәбир ИБРАҺИМ (1958) *– язучы, шагыйрь, драматург; «Аһәң», «Йокыга талган гүзәл», «Газиз ярым» һ.б. китаплар авторы. Абдулла Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

## Илаһи сын

Йөрим урман уртасында,
Узган көннең яртысы.
Төшә агач арасыннан
Сүрән кояш яктысы...

Юк, мин җыймыйм җиләк-гөмбә, –
Кулым бармый өзәргә.
Синдәй гүзәл илаһи сын
Күренәдер күзләргә.

Бу урманның матурлыгын,
Гүзәллеген дөньяның
Күрәм фәкать синең аша
Сылуым минем, җаным...

## Кайда син, Йолдыз?

Йолдыз,
Кайда син, Йолдыз?
Әллә айда, әллә күктә?!
Мин олырак синнән күпкә.

Шалтыратам –
өзек-өзек гудок килә...
Яңгырый күңелем кайтавазы
Ялгызлыкның чиге илә..

Йолдыз,
Кайда син, Йолдыз?
Әллә күктә, әллә айда?
Җаным минем, син соң кайда?

Шалтыратам –
Телефоның ятлар ала...
Сине эзсез югалтуым
Йөрәгемә сагыш сала...

Йолдыз,
Кайда син, Йолдыз?
Әллә айда, әллә күктә?..
Мин олырак синнән күпкә...
Телефонда –
Бер ир заты (тавышы калын):
«Шылтыратма бүтән, абзый,
Ул бит күптән минем хатын!..»

Йолдыз!
Кайда син, Йолдыз?..

## Табарсыз...

Мәхәббәтсез яшәү хәрам,
Бер көнлек – дөнья...
Мине,
Аңлыйсыгыз килсә, әгәр
Тыңлагыз йөрәгемне!

Табалмассыз анда исәп-
хисапны, көннәр санын.
Табарсыз сез сөеп янган
Ләйлә-Мәҗнүннәр җанын.

## Кабатлана бу кайтаваз

Кайтып киләм җәяү атлап,
Кичен. Шактый арылган.
Кайтып киләм шигырь уйлап,
Ромашкалар кырыннан.

Ярсу җаным гүзәллектән
Шаша, тәмам очына!
Кагылып узам йомшак кына
Чәчәкләрнең таҗына.

Күз алдымда мираж булып
Чайкала җәйге рәшә.
Сеңлем, энем, дустым булып
Ромашкалар эндәшә...

Кабатлана бу кайтаваз
Сагыш булып күңелемдә.
Чөнки минем бу дөньяда
Энем дә юк, сеңлем дә...

## Җигүле ат

Җигүле ат җигелгән,
Дугасыннан күмелгән.
Олау йөген тартып бара,
Башы аска иелгән.

Авызлыгын чәйнәп аткан! –
Башын кыскан йөгәне.
Берәрсенең мондый тормыш
Бармы икән күргәне?

Сыртын каты камчы изгән,
Эче эчкә ябышкан.
Усал һәм кырыс хуҗасы
Сөенеп кайта табыштан.

Ашатмый атын, кайткач та
Капкага бәйләп куя.
И бәхетсез җан иясе! –
Моңаеп кешнәп куя.

## Тузанда коенучы чыпчык

Эссе вакыт. Кояш – таба
Шундый хәтсез кыздыра!
Ә бер чыпчык кагынгалап
Ком бураны туздыра.

И очырта, очырта соң,
Җилпеп нәни канатын.
Тузан-туфан арасында
Беразга ул кала тын.

Ялтыратып яшен сукты,
Тамчы гүя таң чыгы.
Яңгыр чакырган икән бит
Авылымның чыпчыгы!

## Тальян гармун

Тальян, тальян, тальян гармун,
Телләре җәһәт уйный.
Кулына тальян алган кеше
Гармунда уйнап туймый.

Уйный, уйный, уйный гармун,
Сыздырыплар моң сибә.
Хәтта тыңлап багучының
Йөрәге ярсып тибә.



Әхәт
Мушинский

# ИРЕНКА-ИРКӘМ

хикәя

Юк, оныта алмыйм аны. Инде ничә еллар узган! – Ә бит хәтердән чыгарып кына булмый. Еллар ага биреп, тормыш дулкыннары күмеп барганда, һәммәсе араларны бүлгән калын вакыт пәрдәсе артында калырга тиештер инде, дигәндә, ул тагын да ачыграк булып, бодай башагы шикелле ачык-сары толымнарыннан, шуның тере кылчыкларыдай, йөрәккә ук булып кадалучы керфекләре арасына сыенган, еш кына сорау чалымын хәтерләтеп күтәрелә төшкән кашларыннан, коңгырт-фирәзә карашыннан алып, гади генә сандалетлы, үсмер кызныкымы, әллә яшь туташныкымы икәнлеген аерып булмас кебек тоелган аяк-тәпиләренә кадәр – бөтен барлыгы белән якыная да якыная гына.

Табигый чик баганалары кебек мәңгелек имәннәр каймалаган, көзге кебек ялт иткән тип-тигез юл – автобан очындагы күтәрмә киртә, ягъни шлагбаум янында кыска җиңел ак күлмәктән торганы әле дә булса күз алдымда. Ә мин, имәннән имәнгә кадәр араны адымлап үтеп, кызыкай, аксыл рәшәдәй тирбәлеп, бер ноктага әверелгәнне күргәнче, ерагая, ераклаша барам шикелле. Тагын, аларның өй морҗасына ук оя корган, шунда инде ничә еллар буе бөтен гаиләсе белән сыенып яткан ак ләкләкне хәтерлим. Ул чакта сорарга башыма да килмәгән: хаҗәте чыкканда, мичне ничек ягалар иде икән соң? Күрче, бүгенгә кадәр мин шуны уйлап яшим ләбаса! Хәзер инде кемнән белешәсең?! Күнегүләр үтә торган залы, кул тубы мәйданчыгы, диварларына ялтырап торган куе яшел хәтфә тарттырылган ике катлы казарма, аның янындагы зур булмаган плац (безнең итекләр таптаганчы, ул әле, ниндидер җае чыгып, халыкара җыр-бию сәхнәсе дә булып алган, диләр) – һәммәсе кичә генә күргән төсле ике кашым арасында тора.

Әйе, миңа совет-поляк чигендәге заставада хезмәт итәргә туры килде. Узган гасырның 70 нче еллар башы, билгеле инде, үткән гасыр ахырына якынлашканда, Багратионовск каласында, дөресрәге, шәһәрчегендә кичердем

Әхәт МУШИНСКИЙ (1951) – *язучы, публицист; күпсанлы китаплар авторы. Г.Р.Державин исемендәге әдәби премия, Россиянең «Заветная мечта» балалар әдәбияты милли премиясе лауреаты. Казанда яши.*

ул хис-тойгыларны, ул хәлләрне. Көнчыгыш Пруссия тарафыннан Прёйсиш-Эйлау дип йөртелгән кечкенә шәһәр янында 1807 елда Наполеон белән рус-пруссак гаскәрләре арасында искиткеч зур бәрелеш булган. Канлы бәрелеш, әмма бер-берсенә бирешмәс көчләр очрашкан анда. Рус гаскәре башында генерал Беннигсен торган. Аның кул астында кенәз Багратион көрәшкән, Барклай де Толли шундагы сугышта яраланган. Тик каланы ни өчендер гаскәр башлыгы исеме белән атамаганнар... Бәлки, Беннигсен, соңгы чиктә, Кутузовның Бородинода чигенергә туры килгәне кебегрәк язмышка дучар булганлыктандыр? Шәһәрдә Наполеон тукталган йорт та сакланып калган иде әле. Хәзер ул йортның диварына шул көннәрне искә төшерүче истәлек тактасы эленгән. Кала читендә исә, готик сыны белән күккә ашарга омтылгандай, Прёйсиш-Эйлау сугышына багышланган һәйкәл басып тора, аны ике ягыннан шул заманның ике тубы «саклый». Матур манзара, минсиңайтим! Менә шушы шәһәрчектә дәүләт чиген саклау насыйп булды миңа. Тагын шуны өстәп әйтим: анда бер генә агач корылма да юк, барысы да таштан һәм кирпечтән иде. Түбәләре әфлисун төсендәге чирәптән, юлларына ташның, безнең Кремль астындагы кебек йодрык-йодрык йомрысы түгел, ә шикәр кебек шакмаклап туралганы түшәлгән. Тип-тигез, аяк астында бизәкләре уйнап-балкып тора, атлап барганда, сокланып туя алмыйсың... Уң кулда элеккеге Тевтон ордены замогы кала, сул якта исә – безнең заманда тарих музеена әйләнгән католиклар чиркәве – костёл. Дәверләр алышына, исемнәр һәм борынгы биналарның кемгә, нинди максатка хезмәт итүе дә үзгәрә. Шулай да, бүгенге сәясәткә каршы килә, дип, еллар, хәтта дәверләр шаһитын бер төн эчендә җимереп, аның ташлары өстендә Иблис биюләре оештыра алсаң да, чын тарихны корама юрган эченә яшереп булмый…

Боларның барчасы да күңелемә якын булганга, шулай берәмтекләп искә төшерәм дә. Ә бит мин хәрби хезмәтемне Калининградта, элекке Кёнигсбергта, Иммануил Кант туган калада башлаган идем. Әмма ул борынгы шәһәр турында сөйләп тормыйм. Аның тарихи язмышы һәркемгә билгеле. Шуны гына әйтә алам: анда миңа ике айлык «яшь сугышчы мәктәбе»н үтәргә туры килде, шунда «калаш»тан яхшы гына атарга, өстеңә өерелеп килүче танктан үзең казыган чокырда качып торырга, аңа каршы басып һәм ул узып киткәннән соң да, гранат тондырырга өйрәндем, сигнал бирү өчен ату, чик буе элемтәчесе коралларын куллану күнекмәләрен алдым… Бу сабакларны үткәннән соң, мине, бүтәннәр кебек, тиз генә озату ягын карамадылар, штабта вакытлы хезмәт үтүче һөнәри хезмәткәр-рәссамнарга шул частьнең музейханәсен – төрле баһадирлар сыны, яу күренешләре белән бизәшергә калдырдылар... Мактанып әйтүем түгел, беркадәр рәссам сәләтем дә бар минем, әле уку-өйрәнү вакытларында ук әгит-күргәзмәләрне бизәгәнем – сурәт төшергәнем, плакат яза торган калын каләмнәрне шыгырдаткан чакларым булды... Аннары бик күп укый идем. Безнең штабта менә дигән китапханә бар. Шекспир, Толстой, Чехов, Шолохов, Катаев… Беләсезме, мин нәкъ менә армиядә кинәт кенә язучы булырга карар кылдым. Классикларны тешемә кыстырган кардәш-карандаш белән чәйнәдем – ушымны китәргән сүзләренең астына сызгаладым, күчереп язгалаган булдым, җөмлә, кызыл юл, фабула дигәннәрен төзергә өйрәндем…

Әмма ләкин ярты елдан музей дигәнебез әзер иде инде. Һәм көннәрнең берендә мин, әлбәттә, артык зур булмаган йөгем белән хәрби йөк машинасы «ГАЗ-66»ның (ике алтылысы аркасында без аны «алтык» дип йөртә идек)

киндер япмасы астына кереп чумдым. Алтынчы (һаман шул сан!) заставага ниндидер әсбаплар илтәсе булган икән, кыскасы, юл уңаенда мине дә үзләре белән эләктереп киттеләр.

Әйе, солдат биштәрендә әлләни байлык юк, әмма минем китап тутырган бер кәгазь тартмам да бар иде бит әле. Китапханәче яшь хатын белән дуслашып алгач, ул минем нәфис әдәбиятка карата тыелгысыз мәхәббәтемне күреп, бераз китап туплап биргән иде. «Булачак язучыга гыйлем эстәр өчен!» – диде ул, озатып калганда. Сер итеп кенә әйтелгән тормыш максатымны белә иде ханым. Менә мин дигән, укымышлы хатын. Шундый бүләк әзерләп куйган бит! Китапларны кайтарып бирү шарты белән, әлбәттә. Хәер, армиядән бөтенләй киткәндә, хәрби часть мөһере сугылган бер китапны, матур саубуллашу сүзләре язып, бүләк итеп тә җибәрде әле ул.

Язмышыма төп юнәлеш биргәне исә Куприн булды. Аның «Олеся»сы, «Гранат беләзег»е һәм бигрәк тә – «Атышу»ы һушымны алды. «Юнкерлар»дагы менә бу юллар исә киләчәгемнең шулай буласына бер тамчы шик тә калдырмады. Зур гына өземтә китерсәм, мине гаеп итмәссез, дип уйлыйм:

«Аның уй-фикерләре хыялында туган тылсымлы язучылык дөньясыннан әле бик озак аерыла алмады: җем-җем килгән яктылык, тантана һәм җиңү шатлыгы били иде аны. Биниһая зур каләм хакы да, дөньякүләм танылу да кызыктырмый, алар шәүлә кебек кенә, коры куаныч, шуңа күрә күңелендәге бер кылны да кузгатмый. Бары тик бер сүз – «язучы» дигәне генә алгысыта... Ул мәшһүр генерал-каһарман да, танылган адвокат, доктор яисә җырчы да, күзләрне камаштырырлык бай-миллионер да түгел, ул агарган чырайлы, акыллы кыяфәтле ябык бер адәм, төннәрен хәерче генә бүлмәсендә утырып, үзе теләгән затларны, башына килгән маҗараларны «тудыра», һәм аларның барысы да меңләгән чын, тормышта булган кешеләрдән, вакыйгалардан озынрак гомерле, еллар, гасырлар буе, хәтта мәңгелек булып, ныграк һәм яктырак сурәттә, исәпсез-хисапсыз буыннарны сокландырып, сөендереп һәм аларга гыйбрәт рәвешендә яшәп кала».

Менә бит ничек! Шул юлларны укыганнан соң бүтән берәр һөнәр иясе буласың килерме?!

Хыяллар, хыялыбыз,
Кайда сезнең балыгыз?

Әмма хыяллану, бәхеткә омтылу, зурдан өмет итү мәле үзе үк мөһим бит. Һәр солдатның букчасында маршал таягы, ә язу осталыгына омтылганнарның куен кесәсендә Толстой каләме ятуы сер түгел. Яшьлек – җүләрлек, диләр. Миңа бит ул чакта унсигез, нибары унсигез генә яшь иде. Беләктә көч тә җитәрлек, ә күңел өмет белән – һәм ышанасызмы-юкмы?! – ирек белән тулы. Армиядәге шикелле азат, бәхетле, киләчәккә омтылган итеп мин үземне бүтән беркайчан да һәм беркайда да тоймадым шикелле. Бәйрәм тантанасын көтү аның үзеннән бәһалерәк икән.

Заставадан ике чакрымда гына – «Багратионовск – Безледа» – чик күчеше. Безнең яктан һәрвакыт бер чакрымга сузылган җиңел машиналар тезмәсе, аның иң алдагы башы мин инде әйтеп узган күтәрмәле киртәгә барып төртелә. Бу халык – Аурупада кунак булып кайтырга теләүчеләр. Польша аша Германиягә дә, аннары, барып чыкса, ераккарак та ычкынырга исәпләре юк түгел. Машина-мазарны КПП (контроль ясап үткәрү пункты)

егетләре тикшерә. Болар – безнең чик буе «каймагы». Аларның кулында матур тимер «Las Palmas» уткабызгычлары, кагып селкеткән саен чишенеп күрсәтә торган кызыйлы каләмнәр, бүтән чит ил әкәмәтләре булыр. Мин алар исәбенә керми идем. Күпчелек егетләр белән бергә, миңа флангларны үлчәүне йөкләделәр. Аңлатып китим. Заставада без сакларга тиешле ике фланг: уң якка ике чакрым, сулга – өч. Бөтен кирәк-ярагыңны асып, көн-төн тегендә-монда йөргәлә. Яисә сәгатьләр буе «яшеренеп» ят. Бер дә булмаса, манарада тырпаеп тор... Мәгәр боларның берсен дә авыр кичермәдем мин. Нәкъ менә чик буенда япа-ялгызың калып, уйланырга, алга таба ниятләр, языласы сюжетларны корырга өйрәндем...

«Кирәк-ярак» дигәнең җиңел түгел иде, әлбәттә: корылган һәм запас магазинлы «АК-47» автоматы, штык-пычак (без аны, селәүсеннәр һөҗүменнән куркып, мылтык көпшәсенә беркетә идек), ракета ата торган корал, билдә – аккумуляторлы фонарь, җебе һәм элемтә өчен штеккер дигән нәрсәкәе булган (розеткалары агач төпләренә һәм ботак-чатакка тыгылган) телефон төребкәсе һәм тагын ниндидер киндердән тегелгән яман аты чыккан соры чик сакчысы япмасы (плащы), соңгысы шулкадәр дым сеңдерүчән, яңгыр явып үткәннән соң, ул күтәргесез авыр булып әверелә, әгәр егыла-нитә калсаң, теге заманнардагы, бөтен йөген өстенә аскан тәре йөртүче рыцарь кебек, үзең генә торып баса алуың икеле. Билгеле, хәзер барысы да үзгәргән – корал да, элемтә чаралары да, өс-баш киеме дә, әмма теге заманнарда, без хезмәт иткән чакта, нәкъ менә мин язганча иде.

Застава зур бер гаилә булып яши, бернинди «бабайлык» юк (аңлыйсыздыр, андагы сугышчы баштанаяк коралланган, димәк, ут белән уйнарга ярамый). Ябык чик буе зонасында кыргый кәҗә тәкәсен атып алабызмы, йә кабан дуңгызчыгын... «Хәтәр хәлләр төркеме»н чакырасың да ул үзенең «газиг»ында табышны кайтарып куя. Ә анда инде уртак казан, туганнарча табын, кайчак пилмән дә пешерәбез. Бер өстәл янында «атабыз» – застава башлыгы, Щербань дигән фамилияле майор белән утырабыз. Аның гаиләсе – нәни кызы Маша белән җәмәгате Марья Петровна да шунда яши. Старлей (өлкән лейтенант – башлыкның урынбасары) белән старшина шулай ук абыйларыбыз кебек – киң күңеллеләр, ярдәмчелләр, әмма хезмәт итү сәгатендә тиешенчә таләпчән, кырыс кешеләр.

Шулай яшәп ятабыз, атыбыз урамда булмагач, буранга исебез китми, кыскасы. Ә хезмәтебезне тел-теш тидермәслек итеп башкарабыз. Ул язда мине кече сержант дәрәҗәсенә күтәрделәр. Яшәү күңеллерәк, иркенрәк була башлады. Әмма армия – армия инде. Бигрәк тә безнең төрдәге, иң тәртипле һәм кырыс тормышлы гаскәрләр өчен таләп тә зуррак.

Укырга, үз эшең белән шөгыльләнергә вакыт күп калмый, шулай да зарланырлык түгел. Мин әле рәсем ясарга да өлгерә идем. Гадәттә дусларны кәгазьгә төшерәм. Шунысы кызык, безнең чакырылыш, нигездә, татарлар һәм белоруслардан тора иде. Полесья егетләренең теле матур: русча карлыгач ласточка булса, белорусча ул – ластовка. Кайсысы йомшаграк һәм нәфисрәк яңгырый?! Фамилияләре дә кызыклы: Виничек, Черёмуха, Ветла… Эшче этебезне йөртүче исә сержант Дубина иде. Бармактан суырып әйтүем түгел, менә шул караламалар салынган папканы ачтым да укып барам, ә аларга, минем рәсем-сурәтләремнең барысына да кемнең кем икәне язып куелган – исем-шәрифләре, хәрби дәрәҗәләре...

Бик үк күңелгә ятмаган чаклар да булгалый анысы. Бигрәк тә «атабыз»

яраткан чабышлар. Отрядтагы (чик сакчыларындагы бүленеш полк түгел, нәкъ менә отряд дип йөртелә) безнең застава беренчелекне бирми. Билгә хәтле чишенеп, итек кигән көе йөгерәбез. Дүрт чакрымны юырттырып узасы – бу – автобандагы күтәрмә киртәдән кире әйләнеп кайтканчы ара дигән сүз. Менә беркөнне чабам шулай, эссе, телем тиргә баткан иякка төшеп ябышты… Бетте, сулышым капты, хәзер егылам инде, дигәндә генә… кемдер аркамнан этә. Беләсезме, ничек хәл кертә бу?! Төртеп җибәрүгә, инде биш-алты адымны йөгермисең, ә очасың, аягыңдагы авыр итекләр шул мәлдә кайнар асфальтка ябышып калган, сине, ялан тәпиле малайны, калак сөягеңә үскән җиңел канатлар гына күтәреп бара. Борылып карасам – якташым, Яшел Үзән егете ефрейтор Вәгыйз Шакиров икән. Шулай итеп, мине, яңа гына табадан төшкән сержантны коткарды, хәтта чабышкыларның уртанчы төркеменә этеп кертте. Дөресен әйткәндә, марафон барыбызны да тигез күрә. Сержант, ефрейтор, гади солдат… нинди аерма булсын? Монда иң мөһиме: сулышың җитәрлек булу. Шәрә күкрәгеңдә дә аеру-дәрәҗә билгеләре юк лабаса.

Кичен утырып, бу хәлне кәгазьгә «сөйләдем». Гомумән, ефрейтор Вәгыйз Шакировның кем икәнлеген сурәтләдем. Ул бит әле атаклы фамилиядәше Илһам абый кебек матур җырлый да иде. Татарча, нәкъ безнеңчә: «Менәргә иде Урал тауларына!» – дип сузып җибәрсә, үзәкләрне өзә инде! Үзе әле бар эшкә дә маһир – балта остасы да, сантехник та ул, ни сорасалар, барысын булдыра. Безнең «коммуналка»да Вәгыйз һәркемгә кирәкле кеше. Кыскасы, язганыма исем тактым да «очерк» дип жанрын билгеләп, конвертка салып, якындагы элемтә бүлекчәсеннән Киевка, «Безнең чик сакчысы» дигән гәзиткә җибәрдем. Әле тушь белән үзем ясаган сурәтен дә өстәдем. Берәр көн чыкканын көтеп хыялландым да аннары көндәлек мәшәкатьләр белән әлеге хатым турында бөтенләй онытканмын.

Икенче көнне Вәгыйз белән икебезне күтәрмәле киртә янына сөт алырга җибәрделәр. Бу бик зур серебез иде: поляк фермеры Милош агай атнага ике тапкыр, автомобиль тәгәрмәченә утырткан ике урынлы арбасына туры атын җигеп, иртән иртүк безнең заставага яңа сауган сөт алып килә. Гадәттә, бу бер зур бидон була. Акчасын хуҗалар түли, безнең эш шул савытны «өйгә» алып кайтудан гыйбарәт. Шунысын гына әйтим: мондый тәмле сөтне минем гомеремдә дә бүтән татыганым булмады.

Яз канатын җәйде. Таллары да җырлап торган, кояшлы май ае иде. Каштаннар чәчәк аткан вакыт. Төннәрен өздереп сандугач сайравына йоклап китәр әмәл юк. Төн уртасында торып, саф һавага чыккан, еракта җемелдәшкән йолдызларга сихерләнеп карап торганым булды. Көмеш яктылык чайпалып түгелгән җирдә сулышлар иркенәеп китә, йөгәнсез хыяллар каядыр еракка дәшә, нииндидер сиземләү күңелне алгысыта... Ә нинди сиземләү? Соң, сиңа унсигез яшь булсын да борыныңа нинди исләр кермәсен!

Иртән мине Вәгыйз төрткәләп уятты, тиз генә битне, кулны суга чумырып алдык та «газик»ка тәпиләдек. Рульдә – заставадагы бердәнбер рус малае Вовка Абрамов, ул да Идел егете, Җигүле тауларыннан. Аның белән мин соңрак ныклап дуслаштым. Армиядән соң бер-беребезгә кунакка да йөрештек әле, озак кына хат алышып тордык, кызганыч ки, барысы да комга сеңгән су кебек югалды. Моңа гаҗәпләнергә дә кирәкмидер, аңлашылмаслык хәл түгел – дөньяда вакыттан да куәтлерәк хөкемдар юк, аның кануннарын берәү дә боза алмый. Кайда ул, кем икән ул хәзер? Шулай ук оста гына рәсем төшерә иде бит.

Сөйләшенгән урында пан Милош күренмәде, туры бахбай җигелгән арба белән күкләр көнләшерлек, аксыл чәчле бер кыз бик килештереп идарә итеп килә иде. Фәрештә инде үзе, калак сөягеннән бөркелеп чыккан ике канаты гына юк. Ул безнең аптырап калган йөзебезгә карап елмайды да туган телендә сәлам бирде:

– Дзень добры, панове![1]

Вәгыйз белән икәү, авызларыбызны ачып, күтәрмәле киртә артында торабыз шулай.

Ул ачыклык кертергә кирәк тапты:

– Әти бераз гына сырхаулап китте… – диде дә бәләкәй учы белән аяк очына сыенып торган дымлы бидонга суккалап алды. – Менә сезгә күчтәнәч – сөт!

Арабыздан беренче булып Вәгыйз аңына килде:

– Хәерле иртә, панна!

Аның артыннан мин дә уянган кебек булдым:

– Әтиегезгә ни булды, панночка?

– Тамагы шешкән, – дип җаваплады кыз. Аннары яртылаш урысча, яртылаш полякча тиз-тиз генә аңлатырга кереште: атасы май аенда һәр елны авырып ала, әмма егерме сигезенче майга кадәр һичшиксез терeләчәк икән:

– Ул көнне шьвиэто – бәйрәм бит!

– Әйе, бер атнадан зур шьвиэто булачак, – дип мин дә аның сүзләрен расладым. – Чик сакчылары көне!

Гадәткә кергәнчә, шул көнне без кичкә таба чикләрне ача идек, ул чакта безгә поляк чик сакчылары, якын-тирә авыл-торак кешеләре килә, табигый ки, Багратионовск каласы башлыгы да безнең белән, шулай бергәләп бәйрәм итәбез. Уртак концертлар, уеннар, биюләр оештырыла, безнеңчә әйткәндә, чын сабан туе башлана.

Кайсыбыз сорагандыр, хәтеремдә калмаган, панночканың исемен беләсебез килде.

– Иренка, – диде кыз.

– Иринадыр, мөгаен? – дип, төгәллек кертмәкче булдым мин.

– Нье-е[2], – дип, каршы килде ул һәм кабатлап әйтте: – Ире-э-энка.

Хәер, дөрес – поляк хатын-кызларының байтагы «ка» белән очлана торган исем-ат йөртә. Ул аларда кечерәйтү-назлау кушымчасы түгел. Шунда ук Анжелика, Генрика, Бланкалар искә төште… Әтиемнең эшендә Агнешка дигән хатын бар иде.

Без дә үзебез белән таныштырдык. Ул, беренче класс укучысы укытучы артыннан тәкрарлаган кебек, исемнәребезне кабатлады, бу эше яхшы гына барып чыккач, энҗедәй ак тешләрен күрсәтеп, көлеп җибәрде, көлүе шат, дулкын-дулкын булып чыга, вак ташлар өстеннән чишмә чылтырап аккан сыман иде.

Күтәрмәле киртә кырындагы оясыннан автомобильләр тикшерүдән бушап торган капэпэ хезмәткәре, Мамадыш егете Закиров кызыксынып, безне күзәтеп тора. Гимнастёркасының якасы чишелгән – әле бик иртә булуына карамастан, эссе, калкулык артындагы кояш аның «өйчег»енә турыдан-туры «бәрә», биектә керәшәләр әллә нинди тамгалар сызып маташа, көн бик матур булырга охшаган, алдан әйтүләренчә, май ахырына кадәр шулай буласы икән.

Мин кыздан: «Безнең бәйрәмдә буласыңмы соң?», – дип сорадым.

[1] Хәерле көн, әфәнделәр! *(пол.)*
[2] Юк *(пол.)*

– Та, натуралнье![3] – дип, сер итеп кенә, концертта бер җыр җырлаячагын да белгертеп куйды. Нинди җыр? «Анысын алдан ук әйтмим әле», – диде.

Җавап урынына авыр сулап кына куйдым, яшермим, күземне кызыйдан алуы кыен иде, әмма ни хәл итәсең. Вәгыйз белән икәү бидонны «кул»ларыннан тотып төшердек, Иренкага арбасын кайту юлына күчерергә булыштык. Ул дилбегәсен кагып кузгалып киткәндә, борылып, безгә кул болгады. Артыннан шактый озак карап тордык. Аннары бидонны тиз генә безнең «газик»ка күчереп утырттык, «ата»бызның беренче класста укучы кызы Машенька, мәктәпкә киткәнче, яңа сауган сөтне эчеп өлгерергә тиеш иде бит.

***

28 май иртәсендә чикне саклау нәрәтләреннән азат булган застава халкы, бик шәп итеп шәһәрчек буйлап марш атлап узды. Бәйрәм хөрмәтенә чик буе сакчылары Көнчыгыш Пруссияне яулаганда һәлак булган сугышчыларыбызга, шулай ук Багратионның мәһабәт сынына чәчәкләр салдылар. Ә мин инде, таң ату белән, бөтен коралларымны тагып, заставамның сул чигенә кадәр – өч чакрым, аннары – өч чакрым кирегә таба атлый идем.

Үзем күзгә күренер-күренмәс КСП (контроль-эз) сукмагыннан барам, ә үзем уйлыйм: Вәгыйз белән ул иртәдә сөткә барганда, ни булды икән соң?

Иренка шул көннән башлап башымнан, уй-фикерләремнән чыкмый, минем кояш үрелмәсендә нindiдер яңа тойгы туды. Әйтерсең лә кемдер касыгыма тондырган да, шул вакыттан бирле аңыма килә, сулыш ала алмыйм. Вәгыйздән сорамыйча түзә алмадым: сөткә барып кайтканнан соң, аның белән бер-бер хәл булмаганмы? Ул җилкәсен генә җыерды:

– Ә нәрсә булырга тиеш иде? Мин бер генә кружка сөт эчтем...

Артыгын нечкәләп тормадым. Димәк, минем белән генә нидер булган, күтәрмәле киртә янына барганчы күңелемә килгән нәрсәләр алдыма килгән булып чыга. «Кеше-амфибия» киносы исемә төште. Беляевның романын аңарчы да укыган идем, билгеле. Ләкин кино, корырак язылган китапка караганда – ул чакта миңа, үсмер егеткә – күңелемә уелып калырлык тәэсир итте. Гуттиэра гыйшык утында янган Ихтиандрдан: «Димәк, бу – бер күрүдә гашыйк булу дигән сүз?» – дип сорый. Тегесе исә сорауга каршы сорау белән җавап бирә: «Бүтән төрле мәхәббәт тә буламыни ул?»

Чынлап та, була микәнни? Беренче караш, мәхәббәт Алласы Амур аткан ук шикелле, йә туп-туры йөрәккә барып кадала, яисә – читкә очып китә. Икенче, өченче уклар инде кеше күңелен газаплау гына, ул чын ярату түгел, ничарадан бичара бергә яшәп торырга өндәү яки мәҗбүр итү генә. Ниһаять, мин үземне җавабын таба алмаган сораулар белән газаплаудан туктадым. Хәтерлим, нindiдер зур, бәхеткә илтә торган үзгәрешләр көтеп яши башладым. Алар озак көттермәделәр дә шикелле.

Ук-җәя белән генә коралланмаган яшь солдатны җавабы булмаган сораулар бер-ике минутка тынычлыкта калдырып торсалар да, инде икеләтә, өчләтә көч белән кабат ябырылалар иде. Кызык, килерме икән ул бәйрәмгә яки килмәс микән?

Заставага мин төш җиткәч кенә әйләнеп кайттым. Алдан күрәзә иткәннәренчә, көн кояшлы, чын-чынлап бәйрәмчә булып чыкты. Сәгатьләр буе йөрүдән, гимнастёрканың тыгыз якасыннан һәм Иренка белән күрешүдән

[3] Әйе, әлбәттә! *(пол.)*

күңелне кузгаткан гаҗәп хис-тойгылардан эссе иде миңа. Пешекче төшке ашка чакырды. Ашыйсым килми иде. Бары тик бер кружка салкын сөт кенә сорап алдым. Ашханәдән үземнең яшәү урыныма – икенче каттагы тумбочкалы караватыма күтәрелдем. Чиста яка эчлеге тегеп куйдым, гимнастёркамдагы төймәләрне, погондагы сержант тасмаларын рәтләдем, юындым-кырындым, итекләремне ялтыратып куйдым…

Бәйрәм сәгать өчтә борысларда, гимнастика божраларында ярышлар белән башланып китте. Майор Щербань үзе йөз метрга йөгерүчеләрне старт пистолеты белән «илһамландырды». Ярар, хет кросс йөгерергә мәҗбүр итмәде әле! Иң ахырдан ирекле көрәш булырга тиеш иде. Җиңүчеләр шәһәр хуҗасыннан һәм застава башлыгыннан бүләк алды, җанатарлар да тик утырмады – сызгырдылар, кул чаптылар…

Нәрәт үтәп кайтканлыктан, минем йөгермәскә дә, сикермәскә дә хакым бар иде… Бәйрәм шаукымына бирелгән застава буйлап, күзләрем белән бердәнбер кешене эзләп, мин әрле-бирле йөренгәләдем. Иренканы, әлбәттә – вәгъдә иткән иде бит… Ничек әйтте әле: «Әйе, натурально киләм», – диде. Кайда соң аның «натураль»леге?

Ул концерт башланыр алдыннан гына күренде. Аркам ягыннан килеп кечкенә учлары белән маңгаемны кысты: кем икәнемне беләсеңме, янәсе. Мин шунда ук әйтеп бирдем:

– Иренка!

Ул учларын бушатты, челтерәп аккан тавышы белән әкрен генә көлеп җибәрде... Җилкәсе өстендә гитараның кыллары тартылган озын тар өлеше тырпаеп тора иде.

– Ә Вәгыйз кайда? – дип сорады.

– Әнә ич ул, көрәшеп маташа, – дип җавап бирдем мин, кул тубы киртәсе янындагы аслыкка ымлап.

Иренка белән без, аның җиде кыллы дускаен уртага алып, каштан күләгәсендәге кечкенә эскәмиягә барып утырдык һәм якташымның, аслыкка сузылып ятса да, таза гәүдәле Гродно егете Виничикка барыбер бирешәсе килмәгәнен күзәтә башладык.

– Әтиең савыктымы? – дип сорадым мин.

– Нье[4], – дип җавап бирде кыз.

– Алайса, ялгызың гына килдең?

– Та[5]…

Мин гитара кылларына кагылып алдым:

– Димәк, җырлыйсың инде?

Ул ризалыгын белдереп елмайды:

– Әйе, җырлармын.

– Ә мин тәки гитарада уйнарга өйрәнә алмый калдым. Үсмер чагымда әти-әнидән шул «уенчык»ны алып бирүләрен сораган идем… Үземчә тырышкан да булдым, әмма «Чегән кызы»ннан ераграк китә алмадым.

Ул арада кызарынган-бүртенгән Вәгыйз килеп җитте. Аның көрәше ни белән беткәнен без күрми калдык. Сөлге белән сөртенә-сөртенә, якташым мыгырдап алды:

– Ул бит миннән ике тапкыр диярлек авыррак! Авырлык үлчәүләрен бүлгәләргә мөмкин булмаганмыни?!

[4] Юк *(пол.)*
[5] Әйе *(пол.)*

– Борчылма, – дип тынычландырырга тырыштым дустымны. – Син бик шәп көрәштең!

– Ә-әй! – дип ярсып әйтте ул. – Мин хәзер душ кереп чыгам.

Концертка кадәр вакыт бар иде әле. Иренка оештыручыларга күренеп-билгеләнеп килде дә, без күлгә, үрдәкләрне карарга киттек. Анда алар бәбкәләре белән ике оя. Соры чүрәкәйләр һәм муеннарында кар кебек ак якалары булган яшел башлы ата үрдәкләр. Алар шунда ук яныбызга йөзеп килделәр дә, үзләрен нишләптер ипи кисәге белән сыйларга ашыкмаган ак күлмәкле нечкәбил кыз белән гитараны мылтык кебек аркасына аскан солдат малайны күздән кичерә башладылар. Аларга күчтәнәч турында уйласам, ашханәгә кереп чыгасы булган ла бит…

Тиздән концертка чакыру көйләре яңгырый башлады, без мәйданда тактадан ясалган эскәмияләргә менеп кунакладык та тип-тигез сәхнәгә күзләребезне төбәдек.

Концерт менә дигән булып чыкты. Поляк чик сакчыларының хор белән җырлавын ялгыз җырчылар, биючеләр, шигырь сөйләүчеләр дәвам итте... Барысы да ихластан, яхшы һәм матур булды, әмма мине бигрәк тә, әлбәттә, якташым Вәгыйз Шакиров һәм Иренканың чыгышлары дулкынландырды. «Менәргә иде Урал тауларына!» көенең канатында илебезнең иң көнбатыш чигендәге каладан мин ерактагы кояш чыгышына, күңелемә якын Идел аръягына таба очтым. Туган телемдә җыр ишетү миңа күңел азыгы бирә, әйтерсең лә, үз ягым болыннарында аунап, рәхәтлек кичерә идем!

Иренканың җыры – шуның капма-каршысы, һичнинди дәрт тә, күтәренке рух та юк анда. Ул агач урындыкка утырып, гитарасын кочаклады, кичкә таба сафлана төшкән безнең застава, туган ягыныкын дияргә дә була – чиккә кадәр ике генә адым бит! – һавасын күкрәген тутырып сулады да, сусыл иреннәре арасыннан тыныч кына агымлы поляк җыры түгелде. Ул иркен һәм җиңел итеп, тавышында аз гына киеренкелек тә сиздермичә җырлый иде. Иренка, башын чак кына бер якка иеп, – бодай башаклары сыман чәч канатлары йөзен яртылаш каплаган көе, тар, сабыйларча ябык иңнәрен җыр агымына туры китереп, нечкә бармаклары белән гитараның көмештәй кылларын иркәләп-назлап аралаганда, – ә гитара аның кулларына буйсынып, аңа кушылып сыздырамы-сыздыра иде, – җырчы һәм гитара уртак җыр куенында иркәләнүче бер җан иясе булып яшәде бу мизгелләрдә. Ә кинәт иреккә чыгып, тулып ташучы чишмәдәй күңелемне күмгән җырны, Ходай хакы өчен әйтегезче, нинди сүзләр белән атарга мөмкин? Иренкага, аның сәләтен, йомшак, агымсу кебек тавышын тулысынча биләп алган, керпе энәләредәй чәч белән капланган баш түбәмнән алып солдат итеге кырган аяк табаннарыма кадәрге чиксез-ярларсыз тойгыларымны ничекләр аңлатып була?!

Славян телләре бер-берсенә охшаган, дисәләр дә, аның җырындагы күп кенә сүзләрне аңлап бетермәдем мин. Җыр – сер дип тикмәгә генә әйтмиләрдер, җыр – җыр инде ул, инглизчә, французча, итальянча булса да… Ул ниндидер сүз-мәгънәләрне аңлатырга дип түгел, җырчының күңел халәтен белдерергә дип туган, аның теле һәркемгә таныш, җырга бернинди тылмач кирәкми. Кайчак җырдагы чит ил сүзләрен аңлап җиткермәвемә сөенәм генә мин, чөнки бу – җаныңны кузгаткан көйгә үзең теләгәнне, шәхси тойгыларыңны салырга, ерактагы якын кешеңә тел белән әйтеп җиткерә алмаганны белдерергә мөмкинлек калдыра. Моңарчы, мәсәлән, поляк мәдәнияте белән әлләни таныш

түгел идем. Ну, Мицкевичны, Сенкевичны укыштырдым, Анджей Вайданы карадым, Чеслав Неманны тыңлаганым булды… Шуның белән шул бугай. Польша чигенә хезмәт итәргә җибәрерләр дә, анда күрше воеводстводагы панночкага гашыйк булырмын, дип кем уйлаган...

Иренкага барысын да уздырып, каты итеп кул чабучылар, әлбәттә, Вәгыйз белән мин идем. Якташтан хәмер исе килгәнен сизенеп:

– Син әле кай арада өлгердең? – дип кызыксындым.

– Пшеклар сыйлады.

Пшеклар дип без полякларны атый идек, чөнки аларның телендә «ш» авазы бик еш кабатлана.

– Чик сакчыларымы, әллә штатскийлармы?

– Чик сакчылары, – дип, гимнастика борыслары янында торган кечкенә төркемгә ишарәләп күрсәтте ул. – Аларга минем җырлавым бик тә ошаган икән. Ә бәлки сиңа да бераз йотып куяргадыр?

– Юк, рәхмәт, – дидем мин, шулай да үзем кызыксына калдым: – Нәрсә эчтегез соң?

– Полякныкын инде...

– Ничегрәк соң ул?

– Соң, аракының барысы да бер иш бит.

– Ә кабымлык бар идеме?

– Чын Краков тутырмасы…

Вәгыйз сүзен әйтеп бетерә алмады, Иренка килеп җитте, без аңа урын биреп, читкәрәк шуыштык, ул уртабызга кереп утырды. Бер-беребезне бүлдерә-бүлдерә, кызның җырлавын мактарга керештек, артыграк та кычкырып җибәрдек, ахрысы, арттан «ш-ш» дип, кисәтү ясадылар.

Сәхнәгә старшина чыкты. Аның төп мактанычы тыпырдап бию – «чечётка» инде. Күн итекләрен кояш чагылырдай итеп ялтыраткан, үзе дә ялт итеп тора, ул тагын – һәр төймәсе, каеш аелы, күкрәгендәге медале, чегәннекедәй кара күзләре, диимме...

Иренкадан, җырың ни турында иде, дип сорадым.

Ул, гадәттәгечә, җылы яклардан иртәрәк кайтып, оясын рәткә китергән һәм сөйгәнен көтә башлаган ата ләкләк хакында икән. Ана ләкләк кайтмый да кайтмый, ди.

– Ник?

– Давылга эләгеп, харап булган, – дип җавап бирде кыз.

– Күңелсез хәл.

– Бик тә.

Иренка, ара-тирә туган теленә – полякчага күчеп алгаласа да, русча яхшы гына сөйләшә. Мин искә алган ул елларда поляк мәктәпләрендә рус телен өйрәнү мәҗбүри иде әле.

Старшина биюен карагач, Иренка тиз-тиз җыена башлады:

– Өйгә кайтыр вакыт. Әти анда йеден – ялгызы, берүзе генә.

– Нишләп берүзе? Ә әниегез кайда? – дип сорадым мин.

– Әни Бартошицада, дзидек[6] янында.

– Бабайга ни булган?

– Аяклары сызлый... Аны әни карап тора.

Шулчак Вәгыйз бер-ике сүз кыстырып куйды:

[6] Бабай *(пол.)*

– Ләкләкләрең дә күңелне төшерде, Иренка, һәм гомумән...

– Хәзер тансы-мансы башлана бит! – дип, сүзне борырга маташып карадым мин. Әмма кунагыбыз үз дигәнен үзгәртергә җыенмый иде.

– Без сине озатабыз, – диде ефрейтор кырт кистереп.

– Добже[7], – диде кыз, икебезгә дә мөлаем караш ташлап.

Без автобан буйлап КПП тарафына киттек, ә артыбызда калган заставада музыка яңгырады – бию башланган иде. Якташым гитараны сак кына күтәреп китте, ә мин, юлдан читкәрәк чыгып, кыр чәчәкләреннән бер бәйләм җыйдым.

Кызларның, чәчәк дигәндә, һәрвакыт аһ итүенә гаҗәпләнеп туя алмыйм. Мин бик килештереп иелдем дә гөлләмәне гүзәл танышыбызга суздым, ә ул рәхмәт йөзеннән бераз чүкте, күлмәк итәкләрен як-якка җәеп, рәхәтләнеп көлеп җибәрде һәм төрле төстәге кыр чәчкәләрен күкрәгенә кысып, аларга йөзен яшергән булды.

Күтәрмәле киртә янында саубуллашкан чакта:

– Күрешербез әле! – дияргә онытмады.

– Әлбәттә, – дип җавап кайтарды Вәгыйз.

– Һичшиксез, – дип, мин дә аларның сүзләрен җөпләдем.

Заставада күңелле иде, мәйданда Багратионовск мәдәният йортыннан килгән вокаль-инструменталь ансамбль көйләре астында бәхетле парлар әйләнә. Бәйрәм әнә шулай дәвам итте. Вәгыйз учын учка шаулатып ышкыды да билендәге каешы астындагы гимнастёрканы төзәтеп куйды, күкрәген киерә төшеп:

– Киттек! – диде.

– Юк, миңа бит иртәнге биштә үк аяк өстендә булырга кирәк. Ял итим, бераз укып ятыйм...

Укып та, язып та булмады. «Без тагын кайда, ничек очрашырбыз икән?» – дигән уй гына миемне бораулап торды.

***

Ике көннән безне хәрәкәт итеп торучы мишеньнәргә төнге ату «уен»ына төяп киттеләр. Полигон шул тирәдә генә, Багратионовск янында иде. Хезмәттәгеләргә заставадан озакка китеп торырга ярамый бит, гәрчә анда нәрәтләр, застава буенча дежурда торучы, «шом салуны кисәтү» төркеме («тревожная группа» – армия термины), сакчы, берәр офицер яисә старшина калса да, бу – катгый таләп. Чик буе уставы шулай куша.

«Калаш»тан атканда, ике төп боерык, ике приказ бирелә: мишеньгә берәмләп яки тоташтан (очередьләр белән) атарга. Әле баскан яки яткан көе, тезләнеп ату шартлары да бар... Мин баштан ук тоташ ату вакытында икешәр патронны гына «өзеп» алырга өйрәндем. Ике ук бергә оча икән – бу инде очередь санала, димәк ки, ату санын арттырырга мөмкинлек кала. Вәгыйзнең менә алай килеп чыкмый, ике мәртәбә басу белән, «магазин»ы бөтенләй бушап кала. Һәммәсе дә «сөт»кә китә, чөнки мишеньгә беренче пулялар гына оча, калганнары исә – өскә яисә читкә.

Төнге ату – искиткеч матур күренеш! Анда бит трасса булып оча торган пулялар сиптерәсең. Мылтыгыңның тетәсенә басуың була, көпшәсеннән төрле төстәге ут көлтәләре бөркелә. Һәр пуляның юлы, синнән мишеньнең үзенә барып җиткәнче, яшел, кызыл сызык булып сузыла. Бердәнбер кыенлык

[7] Яхшы *(пол.)*

– урыннан-урынга чабып күчү генә. Бер сызыктан икенчесенә бар да ат. Караңгыда бит бу! Беребез, шулай йөгергәндә, ниндидер күзгә күренмәс чокырга басып, аягын сындырган иде.

Бу юлы андый бәла-каза, маҗаралар булмый калды. Мин «бишле»гә аттым, Вәгыйз – «канәгатьләнерлек» билгесенә. Күрәсезме, дөнья барысын да тигезли: ул шәбрәк йөгерә, мин – атуда уздырам, ул матур җырлый, мин – рәсем төшерәм, ул сантехника эшендә оста, мин әдәбиятны яхшырак беләм... Шулай бер-беребезне тулыландырып яшәдек, шулай дус булдык. Икебез бер вакытта дембельләштек[8]. Казанга кайткач, башта миңа кердек, ягъни әти-әнием өенә (мин әле аларда тора идем). Исән-имин кайтуыбызны билгеләп алгач, мин аны автобуска озатып куйдым, Вәгыйз үзенең Яшел Үзәненә кайтып китте.

…Атарга өйрәнү урыныннан без төн уртасы узгач кына кайттык. Дежурда торучы егет туктатып, иртәгә миңа баганалар буяу эше йөкләнгәнен әйтте. Аңлашыла, телеграфныкын түгел, ә чик баганаларын. Ул мине җилкәмнән кагып, көлемсерәде:

– Рәссам үз белгәне белән шөгыльләнергә – буярга тиеш, шулай түгелмени? – диде.

Чик баганасы – дәүләт кырыендагы инде иң соңгы тамга. Ул, без хезмәт иткәндә дә, хәзерге кебек үк, кызыл-яшел төстә, биеклеге ике метр, бетон нигезгә утыртылган иде. Өске, кызыл өлешендә – ил гербы төшерелгән тимер пластинка. Аның астында – багана саны. Каршысында, ун метрлап арада Польша баганасы, ул кызыл-ак төстә, матур эшләнгән. Аның кырларындагы тасмалар туры-яссы түгел, ә почмаклары белән өскә күтәрелгән. Шушы баганалар арасыннан дәүләт чиге үтә дә инде. Поляклар аны саклап мәшәкатьләнмиләр. «Ник, – диләр алар, сез саклагач, җитмәгәнмени?» Баганы төзәтәсе яисә буйыйсы булганда гына сәпидләренә утырып килеп җитәләр.

Багана буяу – сержант эше түгел-түгелен. Икенче яктан караганда, моны миннән шәбрәк итеп кем эшли ала? Буяу-пумалалар, сан төшерү өчен өлге-калыплар алып, санитар букчасына салдым да «шом салуны кисәтү» төркеме мине уң флангка илтеп ташлады, КСП, бүтән барлык киртәләр аша туп-туры тиешле багана төбенә үк чыгарды. Шул рәвешле Казаннан килгән сугышчы, буяу савытлары һәм телефон төребкәсе белән, илнең иң көнбатыш тарафында утырган чик баганасы белән бергә-бер калды. Тагын каешта штык-пычак болганып тора.

Бу баганадан мин инде үзем икенчесенә күчәргә тиеш идем. Эшкә керешкәндә, кояш җылы нурлары белән коендырып алды, кыскасы, һәммәсе дә тәртиптә булырга тиеш. Баганам кителмәгән-уелмаган, шуңа күрә аның белән тиз генә саубуллашып, икенчесенә таба кузгалдым, тик юлымны камыш һәм күрән-кыяк баскан чып-чын сазлык бүлде. Мин, мүкле түмгәкләргә баса-баса, сак кына бара башладым. Берсеннән икенчесенә сикерәм шулай. Ләкин тиздән бер аягым батып китте, ул арада итегем белән яшькелт «шулпа»ны «сосып алдым» һәм кирегә борылдым. Нишләргә, «шом салуны кисәтү» төркемен чакырырга да, бөтен киртәләр һәм КСП аша узып, кайту юлына чыгаргамы? Ялгызыма гына ярамый – чик буена җәелгән «комлык»ны бозарга мөмкин, әле бит сигнал чыбыклары да бар – шундый шау-гауга күтәреләчәк! Хәзер,

[8] Дембельләшү (армия телендә) – запаска чыгу. «Демобилизация» сүзеннән.

билгеле, барысы да бүтәнчә, әмма ул заманда ук техник сак чаралары шактый сизгер һәм матавыклы иде.

Мин сазламык аша поляклар ягыннан үтәргә карар кылдым. Аларның да, безнең яктан да чик сакчылары күренми, сазлык дигәнем ул хәтле зур түгел, шикләнмичә узып булыр кебек. Банкалар, пумалалар салган биштәремне әләктереп, максатыма – шактый еракта, сазлык артында кара-каршы тырпаешып торган баганаларга таба тиз-тиз атлап юл тоттым. Сүз уңаенда әйтим, полякныкы, кызыллы-аклысы матуррак күренә, ә безнең ярым яшел багана куаклыклар арасында югалып кала иде.

Һаваның болай тиз алышынуын минем моңарчы да, ул көннән соң да күргәнем булмады. Кайдандыр шәмәхә болытлар килеп чыгып, тирә-юньне кинәт кенә караңгылыкка чумдырды, яшен яшьни башлады, туплардан аткан гөрелте чыгарып, күк күкрәде, һәм ишеп яңгыр яварга тотынды. Мин инде корыдан, яр читеннән сазлыкның уртасына җитеп килә идем шикелле, ә анда яшеренеп яткан чоңгыллар бар икән, аларны әйләнеп үтәргә кирәк булды. Юлдан кире борылу гадәтем булмаганга, үҗәтләнеп, алга таба атлавымны дәвам иттем. Менә шунда башланды да инде…

Дөньясындагы бар нәрсәне – һава бозылуын да, бу нәрәт турында белдергән дежурны да «шом салуны кисәтү» төркемен чакырмаганга, үземне дә каһәрләп, юлымны дәвам итмәкче идем. Шаулап аккан яңгыр туктамады, чын-чынлап Ниагара шарлавыгына әверелгәнче, көчәйгәннән-көчәя генә барды. Өермәле җиле белән, ниһаять, мине аяктан екты. Әллә үзем генә таеп егылдыммы икән? Ни генә булмасын, мин бер чокырга тәгәрәп төштем, шунда аягым белән бәла килеп чыкты да. Электр суккан кебек авырту тубык сөягеннән бөтен гәүдәм буйлап таралды. Мин һәртөрле чир-авыртуларны авыр кичерәм. Йомшакмындыр, мөгаен. Менә дошманнар тотып җәзалый башласын әле, бөтен серләрне ачып бирәм – белгәнен дә, үзем белмәгәнен дә.

Ул арада теге чокыр бик тиз су белән тула башламасынмы! Мин, Идел егете, ниндидер мыскыллы чокырда батып үләргә тиеш, имеш! Ярга таба шуышам, әмма шуам да кире төшәм. Су инде билгә җиткәндә, тырышуым бушка китмәде, ниһаять, бу тозактан ычкынып котыла алдым.

Мин салкын сазламыкта йөзем белән сузылып, үз-үземне белештермичә, учларым белән битемне каплап, бер үк сүзне кабатлап яттым: «Ярый, мин түзем һәм үҗәт. Бу бәлане дә кичеп чыгарбыз әле!» Шунысы кызык: күп еллардан соң, хуҗам булган кеше кабинетына чакырып, мине сүкте: «Син чамадан тыш тискәре, дустым, акылга сыймаслык эш булса да, үзеңнекен итәсең!» Мин теге өермәне һәм яңгыр астында йөзем белән капланып яткан яшькелт сазламык суны искә төшереп: «Хак, ничек булганмын, шундый инде», – дидем.

...Ә яңгыр, инде бозга әверелеп, яварга кереште. Эре ак борчаклар, капланмаган муен тамырымны тишәрдәй булып, аркама чукыпмы-чукый. Ә фуражкам кайда соң? (Чик сакчыларында пилотка дигән нәрсә юк, бары тик фуражкалар гына. Кечкенә җиңел пилотка киеп йөрисе бик килә иде дә соң!) Як-ягымнан бутап карыйм – таба алмыйм. Мөгаен, чокырда калгандыр.

Ниһаять, күк кәнсәләрендә мине кызгандылар булса кирәк – рәхим-шәфкать күрсәтеп, бозны, көчле булса да, гадәти яңгыр душына алыштырдылар. Элеккечә үк, тирә-юнь яктырып-ялтырап торды, күкрәү гөрелтесе тынмады. Хәрәкәтсез ятып тору килешми иде, аягымның авыртуына түзеп, мин алга таба шуыштым. Бу мәхшәр күпме дәвам иткәндер, әйтүе кыен. «Mala-Malina» дигән язулы баганага барып төртелгәч, кинәт зиһенем ачылып киткәндәй булды.

«Мала-Малина», – дип кычкырып кабатладым. Ә инде үз алдыма: «Кирәк бит, әй, ниндидер поляк авылына кадәр шуышып килгәнмен!» – дип уйладым. Торып басмакчы булдым, әмма авырту аяктан алып бөтен гәүдәмә таралып, зиһенемне чуалтты. Шулай да белештерер-белештермәс шуышуымны дәвам иттем. Мине тагын шул бетмәс, үзеннән-үзе көч өстәп торган үҗәтлек алга таба этәрде.

Кайда сазлык, кайда чик, мин үзем кайда – һични аңлашылмый. Борыныңнан кала берни дә күреп булмый. Яңгыр пәрдәсе күзләрне томалаган. Дүрт аяклап алга таба барам. Туктап калырга ярамый. Туктасаң, йомшарып, йокыга китүең мөмкин, ә ул чакта – бетте баш. Мине хәзер, «Мала-Малина» белән саз арасын үтеп, чик баганаларына барып җитү уе гына били.

Ходайны көлдерәсең килсә, аңа иртәгәсе ниятләреңне генә сөйлә, диләр. Бер нәрсә ачык: мин мәгънәсез рәвештә адашканмын.

Давыл ничек башланса шулай көтмәгәндә тынды да куйды. Батарга торган кояш, нурларын төзәтеп, кабат яктырта башлады, күктә болыт әсәре юк, биектә әллә керәшәләр, әллә карчыгалар бөтерелә, күлдәвектә чыпчыклар коена… Мин, үрелеп, ялгыз имәнгә тотындым, аркам белән аның куәтле кәүсәсенә терәлдем – ял итеп алырга, зиһен җыярга, уңга-сулга карап, кайдалыгыңны чамаларга кирәк иде.

Менә яртылаш ятып, яртылаш утырып торам... Бер итекне салдым, икенчесен – булмады... Янәшәмнән генә ап-ак җилкәнле көймә узып бара, аһардан җиңел ак күлмәкле фәрештә төшә, яныма килеп, исемем белән эндәшә, җилкәмнән селкетә, күзләремне киңрәк ачсам – каршымда Иренка тора.

– Же с тобой?[9] – ул минем каршыма чүкте. – Үтенәм, әйтче?!

Йодрыкларым белән күзләремне уам – төшемме, өнемме соң бу? Иренканың кулына кагылам – кайнар, тере… Йокыга китмәгәнемне аңлап, кинәт балаларча ихластан, ышанып көлә башлыйм.

Иренка соравын кабатлый. Сөйләргә туры килә: чик баганаларын буярга җибәргәннәр иде, сазлыкка туры килеп, бер баганадан икенчесенә Польша ягыннан узарга уйладым, давыл башланды, аягымны авырттырдым, адаштым...

– Кайда мин?

– Миндә кунакта, Мала-Малинада, әнә калкулыктагы иң кырый йорт безнеке, – дип, нечкә бармагы белән яр читендәге әфлисун төсендәге түбәле кечкенә генә ак йортка күрсәтә ул. Ул чактагы хәлемне, «сугыш кыры»ннан мескен башымны ничек алып котылуымны, Иренканың туры атын җиккән ике урынлы йомшак тәгәрмәчле арбасы белән өенә алып кайтуын, итек балтырын кисеп, шешкән аягымны коткаруын сөйләп-тасвирлап тормыйм... Ул йөгереп кенә күршедәге табибны, үзләренең гаилә дустын чакырып кайтты. Абзыйның исем-шәрифе Кшиштоф икән. Ул минем шешеп чыккан тубык сөягемне карады, әмма диагноз куя алмады – сеңер тартылганмы, әллә урыныннан чыкканмы…

– Ачыктан-ачык сынмаган лабаса, – дип шаярткан булдым мин.

– Ходайга шөкер! – диде доктор. – Рентгеннан карарга иде. – Йомшак җиремә авыртуны баса торган укол кадады. – Бәлки, вакытлыча тугым куяргадыр?

– Кирәк түгел, – дидем. – Санчастьта барысын да эшләрләр.

Кояш ерактагы урман тарагына төшеп утырды, мин инде өйгә, заставама җыенган идем, Иренка кире күндерде. «Иртәгә иртүк күтәрмә киртә янына илтеп куям, берочтан сөт тә алып барырбыз, ә табиб әйтте бит, аягыңа ашыгыч

[9] Же с тобой? – *(полякча-русча)* сиңа ни булды?

ярдәм кирәкмәс», – диде. Мин хәлне «үлчәп» карадым: бер тәлинкәдә – «дезертирлыгым» һәм аның өчен аласы җәзам, икенчесендә – Иренка, аның белән хыялымдагы аралашу теләге, гәрчә соңгысына бик ышанып җитмәсәм дә... Шулай да икенче тәлинкә ягы басты.

– Теге чакта саубуллашканда, күрешәчәгебезне алдан күргәнсең, – дип, кызның исенә төшердем.

Аның күрәзәчелегеннән көлешеп алдык. «Әйе, хәзер көлке, – дип уйладым мин, – ә ахыры ни белән бетәр?» Миемне яндырып кара тамга узды, анысын яхшы хәтерлим, тик ул бары тик бер тапкыр гына булды, язмыш бүләк иткән әлеге очрашуларны мин бүтән авыр тойгылар белән ямьсезләмәдем. Ул да хаклы иде: ахыр чиктә мин гаепле түгел, давыл – форс-мажор арага керде.

Кичке ашны бакчада ашадык. Майның соңгы көне. Алмагачлардан әле дә булса эленеп калган чәчәкләр коела. Давылның эзе дә юк. Иренканың өе калкулыкта, монда инде күлдәвекләр җыелып ята алмый.

– Ә пан Милош кайда? – дип сорыйм.

– Һоспитальдә. Тән кызулыгы күтәрелде...

– Өстәвенә әле мин аягым белән…

– Ничего, – дип тынычландыра ул. – Тата[10] савыгыр, син дә аякка басарсың.

Акшар өстенә оҗмах кошлары төшерелгән, үрелеп үскән үләннәр арасындагы гаҗәеп чәчәкле, чирәп түбәле һәм өстенә ак ләкләкләр зур таҗ итеп оя корган биек кызыл кирпеч морҗалы бер катлы йорт нииндидер әкияти фильмга дип төзеп куелган сыман иде. Биек морҗа башындагы оя хуҗасы үзенең кара чабулы ак кәчтүме белән бөтен буена басып, башын чөйгән дә озын томшыгын гөрләтеп, янәшәсендәге мәгъшукасына тойгыларын аңлатыр өчен чак-чок килә. Төсле җепләр белән чигүле эскәтер ябылган, гадәти булмаган сый-нигъмәт, кабымлыклар тезелгән өстәл янындагы «кунак» исә яшь чибәр хуҗабикә канаты астында өй шәрабен татып хозурлык кичерә. Пан Кшиштоф ярдәме белән, аякның авыртуы да кимеде, җанга коеннан соң сафланып калган кыр-урманнарның барлык хуш исе тулды; абзардагы безнең бөтен заставаны сөт белән туендыручы сыерның күкрәктән чыккан калын тавышы колакны иркәләде. Мин пан Милошның иркен ак күлмәген һәм киндер ыштанын киеп (үз киемем кер бавында кибә), Иренкага сокланып утырам, дөнья – миңа гүзәллеккә туенган гаҗәеп тормыш, ә киләчәк тагын да гаҗәеброк һәм бәхетлерәк булырга тиеш, имеш. Салават күпере төсле матур һәм илһамлы халәтне бүтән һичкайчан да кичергәнем булмады. Чөнки миңа ул чакта нибары унсигез яшь иде, унсигез генә! Иренка миннән ярты яшькә кечерәк. Икебезнең дә күңеле саф, ниятләребез зурдан. Аның коңгырт-фирәзә күзләренә багам да үземне күкнең җиденче катындагы заттай хис итәм. Иренка яулыгы астыннан ургылып чыккан бодай башакларыдай толымын төзәтеп куя, нәрсәдер әйтә, ә мин, айгыр кебек кешнәп торган егет, гүя тоякларым белән кагам да берни ишетмим.

– Нәрсә? – дип кабатлыйм.

– Казан гдзие[11], молвлю[12], урнашкан? Мәскәүдән якынракмы?

– Юк, ераграк.

– Гдзие ераграк?

– Идел буенда.

[10] Әткәй *(пол.)*
[11] Кайда *(пол.)*
[12] Дип сорыйм *(пол.)*

– Ә-ә… – дип башын кага ул, аңлаганын белгертеп һәм кабат сораша: – Урысча: я тэбе люблю. Ә татарча ничек була?

– Мин сине яратам.

Ул көлә, кабатларга маташа, тик барып чыкмый. Күкрәгендә, күлмәк изүендә бәләкәй алтын тәрене күреп алам. Ул да минем шуңа игътибар итүемне сизә, кечкенә тәре шунда ук күздән югала, бары тар гына алтын чылбыр кала.

Җырлавын сорыйм.

– Нье, – ди, аннары өйдән гитарасын алып чыга, кичке томаннарда һәм төнгә каршы төшкән салкынча чыкларда күңелне кузгатырлык поляк җырлары агыла башлый. Мин инде тагын бер тапкыр аяктан егылам. Һушым китеп, аңа рәхмәт укыйм, ә сеңлем кебек итеп үбәргә – юк, кыюлыгым җитми.

Инде караңгы төшеп килә, ул террасадагы лампа яктысында уч кадәр генә кәгазь кисәгенә нәрсәдер яза да аны миңа суза.

– Бу ни бу?

– Минем адресым.

Тиз генә укыйм. Кыска сызыклар аша язылган, авыр әйтелешле воевода исеме, аннары – Мала-Малина. Бусы аңлашыла. Урам, йорт саны... Һәм имза: Иренка Игначёк.

Дүрткә матур гына бөкләп, кәгазьне күлмәкнең күкрәк кесәсенә салам.

Ул миңа тәрәзәләре бакчага караган кечкенә бер бүлмәгә урын җәйде. Ак диварларда – таныш булмаган кешеләрнең фотосурәтләре, агартылган мичтә йортның тышындагы кебек төрле төстәге бизәкләр. Ачык тәрәзәдән яшенле яңгырдан соң калган саф, чиста, озонлы һава өреп тора. Бакчада төрле тавышларга күчеп сандугачлар сайрый башлады... Йокы алмый. Күз алдымда Иренка тора, мин аңа кичтән әйтергә оялган сүзләремне сөйлим. Ишек артында аның шыпырт кына тегендә-монда йөргәнен, савыт-саба, чиләкләр шылтыратканын, ишегалдына чыкканын – аның нечкә иңнәренә йөкләнгән хуҗалык белән идарә иткәнен ишетеп ятам. Аннары, ничектер, чокырга чумган кебек бер мизгелдә йокыга талам.

Иртән агач урындыкта – мине чиста, әле генә үтүкләнгән солдат киеме, өстәлдә бер стакан яңа сауган сөт көтеп тора иде. Почмакта култык таяклары, бер итегем, галуш – анысы авырткан аягымадыр, һәм бер пакет – күрәсең, киселгән итек беләндер инде. Әйе, аягым, стенага үрмәләп менәрлек булып, яңадан сызларга тотынды.

Алты тулар-тулмастан Иренка кабат шул ук пан Кшиштоф белән бүлмәмә керде. Доктор аягымны карады, тагын бер тапкыр авыртуны баса торган укол кадады да инъекциянең көче дүрт сәгатькә җитәсен әйтте.

– Үзеңнекеләргә кайтып өлгерә аласың, – диде.

– Белмим, сезгә ничек рәхмәтемне әйтеп бетерә алырмын икән, пан Кшиштоф! – дидем мин.

Соңрак тормышымда күп кенә яхшы кешеләрне очратканым булды, әмма пан Кшиштоф сурәте түр башымда аерым торып калды.

Иртәнге ашка пешкән ике күкәй, ипи, май, кичәге пилмән (бәрәңге, эремчек, гөмбә белән) – ул аны бәлеш дип атый иде – һәм сөтле каһвә әзерләнгән иде. Бу юлы без верандада, түбәнлектәге томанга төренгән иксез-чиксез кырларга һәм чикнең теге ягында, ерактагы Русиядә чыгып килүче кояшка каршы утырдык.

Иренка-Иркәмә:

– Тиздән кояш бу якка күчә, ә мин – киресенчә, теге якка, – дидем.

– Кызганыч… – диде ул сабыр гына. – Може (бәлки), калырсың?

– Шаяртасыңмы?

– Шаяртам, натуральне[13].

– Шаяртуың кызганыч. Чынлап та калуымны теләгәнсеңдер, дип уйлаган идем.

– Чынлап торып телим, – дип, кайтаваз кебек җавап бирде ул.

Гашыйклар үзара сөйләшкәндә, читтән карап торучыга алар юкны бушка авыштыралардыр кебек тоела. Чынлыкта, аларның ни әйткәнен түгел, ә җырдагы ноталар кебек һәр сүзне бизәүче хисләрен, тавышларын тою-ишетү мөһим. Яхшы җырны сызгырырга да, борын астыннан сүзсез генә мырлап торырга да мөмкин.

Селкенергә кирәк иде. «Рәхмәт» дип, хуҗабикәнең яңагыннан үптем. Әйе, иртән кыюлыгым җитте, кичтән үбү иртәгесеннән аерыла бит. Ул сабыйларныкы шикелле саф һәм гөнаһсыз. Кыз күзләрен түбән төшереп, эскәтерне төзәтеп куйган булды да миңа үрелгән кулы белән бер пакет сузды:

– Сиңа күчтәнәч бу, на дрогу[14].

Мин пакетны ачып карадым, анда сөткә-майга изелгән күмәчләр, кәнфитләр, кечкенә бал банкасы, һәм «мулине» җепләре белән чигелгән кулъяулык бар иде.

Ничектер уңайсызланып калдым.

– Ал инде, ал, Вәгыйзеңне сыйларсың. – Ул өстәлне җыештыра башлады. – Хәзер сиңа карета бирәм.

Җыенып беткәч, мин шундый кыяфәттә идем: култык астымда таяклар, бер аягымда итек, икенчесе оек эчендә, – галушка сыярлык булмады. Банка, пумала белән букчам да, телефон төребкәм дә, фуражкам да юк – барысы югалган. Бары тик штык-пычак кына билдә. Соңгысы бик мөһим – солдатка коралын югалту килешми.

«Карета»га без өчәү сыйдык: Иренка-Иркәм, мин һәм шул ук пан Кшиштоф иртүк урнаштырып куйган сөт бидоны.

Туры ат, койрыгын болгый-болгый, тупларын сипкәләп, алдыбыздан бара.

– Исеме-аты ничек соң аның? – дип сорадым мин, атка ымлап. – Югыйсә танышмыйча да калабыз.

– Всход, – диде Иренка.

– Восход – Кояш чыгышы, димәк?

– Та… Тагын Востокның Көнчыгыш дигән мәгънәсе дә бар.

Юлның беренче өлешендә без туктаусыз тел яздырдык, ә чиккә җитәрәк, ничектер үзеннән-үзе тукталып калдык, икебезгә дә күңелсез булып китте. Киртә-шлагбаум күтәрелгән иде. Челтәрләр һәм кисәтүле юл тамгалары асылган киртә астыннан Польша ягына таба, туктала-туктала, җиңел машиналар ташкыны уза. Каршы якка таба автомобильләр юк иде. Күтәрмә киртә янында безне «йөкче»ләр – Вәгыйз Шакиров белән Черёмуха көтеп тора. Читтәрәк «газик» белән – Вовка Абрамов. Арбада култык таяклары белән коралланган пассажирны күреп:

– А-а, юлдан язган малай кайтып килә! – дип кычкырды Черёмуха. – Сине заставада особист – махсус хезмәт кешесе көтеп зарыкты.

Үте тулышкан хезмәттәштән аермалы буларак, Вәгыйз сөенечен яшермәде:

[13] Әйе, әлбәттә *(пол.)*
[14] Юлга *(пол.)*

– Кайттыңмы, дустым?! – Һәм миңа арбадан төшәргә булышты. – Мин инде нәрсә уйларга да белмәдем. Суга төшкән кебек югалдың бит! Тәүлек буе тының-башың булмады. Яшен аткан микән әллә, дип тә уйладык. «Шом салуны кисәтү» төркеме, сине эзләп, бөтен флангны айкап чыкты. Ярар, хет исән калгансың!

– Исән инде, исән, – дип, мөмкин булганча битараф кыяфәт белән әйттем дә капэпэ будкасы яныннан аксап-туксап үтәргә ашыктым. Егетләр арбадан сөтле бидонны алып, машинага илтеп куйдылар. Мин Иренкага таба борылдым, култык таякларын суздым: алып кит, янәсе. Ул арбада утырган көе көлеп җибәрде дә йөгереп килде:

– Күчтәнәчне оныткансың бит! – дип, кулыма теге пакетны төртте, аның еш-еш тибрәлгән аксыл керфекләре дымланган һәм кара-кучкылланып киткән иде. – Сау була күр, сержант!

– Сау бул, Иренка!

– Кайту белән яз, яме?

– Һичшиксез язармын!

Ул инде, күрәсең, мине заставада калдырмасларын чамалагандыр (билгеле, монда госпиталь дә, санчасть та юк бит), күтәрмә киртә янына сөт алырга бүтән килә алмасымны аңлагандыр...

Аннары Иренка-Иркәм көтмәгәндә, һич оялып тормыйча, мине кочып алды, кипшенгән иреннәремнән үпте дә кабат арбасы янына йөгерде.

– Ә култык таяклары… Култык таякларыңны ал инде!

– Әлегә үзеңдә калып торсын.

– Рәхмәт! – «Әлегә» дигәне миңа бигрәк тә ошады. Димәк, аларны кайтарасым була икән әле? Күрәсең, кабат очрашасыбыз бар? Авызыңа бал да май, Иренка-Иркәм.

***

Заставага кайту белән мин – «дезертир»дан иң элек аерым бүлек офицеры – кызларныкы кебек бәләкәй куллы, тар җилкәләренә яңа гына майор погоны таккан зур корсаклы адәм сорау алды. Аның «нигә-ни өчен?»нәрен санап тормыйм – берсенең дә кызыгы юк. Бары бер «сөйләшү» тармагы гына истә, аны биредә теркәп калдыру да кирәк дип саныйм. Майор алдында нindидер шпиун, агент-007 түгеллеген аңлап, шуңа күрә сүзне шактый сүлпән, кызыксынусыз гына башлады да бермәлне үзенең курчакныкы кебек учы белән өстәлгә шап итеп сукмасынмы:

– Сүзеңне күрше дәүләт кызы белән әш-мәш килүдән башлап җибәр әле!

– Әш-мәш килү түгел лә инде ул… – дип, акланырга маташтым мин.

– Йә, йә… – дип, авызын кыйшайтып көлгән булды ул. – Бәлки, мәхәббәттер, ә, тагын ни әйтәсең! Берәү шулай, поляк кызына мәхәббәте хакына Ватанын саткан. Атасы аны шуның өчен үз кулы белән атып үтергән.

Особист шактый белемле бәндә икән, ул кайчандыр «Тарас Бульба»ны да укыган, имеш, улын үтергән казак атаманы, аның уенча, һәрьяктан хаклы булып чыга.

– Сезнең Андрий Бульба турында әйтүегезме? – дип ачыклык кертергә маташтым мин.

– Тагын кем турында булсын!

– Ул бит, Тарас бабай бәянында да, карашымча, иң намуслы һәм матур образ. Панночка аның өчен ватан булган да инде.

– Барыгыз да бер иш, – дип нәтиҗә ясады майор. – Стенага терәп үк атмаслар, әмма чикне бозып качканың өчен тиешлесен алырсың...

– Ә мин беркая да качмадым.

– Шулай икән, ни булды соң?

– Өермә, ориентирларны югалту гына…

– Ориентир җәһәтеннән географик планда гына ялгышмагансың бит син! – дип төрттерде майор.

Хәрби тикшеренүченең тел төбен аңлый идем лә, һөнәре, эше шуңа тарта иде аның… Тик китап төягән кәгазь тартмам, минем кайчан югалуым һәм кабат кайтуым, Иренка турында барысын да ничек нечкәләп һәм вакытында белеп барган ул – шунысына гына төшенеп җитә алмадым …

Шул ук көнне, төшке аштан соң теге майор мине «газик»та Калининградка отряд штабына, хокук бозуым турында күрсәтүләрем алынган һәм кайсы губа[15]га ябасылары, кайсы трибуналга бирәселәре хәл ителәсе урынга җибәрде. Мине отряд командиры, полковник Суслов якларга маташты. Ул, башта «дезертир»ны дәваларга кирәк әле, диде. Мине штаб янында гына урнашкан санчастька җибәрделәр. Шул рәвешле берүзем санчастьнең икенче катындагы аерым палатага кереп яттым. Ишек төбендә күкрәгенә «калаш» аскан сакчы торып калды. Сыңар аяк белән кая кача алыйм инде, йә?! Җәрәхәтемнең диагнозы – балтыр белән табанны тоташтырган буынның тартылуы икән. Мине Худяков фамилияле лейтенант, хәрби табиб дәвалады. Аны искә төшереп әйтим инде: без, юк-бар сүзгә күчмичә генә уртак тел таптык. Палата ишеген ачуга ул шат тавыш белән шигырь сөйләргә тотынды:

Кавказның давыллы көннәре,
Шиллер, дан, мәхәббәт турында серләшик.

Ул минем янымда озаклап, матур темаларга күчә-күчә, гәп корып утыра иде. Хәтта бер кичне «Pliska» дигән болгар коньягы белән сыйлады. Ә бервакыт миңа таныш булмаган подполковник белән палатага керде дә миңа төртеп күрсәтте:

– Сез эзләгән кеше менә шул була, – диде.

– Яхшы, – дип җавап бирде аңа зур кунак.

Бу таза, нык бәдәнле, күкрәгенә фотоаппарат элгән ир-ат «Безнең чик сакчысы» дигән гәзитнең җаваплы сәркатибе Барсуков булып чыкты. Вәгыйз Шакиров турындагы язмамны басарга әзерләгәннәр, бүген булмаса, иртәгә чыгарга тиеш икән. Кунак абзый караватым янындагы урындыкка утырды да:

– Аяк ничегрәк? – дип сорады.

– Әйбәтләнеп бара, иптәш подполковник. Бездә менә дигән табиблар бит!

– Синең очеркың безгә ошады, – дип дәвам итте ул. – Безнең гәзит редакциясенә үзеңне сынап карарга, тәҗрибә тупларга килмисеңме соң?

– Мин бит хәрби җинаятьче, – дип моңсу гына көлемсерәп җавап бирдем. – Палата ишеге төбендәге сакчыны күрдегезме? Качмасын, дип саклыйлар.

– Ишеттем, ишеттем… Әмма анысы безнең эш, ачыклык кертербез, – дип, үзенең дәү учын минем кулыма салды. Аннары тормышым турында сораштырды: ата-анаң кемнәр? Рәсем ясарга кайда өйрәндең? Кем булырга хыялланасың?

Мин язучы булырга теләвемне, ә моның өчен журналист мәктәбен

[15] Губа (армия жаргоны) – гауптвахта («базга ябу»).

үтәргә кирәклеген әйттем. Казанга кайтып, университетның журналистика факультетына укырга керергә исәп бар, дидем. Булачак әдипләргә гәзиттә эшләп алу киңәшен Катаевтан укыган идем. Соңрак оялып та куйдым – әтәчләнеп, үземне язучы итеп күрсәтәм, имеш. Редакциядә чирканчык алудан, әлбәттә, баш тартмадым. Подполковник тиздән мине чакырасыларын әйтте… Саубуллашканда, тәрәзә янында күкрәктән генә алып, «агач» аякны кертмичә, рәсемгә төшерде, тизрәк савыгуымны теләде һәм зур итекләре белән идәнне шыгырдата-шыгырдата чыгып китте. Ярты сәгать тә үтмәгәндер, минем ишек төбеннән сакчыны алдылар. Аннары ниләр булды? Бөтенесе дә җайга салынды. Киев дигән данлы каланың Владимирская урамындагы редакциядә стажировка үтү, сроктан тыш хезмәттә калырга тәкъдим ясаулары, хәрбилектән дембельгә китү, туган шәһәремдәге университетта уку, яшьләр гәзитендә эшләп алу һ.б., һ.б.

Ә Иренка-Иркәмә биргән сүземне үтәдем мин. Санитар частьтә шул ук кичне турыдан-туры әйтә алмаган сүзләремнең барысын да тезеп, озын хат яздым. Хәтта аңа багышлап кечкенә генә шигырь дә яздым һәм күкрәгенә гитара күтәргән, калак сөякләреннән канат үсеп чыккан фәрештәкәй итеп рәсемен дә ясаган булдым. Эзләдем-эзләдем дә исемә төште, аның адресы язылган, дүрткә бөкләнгән кәгазьне пан Милошның ак күлмәге кесәсендә калдырганмын. Яшереп куйдым да оныткканмын.

Ул заманнардан соң ничәмә-ничә ел үткән! Мин инде күптән өйләнгән кеше, балаларым үсеп җитте, оныклар йөгерешеп йөри... Әмма Иренка-Иркәм әле дә булса тынычлыкта калдырмый, көндез күз алдыма килә, төнлә төшләремә керә: имештер, мин давылдан соң зур ябалдашлы имән төбендә утырам икән дә, ул килеп сорый: «Нишләп хат язмадың, армиядән соң ник безгә кайтмадың? Әллә заставадан китү белән оныттыңмы?»

Юк, Иренка-Иркәм, онытмадым сине. Аһ, хәтер түремдә ничек кенә саклыйм әле! Бодай башаклары кебек толымнарыңны, якты, фирәзәдәй күз карашларыңны, йомшак кына «та» белән назлы «нье»ңны, гитарага кушылып яки ансыз гына челтерәп аккан тавышыңны... Тик, армия хезмәтемне тутыргач, ник синең яныңа бармавым турындагы соравыңа гына җавап бирә алмыйм. Ни җавап бирерлек, ни акланырлык чарам юк, хәтта шуны аңлатырлык хәлдә дә түгелмен.

Менә шундый тарих-мажаралар булган иде минем тормышымда. Ул хакта элегрәк берәүгә дә сөйләмәдем. Эч серем итеп саклап йөрттем... Ә менә хәзер язу өстәлем янына утыргач, көтмәгәндә генә барысы да ургылып чыкты. Күңелгә ничектер тынычрак булып китте. Чөнки сиңа текәлеп карап, игътибар белән тыңлап торучы әңгәмәдәш – ул бит шул мәлдә каләмең тияр-тимәс торган ак-саф кәгазь бите.

**Мөдәррис ВӘЛИЕВ** *тәрҗемәсе.*

*Гөләндәм Исрафил кызы Галиева 1976 елның 5 сентябрендә Кукмара районының Төркәш авылында туган. Татар дәүләт гуманитар институтының татар филологиясе бүлеген тәмамлагач, Аксубай гимназиясендә балаларга белем бирә. Биредә ул мөгаллимлек итүдән тыш, фәнни-методик эш белән дә шөгыльләнә: аның «Туган як материалларына нигезләнеп төзелгән дидактик күнегүләр җыентыгы» (2010) исемле методик кулланмасы ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан хуплау таба һәм күпләп бастырылып, төбәк укучыларына таратыла.*

*2012 елда гаиләсе белән Түбән Камага күченә, биредә дә укытуны дәвам итә. Хәзерге вакытта Түбән Кама муниципаль районы хакимияте рәсми сайты мөхәррире.*

*«Тәүге адымнар», «Күңел төлгәшләре» исемле җыентыклар авторы.*



Гөләндәм
Галиева

# МИН ЯРАТАМ СИНЕ, ӘЙ, ТОРМЫШ...

## Якты хатирә

Мич алдында әнкәй коймак туглый,
Йөзләрендә – учак шәүләсе.
Ак яулыгы, алсу алъяпмасы –
Нурда йөзә бөтен гәүдәсе.

Изге догаларын укый-укый
Коймак туглый... Чыжлый табасы...
Өйдә рәхәт... Җылы... Шул халәттә
Гомерлеккә килә каласы!..

Тәлинкәдә тимгел-тимгел коймак,
Өстәлләрнең тора түрендә!
Авызларда эрер, ул тәмнәре,
Ул исләре һаман күңелдә!..

...Үткәннәрнең якты хатирәсе
Яши шулай җанны җылытып:
Мич алдында әнкәй коймак туглый,
Дөньяларны тоташ нур итеп!..

## Язучы

Төн ача зәңгәсу пәрдәсен,
Офыкта ал нурлар кызара.
Таңгача тәрәздә ут яна –
Кемнең соң йөрәге сызлана?

Ак кәгазь битендә вак эзләр
Мәрҗәннәр тезелгән дисбе күк.
Көн туа... Чакыра үзенә,
Ә сүзләр? Ә сүзләр шундый күп.

Күңеле төседәй кәгазьдән
Каурый каләме йөгерә.
Йомгагы түгәрәк, җебе нык,
Чуалтмый, ничек тә өлгерә!

Һичкайчан хатага хакы юк,
Халкының өмете аңарда.
Яклыйсын якларга, саклыйсын
Сакларга тиеш ул дөньяда.

Тәңредән йөкләнгән зур бурыч –
Һәркемне иманга өндәргә.
Күтәрмәс Алып та бу йөкне,
Ул бара күтәреп иңнәрдә.

## Хәерхаһ бул...

Ак тау күкрәгенә башын куеп,
Авыл талган татлы йокыга.
Тирә-як тын. Бары инеш кенә
Бәке-күздән моңлы җыр суза...

Челтер-челтер... Саф көмештәй тавыш...
Шыгыр... Шыгыр – итек тавышым.
Айлы төндә айлы сукмак буйлап,
Су буена төшеп барышым.

Бит алмасын кыш салкыны үбә,
Керфекләрем буйый ап-акка!
Шаяртмачы әле, Суык бабай,
Хисләр кайнар – сыймый кочакка!

Су юлында ялгыз басып торам...
Йолдызларга багам. Галәмгә...
Бар җиһанны кочагыма алып,
Җылытасым килә бу мәлдә!..

Күкләр ярып, кычкырасым килә:
«Мин яратам сине, әй, Тормыш!»
Туар таңга кулларымны болгыйм,
Хәерхаһ бул миңа, и Язмыш!

***

Кичә генә әле җәйләр иде.
Ә күңелләр – назлы күбәләк.
Аллы-гөлле болыннарны гизде,
Чәчәкләрне сөйде иркәләп.

Маңгаемны туң тәрәзгә терәп,
Басып торам... Уйлар гәпләшә
(Буран дулый тышта): бүген – буран...
Кичә җәйләр иде, ләбаса!

Җәй челләсе котып салкынына
Әйләнер дип кемнәр уйлаган!..
Кышын болыннардан чәчәк җыя
Бары мәхәббәтен җуймаган...

Буран дулый хәтәр усалланып,
Әйтерсең лә, безгә үпкәләп.
Тәрәз аша алсу гөлләр күзләп,
Тыпырчына хәлсез күбәләк...

***

Ул
Кырык толым үреп
Ефәк чәчен,
Дала буйлап чапты...
Иңнәренә салган ак яулыгын
Кылганнарга япты...

Аяз күңеле аяз күкләр күзләп,
Офыкларга бакты.
Күктә болыт иде:
Яңгыр  катыш
Күз яшьләре акты...

Каты камыл өтте табаннарын,
Итәгенә сырганаклар сарды.
Туктамады... Үҗәтләнеп бары
Сукмак ярып барды...
Һаман барды...

Ачы җилләр
Нәзек иңнәреннән
Әй, какты ла, какты.
Ышык күренмәде. Җылы да юк...
Тик өмете – якты!

...Туктатмагыз, чапсын...
Хыялына – аяз күкләренә
Беркөн җитәр әле.
Җилләре дә сөеп, назлап исәр,
Яңгыры да үтеп китәр әле...

***

Беркөн... Хәтереңнең саллы киштәсен
Дымлы чүпрәк белән сөрткәндә,
Кинәт... Күзләреңне кисәр бер ут күреп,
Син сискәнмә, яме, сискәнмә!..

Исеңә ал ерак яшьлек кичен,
Исеңә ал җәйге болынны.
Иңнәреңә синең башын салган,
Бары син дип янган сылуны...

Синең өчен ул Күкләргә ашып,
Йолдыз булып Җиргә атылды.
Сискәнмәче... Әле дә булса яна
Шул йолдызның ядкәр ярчыгы...

# ГӨЛӘНДӘМ ГАЛИЕВА ШИГЫРЬЛӘРЕ

Гөләндәм Галиеваның «Мин яратам сине, әй, Тормыш...» циклына туплап бирелгән шигырьләренә яңгыраш ягыннан көйлелек, ягъни ритмның (шул исәптән эчке ритмның) саклануы; рифмаларның нигездә уңышлы табылуы ярдәмендә хасил булган төзеклек; кичерешләрнең ачык-гадилеге хас. Табигый сәләт, зәвык, матурлыкны күрә һәм күрсәтә белү, һичшиксез, шагыйрь-язучы өчен мөһим сыйфатлардан.

Шул ук вакытта Михаил Храпченконың сәләттән талантка кадәрге бүленеш баскычларын искә төшереп, бу шигырьләрнең «беренче планда» – ягъни язылуга классик әсәрләргә әйләнеп, дәреслекләргә, әдәбият тарихына кереп китәрлек булмавын әйтеп, нинди сыйфатлар җитешми, дигән сорауга җавап эзләп карыйсы килә.

Беренче шигырь – «Якты хатирә» – әниле, якты, җылы, коймаклы балачакны искә төшерү. Беренче тезмәдәге образ җиткерергә теләгән хис-тәэсирне тулысы белән колачлап ала: «Мич алдында әнкәй коймак туглый». 1, 2, 3 строфаларда ул төгәлләшә бара. Иҗат таләбе буенча, 4 нче строфа йә тирән фикер, йә көтелмәгән образ белән шушы күренешне төгәлләп куярга, яңа биеклеккә күтәрергә, аңлатырга ... тиеш. Чөнки әнкәйләргә, мич алдында коймак туглауга йөзләрчә шигырь багышланган! Ул хатирәгә кагылган иҗатчының шулардан аермалы үз индивидуальлеген күрсәтә алуы шарт!

Әмма боларның берсе дә юк! Хатирәнең күңелдә яшәвен кабатлау гына әлеге күренешне бәяли, шәрехли алмый *(«...Үткәннәрнең якты хатирәсе / Яши шулай җанны җылытып: / Мич алдында әнкәй коймак туглый, / Дөньяларны тоташ нур итеп!..»)*. Аңа салына башлаган фикер төенен – хатирәнең бүгенгене җылытуын үстереп алып китәсе килә! Соңгы строфаның, шигырьне йомгакларга тиешле югары аккордның табылмаганын тагын бер кат раслагандай, дүртенче строфада рифма да (җылытып / нур итеп) ясалмарак. Нәтиҗәдә текст – йомгакланмаган, әдәби әсәргә әйләнмәгән булып чыга!

Икенче шигырь иҗат темасына – «Язучы» дип атала. Җитешсезлек беренче тексттагыга тәңгәл.Тапталган эчтәлек, ул матур итеп җиткерелә. Шуны зур фикер белән йомгаклап куярга вакыт җиткәч кенә, фикер җебе өзелеп кала.

Соңгы строфаны җентекләбрәк карыйк: *«Тәңредән йөкләнгән зур бурыч – / Һәркемне иманга өндәргә. / Күтәрмәс Алып та бу йөкне, / Ул бара күтәреп иңнәрдә»*.

Шагыйрьлекнең – илаһи чыганагы, язучының Тәңре һәм кешеләр арадашчысы булуы турындагы фикер урта гасырлар романтизмыннан ук килә, Мөхәммәдьярда ук бик ачык әйтелгән. Аннан соң романтизм көчәйгән чорларда һәрдаим искә төшерелә. Өндәү фигыленең иман белән янәшә кулланылуы кабат дини әдәбиятка якынайта: чөнки дөньяви әдәбиятта инде иҗатчы яхшылыкка, яктылыкка... өндәргә тиешлеге күрсәтелә. Аннары, иманга өндәү – дин әһелләре эше дә бит әле!

Шуннан соң килә торган ике тезмә генә бүгенге дөньяда язучының урынын, миссиясен, вазифасын аңлату өчен җитәрлек түгел. Иманга өндәү авыр, мифологик юнәлешле образ (Алып) бу авырлыкны күрсәтер өчен кертелгән. Әмма шушы урында фикер җебе киселә.

Өченче шигырь пейзаж лирикасына карый. Шулай ук матур табигать сурәте. Образ итеп ясап бетерергә мөмкин булган үзенчәлекле, әмма өзелеп калган табигать-кеше янәшәлеге: *«Челтер-челтер... Саф көмештәй тавыш.../ Шыгыр... Шыгыр – итек тавышым»*. Табигать һәм кеше – беркайчан да тынмый, туктамый торган хәрәкәт! Матур сынландырулар («Бит алмасын кыш салкыны үбә» һ.б.), чиктән тыш арттыру хисләрнең иң югары чиккә җитүе *(«Бар җиһанны кочагыма алып, / Җылытасым килә бу мәлдә!.. »)*. Һәм иң ахырдан – берни белән дә дәлилләнми торган ике риторик эндәш: *«Күкләр ярып, кычкырасым килә: / «Мин яратам сине, әй, Тормыш!» / Туар таңга кулларымны болгыйм, / Хәерхаһ бул миңа, и Язмыш!»*.

Алар ясалма, мең кат кабатланган. Эчтәлек ягыннан бер-берсенә якынлык, соңгы юлларның логик бәйләнешне өзүе (әле генә тормышка мөрәҗәгать иткән лирик герой инде язмышка ялвара) аларның шигырьне йомгаклап куя алмагач, рифмага җайлаштырып кына табылган кебек тәэсир калдыра.

Циклдагы «Өзелде муенсам», «Кыр казы» кебек текстлар турында да шушы ук гомуми бәяне кабатларга мөмкин. Ачык, гади аңлатылган хисләр иң югары ноктага күтәреләләр дә өзелеп калалар. Бу язу рәвешен сайлаганда, аларны көтелмәгән көчле фикер белән йомгакларга кирәк икәнлеген тагын бер кат искәртик.

Фикер җитмәү кайчак көтелмәгән каршылыклы нәтиҗәләргә китерә. Әйтик, «Ак кәгазьгә тама хисләрем» дигән, иҗатка багышланган шигырьнең соңгы строфасындагы гомерем иҗат белән бәйләнгән дип белдерү генә – каләмгә тотынуның сәбәбен дә, иҗатчының әйтергә-җиткерергә теләгән хис-кичерешен дә үзенә сыйдырмаган, тупламаган. Чын шагыйрьгә – миңа сәләт бирелгән, мин шигырь язам дип игълан итү кирәк булырмы? Яки чын шагыйрь илһамга-иҗатка: «Аерылсам синнән, нишләрмен?» дип эндәшә аламы? Чөнки иҗат – сәләт бирелгәннәр өчен табигый халәт, бу кешенең «һава суламасам, нишләрмен» дип эндәшкәне кебегрәк яңгырый.

Шул ук вакытта иҗатчының башкарак характердагы – әйтелеп бетмәгәнлек күзәтелгән текстларының сыйфат ягыннан югарырак булуын күрсәтергә кирәк. Исемсез шигырьдә («Кичә генә әле җәйләр иде...») беренче һәм соңгы тезмәләргә яшеренгән күңел-күбәләк янәшәлеге шундый тәэсир уята. Әлеге кичерешнең сәбәбе – гомер узумы, әллә ниндидер башка күренешме икәнлеге ачыкланмау текстта сер хасил итә, шул серлелек кабат укырга, сәбәпне эзләп карарга этәрә.

Тагын бер исемсез шигырьдә («Ул кырык толым үреп...») билгесезлек башта «кырык толым үрүченең» табигатьме, лирик героинямы, әллә, гомумән, адәм баласымы булуын әйтеп бетермәүдән туа. Бу очракта да текст яңача яңгырый, кызыксындыра.

Көтелмәгән сурәт-образлылык – шулай ук шигырьдә һәрчак отышлы, гаҗәпләндерергә дә, туктап уйланырга да мәҗбүр итүче сыйфат. Бу иҗатчы шигырьләрендә дә моңа аерып игътибар итәргә кирәк. Менә дүртьюллык «Язга авышу»:

*Чүлмәк авып, түгелепләр киткән,*
*Җир өсләре гүя ак каймак!..*
*Мич башыннан сикереп төшеп килә –*
*Март песие алырмы ялап?!*

Шәп сурәт, ул текстны, соңгы тезмәдә эчке ритм сакланмауга карамастан, яхшы шигырьгә әйләндерә.

«Кышкы мизгел»дәге табигать сурәтенең матурлыгы да тәэсир итәрлек. Бу сурәткә артык аңлатма соралмый да. Шуңа да «мәңгелек мизгел» фразасы уйланып бетерелмәгән сурәт булып тоела, аны дөреслисе килә: чөнки алогизм буларак ул урынлы түгел.

Исемсез шигырьдәге башлап җибәргән «Хәтереңнең саллы киштәсен дымлы чүпрәк белән сөрткәндә» юлларындагы сурәт шулай ук күңелне әләктереп ала. Әмма шушы көчле образ аннары мәхәббәтне саклamaган өчен үкенергә чакырган текстка әйләнеп китә.

Әлбәттә, тәкъдим ителгән текстлар турында сөйләшүне башлап җибәргән мизгелгә әйләнеп кайтсак, чыннан да, шигырьләр – укыла, алардагы кичерешләр аңлаешлы, сүзләр уңышлы сайланган. Әмма – фикердә яки образлылыкта яңалык юк: бик матур булган әлеге тезмәләр 1960 еллардагы халык иҗатына якынайган романтик поэзиябезне хәтерләтә. Шул дәрәҗәдә ки: фамилиясе куелмаган очракта, кайбер текстларны билгеле башка бер шагыйрьнеке, дип тә уйларга мөмкин.

Бу очракта безнең сүзебез, нигездә, иҗатчы үз алдына куя торган максатларга кагыладыр. Дусларга бүләк итәрлек, гаилә ядкаре булырлык, газета-журналларда бастырырлык шигырьләр инде бар. «Олы әдәбият» мәйданында яңгырар өчен өйрәнергә, эзләнергә, үз юлыңны-сукмагыңны табарга кирәк.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*



*Язучылар берлеге ихатасында «Идел» редакциясе. Журналның беренче саны чыгу уңаеннан төшерелгән фото. 1989 ел, июль.*




*Баш мөхәррир Римзил Вәлиев беренче сан чыкканнан соң махсус ялланган катерда Иделдә ял итәбез дигән вәгъдәсен үтәгән.*



*Редколлегия утырышы. 1996 ел, февраль.*



*Редакция коллективы бакчада. 2000 нче ел тирәсе.*



*«Идел» халыкара яшьләр лагеренда татар яшьләре көннәре «Идел» журналының шефлык ярдәме белән үтә. 1990 ел, июнь.*



*«Идел» кызлары. 1989 ел.*

*Фотолар* **Римзил ВӘЛИЕВ, Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА** *архивыннан алынды.*



Гөлшат Дәүләтбаева

# ЭНҖЕ

хикәя

Район хастаханәсендә чиктән тыш җанлылык. Шәфкать туташлары, табиблар тыз-быз чабыша, тегесен чакыра, монысын куа. Шкафларны, стеналарны юып-чистарталар, авыруларның урын-җирен алыштыралар. Нәрсә булган соң боларга?

Бүген иртә белән баш табиб Закир Каюмовичка каладан шалтыраттылар: имеш, алар районына Сәламәтлек саклау министрлыгыннан тикшерү белән киләчәкләр икән. Алмаш-тилмәш итүләр булачак, кыскартулар көтелә, ди.

Шушы хәбәрдән генә купкан гарасат иде бу. Алып гәүдәле баш табиб та хәйран селкенде бүген. Бөтен җирдә чисталык урнаштырылып беткәч кенә, тышта машина тавышы ишетелде.

– Килделәр, – дип, Закир Каюмович йомшак урыныннан сикереп торды. – Барыгыз да үз урыннарыгызга!..

Район хастаханәсенең капкасы шыгырдап ачылды. Аннан зур-зур корсаклы, пеләш башлы хуҗалар килеп керде. Баш табиб алар алдында иелә-бөгелә генә йөрде. Тикшермәгән җирне калдырмадылар. Ахырдан канәгатьлек белдереп, ашханәгә кереп киттеләр. Ә алар артыннан яшьрәге баш табибны читкәрәк дәшеп:

– Закир Каюмович, сездә берәр урын юкмы? – дип сорады.

Көтелмәгән бу сораудан баш табиб аптырап калды.

– Ни… Әлегә урын юк иде шул… Тик, сез сорагач…

Яшь хуҗа серле генә әйтеп куйды:

– Табарга иде берәр урын... Минем хатын – шәфкать туташы. Әле генә укуын бетерде. Эшкә урнаштырырга иде...

Закир Каюмович моның тел төбен сизеп, баш какты. Тегеләр киткәч, ул үзенә тынгылык тапмады. Аны халык акыллы, әйбәт табиб дип белә. Дөрес, үз танышларын урнаштырганы булды аның, әмма бу хәл… Кем урынына куяр соң ул яңа кешене? Эшләп яткан кешене тик торганда чыгарып җибәреп булмый бит инде. Нишләргә? Пенсия яшендәге медсестралар да бар-барын. Тик алар хастаханәнең терәге шул, йөрәге. Алардан башка нишлисең, ди?! Штат тулган бит!..

Энҗе медицина көллиятенә бер дә шәфкать туташы булам, дип түгел, ә диплом өчен генә укырга кергән иде. Укып бетергәч, теләгән эше табылыр, дип уйлады. Тик тормыш син уйлаганча гына бармый икән шул.

Соңгы курста укыганда, кыз бер егет белән танышты. Яхшы гына йөреп киттеләр. Илгиз кызны ярата иде бугай, кем әйтмешли, кулында гына йөртте. Машинасы белән китереп куя, килеп ала. Иптәш кызлары да аларның туен көтәләр

иде инде. Тик кыз ашыкмады. Ярата алмады ул бу егетне. Кайвакытта үзен орышып та ташлый. Нигә шушы күркәм, чибәр, акыллы кешене тиң итми икән йөрәге? Үзе бай, үзе чибәр, тагын ни кирәк?! Илгиз зур урында эшли, бүләкләрне ташып кына тора. Тик йөрәккә боерып буламыни? Дөрес, Илгиз командировкаларга киткәндә, юксынып та куя. Тик бу ияләнгәнгә генә иде шул.

Диплом алгач, кыз кая эшкә керергә, дип уйлана башлады. Монда да Илгиз булышты:

– Мин сине менә дигән урынга урнаштырам, – диде.

«Алар тикшерү белән барасы районда эш булырга тиеш. Булмаса да, тырышырга кирәк. Закир Каюмович аңа урын табып куячак, дип сөйләшенгән. Юкса үзе дә урыныннан колак кагачак». Менә шундый уйлар бөтерелде Илгизнең башында. Ул беркөнне кызга кулын һәм йөрәген тәкъдим итте. Энҗе бу гашыйк егетне рәнҗетүдән куркып, риза булды. Тора башлагач, яратырмын, дип уйлады. Тик бер ел эшләгәннән соң гына кияүгә чыгу шартын куйды. Ә Илгиз исә Энҗене иптәшләренә, танышларына хатыным, дип таныштырды. Үзенә дә хатын, дип дәшә башлады. Энҗе генә шәһәрдән, авыллыгы чыгып бетмәгән районга кайтырга теләмәде. Ләкин бер елга ничек тә чыдарга булды…

***

Рәшит авылда туып үсте. Туганда ук җиргә, авылга кендеге береккән иде, ул шәһәргә китмәде. Унынчы сыйныфны тәмамлауга, тракторга утырды. Тракторын яшь бала урынына күрә ул. Бер генә җире ватылса да, көне-төне казына. Классташлары югары уку йортларына кергәндә дә, кул гына селтәде. Дөрес, укытучылар әзерли торган училищега керергә җыенган иде, ләкин имтиханнар тапшырылгач качып кайтты. Сагынган иде ул авылын, аның кырларын, басуларын. Шәһәрдә боларның берсе дә юк. Анда таш та стена. Ә авылда… Юк, барыбер аңлый алмас шәһәр кешеләре авыл халкының хисләрен, уйларын.

Шулай итеп, Рәшит авылда калды. Болай эшләве бер яктан әйбәт тә, чөнки авылда нигезгә барыбер кеше кирәк. Ике апасы читтә кияүдә, олы абыйсы шәһәрдә өйләнде. Ул кайтмаячак та, шәһәрләшеп беткән. Ә Рәшит калды. Инде ничә ел тракторда эшли. Яхшы эшли. Колхоз рәисе дә, авыл халкы да канәгать аннан. Тик менә әти-әнисе генә картайды. Беркөнне, кич белән, ашап утырганда әнисе сүз башлады.

– Улым, без картаеп барабыз. Синең дә яшең җиткән. Әллә өйләнәсеңме?

Рәшит авызындагы ипигә тончыга язды.

– И әни, кызлар булса, өйләнер идем. Юк бит алар.

– Ник, әнә күрше кызы Әлфия… Сыер сава бит.

– Яратмыйм мин аны.

– Без дә килен кадерен белеп калыр идек, улым.

– Әни, егерме биш кенә бит әле миңа. Бу яшьтә әле…

Ул әйтеп бетермәде, уйга калды. Әнисенә карады. Әйе, картайган әнисе. Маңгаенда, күз төпләрендә җыерчыклары тагын да арткан. Их, өйләнер иде ул! Күңеленә ошаган кыз гына очрамый. Очрасамы, бер дә уйламый алып кайтыр иде.

Әлфия дә, Рәшит кебек үк авыл баласы. Әти-әнисенә бер кыз булганга, шәһәргә күчми калды. Хәзер инде фермада сыер сава. Ул Рәшиттән бер сыйныфка кечерәк. Бергә укырга йөрделәр. Аерылмас дуслар булдылар.

Рәшит клубка йөрергә яратмый иде. Әмма беркөнне иптәш егетенең туган көнен үткәргәч, өйгә генә сыешмыйча, урам әйләнделәр. Моңарчы салырга яратмаган егет ул көнне хәйран гына төшергән иде. Алар клубка кергәндә, кызлар ду китереп биеп яталар. Керүгә үк, егетләр кыз сайлый башладылар. Рәшитнең күзе Әлфиягә төште. Ул кичне Рәшит кызны җибәрмәде. Клуб бикләнгәч, озатып куярга булды. Тик урамга чыккач, салкын һава аны айнытты. Ул ни әйтергә дә

белмәде. Кыз белән сөйләшер сүзе дә бетте. Капка төбенә кайтып җиткәч, Рәшит Әлфиянең күзенә карады. Кызның күзләре яшь белән тулган иде. Шунда гына ул кызның йөрәген алгысытканын, иләсләндергәнен аңлады. Әмма соң иде инде. Егет Әлфияне кочаклап үпте дә китеп китте. Яратмый шул ул бу кызны. Дөресрәге, бер кызны да яратмый.

Шул көннән башлап, Әлфия нигәдер моңсуланып калды. Чая, кыю кызның сүлпәнләнүенә берәү дә аптырамады. Уку белән мавыгадыр, дип уйладылар. Әмма кызның күңелендә бөтенләй икенче хисләр иде. Ул Рәшиткә гашыйк. Авылда да шуның өчен генә калды. Рәшит узган сукмактан йөрергә, аның тирәсендәрәк булырга тырышты. Егетнең үзенә карата салкын икәнлеген дә белде, әмма барыбер яратты. Өметен дә өзмәде. Рәшит уру-сугу вакытларында өйгә соң кайта. Ә Әлфия аның ата-анасына ярдәмгә ашыга иде, әле суларын китерә, әле сыерларын сава. Тик егетнең күңеле аңа карап кына иләсләнмәде, ул аны сеңлесе кебек күрде…

***

Район хастаханәсендә көндәгечә ыгы-зыгы. Көн җылы, матур булгач, авырулар барысы да диярлек урамда. Аягында йөри алганнар бакчада сәйран кылып йөри, коляскадагылары җылы кояшка бит терәп утыра. Бер читтә ирләр домино суга. Шунда барысы да капка ачылганга борылып карадылар. Аннан яшь, чибәр кыз кереп килә иде. Ул барысы белән дә исәнләшеп, кереп китте.

Авырулар тынып калды. Бераздан:

– Ай-яй! Кем булды бу? Нинди кош икән? – дигән сүзләр яңгырый башлады.

– Яшь шәфкать туташыдыр әле, – диде берсе.

– Берәрсенең хәлен белергә килгәндер, – дип куйды икенчесе.

Алар шулай юраганда, кыз баш табиб бүлмәсенә юнәлде. Ә Закир Каюмович бу вакытта телефоннан кем беләндер кызып-кызып тарткалаша иде. Ишектән керүчене күргәч, телефонга:

– Бүген үк, ишеттегезме? – дип кычкырды да трубканы куйды. Аннан: – Ни йомыш? – дип сорады ул, кызга күз йөртеп чыккач.

– Мине Илгиз… Илгиз Ренатович җибәрде, – диде кыз һәм ирнең карашын күтәрә алмыйча, күзләрен түбән төшерде.

Баш табибның төсләре үк үзгәреп китте, моны ишеткәч.

– Илгиз Ренатович? Сез… аның хатыны бит?

Кыз көлеп куйды.

– Булачак…

– Димәк, сезгә эш кирәк…

«Чибәр, каһәр, – дип уйлады табиб эченнән генә, – мондый шәфкать туташы больницаның яме генә булыр иде. Кара син аның битенә, пешкән алма бит, ә күзләре… Билләре өзелеп тора, халат кияр өчен генә яратылган, диярсең...»

Килеп туган тынлык кызның эчен пошыра иде. Ул ашыгып, баш табибка карады. Тегесе аны аңлагандай, торып басты да:

– Урын шушы атнада булырга тора. Бер-ике көннән килә алмассыз микән? – диде. Ә үзе: «Ычкындырмаска иде моны!» – дип уйлап өлгерде.

Кыз китәргә борылды.

– Исемегезне кем дип белик?

Закир Каюмович ашыгып сорау бирде. Әйтерсең, бу кош хәзер очып китәр дә кем икәнен дә белмичә калырлар.

– Энҗе… Энҗе Хәлиловна. Хушыгыз.

Энҗе чыгып китте. Ошамады аңа баш табиб. Әмма хастаханә матур, яңа. Коридорлары да киң, якты. Чыгуга аны өлкән шәфкать туташы күреп алды.

– Сеңлем, син бездә яңа кеше мәллә?

– Мин… мин эш эзләп килгән идем…

– Юкмыни?

– Булырга тиеш. Бер-ике көннән килергә куштылар.

– Мин Рәсимә апаң булырмын. Бергә-бергә эшләрбез... Кайда кунасың инде син?

Менә монысын уйламаган иде Энҗе, аптырап калды.

– Борчылма, әйдә үземә. Мин ерак тормыйм.

– Әллә ничек, уңайсыз да инде…

– Нинди уңайсызлану булсын, ди. Әйдә, әйдә…

Чыннан да, бу шәфкать туташы ерак тормый икән. Чатны борылуга ук аның өе иде. Килеп җитүгә үк кыз аптырап калды. Аларның өе агачлар арасыннан күренми дә иде, тирә-ягын яшеллек баскан. Ишегалдында да чәчәк тә куак кына. Энҗенең аптырап та, сокланып та карап торуын күргәч, Рәсимә горурланып:

– Моны кызым белән ирем үстерә. Икесе дә ботаник. Әле өй эчен күрсәң син! – диде.

Чыннан да, тәрәзә төбе саен гөл иде аларның.

Өйдә кеше юк иде. Иркенләп чәй эчтеләр. Рәсимә Энҗе турында сорашты. Аның ире дә, балалары да көтелмәгән кунакка ачык йөз белән карадылар. Энҗе дә кунакчыл хуҗалар белән бик тиз уртак тел тапты…

Берничә көннән Энҗе яңадан бәхетен сынап карарга теләп, шифаханәгә юнәлде. Бу юлы аны баш табиб елмаеп каршы алды.

– Әйдүк, рәхим итегез!

– Закир Каюмович…

– Әйе, Энҗе… Хәлиловна. Урын әзер. Иртәгәдән үк эшкә керешегез. Ә бүген хезмәттәшләрегез белән танышып чыга аласыз.

Шулчак кабинетка Рәсимә килеп керде. Кулындагы мөһерле кәгазьдән, йөзендәге кара болыттан, ни булганын аңлавы кыен түгел иде аның.

– Закир Каюмович! Нәрсә соң бу? Нигә?

Баш табиб бу шәфкать туташының тагын да ныграк ярсынуыннан куркып, әйтеп калырга ашыкты.

– Рәсимә ханым, сезгә инде пенсиягә чыгарга вакыт. Аннары сезнең урынга кеше дә бар.

Энҗе хәлне хәзер генә төшенеп, сүзгә кушылды.

– Закир Каюмович! Ничек? Мине Рәсимә апа урынына куясызмыни? Аны урыныннан алып… – Кыз елап җибәрде: – Нинди гаделсезлек? Мин монда кеше тормышын бозарга килмәдем бит!

Энҗе чыгарга омтылды. Рәсимә аны тотып калды.

– Кызым, Закир Каюмович дөрес әйтә, мин инде үз урынымны яшьләргә бирергә тиешмен. Син эшлә, тырышып эшлә…

– Юк, Рәсимә апа, мин болай эшли алмам. Мин башка җиргә китәм, – дип карышса да, Энҗене тыңламады ул, чыгып китте.

***

Кайтканда, Рәсимәнең уйлары буталды. Шулай итеп, ул да лаеклы ялга чыгар микәнни? Дөрес, ире дә, кызлары да аңа бу хакта күптәннән әйтеп киләләр иде. Тик алар чын шәфкать туташының йөрәген аңлыйлармы соң? Эшен ярата бит ул! Бер көн эшкә бармаса да, үзенә урын таба алмый иде. Ә хәзер калган бөтен гомерен эшсез үткәрергә тиеш. Тик нигә шулай кинәт кенә, көтмәгәндә? Рәсимә, дүрт малайдан соң туган, көтеп алынган кыз иде. Тик кызны тапкач, әнисе авырып китте. Гаиләдә бердәнбер кыз бала булгач, бар эш аның җилкәсенә өелде. Кечкенәдән үк кул астына керде, эшне җимертеп эшләргә өйрәнде. Ә әнисенең хәле бер дә яхшырмады. Киресенчә, көннән-көн начарланды гына. Шунда кыз үзенә сүз бирде: үсеп кенә җитсен, табиб булып, әнисен дәвалаячак ул. Әнисен дә шулай юатты. Тик әнисе генә көтмәде аның үсеп җиткәнен. Әмма кыз үзенең

вәгъдәсенә тап төшермәде. Урта мәктәпне тәмамлауга, шәфкать туташлары әзерли торган училищега керде. Уку җинел бирелде. Аны өмет канатландырды. Хыялын барыбер тормышка ашырачак! Укып бетерүгә, аны шушы районга җибәрделәр. Менә инде ничәнче ел шунда эшли ул. Дөресрәге, эшләде. Бөтен гомере шунда узды. Менә хәзер шул яраткан эшеннән аерылырга тиеш. Рәсимә уфтанып куйды: «Нишлисең, вакыт җиткәндер, күрәсең, – дип уйлады ул, – яшьләргә дә эш кирәк бит».

***

Ә Энҗе һич кенә тынычлана алмый иде. Ул баш табиб белән сүзгә килде.

– Мин сездән мондый хәл көтмәгән идем, – диде ул, ярсып. – Мин китәм!

– Энҗе Хәлиловна, аңлагыз! Шушы гына сезнең урыныгыз. Бүтән җирдә урын булмас!

Кыз теләсә дә, теләмәсә дә ризалашты. Кичкә табарак Рәсимә, берни дә булмагандай, аны үзләренә алып китте. Берничә ай кыз шунда яшәргә тиеш иде. Шулай итеп, штатта яңа кеше барлыкка килде. Баш табиб мондый кошны очырмаганга куанды, эчендәге сөенечкә түзә алмыйча, кулларын ышкып куйды. Барыбер үзенекен итте бит! Менә шулай! Әмма чибәр дә соң бу Энҗе, Илгиз Ренатович белеп сайлаган!..

Энҗе хезмәттәшләре белән тиз дуслашты. Табиблар да, шәфкать туташлары да бу оялчан, тыйнак кызны яраттылар. Ә авырулар мондый ягымлы, йомшак куллы туташка мөкиббән иделәр. Күбесе аңа бер күрүдә үк гашыйк булды. Кыюраклары инде аңа йөрәген тәкъдим итте. Тик Энҗе генә аларны берсен дә рәнҗетмәскә тырышып, баш тартты. Бүтән бу горур кызга сүз катмадылар, тик эчтән генә янып-көючеләр күп булды. Ә кыз нидер көтте, бәхетенең якында гына йөрүен сизенде.

Закир Каюмович баш табиб та, хирург та иде. Энҗене күбрәк үзенә ассистентлыкка ала башлады. Яшь туташ та аңа ияләште. Бик күндәм, акыллы, һәр сүзне хәзер эләктереп ала, кыскасы, операция вакытларында ул бик кирәкле кешегә әверелде.

Әмма баш табиб моның өчен генә үз итмәде кызны. Күзе төште аның. Дөрес, мәхәббәт түгел, ә яшисен яшәгән күңелнең яшь тәнгә тартылуы иде бу. Беркөнне Закир Каюмович бу турыда кызга да сиздерде. Энҗе йомыш белән кергән иде. Кыз шкафтан кирәкле кәгазьләр эзләп маташканда, врач аның җилкәсенә кулын салды. Энҗе сискәнеп китте.

– Энҗе Хәлиловна, сез бит минем аркада гына эш таптыгыз. Так что, сез миңа тиеш…

Кыз аңлап алды. Әмма төрттереп куйды:

– Ничек аңларга кушасыз бу сүзне? Сезгә Илгиз Ренатович кушты бит, эшләмәгән булсагыз... – диде дә кабинеттан чыгып китте. Кайчан үтәр соң бу ел? Ичмаса, башка җиргә китәр иде. Туйды ул бу табибның ач күзләреннән. Шул көннән башлап, баш табиб аның белән саграк кылана башлады. Бары күзләре белән ашардай булып кына кала иде…

***

...Хастаханәгә авыр хәлдәге кешене керттеләр. Бите-тәне пешкән егеттә җан әсәре дә калмаган иде. Китергән көнне үк аңа операция булды. Аннан соң ул Энҗе карамагына тапшырылды.

Кыз егетне үз туганыдай карады. Ә авыру һаман аңына килмәде. Энҗе ниләр генә эшләмәде, уколлар кадады, дарулар эчерде. Беркөнне пульсын тикшереп утырганда, егетнең күз кабаклары селкенде. Һәм ул күзләрен ачты. Энҗе аны күрде дә имәнеп китте. Егетнең күзләре чем-кара. Керфексез, кашсыз булсалар да, упкын

кебек төпкә тарта. Кыз дерелдәп куйды. Хәрәкәтсез гәүдәдә шушы карлыгандай күзләр генә тере һәм алар ниндидер бер җылылык бөрки иде.

Егет яныннан чыгып киткәч тә, кызның күңелендә шул күзләр калды. Һаман-һаман шул упкынга батасы килде. Ул бу егетне аякка бастырырга тагын да күбрәк көчен куя башлады. Аның җылы мөнәсәбәтен тоеп, авыру да савыга башлады. Пешкән тиреләре кубып төшеп, яшь баланыкыдай яңа тире үсте, йөзе түгәрәкләнеп китте. Янган чәчләре урынына тагын чем-кара чәчләр чыга башлады. Ә күзләре тагын да ялкынланыбрак җемелди иде. Тик сөйләшә генә алмады егет. Моны табиблар шоктан соң, дип аңлаттылар. Энҗе бирешмәде. Әле сөйләште аның белән, әле җырлап йоклатты. Егеткә көненә икешәр мәртәбә массаж ясый башлады. Инде егет аягына да басты, әмма теле генә ачылмады. Нәрсә кирәген ишарәләр белән аңлатып, табиблар белән аралашты…

***

Көннәр бик кызу иде. Яңгыр инде атналап яумый. Бөтен яшеллек саргаеп кипте, җир ярылды. Дөрес, уракка төшәр өчен көннәр әйбәт, әмма шул ук вакытта куркыныч та.

Кырда барлыгы биш кенә комбайн. Икесе күрше авылда. Калган өчесе Рәшитләрдә. Комбайнчылар арасында Рәшит иң яше, башкалар инде тәҗрибәле, олы яшьтәге ирләр һәм оста тәмәке тартучылар. Бригадирлары, уру вакытында тартмаска, дигән иде, әмма тәмәкечеләр аның сүзен, таш диварга борчак ату кебек кенә кабул иттеләр.

Бүген дә адым саен туктап, тәмәке тартып, ял итте алар. Бер Рәшит кенә бурычын яхшылап үти иде. Әмма ул да кеше бит, ял итеп алырга булды. Комбайны белән басуны аркылыга әйләнеп чыкты да, чишмәгә су эчәргә төшеп китте. Ярый әле, чишмә якын гына. Юкса, мондый көндә кибеп үләрсең.

Рәшит чишмә буендагы яшел үләнгә җәелеп кенә яткан иде, борынына төтен исе килеп керде. Ул сикереп торды. Тау башына йөгереп менгәндә, бер комбайн янып ята иде. Ә тегеләр нишләргә дә белмичә, аның тирәсендә йөгерешәләр. Рәшит үз-үзен белештермичә, утка ташланды. Башында бер генә уй: «Игенгә якын җибәрмәскә!» Кинәт аңа ут көлтәсе ябырылды, калганын ул хәтерләми.

Шифаханәдә аңына килгәндә, ул янында утырган яшь, матур шәфкать туташын күреп, аптырап калды, үзен фәрештә янында, дип хис итте. Кыздан бу турыда сорарга, дип авызын ачкан иде, теле әйләнмәде, тавышы чыкмады. Кызның йөзе, йомшак куллары егетнең хәтеренә сеңеп калды.

Шул минуттан ул бу туташны гел көтеп ала торган булды. Ул аңа укол кадаганда да, бәхет күгендә йөзгәндәй тоела иде…

Егетнең сөйләшмәве Энҗенең эчен пошыра. Ул беркөнне өзгәләнеп әйтеп куйды:

– Нигә эндәшмисең соң син? Мине җәзалама болай! Синең белән сөйләшәсем килә минем!

Шунда ниндидер могҗиза булды. Егет күзләрен ачты да кызның кулларын тотып:

– Энҗе… – диде.

Кыз аптырап калды. Мондый көтелмәгән сөенечтән йөзен каплап чыгып йөгерде. Үзе елый, үзе көлә иде. Бераздан башка табибларны да ияртеп килеп керде. Бар да сөенә иде, егетне тагын да сөйләштерергә телиләр. Ә Энҗе бер читтә егеттән күзен дә алмыйча басып торды.

Баш табиб шушы авыруны терелткән өчен мактау сүзләрен ишетәчәк иде, шуңа күрә, ул да сөенде. Бары тик:

– Терел, егет, хәзер барысы да синнән генә тора, – дип чыгып китте.

Энҗе, гадәттәгечә, егетнең хәлен белергә дип палатага керде. Башка авыруларны карап чыккач, Рәшит янына барып утырды.

– Хәлең ничек? – дип сорады ул.

Егет кызга кап-кара күзләрен тутырып карап торды да:

– Энҗе… Сезгә ничек кенә рәхмәтемне әйтим. Сез бит мине терелттегез. Ярым үле кешене. Рәхмәт сезгә… – диде.

Аның тавышы калтыранды. Энҗегә рәхәт тә, кыен да иде бу сүзләрне ишетү. Күп ишетте инде мондый сүзләрне, әмма монысы – бөтенләй башкача шул, көтеп алынганы. Энҗенең йөрәген ут айкады. Колаклары шаулады, дөнья алсу чәчәккә төренгән кебек тоелды. «Мин сине яратам!» диясе килде аның, әмма теле иkenчесен әйтте.

– Терелгәч сөйләшербез.

Ни хикмәт, тавышы коры, салкын чыкты. Ул кулларын тартып алды да тиз генә чыгып китте. Палатада йөрәге торып калган кебек иде. Ярсуын басарга теләп, су эчеп алды да көндәлек эшләргә күчте…

Инде ярты еллап вакыт узды. Энҗе элегрәк ел ахырын түземсезлек белән көтсә, хәзер китәсе дә килми. Рәшит терелеп, чыгып китте, ул көнне Энҗенең ялы иде, шуңа күрә сөйләшә алмый калдылар. Ә бит сүзләр күп иде. Энҗе көннән-көн күңелсезләнә бара. Күзләрен тәрәзәдән алмый. Нәрсә көтә ул? Кемне? Рәшитнедер инде. Тик аның бу хастаханәдә эше беткән шул. Авырмаганда, нигә килеп йөрсен инде…Чү, кем тавышы бу?

– Энҗе…

Кыз сискәнеп, борылып карады – алдында Илгиз басып тора иде. Ул өметенең акланмавыннан үксеп елап җибәрде. Ә тегесе бу елауны үзен сагыну, дип аңлады, күрәсең, елмаеп, Энҗене кочагына алды.

– Сагындыңмы?

Кыз дәшмәде. Ул эченнән генә үзенең мәхәббәтен – Рәшитне каргый иде.

– Мин сине шундый сагындым… Тагын ярты елдан, Алла боерса… Минем инде көтәрлек хәлем дә калмады.

Егет сандугач кебек сайрый. Ә кызның уенда Рәшит. Кайда икән ул хәзер?

– Чыгасыңмы миңа? – дигән сорау аны айнытып җибәрде.

Күзләрен тутырып, Илгизгә карады.

– Йә, елама инде. Берәр нәрсә булмагандыр бит?

– Мин сиңа чыкмыйм, Илгиз… Гафу ит, ярата алмадым…

Күптәннән әйтергә җыенган сүзләре теленнән ычкынгач, Энҗегә җиңел булып китте. Ул Илгизнең кочагыннан ычкынып, тәрәзә янына килде һәм имәнеп китте. Ишектән Рәшит кереп килә иде. Кыз нидер буласын сизенеп, куркып калды. Ул арада Рәшит керде дә:

– Энҗе бөртегем! – дип, кызны кочаклап та алды.

Илгизне ул шунда гына күрде. Ә тегесе дәфтәр битедәй ап-ак булган иде.

– Аңладым мин сине, Энҗе, – дип көчкә телен әйләндереп әйтте дә кырт борылып чыгып китте. Машинасына таба барганда: «Ничек болай булды соң әле бу? Менә бит ялгыз калдырып йөрсәң, ничек килеп чыга икән. Нигә аны сайлаган соң Энҗе? Нигә Илгизне түгел? Нәрсәне дөрес эшләмәдем соң мин?!..» – дип үзен-үзе битәрләде ул...

*«Татарстан. Тарих. Шәхесләр»*
*әдәби очерклар конкурсы*

# РӘСЕМЛЕ ЯЗМЫШ

ОЧЕРК

## Сәйдәшнең кул җылысы

Менә ул – тулы бер чорны сыйдырган остаханә. Башта чолан аша үтәсе, шунда пәлтә-плащыңны салып калдырасы. Түр як белән бәләкәй чоланны чаршау аера. Акрын гына ачып җибәрәсең, ә анда... Картиналар түгел, идәннән түшәмгә кадәр китаплар белән шыплап тулган киштә. Бу китапларның һәрберсе Зәфәр Гыймаевның кул җылысын саклый. Бер почмакта значоклар белән чуарланган вымпел. Түшәмне күзәтә башлаганбыз икән инде, Марсель Марсо фотосына да күз салыйк. Ике тәрәзә арасында иң түргә беркетелгән ул. Марсоны кай яктан карасаң да, карашы сиңа төбәлә. Кызык... Атаклы мим белән безнең каһарманыбызның уртак яклары шактый. Зөфәр Гыймаев та заманында пантомима белән шөгыльләнә. Аның осталыгын күреп, заманында хәтта Казан консерваториясендә төркем җыярга тәкъдим итәләр. Акробат, актёр-мим, рәссам. Зөфәр Гыймаев дөньясы аша Казан тарихының кайбер мизгелләрен барлыйк әле.

## Хәтер

– Мин 1951 елның 9 гыйнварында Кыргызстан белән Үзбәкстан арасындагы Терек-Сай районы тирәсендәге тауларда дөньяга килгәнмен. Бер еллап Наманган каласында яшәгәнбез дә Казанга әйләнеп кайтканбыз. Үзбәкстанга туры сүзле әтием Фаат аркасында сөрелгән булганбыз. Аның бу гадәте миндә дә бар. Туры сүзлелегем аркасында тормышта бик күп киртәләргә юлыгырга туры килә. Без читтә каңгырап йөргәндә, дәү әтиебез бакыйлыкка күчкән. Аның кырыгына Казанга кайтып җиттек. Банк (хәзерге Муса Җәлил урамы) урамының 8 нче йортының 82 нче фатиры әле дә күз алдымда. Еш кына бер яшьтә булган хәлләр хәтердә саклана алмый, диләр. Ә мин хәтерлим. Ә инде Казанга кайтканда, миңа яшь ярым тирәсе иде.

Менә ул – ике бүлмәле фатир. Анда бәләкәй Зөфәрнең дәү әнисе, аның улы Солтан, кызы Рәфидә һәм гаиләсе белән улы Фаат сыенган. Күңелең киң булса, кысанлык сизелми ул. Бигрәк тә сабыйларга. Алар көн буе урамда бит. Зөфәр абый урамда иллеләп малай җыелганын һәм уйнаган уеннарын шулкадәр мавыгып сөйли ки, күз алдына моннан 50-60 еллар элеккеге Казан урамы килеп баса. Островский урамы почмагыннан малайлар өере килеп чыга, кулларында агач мылтыклар, берөзлексез «тах» та «тах» килеп, дошманны «ут»ка тоталар. Менә ишегалды сарайлары. Кич җитте исә, сарай түбәсе малайлар белән тула. Китә әкият сөйләшү, әтиләрдән, бабайлардан ишеткән мавыктыргыч хикәятләр белән бүлешү. Болар да арыткач, шуклык илә йорт астындагы склад тәрәзәсеннән тәмле сулы шешәләрне тимерчыбык белән эләктереп тартып алу. Әйтерсең лә, кармакка балык каптыралар! Болар өчен зурлардан эләкмиме соң инде?! Ничек кенә әле! Бигрәк тә урам себерүчедән шүрли малайлар. Галәмәт усал абзый ул. Беркөнне ачуы килеп кулындагы көрәген малайларга тондыра. Шул көрәк Зөфәрнең абыйсы Фердинандның башына килеп тия...

## Очыш

– Дүрт яшемнән рәсем ясый идем инде. Өстәл астында үз дөньямны корып, шунда фантазиямне эшкә җигә идем. Рәссам булмасам, конструкторлыкка китәсе идем. Самолётлар ярattым. Очу теләге зур иде. Кулчатырдан парашют ясап, түбәдән сикереп караган чаклар да бар иде. Алты яшемдә чын-чынлап очтым. Самолётта...

Ул көнне Фәрхиҗамал апа Үзбәкстаннан кайткан иң яраткан апасы Гөлбостанны аэропортка озатырга чыга. Урамда мәш килеп уйнап йөргән уллары Зөфәр белән Шамил дә боларга иярмәкче була. Кая инде ул шундый пычрак өс киеме белән кеше арасына алып чыгу! Каласыз, дип кулын селти ана. Күңеле Зөфәренең болай гына бирешмәсен дә ваемлый, әмма апасы белән сөйләшеп, уяулыгын югалта. Берничә урамны узгач, ике тере йомгакны шәйләп ала хатыннар. Нишләргә? Өйгә кайтарсалар, самолётка соңга калалар, болай калдырып китеп тә булмый. Балаларны аэропортка алмый чара юк...

– Әни белән апа шундый мавыгып сөйләшә, ә минем күзләр самолётта. Очкыч янында беркем дә юк, ымсындырып, трап та куйганнар. Башта карап кына төшим әле, дигән уй туды. Шамилнең кулын әнигә тоттырдым да менеп киттем. Бөтен җирен карап чыктым очкычның, инде чыгам дигәндә, тәрәзәгә күзем төште. Самолётка таба ташкын булып халык агыла. Бу кадәр кеше ничек тулып бетәр икән, дим гаҗәпләнеп. Аяк астында буталмаска дип, бер утыргычка барып сеңдем.

Берзаман малай янына бер ир кереп утыра.

– Әтиең беләнме? – ди ул, малайны карашы белән бораулап. Зөфәр «әйе» дип, ым кага. Хикмәт шунда: самолётта аның яшендәге тагын бер малай бар икән. Мөгаен, ул әтисе белән аэропортта чиратта торгандыр, һәм бу ир аларны күреп алгандыр. Ул чакта бит әле биш яшькәчә балаларга билет алу юк, шуңа күрә Зөфәргә башка бәйләнеп торучы булмый. Кызмача ир дә башка сорашмый, баланы куркынычсызлык каешы белән эләктереп куя. Бераздан йоклап та китә. Берәр сәгатьләп очкач, Зөфәр апасын эзләп таба. Алга таба нәрсә булган, дисезме? Аптырау, ачу, битәрләү, соклану – бар да булгандыр. Ни генә дисәң дә, баланы самолёттан төшереп калдырып булмый, язмышка күнеп, Үзбәкстанга алып кайтасы гына кала. Алты яшьлек сабыйның исә очарга дигән иң зур хыялы чынга аша.

## Мәрткә китү

Зөфәр абый өч самолёт белән очуларын (Ташкентка очканда, самолёт моторына ут каба һәм алар Сызраньга төшәргә мәҗбүр булалар), ләкин апасының Үзбәкстанга барып җитеп, берничә көн узгач кына, әнисенә: «Зөфәр минем белән», – дип хәбәр салуын аптырап, гаҗизләнеп искә ала. Ана исә өзгәләнә, шаша, югалттым, урлаттым, дип кара кайгыга кала. Дүрт яшьлек Шамиле самолётларга таба төртеп күрсәтә дә бит, ана уртанчы улы очкычка менәргә батырчылык иткәндер дип башына да китерми шул. Зөфәр исә, әнисен апаларында да, Ош өлкәсе Караван авылында яшәгән Рәшид абыйсында кунакта булганда да, могҗизаи Сәмәрканд базарында йөргәндә дә исеннән чыгармый. Матур яулык алып кайтса, бәлки ачуланмас, дип уйлый ул сабый акылы белән. Әнисенә ошардай яулыкны шәйләп тә ала. Бәясе биш сум икән. Аңа акча каян аласы? Рәшид агасыннан сораса да, ул кадәр бирмәс шул.

Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына, дигәндәй, Зөфәргә акча эшләү мөмкинлеге туа. Апасының күршеләре бәдрәф коесы казый икән. Чокыр бик тар булганлыктан, өлкәннәр сыймый, шуңа астан чиләк белән балчык чыгарырга малай эзлиләр. Бер чиләк чыгарган өчен 10 тиен түлибез, диләр. Әһә, ди Зөфәр, нибары 50 чиләк чыгарасы. Була ул! 10 чиләк балчык бәла-казаларсыз гына өскә күтәрелә. 11 нче чиләк буш килеш күтәрелә. Аска карасалар, малаебыз һушсыз ята. Нишләргә? Ярдәм чакыра алмыйлар, баланы эшләтү – «подсуд» җибәрә торган гамәл. Аңына килмәсме, дип кычкыралар тегеңә. Берзаман малай селкенгәндәй итә. Күрше-күлән, чиләккә утыр, чиләккә утыр, дип өйрәтә. Утырыр идең дә бит, хәлең булса... Озак маташа торгач, малай тәки чиләккә утыра. Күршеләр дә җиңел сулый. Апасына әле ике көн ут йотарга туры килә. Зөфәр мәрт хәлендә, сулышы сизелер-сизелмәс кенә чыга. Өченче көнне күзләрен ача да чәй сорый. Анысын эчеп бетергәч, тагын берне сорый. Бала алдына коры сөт тә куялар. Авырмасын гына. «Андый тәмле сөтне мин башка беркайда да тапмадым», – ди Зөфәр абый. Күршеләре исә апасы аркылы биш сум бирәләр. Малайга тәмам җан керә! Икенче көнне базардан теге яулыкны алып кайткач, очып кына йөри ул. Фәрхиҗамал апа баласы белән күрешкәннән соң, алты яшьлек улым акча эшләп яулык алып кайтты, дип, гомер буе горурланачак, җае чыкканда мактаначак әле.

## Татар теле

Эңгер. Рәссамның китап киштәсен кояшның алсу нурлары сыйпап уза. Бу китапханәнең беренче китабы нинди булган икән соң? Зөфәр абый рус теле дәреслеген ди елмаеп:

– Җәй көннәрен әнинең туган яклары Шәдке, Нәфисә апа яшәгән Күки авылларында үткәрдек. Авылга кайтканда, бер авыз татарча белмәсәк, килгәндә, урысчабыз онытыла иде. Әнә шул килеш 39 нчы мәктәпнең беренче сыйныфына кабул ителдем. Сүз уңаеннан, нәкъ менә беренче укытучым – Мария Павловна Дәминова минем рәссам булачагымны аңлады. Мондый фикергә ул матур язу дәресендә килгәндер. Чөнки сурәт ясата һәм янына хәрефен яздыра иде. Ә менә уртанчы сыйныфлардагы укытучым Зинаида Николаевна ышанмады. «Лаек түгел син рәссам булырга!» – дип кенә җибәрә иде. Ленинград сәнгать академиясенә укырга кергән елны мин аны урамда очраттым. Рәссам булам, югары уку йортына укырга кердем, дигәч, куырылып, саубуллашырга да онытып китеп барды.

39 нчы мәктәптә беренче сыйныфтан ук инглиз теле укытыла. Татар теле исә дәрестән соң факультатив буларак керә. Рус балалары укыгыз, укы, чаплашкалар, дип үртәгәч, татар балаларының да күбесе дәрестән кача. Зөфәр Гыймаев исә кала. Ләкин ул дәресләр берни дә бирмәде, безне авыл коткарды, дип искә ала ул хәзер. Ә менә «чаплашка» дигәннәрне акылга утырту өчен урысча китаплар сатып ала башлый. Беренче сыйныф укучысы каян акча юнәтә, дисезме? Җае табыла. Ул өлкәннәр өчен кибеткә чират торып акча эшли. Советлар иленең төп хатирәсе ул – чират. Бу хакта сәнгатьнең бөтен төрләрендә нинди генә әсәрләр иҗат ителмәгән! Үзеңә кирәкле тауарны алу өчен сигезәр сәгать чиратта тору мажаралары юморескага, драмага, фельетонга да әйләнә ала. Бәләкәй Зөфәр өчен исә ул – көненә ике сум акча эшләү чарасы.

– Ул акчалар барысы да китап алуга тотылды. Әти, берзаман кесәдә акча күреп алгач, колакны бормакчы иде. Әллә тартырга өйрәнәсеңме, ди усал карап. Менә бит, китап алдым, дигәч кенә тынычланды.

Фәрхиҗамал апа турында берничә сүз. Зөфәр абый сөйләгәннәрдән кайсы эшкә тотынса да, оста, дигән фикер кала. Матур җырлый, тегә... Башта «Заря» фабрикасына эшкә урнаша ул. Монда урнашу өчен иң әүвәл бер кило шоколад ашарга кирәк була. Шул көннән Фәрхиҗамал апаның иң яратмаган ризыгы – шоколад була. Аннан, гаиләгә бер бүлмә булмасмы, дип, урам себерүче булып эшли. Гаилә 12 квадрат метрлы гына булса да, подвал-бүлмәгә башка чыга. Менә ул, Островский урамындагы 5 нче йорт. Бу йорт өлкәннәрнең хәтерендә генә инде хәзер. Аның урынында киңәйгән, яңарган Качалов театры басып тора. Ары таба ТЮЗ кафесында эшләү, Зөфәрне спектакльләргә йөртү, «Спутник» кибетендә эшләгәндә, Бакый Урманчега рәссам булырга хыялланган улы турында сөйләү. Сизгер ана улын җитәкләп диярлек рәсем дөньясына үзе алып кергән икән бит. Зөфәр абый бигрәк тә Камал театры спектакльләрен хәтерли. «Зәңгәр шәл»дә кечкенә малай йөгереп чыккач, ничек сәхнәгә кечкенә малайны чыгара алганнар, дип, әнисен аптырата ул. Әнисе малайлар ролен бәләкәй гәүдәле кызлар уйнаганын сабыр гына аңлата. Асия Хәйруллинаның тәүге ролен Зөфәр әнә шулай хәтерендә калдыра да.

## Мин – бәхетле кеше

Зөфәр Гыймаев шулай дигәндә, Нургазиз абыйсын, аның дусты – Салих Сәйдәшевне, беренче урытучысы Мария Дәминованы, Казан сәнгать мәктәбе укытучысы Рәшит Гыйззәтуллинны, Ленинград сәнгать академиясендә укыган елларында очрашкан бөек рәссам Марк Шагалны, Бакый Урманчены күз алдына китерә. Урманче... Хәер, сүзне Зөфәр абыйның үзенә бирик әле:

– Гагарин урамындагы ике бүлмәле фатирга күченгәч, әни «Спутник» кибетендә эшли башлады. Бакый ага ипи-сөткә шушы кибеткә кергәли икән. Ничектер уртак тел тапкан алар. Әни берзаман, минем малай да академиягә укырга керде, дип сөйләгәч, Бакый ага, минем өйгә килеп китсен, дигән. Каникулга кайткач, бу хәбәргә шатланып, тизрәк алар яшәгән йортны эзләп киттем. Бакый ага өйдә түгел иде, ишекне Флора апа ачты. Әллә кайчангы танышы кебек өйгә чакырып, өстәл янына утыртты. Әле кунаклар киткән генә, ул янә өстәл әзерли башлады. Мин кыенсындым, өйдән генә килдем, тамагым тук, дигән

булдым. Флора апа бик кунакчыл, ай-вайга карамый иде. Хәзер Бакый ага кайта, әйдә күтәп торыйк, дип, кыстый-кыстый ашата башлады. Бакый ага кайткач, яшьләр фикерен ишетәсем килә, дип академия турында бик күп нәрсәләр сорашты. Шушы очрашуда мин Салих абый Сәйдәшевне искә төшердем. Бакый ага каршында 19 яшьлек егет утырса, Салих абый белән беренче очрашуда миңа нибары 2 яшь иде. Ул минем башымнан сыйпаганда, тәнгә рәхәт җылылык таралган иде. Шул халәт Бакый абый янында яңарды. Мөгаен, шушы көч, аларның энергиясе миңа хәзер дә яшәргә көч бирә торгандыр.

Ленинградтан каникулга кайткач, Бакый абыйга бару гадәткә әйләнде. Мин бик тыйнак идем ул вакытта. Аларда кайчан карама – кунак була торган иде. Кәнәфи Нәфыйков, Рәфкать Вахитов, музыкантлар – кемнәр генә юк. Мин яшь, оялчан, гафу үтенәм дә чыгып китәм. Бакый абый калырга кыстый, мин калмыйм. Шул килүләрнең берсендә ул берәр рәсемеңне бүләк ит әле, эшеңне карыйсым килә, дип сорады. «Каракалпак кызы Зәүрә»не бүләк иттем.

## «Мин сиңа үземне ясарга рөхсәт итмәс идем»

Яшь рәссам Каракалпакстанга Виктор Аршинов, Абрек Абзгильдин, Әнәс Тумашев, Харис Якуповлар белән бергә бара. Төркемдә җырчы Вафирә Гыйззәтуллина, нәфис сүз остасы Айрат Арсланов, драматург Туфан Миңнуллин да була. Туфан дигәннән...

– Театр Туфан абыйның портретын ясарга заказ бирде. Башта бу эш бүтән рәссамга йөкләнгән булган, Туфан абый исә аңа рөхсәт бирмәгән икән. «Әбигә хат килде» дигән картинаның авторы булуымны белгәч, мине сайлаган. Килеп керде остаханәгә, бергәләп чәй эчтек, сөйләшә башладык. Туфан абый берзаман кыбырсый башлады. Аннан соң түзмәде: «Зөфәр, син кайчан эшли башлыйсың соң», – дип сорады. Мин сез ишектән килеп керүгә эшли башладым, дип җавап бирдем. Картина аңа ошады, алырга үзе түгел, Шамил Закиров белән Марсель Сәлимҗанов килде. Шамил абый менә бу төше килеп бетмәгән, ахры, дип сүз башлаган иде, Марсель абый көчле тавышы белән: «Әйбәт!» – дип пичәт сукты. Үзе ошаттымы, ди. Ошатты, минәйтәм. Башын чайкап торды-торды да: «Мин сиңа үземне ясарга рөхсәт итмәс идем... Кешеләрнең эчемдә ни ятканын белүләрен теләмәс идем. Син бит Туфанның бөтен эчке дөньясын, авыл агаена хас булган саранлыгына кадәр чыгарып салгансың», – диде. Марсель белән бу вакыйгага кадәр үк аралаша башлаган идек инде. Аны яратмаучылар да шактый, әмма миңа аның көчле рухлы булуы бик ошый иде. Марсель гади кеше күрмәгәнне күрә белә, ышандыру, үзе артыннан ияртү сәләте зур. Искитмәле гадел кеше. Мөгаен, аның болай формалашуына спорт та тәэсир иткәндер. Үзем дә спортны яратканга, спорт мастерына кандидат булганга әйтәм моны. Портретын ясадым Марсельнең... Тик үзе генә күреп өлгермәде, фанилык белән араны кинәт өзде...

## Җепшеклек җимешләре

Салих Сәйдәшев, Хәсән Туфан, Празат Исәнбәт, Сара Садыйкова – Зөфәр Гыймаев ясаган портретларны саный китсәң, очы-кырые юк. «Салих абыйның портретларын өч-дүрт мәртәбә ясадым. Зыялылык мәктәбе булды ул миңа. Ишек кыңгыравына кечкенә балалар басса да, киенеп, галстугын бәйләмичә ишекне ачмый иде. Шул ук вакытта «халык» исемен йөртүчеләр трусикчан килеш ишек ачканы да булды», – дип искә ала халык композиторын рәссам. 70 нче елларны ул халыкның рухи яктан баю мөмкинлекләре булган чор дип атый. Сәбәбен исә болай аңлата:

– 1972 елда КПСС Үзәк Комитеты иҗат яшьләре белән эшләү турында махсус карар чыгарды. Чөнки ул елларда профессиональлек аска тәгәри башлаган иде. Мин шул карар дулкынына эләктем. Академиягә кергәндә, тарих буенча имтиханны начар бирдем. Белгечлек буенча билгеләр яхшы булгач, миңа тарихтан да «4»ле куйдылар. Элегрәк яки хәзер булса, алай эшләмәсләр иде. Бик күп яшьләр күтәрелде ул вакытта. Хәзер дә талантлар бар. Ләкин алар аз эшләп, күп акча алырга тели. Бездә – совет тәрбиясе. Гаделлек, тәрбиялелек, патриотизм көчле. Хәзер дә кешеләрдә шушы сыйфатларны күрәсе килә.

**Гөлинә ГЫЙМАДОВА**

# МӨХӘММӘТ САДРИ: «МИНЕМ СЕРЛӘР АЧЫК АЛАР, СИН ТЫҢЛАСАҢ»

Бик күп каләм ияләре Тукайдан үсеп чыкса да, араларында зур шагыйрь белән кендек аша береккәндәйләре дә була. Мөхәммәт ага Садри (1913-1999) хакында, һич шикләнмичә, шулай дип язарга мөмкин.

Шагыйрь Мөхәммәт Хәбибулла улы Садретдинов 1913 елның Тукай вафатының артыннан ук – 20 (31) маенда Казанның Яңа бистәсендә туган. Һәм аны бик күп талант ияләренең өлешенә тигән язмыш көткән – сабыйлык гомерендә күпсанлы кайгы-хәсрәтләр кичәргә туры килгән. Гади хезмәт белән – йөк ташып көн күргән әтисе һәм тире-күн заводында эшләгән әнисе 1921 елгы ачлыкта, тамак туйдырырлык эш эзләп, Урал якларына чыгып киткәч, юлда вафат булганнар, һәм ул дөм ятим калган.

Нәсел-нәсәпне аяктан еккан әлеге вакыйгадан соң, әнисе ягыннан әби тиешле Миңсылу карчык Мөхәммәтне балалар йортына тапшыра. Тормышы бераз рәтләнгәч, кире алырга уйлый һәм сүзендә тора да. Ул баланың киләчәген кайгыртып, Яңа бистәдәге Кызыл таш мәчет мәдрәсәсенә укырга бирә, әмма бераздан Мөхәммәт яңа ачылган совет мәктәбенә күчә. Мөхәммәт Садри турында сөйләгәндә, шулай ук күңелгә Тукай, аның сикәлтәле тормыш юлы күз алдына килә. Аңа көннәрнең берендә бәхет кояшы елмая да, ул инде кемгәдер рәхмәт хисләре, үзенең кадерен тоеп яшәп киткәндә генә сүнә. Шатлык һәм хәсрәт тормыш сукмагыннан ике кулыннан җитәкләп баргандай сыман күз алдына килә бу. Мөхәммәт Садри белән дә язмыш әнә шулай уйный. 1927 елда ул иң-иң кадерлесенә әйләнеп киткән соңгы кешесен, тормыш таянычын – әбисен дә югалта һәм кабат балалар йортына урнаша.

1928 елдан шагыйрьнең эшче тормышы башлана, дип әйтергә буладыр, чөнки сабын кайнату заводының ФЗӨ мәктәбендә укый, слесарьлык һөнәре ала һәм заводка эшкә урнаша. Ул чор өчен шулай ук тормышның өметле юлы бу, чөнки хезмәт кешесе – эшче һәм крестьяннар аерым бер хөрмәт кичергән, үзләрен бәхетле итәчәк ил төзүче сыйфатында хис иткән еллар. Нәкъ менә егерменче елларда эшчеләр арасыннан бик күп талантлы кешеләрнең үсеп чыгуы совет илендә аларга куелган шартлар, бирелгән мөмкинлек, илнең гомуми сәясәте белән бәйле. Әлеге сәясәт, әлбәттә, әдәбият-сәнгатькә дә карый.

Ятимлек еллары бала күңелен йомшак, уйланучан итә торгандыр: Мөхәммәт Садри үсмер вакытыннан ук каләм тибрәтергә керешә. Заводта хезмәт иткәндә, аның эшчеләр тормышына мөнәсәбәтле язмалары, шигырьләре басыла башлый. Алар әдәбият мәйданына үзен яңа тормыш кешесе итеп тойган шагыйрь һәм публицист килүеннән хәбәр бирә. 1932 елны нибары унтугыз яшь булган М.Садриның «Җыр башлана» исемле тәүге җыентыгы чыга. Аны бу вакытка инде Г.Гали, Х.Туфан, М.Җәлил кебек танылган каләм ияләре күреп ала һәм җитәкләп диярлек зур әдәби мәйданга алып керә.

1932 елда М.Садри Луначарский исемендәге Мәскәү театр институтына укырга җибәрелә. Бу аңа шул чорда башкалада яшәгән М.Җәлил, М.Максуд, Ш.Маннур кебек зур талантлар белән якыннан танышу мөмкинлеге бирә. Мәскәү яшь шагыйрьнең иҗади активлыгын арттыра, ул Казанга танылып кайта һәм 1935 елда Татарстан Язучылар союзына әдәби консультант булып эшкә урнаша. М.Садри иҗатында илгә мәхәббәт хисләренең чиксезлегенә аптырарга кирәкми – совет системасы аңа зур кеше булырга, танылырга бөтен мөмкинлекләрне тудыра.

Яшьлеге авыр елларга туры килсә дә, сабыйлыгы һәм үсмерлеге ятимлектә узса да, чыннан да, М.Садрины әдәбият мәйданына уздырган сукмаклар катлаулы дип булмый. Алга таба ул зур иҗат юлыннан тауга күтәрелгәндәй атлый. Тупланган тормыш материалы, үзе кичкән вакыйга-күренешләрнең тәэссораты аңа гомер буе иҗат итәрлек көч, таяныч бирә.

Үзен Тукайча язам, Тукайча уйлыйм, Тукайдан өйрәнәм, дип уйлаган М.Садри иҗатындагы оптимизм, системага дан җырлау, аның кычкырып торган җитешсез, кешегә зыянлы якларын күрмәү кемнедер аптыраштa калдырырга, шагыйрь әйткәннәргә ышандырмаска да мөмкин. Мин менә ышанам. Бердән, ул балалар йортында тәрбияләнгән. Андый тәрбия оешмаларының бар максаты совет системасына хезмәт итәрлек, социалистик идеяләргә мөкиббән китәрлек кешеләр тәрбияләү булган. Икенче яктан, М.Садри Тукай нәкъ шушы тормышны көткән, совет иле кешесенеке кебек бәхет турында хыялланган, дип уйлавы да бар бит әле. Шәхес культы елларының ачы тәҗрибәләре дә аны «хаталы» язудан саклаган булырга мөмкин. Иң куркыныч елларны да исән-имин кичкән кешенең хөкүмәткә, илгә дан җырлавына аптырарга кирәкми шикелле.

Инде шагыйрьнең Тукай белән иҗади бәйләнешләре мәсьәләсенә килик. Кайвакыт М.Садри иҗатында фольклордан килгән матур-матур традицияләр турында уйланам да, Тукай искә төшә. Баксаң, икесе дә татар халык авыз иҗатын җыйганнар, өйрәнгәннәр, бастырып чыгаруны кайгыртканнар икән. Фәнни эзләнүләр, шул юлдагы гамәлият, дәреслекләр төзү кебек эшләр һәркемнең күзен иҗатка тагын да ныграк ачарга, аның серләренә тирәнрәк төшенергә ярдәм итә. М.Садри һәм Г.Тукай белән дә шулай булып чыга. Фольклорны өйрәнгәндә, һәрберсенең иҗаты тирәнәеп, каләмнәре шомарып китә, язганнары халыкка тагын да якыная.

М.Садри талантының иң ташып торган чорында – 1956 елгача – һөнәри язучы гына булып яшәмәсә дә, шактый мирас калдыра. Сугыш алдыннан гына да аның берничә китабы дөнья күрә. Әлбәттә, аларның барысы да совет идеологиясе кысаларыннан чыкмаган, яңа ил төзү стратегиясенә җавап биргән әсәрләрдән төзелә. Бу хакта җыентыкларның исемнәре дә ачык сөйли («Совет Ватаны өчен»…). М.Садриның, остазы Тукай кебек, халыкка хезмәт итәргә тиешле әдәбиятка омтылышы язу манерасын ачык билгели. Аның әдәби иҗегенә шомалык, җырга тартым язу хас, һәм бу күренеш шулай ук китап атамаларында чагыла: «Җыр дәвам итә», «Коммунарлар турында җыр», «Волга турында җыр».

Нәкъ менә бик актив язып яткан вакытында – 1941 елның җәендә М.Садри Бөек Ватан сугышына китә. Ни гаҗәп, сугышның башыннан мылтык тотып көрәшүенә һәм, корреспондент булып эшләгәндә, иң кайнар нокталарга керүенә карамастан, ул илгә исән-имин килеш, Җиңү байрагын үзе тоткандай кайта.

Бөек Ватан сугышыннан соң, М.Садриның әдәби иҗаты тагын активлашып китә. Ул бу чорда батырлык, ватанпәрвәрлек, дуслык-туганлык, тыныч яшәү бәхете, совет кешесенең сугышка, җиңүгә бәйле хисләре, хезмәт шатлыгы («Александр Матросов», «Туганлык», «Кышкы бакча» китаплары) кебек мотивларны алга куеп иҗат итә. Әсәрләренең атама сайланышында электән килгән әдәби алымнар да үзләрен әледән-әле сиздереп куя, шагыйрьнең үз иҗатын бәяләүче, ачучы, гражданлык позициясен күрсәтеп торучы төшенчәләр һаман урын ала: «Бәхет турында җыр», «Россия турында җыр», «Җыр дәвам итә».

Бүгенге укучыга М.Садри иҗаты «ура, патриотизм шигърияте» кебек тә тоелырга һәм аның тарафыннан тәнкыйть ителергә мөмкин, кемгәдер ул оптимизм, яшәү көче уятуы белән якын булыр. Ә бит Тукай шигърияте дә, бигрәк тә башлангыч этабында, кешене бөек эшләргә, милли алгарышка хезмәт итәргә әйдәгән. Заман шартлары үзгәргәч, әдәбиятның эчтәлеге үзгәрсә дә, тирәндә яткан бәйләнешләрне барыбер тотып алырга мөмкин. М.Садриның әдәбиятка Тукайлар мәктәбендә тәрбияләнеп килгәнлеге һәм эчтәлек, һәм форма яссылыгында ачык күренә.

Үземнең дә күпмедер танышлыгым булган шагыйрьне Мөхәммәт ага дип атый аламдыр. Аның иҗатын яхшы белмәүчеләр өчен алдан ук әйтеп куйыйм: анда Тукай темасы шактый урын алып тора. Мөхәммәт Садри әсәрләрендә Тукай һәм Пушкинны лирик герой аша бәйләргә омтылыш («Пушкин Одессада»), Тукай иҗатын Пушкинныкы биеклегендә күрү һәм мәңге яшәячәген раслау («Йөрәктән-йөрәккә»), башкалабыз Казан тарихын «кыю җырчы» Тукай белән бәйләү («Нурлы Казан») күзәтелә. Галимнәр шунда ук әйтәчәк: бу мотивларның барысы да Тукайның үзендә дә күзгә ташланырлык дәрәҗәдә ләбаса! Мөхәммәт Садри гомер бакый Тукай стилен үзенә үрнәк итә һәм бу

фикерне иҗатында да чагылдыра («Җырларың булсын Тукайча»). Шул ук вакытта ул фольклордан килгән калыпларга, үлчәмнәргә өстенлек бирә.

Рус халкы белән бергәлекне, дуслыкны еш җырлаган М. Садри «Өлкән туганыбыз бөек рус халкына» шигыренә эпиграф итеп Г.Тукайның: «Рус белән тормыш кичердек сайрашып…» юлларын куйган. Үз биографиясен чагылдырган «Россиянең бөек семьясында» әсәрендә ул Тукай томнарының сугышчы-шагыйрьгә авыр елларда рухи терәк булуы хакында яза: *«Патроннары, гранатлары белән, / Коры паек белән беррәттән, / Йөртте аны солдат ут эчендә, / Дусты итеп, сөеп йөрәктән».* Шигырьнең Тукай иҗаты белән тыгыз бәйләнешен чагылдырган юллар: *«Хөр мәмләкәт, хөр Русиядән без, / «Юлбарыс»тан сезнең көчле без!», «Россиянең бөек семьясында / Көч, гадәт һәм бәхет алмашып!»*

Көчле пафос, публицистик тойгылар белән иҗат ителгән «Россиянең бөек семьясында» әсәре – М.Садриның Тукайга багышлаганнары арасында иң билгелесе. Ул аның өч строфасын бер-берсенә охшаш юллар белән башлый: «Бронядай тышлы Тукай томы», «Бронядай тышлы бу китапта», «Бронядай тышлы Тукай томын». Шагыйрь, уңышлы тапкан метафора ярдәмендә, Тукай иҗатының мәңгелеген, дөньякүләм сугышларда да юкка чыкмавын һәркем, шул исәптән сугышка киткән солдат өчен дә изге булуын сөйли:

*Бронядай тышлы Тукай томы*
*Бишенче ел нуры, хисләре;*
*Йөртте аны Ватан сугышында*
*Зур көч итеп солдат биштәре.*

Әлбәттә, автор хаклы: шагыйрь иҗаты халкына кадерле булганда гына мәңгелек:

*Бронядай тышлы Тукай томын*
*Яшәтәләр халык хисләре,—*
*Аны үзенең Идел буйларына*
*Алып кайтты солдат биштәре.*

*Тукай исән. Завод цехларында*
*Ул эшчеләр белән киңәшә;*
*Юлга чыга геологлар белән,*
*Нефтьчеләр белән сөйләшә.*

Мөхәммәт Садриның поэзия өлкәсендәге остазына, рухи әткәсенә багышланган әлеге әсәре шәхси җыентыкларына «Тукай» атамасы белән кертелгән («Сайра сандугач»), «Йөрәктән-йөрәккә» исә тәүге вариантта «Габдулла Тукайга» исеме белән очрый («Йөрәк тибүе») һәм эчтәлеге дә башкачарак.

Мөхәммәт Садри язганнардан Г.Тукай әсәрләреннән алынган мотивларга, гыйбарәләргә, образларга, цитаталарга мисалларны күпләп китерергә мөмкин. Шагыйрь бигрәк тә алтмышынчы елларда Тукай иҗатына игътибарлы була, аңа ияреп, совет заманы проблемаларын күтәргән сатира-юмор әсәрләренең хәтта тулы бер циклын иҗат итә: «Симез Гали,ябык сыерлар һәм кәҗә турысында», «Мөхәрриргә», «Үгез кадәр… яшь бала», «Тоткач Мәскәүләр якаң», «Бер сатучы хатынның бала тибрәткәндәге өметләре», «Шагыйрь белән Зөбәйдә». Бу атамаларның кайберләре Тукай иҗаты белән турыдан-туры бәйле.

Шагыйрьнең елмаеп торган күзләре, ирен читләре күз алдымда. Ул язган җырларның кушымталары тел очымда:

*Сандугачым сайрый, чут-чут, дип,*
*Безнең илдән матур ил юк, дип…*

Әйе, Мөхәммәт Садри, Тукайдан аермалы буларак, үзе яшәгән илне, үзен тәрбияләгән халыкны дөньяның иң бәхетле кешесе итеп күрә. Ә бәлки, Тукай шигъриятендәге кара төс-буяулар аңа үзе яшәгән чорны шулай бәяләргә сәбәп булгандыр?

**Рифә РАХМАН**

# ПРОТОТӨРКИ БАБАЛАРЫБЫЗГА ЮЛ ЯРУЧЫ КИТАП*

Халыкларның, дәүләтләрнең оешуы мәсьәләсе төрле гуманитар фәннәрнең иң мөһим проблемаларының берсе булып тора. Бу тюркология белемендә дә карый. СССР таркалгач, яңа төрки дәүләтләр оешты, этник үзаң яңарды һәм бу сорауга җавап бирү тагын да актуальләште. Татар халкының килеп чыгыш мәсьәләсендә бүгенге көнгә кадәр төрле, кайчак капма-каршы фикерләр яшәп килә. Ә инде иң борынгы төркиләрнең кайда һәм нинди кавем-кабиләләр җирлегендә формалашуы тагын да билгесезрәк һәм четереклерәк булуы шиксез.




Фәндә «һинд-европа центризмы», «ираноцентризм» кебек идеологик калыпларның өстенлек һәм хәтта хакимлек итүе, төрки халыкларны икенче-өченче сортлы, түбәнрәк дәрәҗәдә торучы халыклар итеп карау аларның килеп чыгышы мәсьәләсен катлауландырып кына калмады, ә фәннилектән шактый ераклаштырды. Моңа флектив һәм агглютинатив телләр мәсьәләсе дә, дөресрәге, беренчеләрен икенчеләренә караганда камилрәк, «культуралырак» итеп карау шаблоны да комачаулык итте. Баксаң, төрки телләрне дә үз эченә алган һәм сүзләрнең тамырын, иң борынгы мәгънәләрен меңәр еллар буена саклап килгән агглютинатив система тарихны, хәтерне дә саклаучы икән! Һәм бу яктан хәтта сүз тамырлары үзгәрүгә корылган флектив телләрдән өстенрәк тә тора икән. Нәкъ шушы үзенчәлек профессор Марсель Бакировка – без моны алда күрербез – иң борынгы язма ядкарьләрдәге чишеп булмый торган «төенле» урыннарга ачкыч табарга, бабаларыбызның иң ерак тарихына юл ярырга ярдәм иткән.

Без горурланып, һун-гуннарны төрки халыклар тарихының чишмә башы итеп карарга күнеккәнбез. Алар Кытай агрессиясенә каршы торып,үзләреннән җанлы дивар ясап, Евразияне Кытай экспанциясеннән һәм ассимиляциясеннән коткарып калганнар. Халыкларның бөек күчешен башлап, бик борынгы заманнарда көнчыгыштан (Якын Көнчыгыштан) килгән юлларын генетик хәтерләрендә саклап, көнбатышка юнәлгәннәр: Урал, Урта Идел, Кама төбәкләрен дә узып (алардан курган («корган»нар), елга, авыл исемнәре, бакыр казаннар сакланып калган), Урта диңгезгә кадәр барып җиткәннәр. Апеннин ярымутравына урнашкан Рим империясендә колбиләүчелек җәмгыятенең юкка чыгуы фәндә хаклы рәвештә һун яулары белән бәйләп карала. Хәзерге, үзләрен өстен итеп санаучы Европа халыклары «варварлар» дип санаган һун-гуннар, асылда, күп яңалыклар алып килгәннәр, аларның яшәешенә тормышчан сулыш өргәннәр.

Ә шулай да без, фаразлау яки җитди дәлилләмичә гомуми планда язылган аерым хезмәтләрне исәпкә алмаганда, төркиләрнең борынгы тарихын өйрәнүдә һуннардан ары китә алмадык. Хәтта Россия Фәннәр Академиясенең Тел гыйлеме институты белгечләре тарафыннан соңгы вакытта чыгарылган хезмәттә дә төркиләрнең иң борынгы бабалары элеккечә һуннар белән генә бәйләп карала һәм «Саян-Алтайның тайгалы-далалы көньяк

* Марсель Бакировның «Прототюрки: изначальная прародина, ранние племена и язык, история и этнокультура» («Иң борынгы төркиләр: беренчел туган җирләре, кабиләләре һәм теле, тарихы һәм этнокультурасы») исемле монографиясе хакында (Казан: Татар.кит.нәшр., 2019. – 463 бит. Рәсемнәр һәм карталар белән).

өлкәсе» аларның иң борынгы ватаны итеп күрсәтелә *(«Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика». М., 1997.–732 б.)*. Бу догматик нәтиҗәгә карата Олжас Сөләйманов: «Асылда төркиләр тарихы итеп вакыт ягыннан иң өстәге катлам, тарихларының Көнчыгыштан кояш батышы ягына күченгән вакытларына бәйләнешле соңгы этабы тәкъдим ителә, ә менә төркиләр Көнчыгышка кайчан һәм кайдан килгәннәр – мондый мәсьәләнең фәндә әле күтәрелгәне юк» дип, хаклы рәвештә үзенең тәнкыйди мөнәсәбәтен белдерә *(«Тюрки в доистории» Алматы, 2002. – 83 б.)*.

Марсель Бакиров исә төркиләр Көнчыгышка кайчан һәм кайдан килгәннәр, дигән сорауны куеп кына калмый, ә күп кенә төрле яңа дәлилләргә, системалы һәм күпьяклы тикшеренүләренә таянып, үзенең монографиясендә аңа гаҗәеп хак нәтиҗәле җавап та бирә. Иң борынгы төркиләрнең Алгы Азия, Якын Көнчыгыш белән бәйле булганлыгын нигезли торган тикшеренүләрен галим борынгы археологик культуралар белән уртаклыкны анализлаудан башлый. Аерым алганда, ул хронологик яктан һуннарның Көнбатыштан башлангыч ала торган карасук культурасына караучы иң соңгы халык булганлыгын дәлилли. Шулай ук ул соңрак чорга караучы һун-савир, хазар, барсил-болгар, төркиләшкән аланнар тартымлылык күрсәткән археологик катакомба культурасында чыгышы белән Алгы Азия җирлегенә барып тоташуына игътибарын юнәлдерә *(Шунда ук. – 168 б.)*.

Күпләребез борынгы бабаларыбызны Үзәк Азия, Ерак Көнчыгыш төбәге белән бәйле җирле автохтоннар яки күчмәннәр булган дип йөртәбез. Арабызда, шулай ук, шаблонга, евроцентризмга корылган хезмәтләргә ияреп, аларны цивилизациядән артта калган һәм тарих мәйданына шактый соң чыккан халыклар итеп караучылар да җитәрлек. Юк, бу шаблон карашлар белән берничек тә килешеп булмый. Киресенчә, М.Бакировның монда сүз барачак фундаменталь хезмәтеннән аңлашылганча, прототөркиләр Урта диңгез бассейныннан, Төньяк Африкадан башлап, бөтен Евразиядә тирән эз калдырганннар, субстрат җирлек һәм нигез буларак, бик күп халыкларның этнокультураларына җуелмаслык йогынты ясаганнар. Татар тюркологының гаҗәеп төпле, тирән эчтәлекле китабын укыгач, мин ерак бабаларыбызны үзләренең ифрат тотрыклы һәм мәңгелек гомерле агглютинатив телен, дини-мифологик һәм дөньяви карашлар системасын, шулай ук күпкырлы традицион мәдәниятләрен тудырган һәм иң мөһиме, гасырлар чоңгылыннан үзләренең этник портретын, милли үзенчәлекләрен бүгенге варисларына исән-имин китереп җиткергән тәҗрибәле һәм талантлы зур халык итеп күзалдына бастырам.

«Өстә – күк Тәңре, аста – көрән җир кылынганда ике арада кеше углы барлыкка килде. Кеше угыллары өстеннән борынгы бабаларыбыз Бумын каган, Истәми каган идарә иткән. Тәхеткә утырып, алар төрки халкының илен һәм кануннарын саклаганнар, үстергәннәр». Бу күпләргә таныш юллар – Күлтәгингә багышланган борынгы төрки рун истәлегенең «Зур язмасы»ннан (Фәнүзә Нуриева укуы һәм тәрҗемәсе). Язмадан аңлашылганча, дөнья яралган дәвердә беренчел кешеләр төркиләр булган, имеш. Алга таба төркиләр «алга – көн чыгышынача, уңга – көн уртасынача, артка – көн батышынача, сулга – төн уртасынача» тирәлектә, ягъни «дөньяның дүрт почмагына кадәр» арада бөтен халыкларны буйсындырып, аларны Төрки каганлыгы составына керткәннәр.

Безнең үзебезгә дә «тюркоцентризм» галәмәтләре сеңгән түгелме? Ничек инде төркиләр дөньяда иң борынгы кешеләр булсын, ди? Ничек инде алар галәмәт зур киңлектәге бөтен халыкларны буйсындырсыннар, ди? Янәшә генә Тибет, Көнбатыш крае, Борынгы Төрки каһанлыгына кадәр биш меңьеллык тарихы булган Кытай. Мин студентларга Күлтәгин язмасындагы бу юлларны Төрки каганлыгындагы дәүләт идеологиясендә чагылыш тапкан шовинизм шаукымы белән бәйләп аңлата идем.

Ә чынлыкта китерелгән рун язмасындагы юллар, мондый фикер сөреше төркиләрнең этник аңында күптәннән оешкан традиция һәм борынгылыктан килүче тарихи-этник хәтер йогынтысында туганнар икән. Димәк, соңрак чорлардагы төркиләр ерак бабаларының күп гасырлар буе Алгы Азиядән Көнчыгышка таба килгән данлы юлларын һәм аларның цивилизаторлык ролен мең еллардан соң да онытмаганнар булып чыга.

Гомумән, борынгы төрки рун язмалары соңгы фәнни ачышлар яктылыгында һәм яңача игътибар бирүне сорый. Бу язмаларда без белмәгән, аңлап җиткермәгән, бик борынгы заманнардан ук килгән этник хәтер һәм аң тәэсире, чыннан да үзен шактый сиздерә икән. Монографик хезмәт безне менә шундый уйларга этәрә.

Әйе, Казан федераль университеты профессоры Марсель Хәернас улы Бакировның монографиясе бик җитди, күпкырлы, тикшеренү өчен бик авыр, әмма үтә актуаль темага багышланган. Аның төп максаты һәм гомуми эчтәлеге – төрки кабиләләрнең килеп чыгышын һәм аларның туган җирен, беренчел Ватанын ачыклау, шулай ук иң борынгы төркиләрнең телен, этник һәм этнокультура тарихын өйрәнү, реконструкцияләү. Авторның күпсанлы һәм күпкырлы ышандыргыч дәлилләргә нигезләнгән төп концепциясе буенча, иң борынгы төркиләр Якын яки Алгы Көнчыгышта, дөресрәге, Урта диңгез ареалында үзара аралашып яшәгән телләр, төрле диалектлар составында оеша башлаганнар һәм агглютинатив төзелешле телләрнең үзара берләшүе, җиңеп чыгуы нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Шуннан соң алар дулкын-дулкын булып Көнчыгыш Европага, Урта һәм Үзәк Азиягә, Себер һәм Ерак Көнчыгыш киңлекләренә үтеп кергәннәр, андагы аерым кабиләләр белән аралашканнар. Әмма тотрыклы һәм куәтле кавем-этнос буларак, алар төрки телне саклап калганнар һәм үстергәннәр.

М.Бакировның бу монографиясе – предметара бәйләнешләргә корылган фәнни эзләнү һәм тикшеренүләрнең гаҗәеп уңышлы үрнәге, дияр идем. Чөнки хезмәт бик күп төрле өлкәләргә (тел, дини-мифологик, этнографик, археологик, антропологик, фольклор, сәнгать белеме һ.б.), шулай ук төрле чорларга һәм телләргә караган чыганакларга нигезләнә. Анда һәр фәннең тикшеренү үзенчәлекләре һәм үзенә генә хас чыганаклар комплексы исәпкә алынган. Кайсы гына фәнне яки өлкәне алма, автор үзен чын белгеч итеп күрсәтә. Төрле фәннәргә караган чыганакларны һәм дәлилләрне ул үз карашларын, үз концепциясен нигезләүдә зур осталык белән файдалана. Авторның 200 дән артык телгә караган чыганакларны җентекләп тикшерүе генә дә ни тора! Ә инде дәлилләре турыдан-туры кулланышка кертелгән яки өземтәләр китерелгән төрле фәнни хезмәтләрнең саны 800 дән артып китә.

Басым ясап әйтергә кирәк: нәкъ менә комплекслы тикшеренү, төрле чыганакларны файдалану юлы гына авторга бик күп авыр сорауларга нигезле җавап табарга ярдәм иткән дә инде. Һәм нәкъ комплекслы ысул гына аңа, төрле характердагы чыганакларны бергә туплаудан бигрәк, төрле өлкәгә караган фактларны үзара бәйләү һәм ары таба үстерү аша гаҗәеп масштаблы, көтелмәгән яңа нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек биргән.

Әйтелгәннәрне раслау өчен хәзергә бер мисал китерү белән чикләник. Белүебезчә, фәндә, тюркологиядә моңарчы һуннар һәм борынгы төркиләр баштан ук монголоид кыяфәтле булганнар, дигән фикер яшәп килде. Хәтта мондый караш 2002 елда чыккан «Татарстан тарихы»ның беренче томына да үтеп керде. М.Бакиров исә тюркологларның игътибарыннан читтә калган археология, антропология материалларын өйрәнеп, шулай ук иң борынгы бабаларыбызның Алгы Азиядән, Иран ягыннан килгәнлекләренә нигезләнеп, үзенең китабында аларның раса ягыннан европеидлар булганлыгын ышандырырлык итеп раслый, ә монголоид кыяфәтен аерым кабиләләр Үзәк Азиядә шундый антропологик типлы кавемнәр белән аралашып яшәгәндә алганнар, дигән нигезле караш үткәрә.

Билгеле, мондый күпкырлы зур хезмәт буш урында туа алмый. М.Бакиров үзебезнең һәм чит ил авторларының күпсанлы хезмәтләренә таяна, аларның фикерләрен нечкәләп, үз карашлары аша үткәреп анализлый. Әмма төркиләрнең иң борынгы этник тарихына турыдан-туры кагылган хезмәтләр бик аз. Шактыенда безнең авторны кызыксындырган мәсьәләләр декларатив рәвештә, нигезләмичә генә каралалар. Ә иң күбесе төрки этносы башлангычын, инде шаблонга әйләнгән карашлардан уза алмыйча, Үзәк Азия, ягъни Алтай, Монголия, Төньяк Кытай төбәкләренә, анда яшәгән һуннарга гына кайтарып калдыралар. Шуңа күрә дә галимнең, иң беренче чиратта, борынгы чыганакларда теркәлеп калган фактик материалга һәм ышанычлы тарихи мәгълүматларга зур игътибар бирүе, аларны

яңа күзлектән чыгып бәяләве бик урынлы һәм отышлы.

Моңа кадәр тюркология фәнендә, шул исәптән тел гыйлемендә борынгы дәверләрдә төрки халыкларга иран тәэсиренең шактый көчле булуы («ираноцентризм») хакында фикер өстенлек итеп килде.Хәтта һуннар арасыннан чыккан ашина ыруы да ираннар йогынтысына эләккән кавем итеп каралды (С.Г.Кляшторный). Сак һәм скиф кабиләләре исә күпчелек галимнәр тарафыннан тоташы белән иран телләләр итеп саналды. Без анализлый торган монография авторының төрле яктан ныклап нигезләнгән карашы моңа кискен каршы килә. Борынгы төрле иран кабиләләре теленә тикшерү уздырып, галим аларның лексикасындагы шактый гына сүзләрне, хәтта аерым Алла исемнәрен дә төркиләр тәэсире белән аңлата.

«Европоцентризм»ның өстенлекле йогынтысы да фәндә үзен нык сиздерә. Һинд-европа семьялыгына кермәгән телләрдәге, шул исәптән төркиләрдәге тамырдаш уртак сүзләр ориенталистикада һәрчак диярлек Европа телләреннән кергән дип карала. Көчленең көчсезгә, зур тел берләшмәсенең кечкенә телләргә йогынты ясавы рәвешендә аңлатыла. М.Бакиров күпсанлы дәлилләргә нигезләнеп, мондый калыплашкан карашларны кыю рәвештә җимерә. Европа, иран телләре белән ярашмый торган бик күп архаик сүзләрнең башка галимнәр башларына да кертмәгән төрки тамырлар белән кардәш икәнлеген исбатлап күрсәтә.

Әле дә хәтеремдә: мин студент булган дәвердә, 1971 елда Олжас Сөләймановның «Аз и Я» китабы зур кызыксыну уяткан иде. Казан кибетләрендә күренгәч, мин бу китапны сатып алырга өлгердем. Ә икенче көнне бу мәшһүр китап сатудан алынган иде инде. Фәндә дөреслекне алай гына җиңеп булмый шул. И.Я.Марр, Н.С.Трубецкой һәм Олжас Сөләйманов кебек белгечләрнең хезмәтләре вакыт сынавын үтеп, яңадан фәнни әйләнешкә керде. Алардагы рациональ фикерләр этногенез процессларын, борынгы телара бәйләнешләрне тирәнрәк аңлауга ярдәм итә һәм әлеге проблема белән җитди шөгыльләнүче аерым галимнәр тарафыннан алга таба үстерелә, яңа казанышлар белән баетыла. М.Х.Бакиров хезмәтендәге берсеннән-берсе кызыклы фикерләр һәм табышлар, яңа һәм оригиналь нәтиҗәләр – шуның бер саллы мисалы.

Икенче яктан, галим хәзерге чорда бик популяр, күккә чөеп макталган авторларның хезмәтләренә дә чын фәнни югарылыктан якын килә (Л.Н.Гумилёв, Б.А.Рыбаков, С.Г.Кляшторный һ.б.). Алардагы уңышларны урынлы файдалану белән беррәттән, җитешсезлекләрен дә нигезләп күрсәтә, берьяклы яки дәлилләнмәгән фикерләр белән кыю рәвештә бәхәскә керә.

Укучыларның игътибарын тагын бер хезмәткә юнәлтәсе килә. Ул – Тариел Азертюркның башта Нью-Йоркта инглиз телендә, ә инде 2018 елда Санкт-Петербургта рус телендә басылып чыккан, шумерларның чөй язуларын төркичә укуга багышланган ике томлык китабы. М.Бакировның монографиясе белән аваздаш бу китап «Генезис Тюрка и Тюркского языка» дип атала. Америкада яшәүче азәрбайҗан галиме М.Бакировның хезмәте турында ишетеп һәм соклануын белдереп, интернет битләрендә коллегасын зур уңышы белән котлады да инде.

Географик яктан караганда, татар тюркологының монографиясе, әйтерсең лә, бөтен Иске Җиһанны, ачыклап әйткәндә, Төньяк Африкадан һәм Урта диңгез бассейныннан алып, Алтай-Саян тауларына, Монголия, Кытайга, Тын океанга кадәрге гаять зур араларны иңли. Хәтта америка индеецлары яшәгән Яңа Җиһанга барып чыга. Әмма үзәктә – Якын Көнчыгыш һәм Алгы яки Көнбатыш Азия. Бу кешелек цивилизациясенең туган җире, нәкъ шуннан инде тирә-яктагы иксез-чиксез киңлекләргә цивилизация казанышлары тарала. Төп юнәлеш, әлбәттә, көньяк-көнбатыштан Урта һәм Үзәк Азия, Алтай һәм Себер якларына таба. Автор дәлилләвенчә, прототөркиләр Көнчыгышка күченгәндә, Урта Азия биләмәләре арадаш төбәк, ә аерым кабиләләр өчен икенче ватан хезмәтен үтәгән.

Сак кабиләләрен сыендырган Туран җирләре һәм Җидесу төбәге дә шушы төбәккә туры килә. Тарихи чыганакларны һәм археологик материалларны автор яңача якын килеп ачыклаганча, һун-гуннар, кангюйлар, исседон-усунь-уйсуннар, бәҗәнәкләр (кангар→ бәҗәнәк), угызлар (аугас→ огуз/угыз), хазарлар, саклар массивы белән бәйле Туран җирлегеннән

(Арал диңгезе буйларын да кертеп) аерылып чыкканнар. Монда оешкан аерым кабиләләрнең исемнәре һәм төрки топонимнар хәтта борынгы җирле атамаларда теркәлеп калган (Өгүз/өкиз, Геродотта Океc>угыз →Амудәрьяның элекке исеме, «Туран науны» (яңа эрага кадәр сугылган көмеш акчадагы язу, «нау» – төркичә «тигезлек», «түбәнлек») – Туран түбәнлеге һ.б.

Бу халыкларның – Көнчыгышка күчү процессында безнең Урта Идел, Кама буйлары да читтә калмаган. Аеруча бу төбәктәге Анани культурасы хакында монографиядә җитди күзәтүләр бар.

Китапның структурасы бик уйланып, көтелмәгәнчә, әмма авторның төп концепциясен ачу, нигезләү өчен бик үтемле итеп төзелгән. Китапның «Кереш» өлешен галим моңарчы саф төрки сүз булып исәпләнгән (А.М.Щербак) «аш» тамыр-сүзенең аш/ац/aç формаларында яңа эрага кадәр үк инде Алгы яки Көнбатыш Азиядә яшәгән элам, аккад, ассирий, әрмән һәм, ахыр килеп, санскрит телләрендә кулланылганын күрсәтүдән башлап җибәрә. Һәм шунда ук: «Уртак мәгънәле бу тамырдаш сүз мәдәни бәйләнешләр җирлегендә генә туганмы, әллә монда без белмәгән телара генетик кардәшлек тә катнашканмы?» – дигән сорау куеп, укучы һәм тарих белән кызыксынучылар алдында проблемалы ситуация тудыра. Шул рәвешле аларны бабаларыбызның гасырлар, мең еллар тирәнлегеннән килгән иң борынгы тарихы белән танышырга әзерли.

Авторның тикшеренү объекты булган тарихи-географик җирлектә яңа эрага кадәр яшәгән Шумер (IV-III меңъеллыклар), Элам (III меңъеллык – VI гасыр уртасы), Аккад (2316-2137), Вавилон (1894-539 еллар), Хетт (XVIII-XII гасырлар, хаттларны да эченә алган дәүләт), Митанни (XVI-XIII гасырлар, субарлар һәм хурритлар төзегән дәүләт), Ассирия (XV-VII гасырлар), Лидия (XII гасыр – 546 ел), Урарту (IX-VIII гасырлар), Мидия (670-550) кебек хәзерге Гыйрак, Сүрия, Төркия, Азәрбайҗан, Әрмәнстан, Төрекмәнстан, Иран биләмәләренә туры килгән борынгы дәүләтләр кешелек тарихының һәм цивилизациясенең бишеген тәшкил иткән. Бу бишектә безнең иң ерак бабаларыбыз да тирбәлгән, шунда акрынлап аларның төркиләргә хас иң борынгы тел, этнокультура, дини-мифология һәм антропологиягә нисбәтле үзенчәлекләре барлыкка килгән, оешкан.

Төркиләрнең оешу процессын М.Бакиров һинд-европа, ностратика, шулай ук бу төркемнәргә кермәгән шумер, урарту, хуррит, кавказ телләрендә сөйләшкән халыклар белән озак вакытлар буена тел-лөгать алмашып яшәү белән бәйли һәм төрки баба тел, дөресрәге, иң борынгы төрки диалектлар берлеге нәкъ менә Көнбатыш яки Алгы Азия ареалында хатт, элгәре яки иске мидия, элам, дравид, кути, кассит, этруск, сабир/савир кебек агглютинатив телләрнең үзара якынаюы, генетик-контакт кардәшлеге җирлегендә формалашканнар, дигән концептуаль нәтиҗәгә килә. Моның өчен ул әлеге агглютинатив телләрнең һәркайсына диярлек аерым бүлекчәләр багышлый һәм аларның телләреннән, матди һәм рухи культураларыннан төркиләр белән уртак катламнар аерып чыгарып, үзенең төп концепциясен ышандырырлык итеп нигезли.

Дәүләтләр дә, тере организм кебек үк туалар, җитлегәләр, төрле сәбәпләр аркасында юкка чыгалар. Теле, этнокультурасы куәтле һәм тотрыклы булган халык югалмый. Демографик үзгәрешләр һәм хайван асрау, җир эшкәртү традицияләренең үсеше, кысымы нәтиҗәсендә прототөркиләр белән кардәш кавемнәрнең бер өлеше, Себер киңлекләрен үтеп һәм хәзерге вакытта Беринг дип аталган бугаз аша чыгып, Америка кыйтгасына кадәр барып җитә. Көнчыгыш Себердә алар җирле халыкка хас монголоид чалымнарны алалар, әмма Көнбатышка, Урта диңгез ареалына барып тоташа торган төркиләр белән уртак дини-мифологик ышануларны һәм шактый күп борынгы уртак сүзләрне саклап калалар, шул исәптән хәтта уникум характерындагы инкарь итү кисәкчәсе «–ма»ны да! Заманында Әбрар Кәримуллин тарафыннан өйрәнелгән һәм соңгы вакытларда М.Бакиров тарафыннан шактый тулыландырылган Америка индеецлары турында мәгълүматлар менә шуны раслый (133-137 б.).

Прототөркиләрнең бер кардәш диалекты булган дравид кабиләләре исә Иран тау яссылыгыннан Урта Азия аша Һиндстан ярымутравының көньяк биләмәләренә

үтеп керәләр. Һәм, әлбәттә, аларның телендә дә баба төрки тел мохитендә үк барлыкка килгән бик күп лексик тамырлар, архаик сүзләр сакланып калган. Дравидлар, эламнар һәм төркиләрнең генетик кардәшлегенә багышланган бүлекчәдә өч төркем телләр өчен дә уртак булган йөздән артык сүз тәңгәл куелып, темаларга, диалектларга аерып китерелә.

Иң борынгы төркиләр тернәкләнүе һәм оешуында якыннан торып катнашкан ностратик тел төркемнәренең берсе – хамит телләре. Алар семитлар (аккад, ассирия, вавилон һ.б.) һәм борынгы мисырлар белән бергә афразий дигән бер тел семьялыгы тәшкил итәләр. Фәндә хамит телләре Төньяк Африкада барлыкка килгәннәр, йә булмаса, Алгы Азиядә формалашып, Африкага үтеп кергәннәр, дигән ике төрле караш бар. М.Бакиров Урта диңгез бассейнына караучы бу телләр белән төрки телләр арасында генетик һәм мәдәни бағланышларына нигезләнгән кардәшлек күрә. Күп гасырлар буена үзара аралашып, тел-лөгать алмашып яшәгәндә, байтак сүзләрне алар бергәләп тә тудырганнар, дигән караш уздыра. Автор табып китергән шундый уртак сүзләргә мисаллар китерик: гач (хамит) + (г//к) – кача (америнд: кечуа) ⇆гөч /күч (төрки) – бер урыннан икенче урынга күчү|кот/куот (хамит: судан) ~кут/куд (хатт.) ⇆кот (төрки) – рух, җан | даг (хамит: кушит) ⇆ таг/тау (төрки) – тау | деба/дибо (хамит: кварт) – биеклек, калкулык ⇆ түбә (төрки) – тау башы, тау түбәсе | ар (хамит: кушит) – ир кеше ~ер/эр (дравид) – «самец»⇆ ар/ер/ир (төрки) – ир кеше, ир-ат | *клн/калла (хамит-семит), – кәләш, килен ⇆ килин/килен (төрки) – килен, «сноха» | кида (хамит) ⇆ куда /кода (гомумтөрки) – кода, «сват».

Табигый инде, монографиянең үзәгендә сүзлек, галиҗәнап Сүз тора. Автор үзе ачыклаган, ареаль генетик һәм мәдәни багланышлар нәтиҗәсендә туган сүзләрне аерым төркемнәргә аера (культ һәм сакраль лексика, табигатьнең стихияле көчләре-объектлары, кыргый һәм йорт хайваннары, үсемлекләр дөньясы, кешегә бәйләнешле социаль һәм туганлык мөнәсәбәтләре, кеше әгъзалары, яшәешне тәэмин итү һәм хуҗалык эшчәнлеге, матди һәм рухи культура элементлары, топонимик һәм антропонимик атамалар, саннар һ.б.) һәм аларның һәркайсына аерым бүлекчәләр багышлый. Сүзлекнең автор тарафыннан менә шул рәвешле тематик төркемнәргә бүлеп төзелүе очраклы түгел. Алар кеше тормышының иң характерлы якларын колачлыйлар һәм төп сүзлек фондына кергән, озак вакытлар саклана торган ачкыч сүзләрне дә үз эчләренә алалар. Шул ук вакытта алар борынгыларның этник йөзен, хуҗалык һәм мәдәни-культура үзенчәлекләрен билгели торган лексиканы да чагылдыра. Өстәвенә, сүзлек составындагы сүзләр кайчандыр Көнбатыш яки Алгы Азия ареалында борынгы төркиләр белән генетик яки мәдәни бәйләнештә булган телләрне, кавемнәрне ачыкларга да мөмкинлек бирә.

Шунысы характерлы, иң борынгы бабаларыбыз чыккан ареалда туган охшаш яки уртак сүзләрне аерым лексик оялларга берләштергәндә һәм анализлаганда, М.Бакиров телне үтә нечкә тоемлаучы белгеч-филолог буларак эш итә. Һәм, әлбәттә, галим төзегән сүзлек, үзе атаганча, чагыштырмалы лексик-семантик сүзлек кенә түгел, ә, бәлки, чагыштырмалы тарихи-этимологик сүзлек тә.

Галим төзегән сүзлектә вакыт сынавына бирешми торган төп сүзлек фондына мөнәсәбәтле лексика гына түгел, ә хуҗалык итүгә, көнкүреш һәм мәдәниятнең төрле өлкәләренә караган, иң мөһиме, берничә мең ел элек Алгы Азиядә, ягъни Анатолия, Месопотамия, Гыйрак, Сүрия, Иран җирләрендә туган субстрат терминнар да шактый күп икән. Алар арасында – могҗиза түгелмени?! – хәтта төрле объект-күренешләр генезисының башында ук торган иң архаик тамыр сүзләр дә, шулай ук соңрак чор терминнары составында субстрат нигез рәвешендә сакланып калганнары да җитәрлек. Яфраклардан ясалган иң борынгы савыт атамасы «ка» (афраз. / дравид) һәм гомумиләштерелгән әлеге тамырга ялгану нәтиҗәсендә барлыкка килгән ка+бак = савыт-кабак, ка+зан = ыруг савыты, ка+бан = савыт, поднос, тәрилкә кебек кушма исемнәр, йә булмаса, очлы агач яки таш бәйләнгән таяк/кәтмән ярдәмендә ясалган ояларга рәт-рәт итеп орлык утыртудан башланган игенчелек терминнары һәм, ахыр килеп, шулар җирлегендә соңрак туган атамалар (сак/сук (афраз) – очлы башлы казык, бо-

так, таяк – «кәтмән», сука (афраз) – җир эшкәртү, сөрү >сука, сука-лау, һб /һаба (афраз) – очлы корал белән казып оялар ясау, туфрак эшкәртү мәгънәләрендә> сабан) моңа характерлы мисаллар була ала (74, 158 б.).

Фикерне дәвам итеп, янә шуны әйтергә кирәк: төрки халыкларда сакланып калган һәм хәзер дә кулланылган чәчү культураларының исемнәре дә борынгы чорларга китә икән. Ачыклап әйткәндә, ашлык – ашлык, ките – китен /җитен, буд' – бодай/богдай, барай/бурай – борай, ара – арпа, таро – тары, дооге – төги/дөге кебек терминнар нәкъ менә иң элгәрге игенчелек, җир эшкәртү төбәге булган Якын Көнчыгышка барып тоташа. Игенчелек җир эшкәртү традициясе төркиләрдә соңрак кабат торгызыла. Белүебезчә, һун-гуннарның бер өлеше җир эшкәртү белән шөгыльләнгән.

Кыргый һәм йорт хайваннарының исемнәре белән дә шундый ук хәл. М.Бакиров Алгы яки Көнбатыш Азиягә бәйләнешле тарихи чыганаклардагы охшаш яки тамырдаш сүзләрдән түбәндәге исемнәрне аерып чыгара: барра – бүре, парс – барс, аруз – арслан, тол' – төлке, табш-ала – тавшан (куян), туар – тувар / (мал)-туар, ат/ат' – ишәк >ат, еш/ешә – ат⇆ишәк, ад – уд (үгез, сыер), буго/буко – бука/буһа (үгез, йорт хайваны), кун – кон/куй, зарк – сарык, так/тека – тәкә, сус – чучка (42–50 б.). Хайван асраугa, ат җигү, арба-дирбиягә бәйләнешле күпчелек сүзләр дә шушы рәткә килеп ялгана.

«Тимере бар тилмермәс» дигән халык мәкале бар. Безнең галимнәр тимер, чуен, тимерчелек эше кытайлардан кергән дигән фикердә. Әмма М.Х.Бакиров китергән мәгълүматлар моның киресен раслый. Асылда бу эшне һәм бу өлкәгә караган аерым терминнарны кытайлар иң борынгы төркиләрдән алган булып чыга (77, 86 б.). Шан һәм Чжоу династияләре чорында (безнең эрага кадәр XIII-VI гасырлар) Төньяк Кытайда чәчәк аткан «Ордос бронза культурасын» шулай ук пратөркиләр – һуннар тудырган булган (325 б.).

Саннарга багышланган бүлекчә дә бик зур кызыксыну уята. Билгеле бер шартлы чикне белдергән, шулай ук магик мәгънәгә ия булган сан атамаларын автор Алгы Азия төбәге һәм пратөрки кавемнәр белән генетик бәйләнешләргә нигезләнеп аңлата. 17 санының бик борынгы заманнарда ук сакраль төсмер алуына һәм актив кулланышта булуына күп мисаллар китерә. Борынгы болгарлар һәм Алтай төркиләре мифологиясендә мәҗүси 17 Алла булганлыгы хакында минем хезмәттә дә әйтелгән иде *(Дәүләтшин Г.М. «Волжская Булгария: духовная культура». Казан, 1990. –57-58 б.)*.

Географик объектларга, шулай ук кавем-этносларга һәм кешеләргә кушылган исем-атамалар да – зур тарихи байлыгыбыз. Әлеге өлкәгә багышланган бүлекчәдә галим һинд-европа телләреннән чыгарып булмый торган Арарат, Урарту, Субарту, Эдир/Идаль/Итил-Идел, Ашина, Ашидә, кути/гути, сак/скиф, хунну/сюнну кебек атамаларның этимологиясен ышанычлы рәвештә төрки телгә бәйләп аңлата.

Һәм тагын бер үтә кызыклы лингвистик табыш: ат/ат-ы – моннан берничә мең ел элек Алгы Азиядә туган әлеге праформа хәзерге кебек үк «исем», «атама» мәгънәләрен аңлата торган сүз булган икән. Ачыклап әйткәндә, ул мөстәкыйль сүз-тамырлар алдына яки ахырына аффикс рәвешендә ялганып, аларның нәкъ менә исемен-аталышын җөпләүче, ялгызак исем булуын белдерүче код хезмәтен үтәгән. Сүзләрнең, объект-күренеш атамаларының шушы рәвештә архаик ысул белән, ягъни иярмә компонент ярдәмендә ясалуы, М.Бакиров ачыклаганча, элек шактый таралган күренеш булган. Менә ул китергән мисалларның кайберләре: Месопотамиядәге Алше дигән ил патшасының исеме – Антаратлы (Антар+атлы), Митиния дәүләтләрендәге Нузи төбәгендә исә шундый ук исем Атиантар (Ати+антар) рәвешендә теркәлгән. Ә болары – Урартау җирендәге исемнәр: Биру-атты (тау), Пур-атту (Ефрат-ат елгасы). (Соңрак чорга караган төрле ономастик терминнар белән чагыштырыйк: Алма-аты, Турбатлы, Кубрат, Аттила, Атийаш). Америка индеецларыннан, мәсәлән, ацтек /azteклардан да мисаллар китерик: томатль – томат, чоколатль – шоколад, хатын-кыз исемнәре: Айаукиатль, Ашайакатль. Күренүенчә, «ат» архетибы (аккадча ат-му – сүз, атама | төркичә ат – исем, нам, атама) иялек кушымчасы ялганып та, шулай ук бернинди кушымчасыз да килә алган.

Чагыштырмалы прототөрки сүзлеген дәвам итеп, галим сак/скифларның һәм өлешчә сарматларның төрки тамырлар белән кардәш-аваздаш сүзләрен анализлауга хәтта аерым бүлекчә багышлый. Алар арасында автор тарафыннан беренче башлап һичнинди тарту-сузуларсыз төрки нигездә укылган һәм аңлатылган яңа сүзләр шактый күп.

Моннан тыш, автор пратөркиләр белән кардәшлек күргән борынгы кути/гути, кассит, сувар кебек Урта диңгез һәм өлешчә Каспий буе кабиләләре теленнән дә байтак уртак сүзләр табып китерә. Шуңа күрә, һич арттыру түгел, автор анализлаган сүзләр, әгәр артык булмаса, кимендә меңгә якын дип әйтергә була.

Марсель Бакиров, чын галим-тикшеренүче буларак, үзе төзегән кайбер лексик тәңгәллекләргә тәнкыйть аша да карый. Шикләнгәннәрен сорау куеп тәкъдим итә. Кайберләрен гипотеза рәвешендә бирә, ары таба тагын да нигезләргә, ачыкларга кирәген искәртә. Димәк, алда булачак тикшеренүләргә, уйлануларга да урын калдыра.

Шулай итеп, тюрколог галим төрле борынгы чыганакларда чәчелеп яткан, моңарчы тикшеренүчеләр игътибарыннан читтә калган бик күп лексик берәмлекләрне ачыклап фәнни әйләнешкә кертә. Тугандаш яки тугандаш булмаган, әмма оешып килүче төркиләр белән бер казанда кайнаган кабиләләр, халыклар телләрендәге уртак, тамырдаш сүзләрне һәм төрле өлкәләргә караган терминнарны системага сала. Иң мөһиме, гаҗәеп сизгер һәм новатор телче-этимолог буларак эш итеп, тарих чоңгылларында яралган иң борынгы төрки телне реконструкцияләүгә, шактый күләмле палеотөрки сүзлек фондын торгызуга ирешә. Бу, һичшиксез, бәяләп бетергесез зур казаныш.

Ә тел, төп сүзлек фонды артында, әлбәттә инде, халыкның иң борынгы этник һәм этнокультура тарихы тора. Иң ерак бабаларыбызның беренче Ватаны кайда булган, үзләре оешкан ареалда алар нинди хуҗалык һәм культура казанышларын тудыруда катнашканнар, пантеоннары, дини-мифологик идеологияләренә нинди үзенчәлекләр хас – лексика нигезендә автор тарафыннан бер-бер артлы менә шундый җитди проблемалар яки өлкәләр ачыклана. Көнчыгышка күченгәндә, аларның икенче ватаны яки арадашчы төбәге булган тарихи урыннар, шулай ук арытаба барып урнашкан пратөрки урыннар билгеле була.

Бу уңайдан янә шунысы бик әһәмиятле: М.Бакиров чагыштырмалы лексик-семантик-этимологик сүзлек ахырында ун бабтан торган гомуми нәтиҗәләр дә чыгара.

Һуннарның телләре хакында да фәндә төрле карашлар бар. Бер төркем галимнәр аларны пратөрки телле булган, дип, икенчеләре – монгол телле, өченчеләр – кет (енисей семьясы), дүртенчеләр ниндидер билгесез телдә сөйләшкәннәр, дип чыгалар. М.Х.Бакиров китергән күп санлы яңа материаллар, дәлилләр исә аларның, һичшиксез, тамырлары белән Якын Көнчыгышка тартылган төрки телле булганлыгын исбатлый. Борынгы Кытай җырләрендә Чжоу династиясен төзүчеләр (б.э.к. 1122–225) пратөркиләр булган дигән фәнни-гипотетик караштан чыгып, автор кытай телендә һәм чжоуларның варислары булып исәпләнүче мяо-яоларның телләрендә теркәлеп калган төркиләр белән уртак сүзләрне тәфсилләп өйрәнгән. Шул лексиканы һәм янә төрле исемнәрдәге һун-гун кабиләләре сөйләменнән килеп җиткән сүзләрне бергә кушып, ул кытайлар белән аралашып һәм чиктәш булып яшәгән пратөрки бабаларыбызның шактый гына күләмле сүзлеген төзүгә ирешкән. Үзе искәрткәнчә, бу сүзләрнең бер өше Көнбатышта теркәлгән һәм Урта Азия саклары телендә ачылган төрки сүзләр белән дә аваздаш икән (189-190 б.).

Марсель Бакировка фәнни ачышлар ясауда ачкыч ролен үтәгән бер методик табышны аеруча игътибар үзәгенә алып күрсәтәсе килә. Бу очракта мин галимнең, күпкырлы сизгер белгеч буларак, борынгы Евразиядәге матди һәм рухи мирастан, нигездә, төркиләргә хас катламнарны аерып чыгаруын һәм аларны этник билге сыйфатында файдалануын күздә тотам. Төрки халыкларның дөньяви һәм дини-мифологик идеологиясендә, шулай ук этник культурасында үзенчәлекле эз калдырган шундый билгеләрне ачкыч рәвешендә кулланып, ул ретроспектив ысул ярдәмендә яңа эрага кадәр Алгы Азиядә һәм Якын Көнчыгышта яшәгән борынгы халыкларның һәм кабиләләрнең яшәү рәвешенә, мәдәни мирасларына үтеп керә һәм

аларның нәкъ менә төрки кавем оешуга нигез булган агглютинатив төзелешле иң борынгы этнослардан башлангыч алуын ышандырырлык итеп исбатлый.

Автор ачкыч итеп кулланган этник билгеләргә мисаллар китерик. Төрле чыганаклар буенча, безгә төрки бабаларыбызның бер башлы канатлы мифик елан-сазаган образын изгеләштергәнлекләре, хәтта үзләренең тотем бабасы итеп санаганнары билгеле. Һәм бары бездә, төркиләрнең риваять-легендаларында гына канатлы зур елан илне саклаучы куәтле көч итеп күзаллана алган (134 б.) Искә төшерик: Казан ханлыгы яулап алыныр алдыннан канатлы елан, моннан соң илне саклап кала алмавын белдереп очып киткән. Ә менә һинд-европа халыкларында, шул исәптән ираннар мифологиясендә, зәрдүшт (зороастризм) динендә исә елан-аждаһаны дошман зат итеп карау, аңа каршы аяусыз көрәш сюжеты киң урын алган (монографиядә шушы ышануларны гәүдәләндерә торган шактый гына рәсемнәр дә урнаштырылган). Аның каравы, галим кулланышка керткән археология, сәнгать, фольклор материаллары белән расланганча, безнең элгәреләребез булган иске телле мидия, элам, дравид, кути/гути, кассит, субар/савир, кушан, сакларда һәм скифларның Кара диңгез буенда яшәгән кабиләләрендә елан-сазаган культы шулай ук изгеләштерелгән (349 б.).

Бүре культы белән дә шундый ук хәл. Алда карап үткән бер иш кардәш кавемнәрдән һәм борынгы төркиләрдән аермалы буларак, һинд-европа халыкларында әлеге образ да дошман булып саналган һәм, мәшһүр тел галиме А.А.Потебняның тикшереп нигезләвенә караганда, бүре белән елан-аждаһаны алар бер-берсе урынына килә ала торган бер үк типтагы үтә зарарлы образлар итеп күзаллаганнар. М.Бакиров үзенең хезмәтендә әлеге образларның да капма-каршы сыйфатлары белән кавем-этносларны, шул исәптән ерак төрки бабаларыбызны аерырга хезмәт итүләрен бик урынлы дәлилли (333-344 б.).

Ахыр килеп, галим төрки кавемнең беренче башлап тау куышында яралуы, баш сөягенең алтын яки көмеш белән каймаланып, эчемлек эчә торган савыт итеп файдаланылуы, бер учка җыелган укларны яки нечкә чыбыкларны сындырып булмавы, ант итешкәндә, кан тамызылган эчемлеккә салкын корал очын тыгып алу, өс киеменең изүен сул якка (йөрәк ягына) эләктерү, толым яки үрмичә, иңсәгә төшереп чәч йөртү, «яда таш» ярдәмендә яңгыр яудыру, төрле типтагы күмү-җирләү йолалары кебек шактый таралыш алган борынгы фактлар һәм сюжетлар да автор тарафыннан кавемнәр арасындагы «без – алар» аермасын ачарга ярдәм итүче төркиләргә хас этник билгеләр итеп анализлана.

Бу фундаменталь хезмәт – тюркологиядә генә түгел, ә дөньякүләм этногенез өлкәсенә дә мөнәсәбәтле зур вакыйга. Ул, һичшиксез, башка телләргә дә, аерым алганда инглиз, төрек, казакъ һ.б. телләргә тәрҗемә ителеп тә бастырылырга тиеш. Бу, әлбәттә, зур көч һәм шактый чыгымнар таләп итә торган эш. Аны авторга гына йөкләү дөрес булмас иде. Чөнки китапны укып чыкканнан соң, бик борынгы бабаларыбыз ирешкән казанышларны, алардан бүгенгегә кадәр килгән традицияләрне күреп зур горурлык хисе туа. Аны бөтен дөньяга күрсәтәсе килә. Китапның фәнни-популяр варианты исә халкыбызның, бигрәк тә яшь буынның горурлыгын, этник аңын күтәрүдә зур роль уйнар иде. Россиядәге татар һәм башка төрки телләр өчен шөбһәле булган заманда бу телләрнең никадәр зур вә куәтле тарихы, бай мәдәни мирасы һәм халыкара сәяси потенциалы аларга бик сак, зур кадер-хөрмәт белән карауны таләп итәр иде.

М.Х.Бакиров хезмәте, һичшиксез, дәүләт бүләкләренә дә лаек.

**Гамирҗан ДӘҮЛӘТШИН,**
*тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстанның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт бүләге лауреаты.*

# МИНЕМ НАДИР ДӘҮЛӘТЕМ...

## НАДИР ДӘҮЛӘТКӘ 75 ЯШЬ

Галим Надир Дәүләт белән беренче мәртәбә 1990 елда очрашып танышуым һич көтмәгәндә булды. Советлар Берлегенең ишек-капкалары әле яңа ачыла башлаган еллар иде бу. Галимнәребез Әбрар Кәримуллин, Яхъя Абдуллин, Мирфатыйх Зәкиев чакыруы белән көннәрдән бер көнне Нью-Йоркта яшәүче Рифат Таби белән Төркиядән Надир Дәүләт, ике профессор, Казанга килеп төштеләр. Кунакчыллык күрсәтү нияте беләнме, әллә башка берәр сәбәп аркасындамы, аларны Көнбатыш илләрендәге гадәт буенча кунакханәгә урнаштырмыйча, Әбрар ага белән Яхья ага үз фатирларына алдылар.

Мин ул елларда Татарстанның Республика (хәзерге Милли) китапханәсендә директор булып эшли идем. Бездә фәнни консультант хезмәтен башкаручы Әбрар Кәримуллин, билгеле инде, Казанга шундый кадерле кунаклар килүе, Надирның үзендә яшәве турында кош тоткандай сөенеп сөйләде. Сүз уңаеннан, кунакларны сыйлар өчен шәһәр кибетләрен урап чыгуын, әмма рәтле-башлы ризык таба алмавын да әйтеп узды. Әбрар ага, кунаклар белән таныштырырга теләп, өенә чакырса да, ул көнне бара алмадым.

Әмма галим кеше китапсыз, китапханәсез яши аламыни: икенче көнне иртән кабинетым ишегеннән ике чит-ят кеше килеп керүен күргәч, мин аларның кем икәнен шунда ук аңлап алдым. Беренчедән, киемнәре үк ыспайлыгы белән аерылып торса, икенчедән, йөзләрендәге, иреннәрендәге ихлас елмаю яктысы безнең төксе кыяфәтле җәмгыять кешесе түгеллеген искәртеп тора иде. Чөнки без һәрдаим сөмсере коелган борчулы кешеләр арасында яши торгач, елмайган кешеләргә сәерсенеп, хәтта шикләнеп карарга өйрәнгән идек инде.

Надир Дәүләтнең китапханә фондындагы борынгы китаплар һәм кулъязмалар белән эшләргә нияте барлыгын белгәч, без бик теләп, аңа булышырга риза булдык. Идәннән түшәмгә кадәр китаплар белән шыплап тутырылган бүлмәнең бер почмагына кечкенә өстәл сыйдырып, Надир әфәндене кертеп утырттык. Атна буе шушы «Әбүгалисина мәгарәсендә» утырганда, төрле оешмалардан килеп, аның эмигрантлык язмышы һәм монда нигә килүе белән кызыксынучылар да, совет чорының «тыелган» китапларын биргән өчен миңа кисәтү ясаучылар да булды. Әмма ул елларда илдә демократия җилләре исә башлагангадыр инде, эшне зурга җибәрмәделәр.

Гарәп хәрефле китаплар һәм кулъязмаларны укый-укый күзләре әлҗе-мөлҗе килә башлагач, ул минем кабинетыма кереп, озаклап чәй эчәргә, чәй янында әңгәмә корырга ияләшеп китте. Дөресрәге, бу инде чын мәгънәсендәге ике яклы әңгәмә түгел, күбрәк ул сөйли, ә мин аның сөйләгәнен йотлыгып тыңлый идем. Чөнки катлаулы һәм гыйбрәтле язмыш кичергән бу шәхеснең һәр җөмләсе, һәр уй-фикере минем өчен өр-яңа да, күңелгә якын да иде. Аны тыңлаганда, мин гүяки бер кеше язмышын гына түгел, ә халкыбызның ачы язмышын күз алдыннан үткәреп, күңелем аша кичереп утыра идем.

1944 елда Кытайның көнчыгышындагы Мукден каласында морзалар нәселеннән килгән Ибраһим Дәүләт-Килде белән Рокыя Мөхәммәдишалар гаиләсендә туып, ике яше тулар-тулмас ятим калган Надирның гомер юлы үзе бер фаҗигале роман кебек иде. Мин кунагыбызга шулкадәр тиз ияләштем ки, әйтерсең, без дөньяның ике читендә

озак вакытлар бер-беребезне күрергә зар-интизар булып яшәгәнбез дә, һәм менә, ниһаять, очрашканбыз. Еллар буе җыелып килгән уй-фикерләр, сагыну-сыктау хисләре күңелләрдән ташып чыгып, без сәгатьләр буе уртак уй-фикерләребез дөньясында йөзә идек. Татар халкының катлаулы тарихыннан, ачы язмышыннан минем дә күпмедер хәбәрдарлыгым бар, әмма Надир туганның фикерләре тирәнрәк, мәгълүматы күпкә масштаблырак иде.

Шушы бер атна эчендә ул минем өчен олы татар дөньясының ишеген ачып, аның үзе белгән сукмаклары, юллары буйлап сәяхәт иттерде, төрек халкы, тугандаш башка төрки халыклар хакында бәйнә-бәйнә сөйләде. Аның фикерләре минем өчен өр-яңа, хәтта бераз ятрак булса да, нигәдер алар күңелемә хуш килеп, шул берничә көн эчендә профессор Надир Дәүләтнең шәкертенә әверелгәнемне сизми дә калдым.

Китапханәдәге гарәп язулы борынгы китаплар һәм кульязмалар белән бергә мин аның рус, инглиз, алман телендәге басмалар белән кызыксынуын күргәч, баштарак аптырап та калган идем. Чөнки бездәге галимнәр нигездә ике тел – татар һәм рус телләрен генә белә, фәнни эшләрендә шул телләрдәге чыганаклардан гына файдалана. Ә рус телендәге чыганакларда һәм елъязмаларда, гадәттә, татар тарихына бәя Россия сәясәте күзлегеннән  карап бирелә. Ә татарның үз чыганаклары гаять аз, чөнки алар системалы рәвештә юкка чыгарылган.

Бер очрашу вакытында академик, олуг тарихчыбыз Миркасыйм Госмановның Надир әфәнде турында әйткән сүзләре гомерлеккә күңелемә уелып калды. «Надир Дәүләт, – дигән иде ул, – безнең тарихчыларыбыздан үзенең киң карашлы, бик тә мәгълүматлы, масштаблы фикер йөртүе белән аерылып тора. Беренчедән, ул татар халкы язмышын үз йөрәге, үз язмышы аша кичергән кеше. Икенчедән, ул цензура чылбырларын күрмәгән хөр фикерле галим, өченчедән, ул безнең тарихыбызга читтән карап бәя бирә ала. Ә зур әйбер еректан яхшырак күренә. Дүртенчедән, ул безнең кебек ике тел генә белми, ә төрек, инглиз, алман, рус, татар һәм башка төрки телләр белән эш итә, шул телләрдәге чыганаклардан иркен файдалана ала».

Казанга әлеге килүләре вакытында, билгеле оешмалардан көч-хәл белән рөхсәт юнәтеп, без аларны Татарстан буйлап сәяхәткә алып чыктык. Алабугада, Чаллыда, Түбән Камада узган очрашулар вакытында халык мөһаҗир милләттәшләребезне якын туганнары кебек кабул итте, сорау өстенә сорау биреп, хәтта йөдәтеп тә бетерде кебек. Әле дә хәтеремдә: Түбән Камадагы очрашу вакытында бер яшь егетнең: «Сез Татарстанның киләчәген ничек күзаллыйсыз? Без кайчан да булса мөстәкыйльлек алырбызмы?» – дигән соравына күңеленнән җавап эзләп, Надир әфәнде шактый вакыт уйланып торды. Аннары ул кулын киләчәккә төбәгәндәй, алга сузып: «Сез бүген эйфориядә. Бәйсезлек турында Декларация кабул итү кирәкле гамәл, әмма ул олы нияткә таба беренче адым гына әле. Ә мөстәкыйльлек алу өчен тәфсилләп язылган программа-алмаксат кирәк. Дәүләт корылышын тирәнтен аңлаган, мөстәкыйльлек өчен ихластан көрәшердәй фидакяр затлар, дәүләт эшлеклеләре җиң сызганып эшкә тотынса гына, ул программаны тормышка ашырып булачак. Әмма моңа Мәскәү аяк чалачак. Әлегә сездә – бәйрәм рухы, бәйрәм халәте, хыял тантана итә...» Надир Дәүләтнең ул чакта сак кына, безне рәнҗетмәскә, бәйрәмебезне бозмаска тырышып кына әйткән бу кинаяле сүзләрендә никадәр алдан күрүчәнлек, үз башыннан кичкән ачы тормыш тәҗрибәсе һәм тарих сабаклары ятканын мин шактый еллар узгач кына аңладым.

«Революция еллары барлык халыклар өчен зур өметләр тудырган иде, ләкин бик күпләр өчен алар фәкать хыял булып кына калды, – дип язды бераз соңрак Надир Дәүләт «Милләт мәҗлесе» китабының сүз башында. – Көрәш юлында бихисап корбаннар бирелде, биниһая җәфа чигелде. Әмма шул ук вакытта байтак кына сәяси һәм хәяти тәҗрибә дә тупланмады түгел...»

Ул озак еллар «Азатлык» радиосы аша бөтен татар дөньясына безнең чын тарихыбыз турында аваз салды, онытылган рухи хәзинәләребезне, тыелган әдәби әсәрләребезне халкыбызга кире кайтарды. Истанбул каласында «Казан» исемле журнал



*Рәсемдә (сулдан уңга): Берил ханым, Надир Дәүләт, Разил Вәлиев.*

оештырып, аның баш мөхәррире булып, мөһаҗирлектәге зыялы милләттәшләребезне үз тирәсенә туплады.

Надир Дәүләт – бик катлаулы язмышка дучар булган шәхес, дип әйттек. Кытайда ун ел буе милли рухлы «Милли байрак» газетасы чыгарган әти-әнисен Сталин төрмәсенә ябып, үзен ятим калдырган илгә гомер буе рәнҗеп яшәве һич тә гаҗәп түгел. Ләкин ул беркайчан да үз халкына үпкә сакламады, аннан читләшмәде, киресенчә, гомере буе аңа хезмәт итте. Казанда һәм Истанбулдагы очрашулар, телефон һәм хат аша аралашулар вакытында безнең сүзләребез күбесенчә халкыбыз язмышы, аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында булса да, Надир Дәүләтнең асылын мин аның фәнни хезмәтләрен, язган китапларын укыгач кына чын-чынлап аңлый һәм белә башладым кебек. Беренче эш итеп, 1998 елда мин аның «Русия төркиләренең милли көрәш тарихы» китабын татарчага тәрҗемә итү эшен оештырдым. Бу китап белән галимнәрнең кызыксынуын күргәч, «Җыен» фонды һәм Милли китапханә ярдәме белән «1917 ел октябрь инкыйлабы вә төрк-татар Милләт мәҗлесе» исеме белән аның бик саллы фәнни хезмәтен дә дөньяга чыгардык. Ә инде Казанда дөнья күргән өченче китабы «Милләт белән Совет арасында. 1917 елгы Октябрь инкыйлабы: Русия төркиләренең яшәеш өчен көрәше» дип атала. XX гасыр башында төрки халыкларның мөстәкыйльлек һәм дәүләтчелек өчен көрәш хәрәкәтен эзлекле рәвештә һәм бу дәрәҗәдә тәфсилләп, фәнни нигезгә салып өйрәнгән тагын берәр галим бар микән дөньяда? Шунысы әһәмиятле, бу фәнни, тарихи хезмәтләрнең һәммәсендә дә татар халкы, аның дәүләтчелек өчен көрәше, милли азатлык хәрәкәте төп урыннарның берсен алып тора. Ни кызганыч, бар гомерен татарны дөньяга таныту, аның тарихына гадел бәя бирү өчен көрәшкән олуг галимгә безнең әле тиешле хөрмәт күрсәткәнебез юк. Аның татар халкы өчен кылган игелекле гамәлләрен халыкка җиткерү һәм аңлату, халкыбыз тарихына багышланган саллы хезмәтләре хакында фәнни конференцияләр үткәрү өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар, югыйсә. Киләчәктә аның фәнни хезмәтләре нигезендә югары уку йортларында диссертацияләр яклanса, студентлар тарафыннан дипломнар язылса, татар тарихын өйрәнүгә яңа сәхифәләр өстәлер иде.

Надир Дәүләт – Төркия һәм Германия уку йортларында белем алып, Америка университетларында укыткан халыкара дәрәҗәдә билгеле профессор. Шундый атаклы галимне Казан университетларына чакырып, яшәү һәм эшләү өчен тиешле шартлар

тудырып, лекцияләр укыттыру бик катлаулы, кулдан килмәслек эш түгелдер бит?! Без хәзер миллионнар түләп, Татарстанга кемнәрне генә чакырмыйбыз, ә үзебезнекеләр еш кына читтә кала.

Надир Дәүләтнең язмышы һәм фәнни хезмәтләре турында тәфсилләп язар өчен бу мәкалә кысалары бик тар булыр. Дөрес, берничә ел элек Мәскәүнең «Культура» телевидение каналында (Казанда түгел!) аның хакында күп серияле документаль фильм күрсәткәннәр иде. Ул фильмны караган тамашачылардан телевидениегә меңләгән хат килде, дип сөйләделәр. Тамашачыларны Надирның язмышы белән бергә аның Казанда яшәүче сеңлесе Фәридә язмышы да уйланырга мәҗбүр иткән. Әнисе тоткынлыкта чакта төрмәдә туган Фәридә тормышның бөтен ачысын-төчесен, кыенлыкларын күреп үскән, балалар йортларында җан асраган. Әмма барыбер тырыша-тырмаша Казанда университет тәмамлаган, заводта инженер булып эшләгән, тулай торактан (!) бүлмә дә алган... Нәкъ менә шул 1990 елда мин агалы-сеңелле бу ике туганның беренче мәртәбә очрашуларының шаһиты булдым. Кытайда туган, ике яшьтә ятим калып, Ибраһим атлы татар кешесе үзенә сыендырган, Төркиядә үскән, Германиядә белем эстәгән мөһаҗир Надир – бүген дүрт-биш телдә иркен сөйләшүче атаклы галим, профессор дәрәҗәсенә ирешкән мәшһүр шәхес. Ә үз ватанында туып, үз илендә белем һәм тәрбия алган, бүгенге көндә Татарстанда яшәп бер кәлимә татарча сүз белмәүче Фәридә Төркиядә гомер итүче туганы Надир аңа туган телендә эндәшкәч, берни аңламыйча, шактый ара сүзсез торды. Надирның татарча әйткән сүзләрен мин аңа русчага күчереп аңлата башладым. Русча белсә дә, Надирның үз туганы белән үз туган телендә аралашасы килгәнен күрү күңелемне нечкәртеп, күздән яшьләр китергән иде ул чакта.

Бу очрашу, бу ике гыйбрәтле язмыш турында аерым бер әсәр язып булыр иде...

Надир Дәүләт белән Фәридә Дәүләтнең туганлык мөнәсәбәтләре, аларның язмышлары турында уйлаганда, минем йөрәгем сулкылдый башлагандай була. «Безнең халык бүген, тулаем алганда, шушы Фәридә образына охшаш микән әллә?»

Ә Надир чит илләрдә яшәп тә югалмаган, язмыш карурманнарында адашмаган, үз-үзен саклаган, үз тирәсенә татар дөньясын өйрәнүче яшь галимнәрне туплаган, аларга канат куйган, хәләл җефете, саф төрек кызы Берилне татар теле, татар тарихы дөньясына алып кереп, аннан чын мәгънәсендә фикердәш һәм язмышына ышанычлы терәк ясаган. Татарстаннан читтә яшәп тә ул туган телен күз карасыдай саклаган, үз милләтенең бәгырь кисәге, аерылгысыз өлеше, нәни генә бер мөстәкыйль Дәүләте булып гомер иткән.

«Минем инде Татарстанда өченче китабым дөнья күрә. Бу факт – минем өчен шатлык чыганагы. 1990 елның маенда Казанга беренче баруымда болай булыр, дип уйламаган да идем. Ләкин ул визит миңа бик кадерле дуслар табуга юл ачып җибәрде. Шуларның иң беренчеләреннән, бүген инде мин «туганым» дип эндәшкән Разил Вәлиев булды... Соңгы 17 елда Казанда 3 китабым, 20 дән артык мәкаләм дөнья күрде. Бу эшләрнең барысы да миңа шушындый дуслар аркасында башкарылды. Алар мине татар халкы белән очраштырдылар. Ерак диаспорада яшәгән кеше өчен моннан артык горурланырлык нәрсә бармы икән? Юк!» – дип хисләнеп язган иде Надир Дәүләт.

Ә үземнең җавап хатымда мин аңа бераз шаяртып, болай дип язган идем:

*«Дәүләтең юк» диючегә*
*Мин болай диеп әйттем:*
*«Нишләп булмасын дәүләтем? –*
*Бар бит Надир Дәүләтем!»*

**Разил ВӘЛИЕВ,**
*Татарстанның халык шагыйре*

# ТАРИХЫҢ ЗУР, ЮЛЫҢ ЕРАК, ГАЛИҖӘНАП ТАТАР КИТАБЫ...



*Татарстан китап нәшриятына 100 ел тулу – татар дөньясы өчен аеруча әһәмиятле вакыйга. Әлеге оешманың генераль директоры **Илдар Камил улы Сәгъдәтшин** белән әңгәмәбез дә шул хакта.*

**– Татар китабы тарихы, мөгаен, меңәр еллар белән исәпләнәдер. Тузга язган сүзләр, тирегә язылганнары калган. Гомумән, Бөтендөнья төрки әдәбиятының да тарихы зур, безнең халыкта галиҗәнап Сүзгә беркайчан да битарафлык сизелмәгән. Шулай булмаса, Кол Галинең 1233 елларда язып тәмам ителгән дип фаразланган «Кыйссаи Йосыф»лары бүгенге көнгә исән-имин килеп ирешер иде микән?**

**Идел Болгарстаны чорында мәктәп-мәдрәсәләр эшләвен дә беләбез. Казан ханлыгы чорындагы бай китапханәләр, хаттатларның (китап күчерүчеләр) аерым остаханәләре дә эшләп торган диләр.**

**Ә бит беренче татар басмасы нибары 1722 елда гына Әстерханда басылып чыга. Бу Пётр Беренченең Иранга яу белән барганда язылган «Манифест»ы. Аны императорның киңәшчесе кенәз Кантимер һәм Тәфкилев фамилияле кеше тәрҗемә итә.**

**1785 елда Петербургта гарәп имласында татарча беренче китап дөнья күрә.**

**1801 елда Казанда беренче басмаханә ачыла. Аны Бурнашев дигән кеше ача.**

**Ә XIX йөзнең беренче яртысында Казан шәһәре Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан кала өченче урында тора. 1919 елдан китап басу дәүләт һәм партия органнары кулына күчә: Госиздат оеша.**

– Әйе, ул тарих белән мин дә кызыксындым. Әлбәттә, нәшриятка йөз ел тулу ул әле йөз ел элек китап чыкмаган дигән сүз түгел. Ә Госиздат Мәскәү нәшриятының филиалы буларак аерылып чыга ул чорда. Аннан Татиздат, Татгосиздат була.Татарстан китап нәшриятына әверелә.

Мин бүгенге көнгә кайтып, шуны әйтәсем килә: әле дә хөкүмәтебез безне ярдәменнән ташламый. Моның өчен рәхмәттән башка сүз юк. Нәшриятларга, шулай ук язучыларга һәм халыкка да, дип әйтергә кирәктер, матди ярдәм күрсәтү хәзер берничә республикада гына калганын да беләбез. Бу яктан караганда, без өченче урында: Башкортстан һәм Якутия генә бездән алдарак. Исемлекне Чувашия, Удмуртия дәвам итә бугай...

Нәшриятыбызга хөкүмәт ярдәме субсидия рәвешендә бирелеп килә. Өч ел элек гонорарлар түләү арттырылды. Дәүләт субсидиясе исә үзебездә чыккан китапларны үзкыйммәтеннән күпкә арзангарак сатарга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, Г.Тукайның төсле рәсемнәр белән бизәлгән, яхшы кәгазьдә басылган «Су анасы» китабы 70 сум тора. Әлбәттә, зур тираж белән чыккан китап бу. Тираж арткан саен китапның үзкыйммәте дә арзанрак. Без күргәзмәләрдә еш булабыз. Башкалар белән чагыштырып карыйбыз. Андый китапның 500 сумнан да арзанрак булганын күргәнебез юк әле.

**– Китап – әдәбиятыбызга, халкыбызның рухына сәнгати һәйкәл ул. Татар китабының йөз еллык язмышы Татарстан китап нәшрияты белән бәйле. Хәер, ничек аталса да, вазифасы бер үк: рухи тарихыбызны теркәп калдыру, гади итеп әйткәндә, заман укучысына яңа әдәбиятны җиткерү. Халыкның рухи яшәешен**

**тәэмин итү. Бүгенге көндә йөз еллык китап нәшрияты нинди чор кичерә? Тарихта үз эзен калдырырлык потенциалы бармы аның?**

– Нинди генә яңа технологияләр кермәсен, заман ничек кенә алга бармасын, китапның дөнья мәдәниятендә үз урыны бар. Халык укымый, дигән сүз дөрес түгел ул. Безнең складларда тузан җыеп яткан продукция, гомумән, юк. Китапның бит аның төрлесе була. Классикларыбызның әсәрләре, күптомлыклар мәсәлән, берьюлы бөтен кешегә дә кирәк түгел. Соңгылары алучыга да кыйммәткәрәк төшә. Әмма кем генә килеп сораса да, мондый китаплар безнең складта булырга тиеш. Соңгы ике ел эчендә Г. Ибраһимовның унбиш томлыгының биш томы, Р.Батулланың ун томы, Р.Вәлиевнең җиде томы басылып чыкты. Аннан, күптомлыклар – үзенчәлекле продукт, алар тарих өчен кирәк, язучыга бәяләмә кебегрәк тә. Аларны халык китапханәләрдән алып укырга ярата.

Нәшриятта елына якынча 200 ләп китап чыга, бу – көн дә яки көн аралаш бер яңа китап дигән сүз. Ләкин китап саны белән исәпләү һич дөрес түгел: ул бик калын да, бик юка да булырга мөмкин. Без табаклар саны белән исәплибез. Шулай да дәүләттән бирелә торган сумма үзгәрешсез, ә кирәкле чималга – кәгазь, буяуга һ.б. хаклар ел саен артып тора. Кәгазь бәясе былтыр 15 процентка күтәрелде. Димәк, барыбер дә аякны юрганыбызга карап сузарга туры килә.

Без ихтыяҗ һәм заманчалыкны алга куеп эш итәргә тырышабыз. Бүген менә электрон китапларга максатчан аудитория барлыкка килде. Кемдер басма китап ярата, кемдер икесен дә читкә этәрми. Үзем дә соңгы арада шактый аудиокитаплар тыңлыйм. Беркөнне машинада «Тапшырылмаган хатлар»ны тыңлап барам. Бер өлеше инде онытылган икән. Кайттым да китапны актарып карадым. Яңадан укып чыктым. Аудиокитаплар миңа гына түгел, күпләргә басма китапны эзләп табып укырга этәргеч булачак, дип уйлап куйдым...

**– Илдар Камилович, сез аудиокитаплар халыкны басма китаптан читләштермәячәк, дисез инде?..**

– Юк. Безнең өчен укучылар даирәсен киңәйтү һәм төрлеләндерү генә ул. Басма китапларны бөтенләй укымый торган кешеләр дә бар бит. Яшьләр күбрәк интернетта. Әлбәттә, минем уйлавымча, һәр прогресс ялкаулыктан килеп чыга. Элек телевизорны розетка янына барып кабыза идек бит, хәзер диванда яткан көе генә төймәгә басасы. Монда да шул ук хәл. Басма китапны кибеткә барып сатып алырга кирәк. Ә бу очракта аудиокитап булып, ул үзе өйгә килеп кергән. Балаларны мәктәпкә, бакчага илткәндә, машинада мин ешрак «Татар халык әкиятләре»н куям. Тыңлап барырга мәҗбүрләр. Машинадан төшеп китә алмый бит бала... Тиктормас бала-чага өчен китап пропагандалауның бер дигән чарасы инде бу. Заманында әни (шагыйрә Ф.Мөслимова – **Ф. Ж.**) минем өчен шулай тырыша иде. Нинди генә шагыйрьләрне укымады!

Текстларны Г. Камал театры артистлары Р.Шәрәфиев, Д.Нурлы, Х.Җәләй, Ә.Шакиров һ.б. укуында тыңлау үзе бер рәхәт. Аудиокитапта, мәсәлән, Г.Тукайның «Су анасы» бирелә икән, анда тыңлаучы әсәрне куәтләү чараларына да игътибар итми калмыйдыр: су тавышы, этләр өрүе һ.б. Болар – текстның кабул ителүен көчәйтүче чаралар. Әсәрләр, хәтта, бераз радиоспектакльгә дә охшап китә. Артистларыбыз бу эшкә теләп алынды: барысы да халык өчен икәнне аңлыйлар, күпме түлисез, дип сораганнары да юк, рәхмәт һәммәсенә. Аларның дөрес итеп татарча сөйләве үзе үк телебезгә мәхәббәт тәрбияли бит инде. Бүгенге заман өчен монысы да бик кирәк. Аннан, бу эшне без киләчәк өчен дә эшлибез. Мәсәлән, татарча биш йөз ел элек сөйләнгән берәр текст тыңлау минем өчен бик кызык булыр иде кебек.

Бүген сайтта 162 сәгатьлек аудиокитап бар. «Татар халык әкиятләре» генә дә 22 сәгатьлек. Быел исә 600 сәгатьлек аудиокитаплар яздырып, сайтка урнаштыру планлаштырылган.

Иң әһәмиятлесе: сукырлар җәмгыятьләре шактый бездә, әлеге проект исә күзләре күрмәүчеләр өчен зур бүләк булды. «Ничек мондый эшне башкарып чыга алдыгыз?» дип, рәхмәт әйтеп еш шалтыраталар. Бу күләмле эшкә һич тә үз көчебезгә ышанып кына тотына да алмас идек, Президентыбыз – Рөстәм Миңнеханов ярдәм итте.

Хәзер безнең шушы проектыбыз белән кызыксынучылар ишәйде. «Татнефть»тән Саҗидә Сөләйманова иҗатын шулай эшләп булмасмы, дип мөрәҗәгать иттеләр. Башка республикалардан, чит төбәкләрдән өйрәнергә килүчеләр бар.

Өстәвенә, интернет-сайтыбызда электрон китапларның ассортименты бай, аларның күбесе – бушлай.

Шуны онытмаска кирәк: әлеге проектлар безнең төп эшчәнлеккә керми. Төп эшчәнлегебез – басма китаплар.

**– Әлбәттә, әдәбият ул халкыбызның рухи күрсәткече дә. Аның меңәр еллык тарихын, тормыш-көнкүрешен, җәмгыятьнең кайчан кайсы якка үзгәрешен язучыларыбызның әсәрләре билгели. Бер мәшһүр гаскәр башлыгы юкка гына: «Мин тарихны әдәби әсәрләр аша өйрәндем», димәгән. Аллага шөкер, бездә чорны тарихка теркәп калдырырдай язучыларыбыз байтак булган һәм бар.**

**Нәшриятның йөзен дә гомер-гомергә язучылар билгеләгән. Бердән, басылган китапларның күпчелеге – матур әдәбият. Укучының көткәне дә – яңа әсәрләр. Әдәби әсәрнең эчке дөньясын яхшырак тоемлагангамы, нәшриятта кайсы гына чорны алсаң да, язучылар эшләгән.**

**Истәлекләрдә XX гасырның егерменче елларыннан, ягъни Галимҗан Нигъмәти, Фәтхи Бурнаш, Ибраһим Гази, Гази Кашшаф, Фатих Кәрим, Мирсәй Әмир, Гомәр Толымбай, Гомәр Бәширов, Нур Баян, Сибгат Хәким, Фатих Хөсни, Афзал Шамов, Мөхәммәт Садри һ. б. бик күп әдипләребез искә алына. Күренекле әдипләребез үзләренең тырыш хезмәтләре, яшь авторларга мөнәсәбәтләре, аларда әдәби-эстетик зәвык тәрбияләүдә үзләреннән шактый өлеш керткәннәр. Зур язмышлардан, әлбәттә, тарихта да яхшы энергетика калган. Яхшы эшләр, яхшы әсәрләр... Аларны Шәүкәт Галиев, Вакыйф Нуруллин, Марс Шабаев, Шамил Рәкыйпов, Харрас Әюп, Рафис Корбан, Мөдәррис Вәлиев, Наис Гамбәр, Фәиз Зөлкарнәй, Солтан Шәмси, Фәүзия Бәйрәмова һ.б. язучыларыбыз алыштырган. Бүген исә тулы бер гасырлык традицияне кемнәр дәвам итә?**

– Әйе, нәшриятның дәрәҗәсен арттыручы кешеләр алар – язучылар. Әдәбиятны алардан да яхшырак кем белсен соң? Бүгенге көндә бу традицияне нәшриятның баш мөхәррире, шагыйрь Ленар Шәех, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь Газинур Морат, язучы Галимҗан Гыйльман, шагыйрь Рифат Сәлахлар дәвам итә икән, димәк, нәшрият әле элекке эздән чыкмаган.

Аннан, мин безнең коллективта кемдер начаррак эшли, дип әйтмәс идем. ТКН – сыйфат билгесе ул. Һәркем үз эшенең остасы булмаса, мондый уңыш белән мактана алмас идек. Нәшрият коллективы сәгать кебек төп-төгәл эшли торган механизм. Элек «Правда» газетасы ничек язган – шул дөрес, диләр иде бит... Безнең хакта да шулай әйтерлек. Совет чорында иҗатка һәм пропагандага аеруча зур игътибар бирелгән: аерым дәүләт ГОСТлары кабул ителгән. Басылып чыкканчы, биш тапкыр укылган бер китап. Әле дә шулай. Үзгәреш кергәне юк. Иң мөһиме: хата калмаска тиеш. Шуңа да Татарстан китап нәшриятында китап чыгарырга теләүчеләр саны кимеми. Бу беренчедән, сыйфатка бәйле булса, икенчедән, дәүләт нәшриятында чыккансың икән, димәк, син язучы буларак өлгергән дигән сүз, укучы да сине тизрәк күреп алачак.

**– Директорлар составы да шактый икән инде: мин белгәннәре генә дә Гарәф Шәрәфетдинов, Ринат Мөхәммәдиев, Харис Әшрәфҗанов, Дамир Шакиров, Илдар Сәгъдәтшин...**

**Нәшрият тарихына һәрберсе нинди дә булса нәтиҗәле эшчәнлеге белән кереп калган. Гарәф Шәрәфетдиновны китапның, язучының кадерен, дәрәҗәсен белүче җитәкче иде, диләр. Харис Әшрәфҗановны 90нчы еллардагы кризис чорында да татар китабын югалтуга юл куймады, коллективны ач тотмады, дип искә алалар. Дамир Шакиров вакытында күптомлыклар күпләп басылды. Ә сезне җәмәгатьчелек, эшли башлауга, Мәскәүдәге китап күргәзмәсенә баргач, Президент В.Путинга Г.Тукайның үз нәшриятыбызда унбиш телгә тәрҗемә ителеп басылып чыккан «Шүрәле» сен бүләк итеп, татар китабын «өстәгеләргә» җиткерүче буларак искәреп калды. Ул китапны ил башы кулына тапшырганда, уегызга килгән фикерләрне безнең дә беләсе килә...**

– Минем, әлбәттә, сез әйткәнчә генә тарихта каласым килми. Һәркем урынны эше белән яуларга тырыша. Киләчәктә дә зур-зур эшләребез булыр әле дип өметләнәм. Әйе, Президент В.Путин белән биш ел элек Мәскәүдә китап күргәзмәсендә очрашу

мөмкинлегем булды. Китапларның затлылыгын күрепме, яныбызга аерым тукталды. Ун минутлап сөйләшеп тордык. Ул Татарстанда нинди китаплар чыгуы белән кызыксынды. Күбрәк нинди телдә нәшер ителә, дип сорады. Мин Татарстанда – үзебездә чыккан китаплар турында сөйләдем. Ул безнең китапларны бик кызыксынып карады. Г.Тукайның 15 телдә басылган «Шүрәле»сенең немец телендәге вариантын укып: «Яхшы язылган», – дип мактап та куйды. Мин китапларыбызның 85 проценты татар телендә басылуы хакында әйттем. Президент: «Бу – бик дөрес», – дип бәяләде.

Ә күргәзмәләр хакында сүз чыккач, шуны әйтер идем: безнең үзебездә чыккан китаплар өчен оялганыбыз юк. Алар сыйфат ягыннан башкалардан аерылып та тора әле. Китапларны төрлесеннән һәм сайланырлык итеп тә алып барырга тырышабыз.

**– Сезнең өчен коллектив ни ул?**

– Икенче гаилә, дисәң генә инде. Гомеребезнең күп өлеше эштә уза бит.

**– Коллективта күпме кеше эшли?**

– Тотрыклы өлеше 80ләп кеше. Ә болай проектларга карап, вакытлыча эшкә шактый белгечләр яллыйбыз.

**– Сез усал җитәкчеме?**

– Мин кабинет саен кереп: «Син нәрсә эшлисең?» – дип тикшеренеп йөрүне хупламыйм. Үзем дә ирек яратам. Кешеләрнең дә бернинди басымсыз ирекле эшли белүләрен бәялим. Чикләүләр иҗатка комачау итә. Ә китап эше – иҗади эш ул. Минем максатым – иҗат эшенә мөмкинлек тудыру.

**– Нәшриятка кризис кагылырга да мөмкин, ә бит әдәбиятка кагылырга тиеш түгел ул. Әдәбиятка кагылганы кешеләрнең рухын зәгыйфьләндерә, халыкның яшәү көчен бетерә, алай гына да түгел, җәмгыятьнең иминлегенә куркыныч яный дигән сүз. Алтын урталыкны ничек табып, моны бүгенге көндә ни рәвешле хәл итеп була? Бүгенге көндә тиражларның коточкыч тизлектә кимүе әнә шушы упкынга табан атлау түгелме? Гарәф ага Шәрәфетдинов «Һәр буынның үз тарихы» исемле истәлек-мәкаләсендә: «Балалар, яшүсмерләр өчен милли китаплар чыгару бик нык кимеде. 1970 еллар башында татарча шигырь китапларының уртача тиражы 7–8 мең данә тирәсе булса, биш елдан ул 4–5 меңгә, 1980 елларга кергәндә 3–4 мең данәгә кадәр төште. Шушы ук хәл башка жанр китапларына да тәэсир итте», – дип язган иде. Бу җәһәттән XXI гасыр китаплары тиражы ничегрәк күзаллана?**

– Шигырь китапларын сату авыррак. Шигырьне 17-18 яшьлекләр үзләре язалар, алар өчен беркем дә авторитет түгелдер кебек. Чын шигырьне укучылар да, язучылар да аз. Урта яшьтәгеләр, олыраклар проза укый. Тарихи китаплар, балалар әдәбияты яхшы сатыла. Тираж да ихтыяҗга карап куела. Балалар китабына ун-унбиш мең дә булырга мөмкин ул, ә шигырьгә бер меңнән артмый инде... Элек бит 300-500 мең тираж белән чыккан китаплар да булган. Алып бетергән халык... Кайчак азык-төлек кибетендә карап торам: ата-ана бала ни сораса, шуны ала. Ә китап янында акчасын чыгарырга никтер ашыкмый.

Рухи ихтыяҗга кризис кагылмаска тиеш, дигән фикер белән килешәм. Язучылар язсыннар гына. Ләкин кабатлап бастыруны сорап килүчеләр дә шактый. Кабатлап бастырулар яңа әсәрләргә юлны яба бит.

**– Н.Кушнер: «Тарих ул – киләчәк фәне», – дигән. Ерак тарихтан чыгып караганда, татар халкын укымый торган милләт дип булмый кебек. Бәлки китап укучыга барып җитмидер? Аны илтеп җиткерүнең нинди юлларын күрәсез? Китапка рухи азык итеп түгел, ә сатыла һәм сатып алына торган товар итеп карау дөресме?**

– Татарстан җитәкчелеге халыкны рухи азык белән тәэмин итүдән баш тартканы юк: бездә чыккан китапларның 85 проценты республика китапханәләренә һәм республикадан читтә урнашкан китапханәләргә таратыла. Халыкка уку, рухи азык алу мөмкинлеге бирелгән. Һәм халык китапханәләргә юлны суындырмый.

Элек «Таткнигаторг» дигән оешма булган. Тарату, сату белән шөгыльләнгән. Ул банкротлыкка чыккач, бу эш һәр нәшриятның үз җилкәсенә авып калган.

Чарасызлыктан маркетинг бүлеген булдырырга туры килгән. Сату-алу җирлегенә күчкәч, китап та товарга әйләнгән инде.

Аренда түләп зур кибетләр тоту бүген үз-үзен акламый. Китап ипи түгел, аның кемгә кайчан кирәге чыгасын алдан белеп булмый. Ул озак кына үз алучысын көтәргә дә мөмкин. Бозылыр, дип куркасы юк. Кибетләргә килгәндә, безнең бер кибетебез – ГУМда, икенчесе дә Бауман урамында, тарихи бинада – Матбугат йортында урнашкан. Аннан без китап кибетләре белән элемтәләрне ныгытабыз. Аерым китап сату челтәрләре белән эшлибез: 800 дән артык кулдашыбыз бар. 200 ләп оешма бездән күпләп сату өчен китаплар ала. Республиканың төрле шәһәрләрендәге китап кибетләрендә нәшриятның китап киштәләре бар. Киштәләрдә китаплар гел яңартылып тора. Әдәбият сөючеләргә республика районнарында китап бәйрәмнәре оештырабыз: анда алар билгеле шәхесләр, мәшһүр язучылар, нәшрият мөхәррирләре белән очраша, яңа китаплар белән таныша, кыскасы, үзләренә рухи байлык ала. Мөхәммәт таугa килмәсә, тау Мөхәммәткә килер, диләрме? Менә шулай.

**– Укучының ихтыяҗын ничек белеп була соң?**

– Китап бәйрәмнәре, китапханәләр челтәре белән берлектә «Ел китабы» бәйгесе уза. Алар китапханәләрдән алынган мәгълүматлар аша иң күп укылган китапларны санап-исәпләп чыгаралар. Сайтларда укылган китапларны да күзәтеп торабыз. Ничек сатылуга да игътибар итәбез. Китапханәләрдән, маркетинг бүлекләреннән алынган мәгълүматлар безнең киләчәктәге эшебез өчен мөһим. Планга кергән китаплар чынлап та кешегә кирәкле булырга тиеш. Бер тапкыр мин Газинур абыйдан (Морат): «Бик әһәмиятле китап дип нәрсә тәкъдим итәр идегез?» дип сорадым. «Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»н бастыра алсак, милләт өчен файдалы эш булыр иде, тик күп акчалар кирәк булачак инде», – диде. «Миллият сүзлеге» булган милләт юкка чыкмас,  дип тә өстәде. Инде сүзлекнең өч томы да басылып бетте. Ихтыяҗлар да төрле: милләт ихтыяҗы, яшьләр ихтыяҗы, яхшы әдәби әсәрләргә ихтыяҗ, тарихи китаплар, сүзлекләр һ.б. Без барысын да күз уңында тотарга тырышабыз.

**– Дәреслекләр мәсьәләсе ничегрәк тора?**

– Дәреслекләр бастыру юнәлешендә ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы заказы буенча эшлибез. Мәктәпләрдәге ихтыяҗны алар өйрәнә. Даими заказларыбыз бар. Нәшриятыбыз эшчәнлегендә бу юнәлеш – аерым игътибар үзәгендә. Дәреслекләрне нәшриятыбызда эшләүче югары квалификацияле мөхәррирләребез зур җаваплылык тоеп әзерли.

**– Ә нәшриятның йөз еллык гомерен ничегрәк теркәп калдырырга җыенасыз?**

– Бәйрәм чаралары башланды инде. Бу уңайдан хөкүмәтебез карары нигезендә оештыру комитеты төзелде. Аны ТР Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева җитәкли. Нәшрият тарихына багышланган альбом чыгарырга җыенабыз. «Татар китабы» сериясеннән икенче китапны әзерләдек. Шул уңайдан халыкка якынаюның тагын бер юлын җайладык: районнарда язучылар белән бергәләп «Китап бәйрәме», очрашулар уздырабыз. Сатуга китаплар да алып барабыз. Һәр районга барып җитәргә исәп тотабыз. Татарстанның күпчелек районнарында булырга өлгердек инде. «Әдәби марафон»да, төрле күргәзмәләрдә катнашабыз. «Безнең Мирас» һәм «Тылсымлы куллар» журналлары белән берлектә әдәби конкурс оештырдык. Әдәбият сөючеләргә китаплар тәкъдим итәбез. Дөресрәге, безнең максатыбыз – халыкның игътибарын китапка юнәлтү.

**– Бүгенге базар шартларында нәшриятның киләчәге ничегрәк күзаллана? Милли мәсьәлә катлауланып кискенләшкән бер чорда нәшриятка үзенең йөз еллык традицияләрен саклау кыенга төшмәсме?**

– Тарих тәгәрмәче гел әйләнеп тора. Иртәгә ни буласын беребез дә тәгаен генә әйтә алмыйбыз. Бәлкиниләрдер үзгәрер дә. Әмма кушылучыларның урыннарын алыштырудан сумма үзгәрми, дигәндәй, китап барыбер чыгачак, дип уйлыйм. Традицияләр дә саклаер, эз салынган бит инде. Бездә өмет бар, эшләргә теләгебез бар. Яңа проектларыбыз да җитәрлек... Аларны заман үзе әйтеп җибәрә. Халык ихтыяҗы алгы сафта. Ә татар халкында китапка ихтыяҗ бар һәм булачак.

*Әңгәмәдәш* – **Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА**

# КӨМЕШ КАСӘ СЕРЛӘРЕ

Еш кына кечкенә ачыш зур тарихны үзгәртергә сәләтле булып чыга. Сүзебез шул хакта булыр.

Археологиядә «Алтын адәм» исеме белән билгеле, ягъни алтын киемнәргә киенгән мәрхүм – патша-хан яки аның уллары каберлеге 1969-1970 елларда Ыссык-күлдә табыла. Бүгенге көнгә ачылган биш курганның беренчесе була ул. Безнең эрага кадәр VI-IV гасырларга караган әлеге мазарда патша улы – 16-18 яшьлек сак сугышчысы күмелгән, диләр (хатын-кыз сугышчы дигән фараз да яши). Курганның үзәк өлеше ике тапкыр талана, әмма караклар ян-яктагы камераны тапмый. Нәкъ шунда алтын киемгә киендерелгән мәрхүм җәсәде, алтын кораллар, хуҗалык кирәк-яраклары белән бергә, төбенә тышкы яктан ниндидер сызыклар тырмалган көмеш касә дә табыла.

Беренче булып касәдә төрки рун язулар икәнлеген күренекле казакъ язучысы Олжас Сөләйманов белдерә (1970 ел). Ул 26 хәрефнең сигезен төрки рун белән тәңгәлләштереп, аны үзенчә укып карый. Нәтиҗәдә мондый текст күрә: «Хан улы егерме өчтә юк булды, даны көлгә әйләнде».

Әлбәттә, 8 хәреф текстның эчтәлеген укуга дәлил була алмый. Аннан соң бу эшкә алынган профессор Алтай Аманжолов 26 хәрефнең барысын да төрки рун, финикий, арамей һәм мессан әлифбалары белән чагыштырып карый, текстның борынгы төрки телдә булуын дәлилләп, һәрберсен уңнан – сулга, төрки рунда укый (1971 ел). Мондый текст килеп чыга: «Ага, сиңа (бу) учак! Чит (кеше), (тез) чүк! Бүген азык булыр!» (Aya, sana ocuq! Bez, cok! Boqun isra (r?)azuq! ...i). Шуннан чыгып, Аманжолов касәдәге текстның рун язуының чишмә башы булган борынгы төрки язу үрнәге булуын әйтә.

Әлеге язма басылып чыгуга, текстны укуга күп кенә танылган галимнәр кушылып китә. И.М.Дьяконов, В.А.Лившиц, С.Г.Кляшторный аны арамей әлифбасы (аның б.э. кадәрге I гасыр варианты) белән чагыштырып карыйлар. Бу очракта касә читтән, Ираннан кертелгән дигән фикер алга сөрелә. Әмма мәгънәле текст килеп чыкмый.

В.А. Лившиц аның фарсы халыкларына, аларның «кхарошти» әлифбасына каравын фараз итә (1978 ел), шушы нигездә маҗар филологы Янош Хармат та беренче сүзне «касә» дип укый (1994 ел) һәм текст мондый эчтәлекле түгелме дигән фикер белдерә: «Касәдә йөзем шәрабе. Аңа май кушылган». Әмма бу версия фарсы теле белгечләре тарафыннан кире кагыла.

Тамырларында Казан татарлары каны аккан азәрбайҗан галиме Исмехан Госманлы А.С.Аманжолов рәсемен һәм ул ясаган транслитерацияне чагыштырганда (2014 ел), бер үзенчәлеккә игътибар итә: ике юл итеп бүленгән 26 хәрефтән тыш, алардан өстәрәк тагын бер сызык бар! Моны казакъ галиме икенче юлга сыеп бетмәгән соңгы «и» хәрефе дип күрсәткән була: «azuq! ...i». Әмма касәдә аның урнашу урыны бу билгенең текстны башлап җибәргәнен сөйли. Уелу рәвеше исә рунда «л» хәрефе буларак укырга кирәклекне искәртә. Борынгы төрки әлифбада сузык авазлар булмау И.Госманлыны бу беренче өлешне «или» яки «ылы» сүзе дип укырга этәрә. Каберлек таудан төшә торган Иссык елгасының Или (Ылы) елгасына коя торган үзәнлектә урнашкан. Димәк, беренче билге күмелү урынын күрсәтә.

Или (Ылы) топонимын галимнәр бик борынгы төрки телдәге җылы сүзенең варианты, ә Иссыкны – эссе, кайнар елга дип карыйлар. Тел белемендә топонимнарның гасырлар дәвамында үзгәрешсез саклануы кагыйдә дип санала. Димәк, бу җирләрдә, саклар килгәнче үк, төрки кабиләләр яшәгән, алар гел күченеп торсалар да, атамалары үзгәрешсез калган.

Шулай итеп, әлеге версия борынгы төркиләрнең бик борынгы заманнардан ук язулы булуы хакындагы ачышка тагын бер дәлил.

*Бу хакта Азәрбайҗан Милли фәннәр академиясенең (НАНА )*
*М.Физули исемендәге Кулъязмалар институты фәнни хезмәткәре*
*Исмехан ГОСМАНЛЫ белән Дания ЗАҺИДУЛЛИНА сөйләште.*

## ИҖАТЫҢА АК ЮЛ СИНЕҢ, БАЛА!

Журналның һәр санында кызыклы әсәрләр басыла тора. Бу бик куанычлы хәл. Май саны мине аеруча куандырды, дисәм, һич тә артык булмас. Андагы башка әдәби уңышлар белән беррәттән якташым, дөресрәге, авылдашым, тагын да дөресрәге, безнең Бәләкәй Кәркәле авылыннан өч-дүрт чакрымда гына яткан, бишенче-җиденче сыйныфларда без көн саен җәяү йөреп укыган Олы Кәркәледән булган (исемнәре раслап торганча, аларны еш кына бер авыл, дип тә телгә алалар) Розалина Тимербулатованың «Сагыну» хикәясен телгә алсам, бик тә урынлы булыр кебек. Ул мине үзенең җыйнаклыгы, кыскалыгы, теленең гадилеге, байлыгы, моңлылыгы, сюжетының тормышчанлыгы, халыкчанлыгы белән куандырды. Матбугатта беренче тапкыр бердәнбер хикәясе белән әле кичә генә чыгыш ясаган кыз бала өчен бик зур вакыйга бит инде бу! Чынлап әйткәндә, җиңү дип бәяләнерлек бу адымы белән мин Розалинаны, аның ата-анасын, туганнарын, авылдашларын чын күңелдән котлыйм. Хикәяне басарга әзерләгән, аны «Җәһәт тәнкыйть» белән тәкъдим иткән хадимнәргә рәхмәтләремне белдерәм.

Мине бу хикәя икенче яктан да якты тойгылар белән баетты. Эш шунда ки, мин, шушы авылдан чыккан, 77 яшь өстенә баскан, дистәләрчә китаплар нәшер иткән автор, Казан кадәр Казанда чыга торган «Казан утлары»нда Розалина сеңлемнең шушы искиткеч моңсу хикәясен укыгач, «57 ел буе әдәбиятка хезмәт итеп, үземнең туган ягым, бу очракта туган авылымнан бер генә язучы да үстереп чыгара алмадым» дигәнрәк шактый шартлы үкенечтән (чөнки әле Розалинаның нинди юл сайлавын, кайсы юнәлеш белән китәчәген фаразлавы авыр) гаҗизләнеп йөргән көннәремдә ул, мине бу «гаеп»тән коткару юлында уңышлы адым ясады кебек. Амин, шулай булсын. Әлбәттә, хәзерге заманда әдәбиятка килү һәм анда үзеңчә юл саба алу – бик четерекле бурыч. Әмма куркырга кирәкми. Милләтебез батыр, акыллы, талантлы яшьләребезне иман өчен көрәш кырында көтә.

Авылдаш сеңлемне уңышы белән котлый алу, әйткәнемчә, минем үземә дә шатлык китерде. Кайчандыр «Казан утлары»бызда (1966 ел, 9 нчы сан) минем беренче шигырьләремне Башкортстанның халык шагыйре, быел октябрь аенда 100 еллыгы билгеләп үтеләчәк Мостай Кәрим зур өметләр баглап, дөньяга күрсәткән иде. Мин аңа мәңге рәхмәтле булдым. Куанычка, аның ышанычын әсәрләрем белән акладым бугай. Розалина сеңлем Тимербулатовага да шундый язмыш насыйп итсен иде.

**Айдар ХӘЛИМ,**
*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе*

---

*Игътибар!*

## «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең филиалы «Казан утлары» журналы редакциясе» ТАССРның 100 еллыгына багышлап иң яхшы әдәби очеркка конкурс игълан итте.

Ул **2019 елның 1 гыйнварыннан 2019 елның 15 декабренә кадәр** үткәрелә. Татар телендә язылган, моңарчы беркайда басылмаган очерклар гына кабул ителә. Аларның күләме А4 форматында 15 биттән артмаска тиеш.

Конкурста катнашучылар үзләренең эшләрен электрон почта аша җибәрергә яки «Казан утлары» журналы редакциясенә электрон вариантын китерергә тиеш.

Җиңүчеләр жюри тарафыннан **2019 елның 20 декабрендә** игълан ителә. Премияләр:
**I урын – 15 000 сум (бер премия).**
**II урын – 10 000 сум (бер премия).**
**III урын – 7 000 сум (бер премия).**
**Кызыксындыру премияләре – 3 000 сум (өч премия).**

# КАЗАН ҮЗӘГЕНДӘ – «ТАТАР КИТАБЫ ЙОРТЫ»

Островский урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан музейны казанлылар моңарчы Шәриф Камал музей-фатиры дип белә иде. Хәзер ул яңа концепция буенча «Татар китабы йорты» буларак тәкъдим ителде. Рәсми исеме – «Татар әдәбияты тарихы музее һәм Шәриф Камал мемориаль фатиры».

Йорт XIX гасырда төзелеп, революциягә кадәр Т.С.Санин, М.И.Подуруева, И.Д.Иванов, Д.И.Журавлёв исемле берничә сәүдәгәр кулында була. 1908 елда фасады белән эчке бизәлеше көнбатыш Европа бароккосы стилендә эшләнә. Совет заманында йортның бүлмәләре коммуналь фатирлар итеп бүленә.

Шәриф Камал мемориаль музей-фатиры 1950 елда ачыла һәм республикадагы татар язучысына багышланган беренче музей була. Татар әдәбиятының классигы, прозаик, публицист, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе Шәриф Камал бу фатирда 1928 елдан алып 1942 елга кадәр яши. Язучының фатиры өч бүлмәдән гыйбарәт. Беренче бүлмәдә Шәриф Камалның үзе, гаиләсе һәм иҗатташ дуслары белән бәйле документлар, фотографияләр, шәхси әйберләр урын алган булса, калган ике бүлмә мемориаль рәвештә торгызылган. Зур бүлмә берьюлы эш бүлмәсе, аш бүлмәсе, шулай ук кунак бүлмәсе вазифасын да үтәгән. Бинадагы затлы мич бүгенгәчә сакланган. Янәшәдә – кечкенә генә голландка миче, анысы кырыс сугыш елларында чыгарыла. Кечкенә бүлмәдә Шәриф Камал йоклаган караватт, кулдан ясалган китап киштәсе урнашкан. Кунак бүлмәсендә язучы якты дөнья белән хушлашкан вакытны күрсәтүче түгәрәк сәгать эленеп тора – аның телләре 15 сәгать 30 минутны күрсәтә. Алар 1942 елның 22 декабрендә туктатылган.

Татар китабы йорты концепциясе буенча биредә татар телендәге һәм татар темасына кагылышлы барлык басма һәм электрон китаплар тупланырга тиеш. Аларның төп өлеше китапханәдә урнашкан. Китапханәдә шулай ук татар язучылары, галимнәре фондларга бүләк иткән шәхси китаплар белән шәхси предметлар да саклана. Экспозициядә Ш.Мәрҗани, Г.Баруди, сәүдәгәр Юнысовлар, Г.Апанаевның автографлары һәм мөһерләре куелган басмалар, К.Нәҗми, Г.Бәширов, Г.Ахунов, В.Нуруллин, Г.Әпсәләмов, И.Кәлимуллин, З.Рәмиев, Ф.Хатыйпов, Р.Сверигин, М.Әхмәтҗанов һ.б. язучылар белән галимнәрнең шәхси китапханәсеннән китерелгән китаплар бар.

Музейның төп экспозициясе – «Татар китабы тарихы: пергаменттан – цифрга» дип атала. Борынгы һәм урта гасырларга караган чыганаклардан башлап, безнең көннәргәчә татар китабы нинди юл үткән – экспозиция әнә шул хакта сөйли. Уникаль экспонатлар арасында Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы кульязма күчермәләре, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорына караган кульязма үрнәкләр – Рабгузи, Мәхмүд Болгари, Мөхәммәдьяр ядкарьләре.

Татар басма китабы тарихының тамырлары XVIII гасырга барып тоташа, нәкъ шул гасырда Сәгыйть Хәлфин тарафыннан Коръән һәм Татар теленең әлифбасы бастырып чыгарыла. Татар китабы йорты электрон яктан заманча бай һәм югары дәрәҗәдә җиһазландырылган. Электрон экспозиция, киосклар һәм станцияләр, мэппинг эшли: «Шәриф Камал һәм аның дәвере», «Тәрәзәдән күренеш: 20-30 нчы еллар Казаны», «Татар язучылары: репрессия корбаннары», «Татар әдипләренә багышланган видеоархив» «Татар китабы тарихы», «Китап һәм аның өлешләре» һ.б.

Балалар бүлмәсендә татар телендә уеннар, спектакльләр, кызыклы чаралар оештырыла. «Татар балалар китабы дөньясы» интерактив экспозициясе эшли. Бүлмәдә шулай ук татар балалар әдәбиятын тәшкил иткән иң атаклы китаплар, әлифбалар тупланган.

Музейның мемориаль-экспозицион өлеше, нигездә, 2 нче катта урнашкан булса, 1 нче кат күбрәк милли интеллигенцияне туплый торган ирекле, ачык мәйдан буларак күзаллана. Биредә типография, китап кибете һәм Коворкинг эшли. Милли-интеллектуаль уеннар, квест, лекторийлар, түгәрәк өстәлләр, интерактив чаралар – Татар китабы йортының ишекләре мондый төр милли чараларга сусаган һәркем өчен ачык.

**Луиза ЯНСУАР**



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Зиннур МАНСУРОВ**

## Хатын нәрсә әйтер?!

Мәгълүм ки, Салих Баттал олуг язучы гына түгел, махсус белемгә ия очучы да иде. Бөек Ватан сугышы чорында ул Хәрби Һава Көчләренең Тын Океан флотында очучы буларак көрәшә, аңарчы конструкторлык бюросы каршындагы сынау отрядында Р-5 очкычыннан җиргә мөһим йөкләр ташлау белән шөгыльләнә. Күңеленә уен-көлке, киная, төртмешләр тулган әдип «Борчылма» исемле дүртьюллыгын тикмәгә генә язмагандыр.

*Шулай шәһәр өсләп очкан чакта,*
*Тәрәз ачып, аска төкердем.*
*Борчылмагыз: мин бит төкрегемне*
*Чүп-чар савытына төшердем.*

Гелән алай булмый икән. Тормыш үзе дә еш көләргә ярата...

Һәрвакыт туган авылын сагынып яшәгән Салих Баттал, Казанның 9 нчы трамваенда колхоз базарына барып, атна саен дистә ярым йомырка алып кайта. Менә ул Волгоград урамындагы йортыннан ерак түгел тукталышка якынлашып килә. Уң кулында – үреп эшләнгән сетка, сул кулында – кондуктор биргән билет. Товары, шөкер, исән-сау. Баскычтан төшкәч, әдипнең баш мие нерв җепселләре аша кулына әмер бирә: трамвай билетын ташларга! Бүтән төрле уйларга чумган зат мизгел эчендә бөтенләй буталып кала. Ул үтә күренмәле кечкенә ятьмә капчыгын... бетоннан коелган чүп савытына атып бәрә. Ә йомыркалар челпәрәмә килеп ватыла, сарылары аяк астына агып төшә.

– Эх, чүп савытына салават күпереннән кирәкмәс нәрсәләрне генә ташлаган чаклар бар иде, – дип көрсенә чал чәчле Салих Баттал, сул кулындагы билетны учына ныграк кысып. – Өйгә күкәйсез кайтсам, хатын нәрсә әйтер?!

## Җитди шаярту сабагы

Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Зиннур Мансуров кабинетына күренекле драматург, прозаик, табиб Шәриф Хөсәенов килеп керә. Үзара хәл-әхвәл белешәләр. Хөрмәтле кунак сорап куя:

– Йөзең моңсу күренә. Бер-бер хәл булдымы?

– Менә борчыла башладым әле... Сау тәнемдә һәрбер минут саен 300 миллион күзәнәк үлеп тора, – ди сирәк елмаючы шагыйрь, җитди рәвештә шаярырга теләп.

– Һи, тапкансың хафаланыр нәрсә! Бүтән кайгың юкмы? Исеңдә калдыр: аның каравы бөтен әгъзаларны берләштергән гәүдәңдә көн саен 10-50 триллион күзәнәгең яңара. Трил-ли-он!..

Шулчак кабинет хуҗасы үзен эчтән генә тиргәп ала: «талканы коры» әдипне уйнап сөйләшүгә нишләп тартты ул? Әңгәмәнең бу өлешен җәһәт түгәрәкләргә кирәк.

– Сөендердегез, Шәриф абый! Монысын белми идем...

Вәләкин уенга чынлап керәсе иткән язучы теманы алай тиз генә үзгәртергә ашыкмый.

– Мәсьәләнең асылын аңламыйча, тота-каба төшенкелеккә бирелергә дә, коткы таратырга да ярамый, – дип мәслихәт кыла ТАССРның атказанган табибы. – Киресенчә, каләм әһеле үзенең сүзе белән кешедә яшәү дәрте уятырга тиеш. Теләсә нинди очракта...

Пессимист роленнән чыгарга азапланган Зиннур Мансуров үзенең тәнендәге күзәнәкләрнең күпләп яшәрүен тойды.

## Хәл белүче

«Мәдәни җомга» атналык газетасының баш мөхәррире Зиннур Мансуров каләмдәше Рабит Батулланы редакциянең сәнгать бүлеген җитәкләргә чакыра. Мөдирлек вазифасын беркадәр башкаргач, сырхаулаган әдипне 1996 елда Германиягә озатырга туры килә. Гамбург каласындагы мәгълүм хастаханәдә аның йөрәгенә берничә операция ясыйлар: дүрт тамыры алыштырыла, аорта клапаны киселеп, тимер протез куела.

Катлаулы сәфәреннән исән-сау әйләнеп кайткач, Рабит Батулла янәдән каләменә үрелә, бераздан тагы хастаханәгә кереп ята... Палатада ул ялгызы. Ишектән Зиннур Мансуров күренә. «Хәлеңне белергә килдем... Инде авырый күрмә, – ди баш мөхәррир гадәти сүзләр белән. – Аттай эшләргә язсын... Син халыкка кирәк!..»

Ятак алдына килеп баскач, хәл белүче сораштыра башлый: «Ну, ничек соң?» Шунда шук-шаян Батулла өстендәге халатын ике якка ачып җибәрә, пычак астына кергән тәненең буйдан-буйга тегелгән кызгылт җөйләрен күрсәтә. Бала чактан ук кан яки җәрәхәт күрүдән курыккан Зиннур, агарынып, системадан сихәт алучының аяк очына ипле генә барып ава. «Тоже мне хәл белүче!» дип сукранган язучы, беләгенә беркетелгән энәне ычкындырып, биредә дәвалый торган табибы янына чыгып йөгерә. Хәлсезләнгән шагыйрьгә укол кадыйлар. «Ямаулы йөрәк» иясенең караватында бер сәгать чамасы көч җыйгач, Зиннур Мансуров үзен гаепле тойган кыяфәттә саубуллашып китәргә җыена. Ә Рабит Батулла үз амплуасында кала, палата кунагының элегрәк әйткән сүзләрен кабатлый:

– Инде авырый күрмә... Аттай эшләргә язсын... Син халыкка кирәк!

## Саный белмәү бәласе

Татарстан Язучылар берлегендә идарә утырышы бара. Яшерен тавыш бирү юлы белән хәл ителәчәк мәсьәләгә җиткәч, өч кешедән генә торган санау комиссиясен төзү ихтыяҗы туа. Кемдер хисап эшенә Равил Фәйзуллинны күрсәтә. Тегесе риза түгеллеген белгертергә ашыга. Чыннан да, ярты гасыр дәвамында идарә әгъзасы булган корифейның мондый вазифага беркайчан да алынганы юк иде. «Кирәкми, ул бит бишкә кадәр дә саный белми», – ди Зиннур Мансуров, каләмдәш дустын өстәмә мәшәкатьтән коткару әмәлен эзләп. Комиссия бүтәнчә тәгаенләнә.

«Бишкә кадәр дә саный белмәү аргументы» тәнәфес вакытында янәдән тәфсилләп искә алына.

– Нишләп алай әйттең? – дип сорыйлар Зиннурдан.

– Тыңлагыз, төшендерәм. Мәгълүм ки, Равил Фәйзуллин бер-бер артлы дүрт хатынга өйләнде һәм аннары ниндидер киртәгә очрагандай тукталып калды. Нилектән? Чөнки ул 4 тән соң 5 саны килүен белми иде. Югыйсә...

## Чын дусларны барлау

Язучылар йортының ишегалдында бер төркем каләмдәшләр сөйләшә. Сүз иярә сүз чыга. Иҗат берлеге җитәкчесен сайлау мәсьәләсе кузгалгач, көтмәгәндә генә Ркаил Зәйдуллага сорау бирелә:

– Соңгы берничә съездда син үз кандидатураңны рәислеккә күрсәттерден. Мондый мәрәкәдә катнашу гадәтеңә әйләнеп китмәдеме?

– Шәхси иркемне кысмагыз инде, егетләр! – дип каршы төшмәкче була Ркаил, киң итеп көләргә әзерләнгән кыяфәттә. – Мин бит 4-5 ел үткән саен шул рәвешле якын дусларымны барлап алам.

– Үзеңә генә кагылышлы максат өчен нигә корылтай кадәр корылтайдан файдаланасың?

Җиңелүгә күнеккән «кандидат» төрлечә акланырга керешә:

– Яшерен тавыш бирүдән дә камилрәк ысулны кешелек дөньясы әлегә уйлап тапмаган лабаса. Чын тарафдарлар шунда ачыклана.

– Съездлардагы сайлау нәтиҗәсе күрсәткәнчә, сине хөрмәт итүчеләр егермедән артмый бугай.

– Ихлас якын күргән дуслар ишәеп торырга тиеш түгел, – ди Ркаил Зәйдулла, зирәклеген күрсәтергә теләп. – Киресенчә, аларның кимүгә бармавы яхшы бит инде!..

Кабатланмас яңгырашлы ихахайлап көлү гөрелтесе тирә-юньдәге тәрәзәләрнең пыяласын зеңгелдәткәндәй тоелды.

## Хаталар төзәтүче стилист

Беркөн шагыйрь Зиннур Мансуров көтелмәгән хәлгә тап була. Кемдер эш бүлмәсенең тәрәзәсе каршындагы асфальтка «Матурымка я тебя люблю» дип язган. Мөгаен, әлеге Мәҗнүннең сөйгәне өскерәк катта яшидер. Күзәтүчән иҗатчыга ошбу кайнар мәхәббәт карарын йөзләрчә тапкыр ирексездән укырга туры килә. Кайчак ул чәүчәләкләнә үк карарын. «Эх, шунда кечтеки генә өтер белән өндәү җитешми бит!» ди мөхәррир вазифасында меңнәрчә язманы эшкәрткән каләм әһеле. Төгәлсезлек мондый затны, гадәттә, тәмам чиргә сабыштыра. Түзеп тора алмый сабыр холыклы Зиннур Мансуров, ак буяу һәм пумала тотып, төнге сәгать бердә тиз-тиз урамга чыгып китә... Кулы кычыткан – эшне пыжыткан. «Йокымны качырдың, надан тәре!..» Үзалдына шулай сөйләнеп, «люблю» кәлимәсе артыннан өндәү билгесен куйган мизгелдә кизүлектәге полиция хезмәткәре аның янында туктап кала.

– Югыйсә үзегезнең яшегез дә бар инде, – дип бәйләнә хокук сакчысы. – Җәмәгать урынында шундый сүзләр сызгаларга ярамый. Өзелеп ярату хисләрен бүтәнчә аңлатырга кирәк.

Шулай итеп, атна буе борчылып яшәгән Зиннур Мансуровны якында урнашкан полиция бүлегенә алып китәләр. Аның үз-үзен акларлык дәлилләре юк иде. Хәер, ул башкаларның хатасын төзәтүче стилист кына – тәртип бозучы шундый аргумент китерергә мөмкин.

## Төртмешләр

- Кайчак максатлы зур эшләр башкарыр өчен, «өч тиенлек» кенә акыл җитеп бетми.
- Безнең баш миебез тулы куәтенә эшләсә, бәлки, ахмаклыклар тагын да күбрәк кылыныр иде.
- Бездә чистартуга бәйле күпчелек гамәлләр пычракны тигезләп таратуга кайтып кала.
- Татар халкының кайвакыт артык тырышып гамәл кылуы үзенең капкасына туп керткән кебек килеп чыга.
- Безнең җәмгыятьтәге зоологлар тартарны арттырып, демографлар татарны киметеп күрсәтергә тырыша.
- Югары даирәдәге «сәяси мәет»ләрне исәпкә алсаң, илдәге үлем-китем саны артып китәр иде.
- Үзгәртеп кору чорының мәдәнияте юксыллык шартларында бетле киемне үтүкләп кию гаҗизлеген хәтерләтә.
- Илдә үлүчеләр кимеде, чөнки бурычлылар артты.
- Акчаны ашап булмый, эчәргә генә мөмкин.
- Балаларны башта Баба Яга белән, аннары ЕГЭ белән куркыталар.
- АКШ президентларын кайбер гамәлләре өчен почмакка бастырып тотасы килә, әмма аларның озынча түгәрәк эш бүлмәсендә почмак табып булмый.

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## САБАН ТУЕ

Быел Сабан туе Казанда дүрт урында – Тынычлык бистәсендәге Каенлыкта, Дәрвишләр бистәсендә, Аккош күлендә һәм Ипподромда булды. Милли бәйрәмебезне Төрекмәнстаннан килгән кунаклар да күрде. Сабан туе алдыннан Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов белән Төрекмәнстан Республикасы Президенты Гурбангулы Бердымөхәммәтов хезмәттәшлек турында килешү имзаладылар. Аннары алар Тынычлык бистәсендәге Каенлыкка килде. Казан ипподромындагы ат чабышын да карады. Сабан туена җыелган халыкка Рөстәм Миңнеханов Россия Федерациясе Президенты Владимир Путинның котлавын ирештерде.

## ТИЗДӘН САЙЛАУ

«Бердәм Россия» партиясенең Татарстан бүлекчәсе республикада сайлау алды кампаниясе барлык катнашучыларга карата гадел һәм хөрмәт белән үтсен өчен эшли. Бу хакта кичә Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлегенең XXX конференциясендә белдерде. Анда партиянең 45 җирле бүлегеннән 189 делегат катнашты. Конференциядә партия «Республикабыз иминлеге – һәрберебезнең мәнфәгатендә» дигән сайлау алды программасын раслады һәм алтынчы чакырылыш дәүләт Советы сайлауларына депутатлыкка кандидатларны тәкъдим итте.

Татарстан парламенты башлыгы Фәрит Мөхәммәтшин, «КамАЗ-мастер» командасы җитәкчесе Владимир Чагин һәм «Бала-сити» үзәкләре челтәре директоры Альбина Насыйрова кандидатлар исемлегенең башында тора. «Бу өчлек иң күп тавыш җыйды», – дип белдерде исәп-хисап комиссиясе рәисе Евгений Ивлев. Праймериз нәтиҗәләре буенча, партия исемлегенә бердәм сайлау округыннан – 56, бер мандатлы округлардан 46 кандидат керде.

Алар арасында Татарстан авыл хуҗалыгы министры Марат Әхмәтов, «Татарстан-Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры Илшат Әминов, Татарстан Дәүләт Советы секретаре Лилия Маврина, республика парламентында «Бердәм Россия» фракциясе җитәкчесе Юрий Камалтынов, «Татмедиа» республика агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов, Татарстанның халык шагыйре Ркаил Зәйдулла һәм башкалар бар.

Татарстан Дәүләт Советы депутатларын сайлау 8 сентябрьдә узачак.

## «ЯҢАРЫШ» ЭШЕ – КИТАПТА

Татарстанның мәдәни-тарихи мирасы һәм аны саклап калуга «Яңарыш» фонды керткән өлеш аерым китап булып дөнья күрәчәк. Бу хакта Татарстанга килгән Ага хан премиясе комитеты әгъзасы, ЮНЕСКО генераль директорының элеккеге урынбасары, китап проекты координаторы Франческо Бандарин әйтте. Дәрәҗәле кунак Казан Кремлендә Татарстан Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» фондының попечительләр советы рәисе, ЮНЕСКОның халыкара диалог буенча махсус илчесе Минтимер Шәймиев белән очрашты. Алар республика фонды эшчәнлегенә бәйле экспозицияне карады, Минтимер Шәймиев Изге Болгар һәм Зөя шәһәр-утравында башкарылган эш турында сөйләде. «Сез мирасны саклауга зур әһәмият бирәсез һәм күп еллардан бирле әлеге эш белән шөгыльләнәсез. Халыкара диалог төзүдә моның ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын да сездән яхшырак аңлаучы юк», – диде Франческо Бандарин, Минтимер Шәймиевкә мөрәҗәгать итеп. Очрашу барышында Татарстанның беренче Президенты булачак китап өчен интервью да бирде.

## ПУШКИННЫҢ ТУУЫНА – 220 ЕЛ

Россия Федерациясе Президенты Указы белән Александр Пушкинның туган көне Рус теле көне буларак билгеләп үтелә. Шушы вакыйга уңаеннан Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, дәүләт, җәмәгать эшлеклеләре, әдәбият, сәнгать әһелләре, галимнәр шагыйрьнең Казандагы Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры янындагы һәйкәленә чәчәкләр салдылар. Шушында ук шигъри митинг булды.

Пушкинның тууына 220 ел тулуга һәм Рус теле көненә багышланган тантаналы чара Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында үтте. Анда ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин чыгыш ясады

## АНДРЕЙ КУЗЬМИННЫҢ ЯҢА КИТАБЫ

Kazan Palace by Tasigo отелендә «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Андрей Кузьминның яңа китабын тәкъдим итү булды. Авторның 50 яшенә чыгарылган бу китапта республикабызның атаклы кешеләре белән галстуксыз үткәргән 50 әңгәмәсе тупланган. Тантанада ТРның беренче Президенты, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР Президенты ярдәмчесе Камил Исхаков һ.б. танылган шәхесләр катнашты.

## АЛТЫН УРДА

Казанда Алтын Урда дәүләте оешуга 750 ел тулу уңаеннан халыкара фәнни-гамәли конференция булды. Анда ундүрт илдән килгән галимнәр, археологлар, дин әһелләре катнашты.

## «ТУКАЙ ЮЛЫ»

Арча районында «Тукай юлы» дип аталган яңа туристик маршрут ачылды. Халык Арчадан Яңа Кырлайга юл тотты. 21 чакрымлык юлда Түбән Мәтәскә, Югары Мәтәскә, Мөндеш, Иске Кырлай, Яңа Иябаш авыллары аша уздылар. Киләчәктә аны Казан артындагы Биектау, Балтач, Кукмара, Әтнә районнарына да сузу күздә тотыла. «Тукай юлы»н ачу тантанасында ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, РФ Дәүләт Думасы депутаты Ольга Павлова, ТР Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе Сергей Иванов, ТР Президенты каршындагы мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды башкаручы директоры Нурия Һашимова, ТР Велосипедчылар берлеге рәисе Илдус Янышев, Арча муниципаль районы башкарма комитеты рәисе урынбасары Рамил Гарифҗанов һ.б. катнашты. Проектны гамәлгә ашыручылар аның татар авылларының көнкүрешен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен күрсәтүгә хезмәт итәчәген әйтә.

## ПЕРМЬ КРАЕ САБАН ТУЕНДА

Арча муниципаль районы башкарма комитеты рәисе урынбасары Рамил Гарифҗанов, мәдәният идарәсе житәкчесе Рамил Мөхетдинов, «Казан арты» тарих-этнография музее директоры Шәфигулла Гарипов, «Казан утлары» журналының даими авторы, язучы, журналист Риман Гыйлемханов, басманың баш мөхәррир урынбасары Вакыйф Нуриев Пермь крае Сабан туенда Татарстан илчеләре сыйфатында катнаштылар. Мәйданда Арча төбәгендә туып-үскән шәхесләр иҗатына багышланган күргәзмә ачылды, район һәвәскәрләре тарафыннан концерт күрсәтелде, халыкка «Казан утлары» журналлары таратылды.

## ЮБИЛЕЙ

Казанда Евгений Боратынский музеенда Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Максим Горький, Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты Наилә Ахунованың юбилеена багышланган кичә булып узды. Бәйрәмдарны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Казан шәһәре хакимиятенең мәдәният идарәсе җитәкчесе Азат Афзалов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт, Арча муниципаль районы башкарма комитеты рәисе урынбасары Рамил Гарифҗанов, Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт оешмасы җитәкчесе Рәфкать Шаһиев, каләмдәшләре Фоат Галимуллин, Әхәт Мушинский, Салават Юзеев, Александр Воронин, Елена Михалева, Сергей Карпеев, Галия Бәхтиярова, Инесса Фа, Галина Кашина, Юлия Сандлер, Ирина Покровская һ.б. котлады.

Кичәне Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары Борис Вайнер белән Әлфия Галимуллина алып барды.

## ТУКАЙ ОНЫКЛАРЫ ЯНЫНДА

«Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләре Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Фирүзә Җамалетдинова Арчада «Без – Тукай оныклары» төбәкара чатырлы җәйге ял аланында балалар белән очраштылар.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы Президенты Указы белән һөнәри эшчәнлегендәге казанышлары һәм нәтиҗәле хезмәтләре өчен Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары **Әхмәтова Эльвира Фәнис кызы** һәм «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Кузьмин Андрей Владимирович** «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнделәр.

***

ТР Президенты Указы белән татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык иҗат эшчәнлеге өчен шагыйрь, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге (Иҗат берлеге) әгъзасы **Мансуров Зиннур Мөҗип улы** Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

2019 елның 30 июнендә алтмышынчы яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, драматург һәм прозаик **Аманулла (Әмир Аман улы Камалиев)** вафат булды.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: фантастический роман Ф.ИМАМОВА «Неподходящее время…», повесть К.КАРА «Ягодная поляна», повесть Р.ЛАТЫПОВА «Нефтяники без лопат», рассказ А.МУШИНСКОГО «Моя ласковая Иренка»; поэма Р.ХАРИСА «Тринадцать на тринадцать», стихи З.МАНСУРОВА, Ф.МУСЛИМОВОЙ, Х.ИБРАГИМОВА.*
*«Новые имена»: стихи Г.ГАЛИЕВОЙ.*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*30 лет журналу «Идел» – «Идель»: фотоархив.*
*Конкурс «Исцеляющие руки»: рассказ Г.ДАВЛЕТБАЕВОЙ «Энже».*
*«Татарстан. История. Личности»: очерк Г.ГИМАДОВОЙ.*
*«Тукай и татарская литература»: статья М.САДРИ.*
*«Книжное обозрение»: Г.ДАВЛЕТШИН. «Книга, «пробивающая дорогу» к нашим прототюркским предкам».*
*«Юбилеи»: статья Р.ВАЛЕЕВА «Мой Надир Давлет» (75 лет Н.ДАВЛЕТУ).*
*100-летие Татарского книжного издательства.*
*Интервью Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ с генеральным директором Татарского книжного издательства И.САГДАТШИНОМ.*
*«Наука»: «Тайны серебряной чаши» (беседа Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ с И.ОСМАНЛЫ).*
*«Отклик»: статья А.ХАЛИМА.*
*«Наши музеи»: Л.ЯНСУАР. «Дом татарской книги» в центре Казани.*
*«Страницы юмора»: подготовил З.МАНСУРОВ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Дом татарской книги». Фото Л.Петуховой;*
*поэтесса Людмила Аланлы (Янеева Людмила Николаевна).*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: fantasy novel by F.IAMAMOV «The Wrong Time ...», novel by K.KARA «The Berry glade», novel by R.LATYPOV «Oilmen without a spade», story by A.MUSHINSKY «My tender Irenka»; poem by R.HARIS «Thirteen to thirteen», poems by Z.MANSUROV, F.MUSLIMOVA, H.IBRAGIMOV.*
*«New Names»: poems by G.GALIEVA.*
*«Actual Critics»: section is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*30th anniversary of the «Idel» magazine – «Idel»: photo archive.*
*Contest «Healing Hands»: story by G.DAVLETBAEVA «Endge».*
*«Tatarstan. History. Persons»: essay by G.GIMADOVA.*
*«Tukay and Tatar literature»: article by M.Sadri.*
*«Book Review»: G.DAVLETSHIN. «The book, «making the way» to our proto-Turk ancestors».*
*«Anniversaries»: article by R.VALEEV «My Nadir Davlet» (75th anniversary of N.DAVLET).*
*100th anniversary of the Tatar book publishing house.*
*Interview by F.ZAMALETDINOVA with the General director of the Tatar book publishing house I.SAGDATSHIN.*
*«Science»: «Secrets of the Silver Bowl» (discussion by D.ZAGIDULLINA with I.OSMANLY).*
*«Response»: article by A.HALIM.*
*«Our museums»: L.YANSUAR. «The House of Tatar book» in the center of Kazan.*
*«Pages of humor»: section is conducted by Z.MANSUROV.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: «The House of the Tatar book.» Photo by L.PETUKHOVA;*
*poetess Lyudmila Alanly (Yaneeva Lyudmila Nikolaevna).*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Татар китабы йорты». *Л.Петухова фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрә Людмила Аланлы
(Янеева Людмила Николаевна).